ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.1990



## ЖУРНАЛ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: *420066, Казань, Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.*

Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ
ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ
МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

**1990**

**3**

(809)

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА
ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Г. ТАВЛИН. Афәт. *Роман* . . . . . . . . . 3
Э. МОСТАФИН. Мин бәләкәй чакларда... *Заман фрагментлары* . . . . . . . . . . . . . . . 64
Ж. ТӘРҖЕМАНОВ. Кичерергә мөмкин түгел. *Повесть* . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Э. МӨЭМИНОВА. Ике җыр. *Шигырьләр* . . . 95
Ф. ЗЫЯТДИНОВА. Ташкын. *Шигырьләр* . . . 96
Б. РӘХИМОВА. Кирәк түгел фал ачулар. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Х. МӨДӘРИСОВА. Көмеш дага. *Шигырьләр* . . 100
Д. БУЛГАКОВА. Вакытның минутын... *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Ф. МӨСЛИМОВА. Олы кое. *Шигырьләр* . . . 103

ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ

М. ХУҖИН. Кулаклар колхозы. *Хикәя* . . . 105
Ә. ХӘММӘДИШИН. Ясин. *Хикәя* . . . . . . 121
И. СИРМАТОВ. Әткәй сәгате. *Нәсер* . . . . . 127

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

ЛӘЙСӘН. Бүләк. *Шигырьләр* . . . . . . . 131

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ЮНЫС. Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре 133
Д. ВӘЛИЕВ. Ышанычың әгәр какшаса . . . . 142
А. МӘХМҮТОВА. Әйдә халыкка хезмәткә! . . 149

ТӘНКЫЙТЬ

М. ВӘЛИЕВ. Мәхәббәт яшәргә тиеш! . . . . . 152
Ф. РӘМИЕВА. Шагыйрь белән янәшә . . . . . 163
Ә. ЕНИКИ. Сарьян . . . . . . . . . . . . . 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

Г. ГЫЙЛМАНОВ. Сискәндерә торган шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Д. ИСХАКОВ. Нократ татарлары . . . . . . . 175

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Җиденче дәрес . . . . . . . . . . . . . 180

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . 183

КОТЛЫЙБЫЗ!

М. Газизовка 50 яшь . . . . . . . . . . . 179

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Ә. САФИУЛЛИН. Нюанс . . . . . . . . . . 187

Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . . 189

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛУС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛУН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘУФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066.
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60
баш редактор урынбасары — 53-07-09.
җаваплы секретарь — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61.
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.
корректорлар — 53-06-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: начало романа Г. ТАВЛИНА «Рок», повесть Дж. ТАРЗЕМАНОВА «Нельзя простить». Стихи Э. МУСТАФИНА, Э. МУЭМИНОВОЙ, Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ, Б. РАХИМОВОЙ, Х. МУДАРИСОВОЙ, Д. БУЛГАКОВОЙ, Ф. МУСЛИМОВОЙ.
«На конкурс»: рассказы М. ХУЗИНА, А. ХАММАДИШИНА, И. СИРМАТОВА.
«Творчество молодых»: стихи ЛЯИСАН.
«Юмор и сатира»: А. САФИУЛЛИН. Нюанс.
«Публицистика»: М. ЮНЫС. «Корни и плоды безъязычия»; Д. ВАЛИЕВ. «Когда теряется вера»; А. МАХМУТОВА. «Служить народу».
«Литературная критика»: статьи М. ВАЛИЕВА «Любовь должна жить», Ф. РАМИЕВОЙ «Рядом с поэтом»; А. ЕНИКИ «Сарьян».
«Библиография»: Г. ГИЛЬМАНОВ рецензирует книгу Р. Юнуса «Синица на ладони».
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: статья Д. ИСХАКОВА «Нукратские татары».
Уроки татарского языка.
Навыки чтения на основе арабской графики.
На наших обложках — историко-архитектурный памятник «Черная палата».
Портрет известного писателя, лауреата премии им. М. Горького и Государственной премии Татарии имени Г. Тукая Аяза Гилязова.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рашит Әхмәтҗанов.
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина, Р. Сөләйманова.

Производствога бирелде 10.01.1990 ел. Басарга кул куелды 1.03.1990 ел. ПФ 05167. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83844. Заказ Д-12. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

# Гурий Тавлин

# АФӘТ

РОМАН

## Беренче кисәк

## Кояштан болытка кергәндә

### Беренче бүлек

### I



Ишелеп ябалак кар ява. Һавада җиргә җай гына иңә баручы очсыз-кырыйсыз ак челтәр пәрдә тирбәлә кебек. Эре кар бөртекләре аша барлык таныш, үз, әллә кайчан күнегелгән бөтен әйләнә-тирә ничектер ят, чит булып төсмерләнә. Авыл, инде яктырып көн туса да, әле уянмаган, тирән йокыда сыман.

Мин мәктәпкә барам. Өс-башыма инде әллә никадәр кар сырды, читтән кечкенә кар бабайны хәтерләтәмдер, әмма кагынмыйм — кар яңгыр түгел, чылатмый, куна бирсен, быел аның бәлки болай соңгы явуыдыр бу, рәхәтен күреп калыйм дим. Эленке-салынкы атлап дәрескә соңга калудан курыкмыйм, өйдән иртә чыктым, өлгерәчәкмен. Иртәләтеп яхшы иткәнмен әле, табигать минем өчен махсус тырыша диярсең, нинди матурлыкка юлыктым! Күктән җепшек ябалак кар түгел, чәчәкләр ява сыман... Сөләй дә күрәме икән моны? Күрәдер, күзе бар кеше күрмәскә мөмкин түгел бу хозурлыкны. Капка төпләренә чыгып, ул мине күптән көтәдер инде. Көтсен соң! Өйгә бирелгән эшләрне көн саен күчертә-күчертә тәмам гарык мин аңардан. Өйрәнде Тәкәрлек, баш ватып тормый, әзергә бәзер, аннан-моннан күчерә дә эше бетә. «Йөзең чытма, дус, син бит минем негр»,— дип көлә әле җитмәсә. Әнә карачкысы күренә, капка төпләренә чыккан, көтә. «Кытый»[1] аласы килми сипкел оясының, килми. Укыйм, белем алам, дип йөри инде ул хәрәсән сыңары. Кичә утыбыз булмады, керосиныбыз беткән иде, өйгә бирелгән эшләрне үтәмәдем, диим әле, нишләр икән?

Менә Тәкәрлек димә инде аны, миңа атарга кабалана-кабалана

---

Гурий ТАВЛИН *(1925) — әдип, «Сары яфраклар коела», «Йолдызлар безгә янәшә», «Тәвәккәл таш яра» — барысы тугыз китап авторы. Казанда яши.*

кар йомарлыклап маташа бит, кәтмәгәндә маңгаема чәкергә ниятлидер, мөгаен. Шаярмый тор, мин синнән остарак атам ул кар йомарлыкларын, дускаем, күр дә тор, маңгаеңа үзем чәпим хәзер. Тик бигайбә, үпкәләштән булмасын...

Портфелемне тиз генә юл читенә куеп, учларыма кар алырга иелдем. Шулчак Сөләй: «На пасаран!» — дип кычкырып миңа «һөҗүм» башлады. Күптән әзерләнеп торган булган ул моңа, учларымда бер кар йомарлыгы әвәләгәнче, миңа өч-дүрт «җәдрә» җибәрергә өлгерде. Тик ул кәкре кулдан эш чыкса, әтисенең пеләшенә күптән инде чәч үсәр иде — аткан бөтен «җәдрәләре» җилгә китте. «На пасаран!» — ди җитмәсә. Республикачы испанлы, имеш. Республикачы испанлы туганнар фашист кабахәтләр өстенә чөйгән җәдрәләрен Сөләй шикелле «сөт»кә җибәрсәләр, әллә кайчан җиңелерләр иде инде. Алар исә фашист башкисәрләрнең тетмәләрен тетәләр! Эх, Тәкәрлек, сул күзеңне чытырдатып йомып, иреннәреңне кыйшайта-кыйшайта төзәп аткан буласың тагын. Төзәгән җиреңә тидерсәң, сине Сөләй димәсләр, күптән Сөләйман дип исемеңне тутырып әйтерләр иде. Әнә, кузна уйнаганда да борын яфракларыңны киереп, кулыңдагы аткыеңны әллә ничекләр боргалап төзисең, тик ялгышып, күңел өчен бер тапкыр да кузналарга тидергәнең юк. Малайларның барысының утызар, кырыгар кузнасы бар, тик синең генә шымытыр — аксак кузнаң да юк. Үзеңне белеп, кузналы уйнамасаң иде хет. Откач бирермен, дип кузналарны әҗәткә теләнеп алып, хәрәмләшә-хәрәмләшә уйныйсың әле. Ә сиңа нәрсәңнедер әҗәткә бирү — әйбереңне суга ату белән бер, алган нәрсәңне кире кайтармыйсың, оныктасың...

Мин җүнләп төзәп тә атмадым, беренче йомарлыгым ук дусымның чыраена эләкте. Ул, куллары белән йөзен каплап, карга тезләнде.

— Күзем чыкты... Күзем... күзем... У-у-у...

Йөгереп янына бардым. Күрәм, дустымның күгәрчен аягы төсенә кереп кызарган бармаклары арасыннан кан бәреп чыккан. Бөтен тәнем эсселе-суыклы булды, өнсез калдым. Яшь кыяр исе аңкытып ишелеп яуган ябалак кар да, мәктәпкә баруым да онытылды. Мин үземне бу мизгелдә кичермәслек җинаятьче итеп тойдым.

— Сөләй дус, әйдә медпунктка барыйк, анда күзеңне дарулап бәйләрләр, бәлки төзәлер күзең, ә?..

Чиксез дулкынланудан тавышым куркып, калтырап чыкты.

Сөләй, шушы сүзләремнән соң үкерүеннән кинәт туктап, кулларын йөзеннән алды һәм шар ачылган ачулы күзләрен миңа төбәде. Аның борыны каный, күзләре икесе дә исән иде. Җиңел сулап куйдым.

— Чалкан ятып башыңны артка каер, туктасын борыныңның канавы. Мә кульяулык, сөрт битеңдәге канны...

— Өйрәтмә, килмешәк, нишләргә кирәген синнән башка да беләм. Үз танавыңа да берне тамызганчы югал күз алдымнан!

Мин Сөләйнең тупас сүзләренә игътибар итмәскә тырыштым.

— Син өйгә бирелгән эшләрне күчермәссеңмени?..

— Кирәкләре юк аларның миңа. Моңарчы бар курыкканым алгибра ые, котылды хәзер аңардан башым. Бетте алгибра гиомитриясе белән бергә. Чәнчелделәр пәри фәннәре! — диде Сөләй, күзләрен ялтыратып.

— Нигә бетсен, нигә чәнчелсен алгебра белән геометрия, саташтыңмы әллә?

— Саташмадым. Фәсхи абый юк хәзер, ул бүтән укытмаячак.

---

[1] Кытый — канәгать түгел, к/т. Утызынчы елларда татар мәктәпләрендә укучыларга куелган иң түбән билге. Башка билгеләр: канәгать, яхшы, бик яхшы.

— Нәрсә булган аңа, нигә укытмаячак ул? — дидем, гаҗәпләнеп.
Дустым, борынын уң кулының баш һәм күрсәткеч бармаклары белән кыскан килеш, миңа мыскыллы караш ташлады. Аннары тынкыш тавыш белән тезеп китте:
— Төнлә килеп кулга алганнар аны. Әти әйтә, ул корткыч булган, ди. Фатирында тентү ясап, ярамаган нәрсәләр язылган дөнья кадәр кәгазь, әллә нинди хатлар тапканнар. Кәнсәләрдә әти кичә исполнитыл ие, бөтенесен үзе күргән, шаккатып сөйли. Кулларына богау салып, аркасына ике наган терәп алып киттеләр, ди.
Мин бу коточкыч яңалыкка ышанырга да, ышанмаска да белмәдем. Үз-үземне тынычландырырга теләп, шаярта, мине тишек чуманга утыртырга чамалый Тәкәрлек, дип уйладым. Андый гадәте бар бит аның. Кемгә дә билгеле Сөләй ич ул. Тик ни дип бирелгән эшләрне сорамый сипкел оясы? Бүтән чакта тизрәк күчерү ягын кайгырта иде, бүген алар аңа әллә бар, әллә юк, ыжламый да.
Фәсхи абый — мәктәптә минем иң яраткан укытучым. Бәештә, гомумән, Фәсхи абыйны өнәмәгән, аны ихтирам итмәгән укучылар бик аз, минемчә. Шуларның берсе әнә Сөләй булып чыкты. Фәсхи абыйның укучылар таккан кушаматы булмау үзе генә дә аңа булган хөрмәтнең ачык дәлиле бит. Ботаника һәм зоология укытучысы Мирсәет абыйны әнә Дәһәр кадаяк, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Һаҗәр апаны Бичура, физкультура укытучысы Габбас абыйны Дагалы бүре, хезмәт укытучысы Кәшиф абыйны Эйе-бит, рус теле укытучысы Хөршидә апаны Прокурор дибез. Бары Фәсхи абый гына кушаматсыз. Сөләй, аны кулга алганнар, ул корткыч булган, ди. Башка сыймый торган нәрсә бу! Нигә әтигә ул җитәкләгән мәктәпнең бер укытучысын кулга алуны әйтмәделәр икән соң? Бәлки, төнлә йокыда калып, мин генә аны ишетмәгәнмендер? Әти, бүген таңнан торып, район үзәгенә китте, күз алдымда әни белән чөкердәшеп чәй эчтеләр. Сөләй сөйләгән төнге вакыйга турында араларында ләм-мим сүз булмады. Гаҗәп. Төрле газеталарда һәм «Чаян» журналында басыла торган карикатуралардагы корткычларга кыяфәте белән якын да килми бит Фәсхи абый. Үзе һәрвакыт көләч, иртәдән кичкә кадәр гел мәктәптә, гел балалар арасында. Корткычланырга вакыт кайчан тапты икән ул? Кулларын богауларлык булгач, тапкандыр, тик ятмагандыр инде. Дөнья кадәр ярамаган кәгазь, хатлар ди тагын... Алгебра белән геометрияне кем укытыр икән безгә хәзер? Фәсхи абый урынына Һаҗәр апаны, я Габбас абыйны алып китсәләр ни булган инде?!. Юк шул, алар корткыч түгел, Фәсхи абый — корткыч...
Сөләйнең борыны канаудан туктагач, без мәктәпкә юнәлдек. Юлда үзара сөйләшмәдек. Көтелмәгән хәбәрдән һәм дус классташымның үземне килмешәк дип атавына минем кәефем кырылган иде. Сөләйнең исә борынын җимергәнем өчен миңа үпкәсе бетмәгән иде...
Һич аңламассың бу Бәеш кешеләрен. Аларга ошамый торган берәр эшеңне күрделәрме, тоталар да «килмешәк» диләр. Әйтерсең безне алардан аера торган килбәтсез мөгезләребез, ямьсез койрыкларыбыз бар. Килмешәк. Бу кимсетүле сүз күбрәк әти адресына әйтелә. Без үзебез Чистай ягыннан. Әтине монда яңа мәчетне мәктәп итүне башлап йөргәне өчен өнәмиләр. Синең өчен Бәеш хәсрәте кысыр хәсрәт кенә, бүген монда син, иртәгә әллә кайда, арба ватылса утын, үгез үлсә ит сиңа, диләр. Башта әти килмешәк диюгә гарьләнә, чыгырыннан чыга иде, хәзер исе китми, күнекте, мине ник чүлмәк дип атамыйлар шунда, тик мичкә генә утыртмасыннар, ди уйчан елмаеп. Бәеш халкы нигә үзен генә әллә кемгә саный, нигә шулкадәр һаваланадыр — белмим. Алар бер камырдан, без икенчедән әвәләнгән бәндәләр түгелдер бит инде? Әт чаба дип бет чаба.

эти кушаматын Сөләй миңа тага. Акылы чамалы кешегә үз акылыңны әҗәткә биреп торып булмый, дип бик дөрес әйтә эти.

Без мәктәпкә барып җиткәндә аның тирәсе кырмыска оясы шикелле кайный, укучылар барысы да диярлек җыелып беткәннәр иде инде. Мин мәктәп ишегалдына аяк басу белән Фәсхи абый турында ни дә булса ишетермен дип өметләнгән идем, әмма ялгыштым. Сөләй сөйләгән төнге вакыйга турында укучылардан әле беркем дә берни дә белми төсле иде монда. Борчылучы да, пошынучы да, сикерә-сикерә шатланучы да күренми. Берәүләр, көн җылылыктан файдаланып, чыр-чу килеп әбәкле уйный, икенчеләр мышный-мышный кар тәгәрәтә, өченчеләр шау-гөр килеп кала алалар. Сөләй, мәктәп ихатасына керү белән, букчасын миңа тоттырып, кала алучылар янына йөгерде. Кайда гауга, кайда күбрәк шаушу, кайда этеш-төртеш — ул шунда. Мин ишегалдында тукталмадым, мәктәпкә кереп, караңгы коридор буйлап классыбызга уттем. Класс буш, анда әле беркем дә юк иде.

Дәресләр башланасын белдереп, кыңгырау чыңлады. Коридорны аяк тавышлары, шау-шу күмде. Сабакташларым классыбызга нигәдер бик акрын җыйналдылар. Беренче дәресебез география иде, әмма география укытучыбыз Нурулла абый нигәдер ун минутлап керми торды. Түземсезрәк укучылар, ул коридорда туктап берәрсе белән гәп куертмыймы яки берәр укучыга бәйләнеп аңардан аерыла алмыймы, дип, ишектән куркып кына башларын да сузып карадылар. Класстан чыгып аны эзләп килергә берәүнең дә кыюлыгы җитмәде. Нурулла абый дәресләр башлангач укучыларның коридорга чыгуларын зур тәртипсезлек саный, шуның өчен җаза биреп яз, җәй, көз көннәрендә мәктәп тирәсен себертә, кыш көне дәрестән соң калдырып классны юдырта, йә кар көрәтә,— шуннан курыктылар.

Нурулла абый, география укытуы белән бергә, мәктәпнең укуукыту бүлеге мөдире дә әле. Ул җыйнак гәүдәле, бераз бөкрерәк кеше. Йөзе шадра. Яше егерме биш-егерме җиделәр тирәсеннән ары юк. Буйдак. Укучылар аны үзара Нәмә дип атыйлар. Бу аның «нәмә кылдың, нәмә күрдең, сиңа нәмә кирәк» кебек сорауларына нигезләнгән кушаматы.

Ниһаять, Нурулла абый, класска журналсыз гына кереп, безгә дәреслектән укырга эш биргәч, тыныч кына утырырга, коридорга чыгып буталмаска, тәртип бозучы табылса, үзенә үпкәләргә кушып чыгып китте һәм бүтән кермәде.

Расписание буенча икенче дәрес алгебра иде, аны физкультурага алыштырдылар. Миңа бу табигый булып тоелды. Фәсхи абый физкультура укытучысы Габбас абыйларда тора иде бит, менә кем юксынадыр аны, дип уйладым мин дулкынланып.

Габбас абыйны без яратмыйбыз. Ул бик тупас кеше. Өстәвенә, ярыйсы ук кыланчык та. Дагалы бүре кушаматы аңа бик тә мач. Ул бер карасаң — бер төрле, икенче карасаң — бөтенләй башка, күзгә көйсез көн кебек. Һич уйламаганда алмашына. Армиядән кайтканына инде өч елдан артса да, шлемы белән шинелен һаман салганы юк. Бу аның кияренә бүтән кием-салымы булмаудан түгел, каракүл якалы өр-яңа пальтосы да, бер дигән бүреге дә, гәүдәсенә сыланып торган кара кайры туны да бар. Ул аларны бик сирәк, район үзәгенә барганда гына кия, хәрби киемнән йөрүе башкаларга охшамаска тырышуыннан. Бәештә гомер булмаган хәл, ди мәктәпне җыештыручы безнең күрше апа, кышын да көязләнеп, юка хром күн итекләрдән йөри. Авылдашларының аны «Дагалы бүре» дип атаулары да шуңарга бугай.

Габбас абый безне ишегалдына алып чыкты. Тезде. Смирно бастырды. Санатты. Уңга, сулга борылдырды. Аннары, «Вольно!» командасы биреп, тәмәке кабызды. Шулчак нинди генә әмерне дә дөрес

үтәми торган ике күзе ике төсле Гайшә:

— Габбас абый, бүген безгә фискультуры җук ые ич, бу дәрес алгибры буласы ые. Фәсхи абый кая китте? — дигән сорау бирде.

Көтмәгәндә бирелгән бу сораудан соң укытучыбыз кулындагы тәмәкесен аяк астына атып, нишләвемне берәрсе күреп тормыймы, дигән төсле як-ягына ялт-йолт каранып алды. Аннары ачулы тавыш белән:

— Кем сиңа гәп сатарга рөхсәт итте стройда, Хәсәнова? — дип җикерде.

Гайшә җавапсыз калмады.

— Бәлеш, гәп сатмадым, сорадым гына ич мин. Бүлне камандасы булгач кына. Дәрес саен миңа бәйләнәсең...

Гайшәнең каршы әйтүе укытучыны чыгырыннан чыгарды.

— Шулай тел озәйтасың, әрепләшәсең, мине өйрәтәсеңме әле син, чагыр күзле кәҗә кәләше? Мин сиңа Гыймади түгел, бел!.. Аулак өй сәкесендә симәнке ярып утырмыйбыз, дәрестә без. Яле әйт, кем мин сезгә?

— Мин чагыр күзле кәҗә кәләше икән, син Дагалы бүре инде, кем буласың тагын? Габбас дип түгел, авылда бөтен кеше Дагалы бүре дип атый сине. Кайберәүләр Калай әтәч тә диләр әле. Менә кем син, белмәсәң бел, карун урыс...

Бөтен классыбыз белән шаркылдап көлеп җибәрүебезне сизми дә калдык. Әмма кыйммәткә төште безгә бу көлү. Габбас абыйның йөзеннән кан качты.

— Ягез әле мәктәп тирәсе әйләнәли бегом арш!..— дип акырды ул, бугазын ертып.

Әмергә буйсынмый ярамый, киттек йөгереп. «Калай әтәч»ебез, айт-двасын такылдап, артыбыздан иярде. Ачуы аның чиктән ашкан иде бугай, йөгерүебезне кызулатканнан-кызулата барды һәм, шул рәвешчә, дәрес бетүне хәбәр итеп звонок шалтыраганчы куды. Бөтенебез шабыр тиргә төштек, бугазларын камыт кыскан атлар шикелле, гыжылдап сулый башладык, әмма арабызда бу вәхшиләрчә җәбергә сәбәпче булган ала күзле Гайшәне тел озайтканы өчен сүгүче булмагандыр.

Гайшә безнең класста иң өлкән укучы. Аңа инде унсигезенче яшь бара. Күкрәкләре туптай кабарып торган, иреннәре өлгергән чиягне хәтерләтеп ялтыраган җиткән кыз. Укуга Гайшә ялкау, «кытый»лардан гел башы чыкмый. Алтынчыга җиткәнче инде икеме, өчме тапкыр класста утырып калган булган. Әмма моның аңа файдасы тимәгән. Ул үзенең начар укуына борчылмый, «кытый»лары белән оялта башлаучыга җавабы тел очында гына.

— Әби белән әни, гомерләре буена хәреф танымасалар да, дуадак калмаганнар. Мин дә, «кытый»ларым булганга карап, ирсез калмам. Хатын-кызга утауда, урак урганда, ипи салганда, аш пешергәндә, төн йокыларын калдыра-калдыра бала үстергәндә уку гел кирәк түгел. Абыстай буласым җук. «А»га «б»ны кушкач, нәрсә чыкканы нигә хаҗәт миңа?— дип күз дә йоммый такылдый башлый.

Габбас абый белән Гайшә кичләрен бер үк аулак өйләргә йөриләр, күрәсең. Гаҗәп түгел, берсе өйләнмәгән егет, икенчесе бүген кияүгә бирерлек җиткән кыз. Бәештә клуб юк дәрәҗәдә. Ул колхозлашу елларында читкә сөрелгән бер байның таш амбарында. Кышын рәтләп ягылмый, кайчан да куян өшерлек суык була. Кышка кергәч авылга айга бер килгән киноны да анда, салкын җилекләргә үткәнгә, ахырынача карый алмыйсың. Шуңа ул клубка йөрүче дә юк. Кичләрен яшьләр җылы мунчаларга, аулак өйләргә җыйналалар. Габбас абый телгә алган Гыймади — Гайшәнең күңеленә хуш егеттер, күрәсең. Югары очның Кәҗә Гыймадие түгелме икән ул? Ул булса, шәп егет, якын тирәдә дан тоткан көрәшче. Узган ел

сабан туенда Габбас абыйны да бөтенләй көч тукмичә баш аркылы гына чөйгән иде. Гайшәдән, бәлки, бүген шуның ачуын алуы булгандыр бу? Алай дисәң, нигә бер кеше өчен бөтен классны тирләтергә?

Зада апа әйтмешли, пәри каргаган көн булгандыр бу, бүтән дәресләребез дә, башкаларга белмим, миңа шатлык китермәде. Хезмәт дәресенә укытучыбыз Кәшиф абый «төшереп» кергән иде, дөньяда такта шомарта торган нинди ышкылар барлыгы турында телен көчкә әйләндереп әчпошыргыч итеп сөйләде.

— Ы-ы-ыш-кы ш-ш-шомарту к-к-кор-ралы, әйебит. Ы-ы-ышкы-кысыз ө-ө-өстәл дә, ы-ы-ырам да, и-и-ишек тә жа-жасап бу-улмый. Ы-ы-ышкы-ы ю-юка жо-жомычка чы-чыгара, жомшак жо-жомычка, әйебит...

Шулай һәр җөмләсенә диярлек «әйебит» өстәп, дәрес бетүне белдереп звонок шалтыраганчы сайрады укытучыбыз. Ник беребезгә бер сорау бирсен, ник беребезнең агач шомарту коралларын белүбелмәвебез белән кызыксынсын! Үз тавышына мавыгып бүтән тавышларга колак салырга онытучы урман тавыгы суер кебек ул Кәшиф абыебыз. Җитмәсә, дәрескә «төшереп» тә кергән әле.

Кәшиф абый — Габбас абыйның капма-каршысы. Ул карусыз, ярдәмчел кеше. Авылда кемгә балтасын саплатырга, кемгә тиз генә рам ясатырга, кемгә тәрәзә яки ишек йозлеге эшләтергә кирәк — аңа киләләр. Берәүне дә кире борып җибәрми, барысын да канәгатьләндерә. Аның кемгәдер авыр сүз әйткәнен, кемнедер орышканын беркайчан да ишетмисең. Йөзе һәрвакыт, бик кирәкле һәм бик кадерле нәрсәсен югалтуына йөрәге таланган кешенеке шикелле, уйчан.

Сөләйнең миңа, Кәшиф абый элек үзе аракы эчү түгел, авызыннан аракы исе килгән кешене әйләнеп үтә иде, дип сөйләгәне бар. Имеш, ул күпер башы Габдери абзыйның бик чая Мөслимә исемле кызы аңа тормышка чыгарга риза булмаганга эчә башлаган. Имеш, ул апа Кәшиф абыйга:

— Егет булса мут булсын, ике күзе ут булсын,
Ике күзе ут булмаса, бар булганчы юк булсын,— диган

Имеш, ул, мин дә иремнең мут та, ут та булуын телим, синең кебек чебенне дә кыерсытырга курка торган усак гөмбәсенә барып башыма бәла алганчы, гомерем буе кыз килеш сазавым мең артык, дигән.

Мөслимә апа кыз килеш сазамаган. Чокырлы авылының бик үткен бер егетенә ябышып чыккан булган. Әмма бәхетен үзе телә-гән мут егет белән тапмаган. Бер аймы торгач, ире аны бик каты кыйнап күзен чыгарган һәм биләнке иткән. Шуннан соң Мөслимә апа, гарьлегеннән бүре шомырты ашап, дөньядан киткән. Кәшиф абыйның гел салмыш йөрүе шул Мөслимә апаны юксынудан, имеш.

Соңгы ике дәресне Һаҗәр апа үткәрде. Аның да эше көйле. Күпвакыт звонокка кадәр тел кашып азапланмый, дәрескә берәр кызыклы китап алып керә дә шуны укыйбыз. Әнә бүген дә «Карт Имтургинның тормышы»н укыдык. Ярыйсы ук мавыктыргыч китап. Үзе калын да. Өч дәрес буе укыдык инде, әле тагын кимендә өч дәрескә җитәрлек калды. Татар теле һәм татар әдәбиятына бернинди катнашы да юк ул китапның. Анда тундрада яшәүче кыргый халыкларның революциягә кадәрге авыр тормышлары тасвирлана. Иксез-чиксез кар сахрасында болан тиреләреннән аннан-моннан корамаланган ярангаларда зәмһәрир салкыннарда туңудан бизгәк тоткандагыдай калтырап, җил йотып, ачы төтенгә карлыгып, җәйләрен хәтта кояшны болыт күк каплаган исәпсез-хисапсыз черкиләрдән таланып, ачлы-туклы ничек яши алганнардыр алар, гаҗәп. Ул мескен халыкларның дөньяда барлыкларын тик үз кесәләрен генә кайгыртучы ачкүз сәүдәгәрләр белән алдакчы комсыз шаман-

нар гына белгән. Алар бу халыкларны, теләгәнчә мәсхәрәләп, аяусыз талаганнар. «Карт Имтургинның тормышы»ның татар теле һәм татар әдәбиятына ни катнашы бардыр, укытучыбыз ул турыда безгә бер сүз дә әйтмәде. Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал, Фатих Әмирханның, тагын бүтән бик күп татар язучыларының без белмәгән кызыклы әсәрләре аздырмы? Минемчә, Һаҗәр апа татар язучыларын санга сукмый. Моңа кадәр ул безгә Жюль Вернның «Серле утравын» укыткан иде, хәзер менә, җәелеп, төньяк халыклары тормышын өйрәнәбез. Андый китапларны дәрестә түгел, өйдә дә укып була бит югыйсә. Юк, без дәрестә укыйбыз. Ни өчен укытучы үзе ни теләсә шуны укыта торган дәресләр татар теле, татар әдәбияты дәресләре исемен йөртәдер, аңлашылмый...

Мин Нурулла, Габбас, Кәшиф абыйларның һәм Һаҗәр апаның җиңел юл белән генә безне белемле итәргә, безгә гыйлем бирергә «тырышулары» аларның безнең киләчәгебез өчен эчләре пошмау, безне санга санамау, үз-үзләрен дә, укытучылык хезмәтен дә яратмаулары дип карыйм. Аларның безгә дәрес бирүләрен тилмереп яңгыр көткәндә яварга иренеп шым гына үтеп киткән кысыр болыт белән чагыштырасым килә.

## 2

Эти район үзәгеннән кичен өйдә ут алгач кына кайтып төште. Кыяфәте көне буе ниндидер бик авыр эш башкарып тәмам арыган, йончыган кешенеке кебек булган иде аның. Күзләре сүнгән, сул битендә кашыннан иягенә таба сузылган кылыч ярасының тупас киндерәне хәтерләткән ямьсез җөе дә нигәдер калыная төшкән, шуңа чырае картаебрак киткән шикелле. Фәсхи абый турында кайту белән сорармын дип көткән идем этине, ләкин аның сүлпәнлеген, үз эченә бикләнүен күреп сүз кушарга базмадым. Әни дә этидәге үзгәрешне ул ишектән керү белән күрде.

— Нигә сөмсерең коелды, Сабир, чирләдеңме әллә? — диде ул, аның йөзенә борчылулы текәлеп.

Эти, ялкау гына кул селтәп, авыр көрсенде.

— Чирләмәдем. Тик минем хәлем чирленекеннән яманрак, Мәликә.

— Нишләп? Нәрсә булды?

Эти, өстен чишенгәч, өстәл янына үтеп, гимнастерка кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды.

— Мә, кара.

Әни кәгазьне кулына алып җәйгәч, мин, муенымны сузып, аңа күз төшердем. Анда эти кулы белән язылган ниндидер гаризаның өске өлешенә кызыл тостәге язма хәрефләр белән «Отказать» диелгән һәм бөтеркәле имза салынып, число куелган иде.

Әни кәгазьгә күз төшерде дә:

— Кире кагуларын нәрсә белән дәлиллиләр, белдеңме? — диде.

Эти җавап бирмәде, тутырып миңа карады. Аннары әнигә:

— Кая, юынып алыйм да ашыйк, сөйләшергә өлгерербез, иртәдән бирле авызыма ризык кергәне юк әле минем,— дигәч, бүлмә якка кереп китте.

Әни, җиз комганга су салып ләгән янына утырткач, табын әзерли башлады. Мин кулларын сүлпән генә юучы эти янына кереп, үземне көне буе борчыган мәсьәләне тизрәк ачыкларга ашыктым.

— Эти, Фәсхи абыйны күрмәдеңме син районда?

— Юк,— дип җавап кайтарды эти, төксе генә итеп.— Кара әле, улым, ул бәндәне оныт син, зинһар. Аны бүтән бер чакта да телгә

алма. Намуслы, әйбәт кеше булмаган ул, шуны төшен...

— Корткыч булган, диләр аны. Димәк, бу дөрес сүз?

Эти миңа җавап бирергә өлгермәде, яныбызга әни килде.

— Бар, улым, кече якка чык әле, ашны мин сиңа шунда состым, шунда ашарсың. Бар, юк-бар сораулар белән алҗытма атаңны, арыган ул.

Өлкәннәрнең үз бишләре биш! Фәсхи абый белән кызыксынуым аларга юк-бар. Кара инде этине, «Ул бәндәне оныт син, зинһар, бүтән телгә алма»,— дип кырт кисте. Нинди ярамаган нәрсә эшләгән ул, әйтмәде.

Башта олы яктан берниндә дә тавыш ишетелмәде. Аннары, дүрт-биш минут үткәч, әни акрын гына:

— Йә, ничек дәлилләгәннәр, сөйлә инде,— диде.

— Сәбәпләре көчле аларның, Мәликә, һәм нигезле дә. Мин очучы да, танкист та, хәрби белгеч тә түгел, гап-гади кавалерист кына ич. Чит телләрне дә белмим. Фарсыча бераз сукалыйм сукалавын, әмма фарсы теленең анда керәге тавыкка тешләр кирәккәне кебек кенәдер. Испаниягә беренче чиратта техникадан хәбәрдар кешеләр җибәрүне хуп күрәләр икән. Инде килеп, сәламәтлек мәсьәләсе. Үзеңә мәгълүм, миндә ул чамалы...

— Ашказаның белән изаланганыңны каян белгәннәр соң алар, Сабир?

Этинең телен шартлаткан ишетелде.

— Алар син тазамы, чирлеме икәнне генә түгел, тугызынчы бабаңның нинди юллардан нилөр эшләп йөргәнен дә беләләр хәзер, җанашым. Минем турыда аларга бөтен белешмәләрне Җәгъфәров биргән. Фәсхи өчен аңардан яман әләкте үземә. Коммунист башың белән нигә сәяси сукырлык күрсәттең, нигә аның сарык тиресе ябынган бүре икәнен күрмәдең, авыл халкы арасында нинди шикле эшләр үткәргәнен ишеткәнсеңдер, һич яшерми сөйлә әле шуларны, дип бәйләнде. Бүтәннәр Фәсхине ничек белсәләр, мин дә аны шулай гына белә идем, дигәч, ярсып ук китте. «Ул троцкийчы Җәмилевегез бер сезнең мәктәпне генә түгел, бөтен районыбызга кара тап булып ятты. Январь аенда Союз Прокуратурасының советка каршы троцкийчылар үзәге эше буенча тикшерүе тәмам булу турындагы белдерүен бөтенләй укымагансың, күрәсең. Ул үзәк эмиграциядәге сатлык җан Троцкийның тапшыруы буенча 1933 елда Зиновьев, Каменев, Смирнов, Мрачковский һәм башкалар составында троцкийчы-зиновьевчылык үзәге белән беррәттән оештырылган һәм аның составында Пятаков, Радек, Сокольников һәм Серебряковлар торган. Исеңә төшерәм, алар илебез хезмәт ияләреннән барлык казанышларын тартып алуны, фабрика һәм заводларны капиталистларга кайтарып бирүне үзләренә максат итеп куйганнар. Алар тарих көпчәген кирегә борырга, колхоз строен бетерергә, авылда хуҗа итеп кулакны куярга, совет крестьяннарын коллыкка төшерергә, аларны кулак изүенә тапшырырга теләгәннәр. Сезнең Җәмилевегез шуларның сыбызгысы булган, сез шуны күрмәгәнсез»,— дип дулады. Аның өчен Зиннәткә дә шактый нык эләгәчәк. Парторгның җаваплылыгы икеләтә бит. Ул партоешмадагы һәр кеше өчен җавап бирә. Эшләр шулай, Мәликә. Ә син, нигә сөмсерең коелды, дисең...

Кара инде этине, Испаниягә сугышка барырга уйлаган булган икән ич. Радиодан көн саен Испаниядәге хәлләрне йотлыгып тыңлавының сере ачылды хәзер. Ә менә Фәсхи абый турындагы сүзләргә һич ышанырлык түгел. Кара, троцкийчылар сыбызгысы булган икән бит ул. Алай...

Этинең Испаниягә сугышка барырга омтылуы табигый. Ул — коммунист, запастагы кызыл командир. Урта Азиядә озак еллар чик буенда хезмәт иткән кеше. Шунда басмачыларны бастыруда

күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән. Әти әни белән дә Урта Азиядә танышкан. Мин дә шунда туганмын. Ләкин анда үсмәдем. Татарстанда әтинең бертуган энесе Моталлап абый гаиләсендә үстем. Урта Азияне бөтенләй хәтерләмим. «Сине без үз янибызда асрарга курыктык, ул елларда тынгысыз һәм борчулы хәрби тормышта һич уйламаган нәрсәләр килеп чыга иде»,— ди әни. Сөйләүләренә караганда, җиңел булмаган аларның тормышы. Чик буенда көн саен кыл өстендә яшәгәннәр. Әтинең битендәге кылыч ярасы эзе — шул тынгысыз көннәр истәлеге. Шунысы кызык, әти белән әнинең танышуларына да шул яра сәбәпче булган. Ул чакта әни хәрби лазаретта шәфкать туташы булып эшләгән. Фельдшер-акушерлык мәктәбен ул мин тугач бетергән. Әтиең белән мин талашып таныштым, дип көлә әни хәзер.

Беркөнне кичкырын әни эшләгән лазаретка йөзен, уң күзен генә калдырып, ак чүпрәк белән аннан-моннан ураган яшь кенә командир килеп керә. Бу вакыт лазаретта врачлар инде кайтып киткәннәр, анда тик кизү шәфкать туташлары гына калган була. Кояшта янып тәненең бөтен ачык урыннары чуенга охшап каралган яшь командир шәфкать туташларыннан ярасын юып бәйләүне үтенә. Әни, аның йөзенә уралган чүпрәкне сүткәч, куркып китә. Яра эшкәртелмәгән, бик нык үлекләп шешкән, ялкынсынып кызарган була.

— Яралану белән нигә безгә килмәдегез, бу коточкыч хәлгәчә суздыгыз? — ди әни командирга, ачуланып.

— Кайчан килсәм дә, барыбер түгелмени? Шар сугып йөрмим, хезмәттә мин,— дип җавап кайтара аңа егет, бер дә исе китмичә.— Йә, тизрәк таза марля белән ярамны бәйләгез дә, китәм, кызылармеецларым көтә мине.

— Документларыгызны күрсәтегез әле,— ди аңа әни.

Яшь командир түш кесәсеннән ниндидер кәгазьләр чыгарып өстәлгә сала. Әни аларны алып:

— Сез тәмам савыкмый торып моннан беркая да китмисез,— ди кистереп.

— Кем әйтте аны сезгә?

— Менә мин әйтәм.

Яшь командир белән әни шуннан соң шактый әйткәләшәләр. Лазареттагы башка шәфкать туташлары да алар янына җыйнала. Командирның температурасын үлчиләр — 39,7.

— Сәламәт кешенең температурасы 36,5. Яшәүдән туйсагыз, барыгыз,— ди аңа әни тыныч кына.

Яшь командир лазареттан китми, кала. Берничә айдан соң әни белән алар өйләнешәләр.

Әти — сабыр холыклы кеше. Аның кемгә дә булса тавыш күтәргәнен, кем беләндер талашканын (менә өч ел инде алар белән бергә торам) ишеткәнем юк әле. Башкалардан нәрсәсе беләндер аерылырга да, мактанырга да яратмый әти. Хәтта энә орденын да зур бәйрәм тантаналарында гына тага. Ул уйлаганын беркайчан да эшләми калмый. Иң сөймәгәне — сүзендә, вәгъдәсендә тормаган кеше. Үз сүзеңә хуҗа булмау — беренче чиратта үз-үзеңне, аннан килеп башкаларны да санга сукмау ул, ди. Аңа әле дә күнегеп җитә алмыйм, ничектер әти түгел, чит кеше сыман ул. Әти минем белән һәрвакыт җитди итеп, үз тиңе белән сөйләшкән шикелле сөйләшә. Әни алай түгел, адымым саен орышып, битәрләп тора, шулай да ул — якын, үз. Әтигә өлкәннәр белән балалар арасында аерма юк кебек. Ул безне тарихтан укыта. Кайбер дәресләрендә мавыгып китеп, без аңламый торган әллә нинди фәлсәфи нәрсә-

ләр сөйләп ташлый. Күп белә ул, тик белгәнен һәркем төшенерлек гади тел, гади җөмләләр белән аңлата алмый. Сөйләгәне ничектер коры, җансыз чыга.

Эти буйга зур түгел. Һәрвакыт пөхтә киенә, йөргәндә гәүдәсен хәрбиләрчә төз тота. Вакыты нинди генә кысан чакта да көндә кырынмый калмый. Күзләре уйчан, йөзе кырыс. Дулкынланганда сул бите буйлап кашыннан иягенәчә сузылган яра җөе ара-тирә тартышып, аның чыраен шактый ямьсезли. Миңа: «Син этиеңә охшагансың»,— диләр. Мин дә эти кебек үк каратут, әмма холкым аныкы кебек сабыр түгел. Тиз кызам, уйлап эш итә белмим, юктан гына кәефем кырыла, үпкәлим. «Этиең дә элек синең кебек кызу канлы иде, тормыш сабырлатты Сабирны»,— ди әни. Бу аның миңа, тормыш алда сине дә басар, игә китерер, дию, минемчә.

Әни Оренбург ягында туган. Аның этисе мөгаллим булган. Октябрь революциясеннән соң, егерме беренче елгы ачлыкта, миңа бабай тиешле кеше бөтен семьясы белән Ташкентка күчеп барып, шунда төпләнгән. Әнинең Үзбәкстанда бер абыйсы, ике сеңлесе бар ди, аларны минем күргәнем юк, белмим.

Әни өчен мин һаман имчәк баласы белән бер. Ул минем тагын күпме үсүемне телидер, белмим.

Өлкәннәрне аңлавы, гомумән, кыен. Алар үзләре кайчандыр бала булмаган кебек. Өлкәннәр бала-чагага күп вакыт үзлекләреннән фикер йөртергә, тормыш четреклекләрен аңларга, теге яки бу күләмдә җаваплылык сорый торган эшләрне башкарып чыгарга сәләтсез, дип карыйлар шикелле. Мин кайчан мөстәкыйльлеккә өйрәнермен, үземдә ничек тормыш тәҗрибәсе туплармын — ул турыда әни уйлыймы икән? Юк, уйламыйдыр, юкса һаман да үсә төшүемне көтмәс иде. Бер китапта мин, тормыш ялгышлардан тора, кеше ялгышлары аша яшәргә өйрәнә, диган кызыклы бер фикер укыдым. Шуннан соң ялгышасым, ялгышларым аша яшәргә өйрәнәсем, кулларымны әни-этиләремнең чабуларыннан тизрәк ычкындырасым килә башлады. Әни моны аңласа, үсә төшүемне көтүдән туктаса, һәр адымымны тикшереп, күзәтеп торуын ташласа иде. Рус язучысы Аркадий Гайдар уналты яшендә полк командиры булган, диләр. Димәк, өлкәннәр аны малай чакта ук шәхес итеп таныган, үсә төшүен көтеп тормыйча, иреннәрендә ана сөте кибеп җитмәс борын ук, зур ышаныч белдергәннәр. Ул бу ышанычны аклаган. Мин үземне яшүсмер Гайдар белән янәшә куярга, зур җаваплылыкны шушы яшемнән аның шикелле үз өстемә алырга сәләтлемен, димим, уналтыга җитәргә миңа тагын ике ел кирәк әле, эти белән әни мине инде гамьсез сабыйга исәпләүдән туктасалар, үземне чиксез бәхетле санар идем...

## 3

Фәсхи абый кулга алынгач күп тә үтмәде, мәктәп тормышыбызда тагын бер сәер вакыйга күңелгә кара күләгә иңдереп узды. Ул да һич уйламаганда булды.

Февраль башында бөтен илебез бөек рус шагыйре Пушкинның дуэльдә патша ялчысы кабахәт Дантес тарафыннан вәхшиләрчә үтерелүенә йөз ел тулуны билгеләп үтте. Шул уңай белән төрле шәһәрләрдә газеталар шагыйрьгә һәйкәлләр куелу, миллионлаган тиражлар белән аның әсәрләре басылу, аңа багышланган кинофильмнар чыгу, театрларда спектакльләр куелу турында яздылар. Бу юбилей мәктәпләрне дә читләтеп узмады, аларда бөек шагыйрьгә багышланган кичәләр үткәрелде. Иң күңеллесе — дәфтәрләребезнең тышлары Пушкинның портретлары, аның үлемсез шигырьләренә

ясалган искиткеч рәсемнәр белән бизәлгән иде. Әйбәт зәвыклы, бөек шагыйрьне чын-чынлап яраткан кешеләр уйлап чыгарган булгандыр ул дәфтәр тышларын. Алардагы рәсемнәр Пушкинны безгә тагын да якынайта, аңа хөрмәт уята, аны яраттыралар иде. Бер тышлыкта сөекле шагыйрьнең сурәте: «Исәнме, таныш түгел яшь буын!» — дип сиңа турыдан-туры мөрәҗәгать итә, икенче тышлыкта сыек зәңгәрсу җирлектә шаулы диңгез култыгында үскән сихри имән рәсеме игътибарны үзенә тарта. Бүтән тышлыкларда — «Изге Олег турында җыр», «Һәйкәл», «Анчар» шигырьләре һәм аларга ясалган күренешләр. Бу шигырьләрне дәреслектән эзләп торасы да юк, алар һәрвакыт кул астында. Аларны туктаусыз күрә-күрә иң ялкау, иң хәтерсез укучылар да ятлады. Аларны ятлау буенча мәктәптә без ярыш та оештырган идек.

Бер дә бер көнне, һич искәрмәстән, бөтен мәктәптә барлык укучыларның дәфтәрләрен җыеп алдылар да (өйдә калганнарын да китерттеләр), иртәгесен аларны тышсыз калдырып, безгә кире кайтардылар. Анда инде бөек шагыйрь рәсемнәренең дә, әсәрләренә ясалган сурәтләренең дә, әсәрләренең дә эзләре калмаган иде. Ни өчен дәфтәрләребез ашыгычлык белән тышсыз калдырылды — безгә аңлатучы булмады. «Шулай кирәк иде»,— диюдән бүтән җавап ишетмәдек. Бу турыда мин өйдә әти белән әнидән сорарга кыймадым, чөнки аларның соравыма тиешенчә җавап бирмәячәкләренә шигем юк иде. Укучылар арасында: «Дәфтәр тышлыкларындагы Пушкин әсәрләренә ясалган күренешләрдә һәм шагыйрьнең портретларындагы буталчык сызыкларда илебезгә, партиягә, бөек юлбашчыбыз Сталинга карата кабахәт сүзләр язылган булган»,— дигән имеш-мимешләр йөрде. Моның алаймы, түгелме икәнен без инде теләсәк тә тикшерә алмадык, ул серле рәсемнәр беребездә дә сакланып калмаган иде. Ни гаҗәптер, бу сәер вакыйгадан соң таланган дәфтәрләрнең элекке матур тышлыклары озак вакытлар төшемә керепйөдәтте. Шул каһәрләнгән дәфтәр тышлары белән бергә мин ниндидер бик кадерле нәрсәмне югалткан сыман булдым.

Фәсхи абый турында Сөләй белән әти әйткәннәрдән башка берни дә ишетмәдем. Әти нәрсә генә димәсен, Фәсхи абыйны мин дошман итеп тә, корткыч итеп тә, начар кеше итеп тә күз алдыма китерә алмадым. Бераздан мәктәбебезгә алгебра һәм геометрия укытырга зур авызлы, черек тешле Нижгар мишәре Җамалый абый килде. Үзе укыткан фәнне биш бармагы кебек белә иде ул. Әмма белгәнен безгә аңлата, җиткерә алу сәләте чамалы иде шул аның. Җамалый абый дәресләрендә бер мин генә түгел, бик күп башка укучылар да Фәсхи абыйны якын итеп, җылы, ярату хисе белән сагынып искә ала идек. Аннары кичләрен Җамалый абый фатиры турыннан үткәндә шыран ярып:

Мәвештә тора кочерга  
Топканы болгатырга.  
Зубам сызлый авызымда,  
Һай ничек туктатырга?  
Ай-ли, Җамалый,  
Укыту ягың чамалы...

— дип җырлый торган булдык. Укытучыга җырыбызның ничек тәэсир итүен белмәдек. Бу җырыбызда яңа укытучыбызны мыскыллауга караганда Фәсхи абыйны юксыну, аны сагыну хисе өстенлек итә иде. Аны кем дә булса аңладымы икән?

## Икенче бүлек

### 1

Бәеш — Чокырлы авыл советына карый. Чокырлы белән Бәеш арасы җиде чакрым. Бәешләргә, авыл советына эшләре төшкәндә,

аз дигәндә, ярты көн вакытларын югалтырга туры килә. Кеше анда бер баруда йомышын башкарып кайтса, юлын уңган саный, шатлана, чөнки еш кына йә совет председателе, йә аның секретаре урыннарында булмыйлар, шуңа күрә авыл советына эше төшкән кешегә Чокырлыга кат-кат барырга туры килә. Әтигә еш кына мәктәпкә кагылышлы теге яки бу эшне җирле совет башлыклары белән хәл итәргә кирәк була. Бәеш белән Чокырлы арасында телефон элемтәсе юк. Кичектергесез эшен тормышка үткәрергә вакыты иркенме, тармы — әти Чокырлыга юл тота. Авыл советы үзебездә булмау пычаксыз суя, ди ул үртәлеп. Совет председателе Әюп абый Муллинны бәешләр ни өчендер, ул тирестән көрәк булган кеше, диләр. Әюп абыйның бер сәер ягына күз йомсаң, башкалардан һич аерылып тормый шикелле үзе. Ул озын буйлы, төз гәүдәле, киң яңаклы, эчкәрәк батып торган кысыграк күзле, калын иреннәре алга чөмкәеп торган утыз биш яшьләрдәге кеше. Сәерлеге — ике як күкрәген дә төрле значоклар белән бизәү. Значокларның ниндиләре генә юк аңарда! ПВХО, БГТО, ГТО, ГСО, МОПР, осоавиахим, халык исәбен алучы, Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе, КИМ, «Спартак», «Динамо» җәмгыятьләре, хәтта яшь ворошиловча атучы значоклары да бар. Кайберләре икешәр, өчәр. Барысы — иллеләп. Якасыннан бил каешына кадәр дүрт-биш рәт тезеп тага. Аларны кешеләр күрсен өчен өстендә кожан булса — кожанын, пальто булса — пальтосын, тун икән тунын елның теләсә кайсы вакытында да төймәләмичә, җилбәгәй җибәреп йөри.

Атлар караучы Камали бабай:

— Тиле Хәйрулланың варисы безнең рәис Муллин иптәш,— дип көлә аңардан.

Хәйрулла дигәннән, моннан күп еллар элек яшәгән ул акылдан мәхрүм бәндә. Аңа солдат хезмәтеннән кайткан һәр авылдашы йә кокардасын, йә ике башлы сәмруг кош сурәтле ялтыравыклы төймәсен, йә тутыккан медален бүләк итә торган булган. Кыз-кыркын, күзләре төшеп йөргән егетләренә яр булудан коры калмаска дип адарынып, аңа тамакса, дәвәт, хәтта чулпы тәңкәләрен кызганусыз өзеп биргәннәр. Хәйрулла аларның барысын да түшенә ничек туры килсә шулай тагып, Бәештә «җанарал» булып йөргән.

— Хәйрулла мәрхүм урынына хәзер Әюп, җанараллык — аңарда. Әнә ул үзе килә, үрә катып сәламлик аны, җәмәгать,— ди Камали бабай, тирәсендә булган кешеләргә тешсез авызын ерып.

Муллин абыйны әти дә өнәми. Аның белән ул, кичектергесез эше булмаганда, очрашмаска тырыша. Моның сәбәбе, минемчә, авыл советы рәисенең значокларга гашыйклыгына кайтып кала бугай. Әти Бәешкә ТБУМ директоры булып килгәч, Әюп абый, аның күкрәгендә Кызыл Байрак орденын күреп, өнсез калган. Аннары күпмедер вакыт үткәч, ул әтидән орденын сатуны үтенгән. Әти аңа, кырт кисеп, үзендә сатлык орден юклыгын әйткән. Шуннан соң Әюп абый әтидән орденын значоклары арасында берничә көн тагып йөрергә биреп торуын үтенгән. Шул чакта әти аңа бик кискен сүзләр әйткән. Үзе лаек булмаган зур бүләкне тагып йөрүдән нинди тәм табарга уйлагандыр Әюп абый. Үзе инде ир уртасы кеше бит, җитмәсә — авыл советы башлыгы. Үтерсеннәр, аңламыйм аны...

Түшен төрле значоклар белән бизәүдән тыш, Муллин абыйның күңеленә хуш тагын бер сәерлеге бар. Ул — салымнарын вакытында түләмәгән кешеләрнең капка түбәләренә яки өй кыекларына чүпрәк байрак элү. Бу ахмаклыкны әти, гомумән, күрә алмый. Мин чүпрәк байракны миллионнарның каннары сеңгән азатлыгыбыз, бәйсезлегебез символы — урак-чүкечле һәм йолдызлы изге кызыл байрагыбызны мәсхәрәләү дип карыйм, совет авылы өстендә тик кызыл

байрак кына җилфердәргә тиеш. Дегет белән мыскыллау сүзләре язылган иске чыптаны совет кешеләре торагына элү — аны кимсетү, түбәнсетү, хурлау, мәсхәрәләү, аңардан оятсызларча көлү ул, ди.

Бу турыда эти райкомга да язды. Шуннан соң берничә көн узгач, Муллин абый, кашын-күзен җимереп, безнең өйгә килде һәм, бусаганы атлап кергәч, исәнләшеп тә тормастан, тотлыга-тотлыга:

— Рәхмәт, Кадыйров иптәш, әйткән сүзеңдә торгансың. Мине Җәгъфәров иптәшкә әләкләшеп яхшатлы булыйм дидеңме? Булмый тор. Авыл сәвитсез, сәяси аңгыра Муллинсыз мәктәбеңне римунтлатып, җылытып кара әле син менә. Минем аягыма җыгылмасаң, Әюп булмасын исемем, бел! — дип ярып салды.

— Туктале, Муллин, янама миңа. Кызма да. Чишен әле өстеңне, утыр, иркенләп сөйләшик,— диде аңа эти тыныч кына.

— Утырмыйм, мин әйтәсемне әйттем инде.

— Үзең әйтү белән генә түгел, мине дә тыңлап бак син, иптәш председатель. Мин җитәкләгән мәктәп — совет мәктәбе, минем шәхси мәктәбем түгел, шуны онытма. Әгәр мәгариф эшенә аяк чаласың икән, башыңнан сыйпамасларын, тиешле җирдә тиешенчә җавап бирәсеңне уйла. Бу минем сиңа башта җиде кат үлчә, аннары гына кис, дию.ем. Башкача сиңа председательлек эшен бүтән кешегә тапшырырга туры килмәсен. Басып торма, утыр әле, утыр.

Әюп абый теләр-теләмәс кенә ишек катындагы диванга утырды. Әни кече якта самавыр шылтырата башлады. Эти председательнең каршына ук барып басты.

— Син, иптәш Муллин, СССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советының «Авыл советларын акчалата салымнарны, страхование түләүләрен, натуралата тапшыруларны исәпләү һәм түләтү эшләреннән азат итү турында» шушы елның егерме беренче март карарын укыдыңмы?

— Ул карар турында ишеттем, тик укыганым җук әле. Нindirәк карар ул, анык кына белмим аны, Кадыйров иптәш.

Эти Әюп абыйның янәшәсенә утырды.

— Ул карар авыл советларына эшләрен Сталин Конституциясе куйган сәяси, хуҗалык һәм культура бурычларына туры китереп яңартып оештырырга мөмкинлек бирә. Массаларның сәяси активлыклары үсү советлардан бу активлыкның башында торуны таләп итә. Койрыкта сөйрәлеп баручы, массаларны үз артларыннан иярт э белмәүче совет җитәкчеләре Конституция нигезендә сайлаулар вакытында читкә алып ташланачаклар. Ул гына да түгел, безнең сайлау системасы сайлаучыларның ышанычларын акламаган депутатларны теләсә кайчан кире чакырып алу хокукын бирә. Эшегезне үзгәртеп коруда яңа карарның гаять зур әһәмияте бар, иптәш Муллин. Совет эшен сүздә генә түгел, гамәлдә җитди төстә үзгәртеп корырга кирәк, диелгән яңа карарда. Гомумән алганда, авыл советларының бүгенге бурычлары халыкның политик, хуҗалык һәм культура тормышын чын-чынлап оештыручылар булуга һәм массаларның үзешчәнлегенә җитәкчелек итүгә кайтып кала...

Этине Әюп абый башын иеп, уңайсызланып тыңлады. Ул үзенең безгә җилтерәп килеп керүенә үкенә кебек иде инде. Үенә ни килсә, шуны башкаручы дуамал түрә түгел, халык хезмәтчесе икән бит ул...

Эти сүздән туктагач, Әюп абый кыяр-кыймас кына сорау бирде:

— Бу карар көченә кергәнме соң инде?

— Юк әле. Ул быелның беренче июленнән көченә керәчәк.

— Барысын да төшендердең, рәхмәт сиңа, иптәш Кадыйров.— Председатель этигә күтәрелеп карамады.— Дулап килеп кергәнем өчен ачуланма инде, надан бит мин, кичер...

— Чыпта байракларыңның законга сыймавына төшен син, Эюп. Без Бөек Октябрь революциясен үз көче белән көн итүче кешеләрне кыерсыту, кимсетү, мыскыллау, мәсхәрәләү өчен ясамадык бит. Киресенчә, аларга канатлар үстерү, яңа казанышларга илһамландыру, уңышларга дәртләндерү, үз-үзләрен җир кортлары итеп түгел, күз күрмәгән, колак ишетмәгән могҗизалар тудырырга сәләтле баһадирлар итеп тойдырырга, аларны кешелек дөньясының якты киләчәге — коммунизмны төзүчеләр итәргә ясадык. Илдә Төрексиб салынды, Днепрогэс төзелде, Магнитка торгызылды, ком чүлләре җимеш бакчаларына, мамык игү кырларына әверелдерелә, элекке караңгы, надан, хәерче авылларда колхозлар чәчәк ата. Син исә көннән-көн яктыга омтылучы совет авылы өстенә шакшы чыпта байрак эләсең. Бу сап-сары юкә балы белән мөлдерәмә тулы дәү мичкәгә кара дегет тамызу белән бер түгелме, Муллин?

— Аңладым, бетте. Мин бүтән ул рисвай әләмен элүче түгел. Менә партбилетем белән ант итәм сиңа, Кадыйров иптәш, ялгышымны бүлше кабатламам.

Әни өстәл хәзерләгәч, эти кунакны көчләп диярлек чәй эчәргә утыртты. Мин урамга уйнарга чыгып киттем.

Йокыдан яңа торып кына килә идек әле, безгә тыны-өне кабынып күршебез Зада апа атылып килеп керде. Керә-керешкә:

— Сабир туганкаем, капкаңа Эюп мәлгунь мәсхәрә әләме элеп киткән, кеше-кара күргәләгәнче алып чөй шуны, зинһар,— диде ул инәлеп этигә.

Эти аны аңламады.

— Нинди мәсхәрә әләме?

— Теге дегетле чыпта әләм инде...

Эти, өстенә дә киенеп тормыйча, өйдән чыгып китте. Бераздан ул, ачуыннан шартларга җитеп, кулына чыпта байрак тотып әйләнеп керде. Аның кашлары җимерелгән, битендәге яра җөе тартышып-тартышып куя, куллары калтырый иде.

— Кабахәтлекнең чигеннән ашу бит бу!..— диде ул таякка беркетелгән чыпта кисәген идәнгә атып.— Чыптага фашист билгесе ясап, астына: «Бу йортта троцкийчы корткыч Кадыйров яши»,— дип тырнаган, подлец. Кем эше булыр бу, кем эше?..

— Кем эше дип, билгеле силсәвит рәисе эше инде ул. Авылда бүтән кеше әлми мәсхәрә әләмен.

— Юк, Зада, Муллинның мондый этлек эшләвенә ышанмыйм. Өстенә сарык тиресе бөркәнгән яшерен дошман кулы кадаган капкама бу кабахәт нәрсәне. Провокация бу, намусымны пычратырга маташу. Моны ул подлец ничек кенә астыртын эшләсә дә, кем икәнен белербез барыбер. Ертырбыз сволочьның битлеген...

Этинең сүзләре тормышка ашмады. Бөтен авыл активы, коммунистлар, комсомоллар бик нык тикшерсәләр-эзләнсәләр дә, капка төбәбезгә пычрак чыпта кисәген элүче табылмады.

Районга баргач, эти ул мәсхәрә әләме турында райком секретаре Җәгъфәров абыйга да әйткән. Аннан кайткач эти әнигә:

— Солтан янына бүген ник кергәнемә үкенәм,— диде, сукранып.— Теге рисвай әләменә язылган кабахәт сүзләр өчен ул үземне гаепләде. Имеш, без, Бәеш коммунистлары, барыбыз да сәяси сизгерлегебезне югалтканбыз, халык арасында бүгенге таләпләргә җавап бирерлек эшләмибез. Фәсхи Җәмилев ише политик җинаятьчеләрнең иярченнәрен фаш итеп, аларның йөзләрендәге битлекләрен ертып атарга ашыкмыйбыз. Хәтта ул шуңа барып җитте: «Син, Сабир, үзеңнең троцкийчы да, корткыч та түгеллегеңне дәлилләргә, утсыз төтен булмый әйтеменең сиңа карата нигезсезлеген исбат итәргә тиешсең»,— диде. Кемнән-кемнән, мин Җәгъфәровтан андый мәгънәсезлекне көтмәгән идем...

— Намусын югалткан ниндидер бер хулиганның сиңа үч итеп эшләгән этлеге өчен җаныңны кыйнама, Сабир, тынычлан, зинһар. Күңелеңнең керсезлеген Солтан бик яхшы белә. Син аның ярсулык белән әйткән сүзләрен авырга алма. Ул җитәкче кеше бит, нәрсәдер әйтергә тиеш,— дип тынычландырырга тырышты аны әни.

— Ул кем генә булмасын, минем гаделлегемә, намусымның тапсызлыгына шикләнмәскә тиеш иде. Ул миңа урынсыз таләп куюы белән үзенең дәрәҗәсен төшерде, бичара бер перестраховщик икәнен күрсәтте...

Урыны чүплек башыннан ары китмәслек шакшы чыпта кисәге этине йокыдан яздырды. Төннәрен уянганда мин аның гел йә өстәл артында ияген кулларына терәп уйланып утырганын, йә башын иеп идән буйлап ашыкмый гына ишекле-түрле йөренүен күрә торган булдым.

Этинең чыпта байрактагы фашист билгесенә нинди катнашы бар, нигә аны троцкийчы һәм корткыч дип атаганнар, үз алдыма куйган бу сорауларга мин туктаусыз җавап эзләдем, ләкин таба алмадым. Дегетле фашист билгесе нәрсәне аңлата, Троцкий кем, ул нинди ярамаган эшләр башында торган, троцкийчы белән корткыч арасында нинди уртаклык бар — болар минем өчен серле табышмак иде. Газеталарда, радиодан ул чирканыч сүзләр күп кабатлана, әмма аларны җисемләп күзаллап булмый. Колхозчыны, эшчене мин теләсә кайчан, төнлә дә, көндез дә күз алдыма китерә алам. Алар матди байлыклар тудыра. Ә троцкийчылар һәм корткычлар аларның эшләренә аяк чалучы, комачаулаучы, этичә әйткәндә, тарих тәгәрмәченә таяк тыгарга маташучылар, күрәсең. Чыпта байракка ышансаң, эти коточкыч кеше бит. Ул бөтен яңалыкларга, кешеләрнең бүгенге һәм киләчәк бәхетләренә каршы көрәшүче була түгелме? Алай түгел икән, нигә ул үзенең совет властена дошман түгеллеген, намусының пакьлеген дәлилләүдән баш тарта — аңламыйм. Үсемлекләрнең, тереклек ияләренең эшләре шәп, аларны берберләре белән бутарга һич мөмкин түгел. Имәнне берәү дә юкә дими, миләш миләш, шомырт һәрвакыт шомырт булып кала, сыерны да кәҗәдән аеруы җиңел, әрем дә билчән белән туган түгел, инде килеп, бүрене төлке белән кем бутый? Бутамый. Бутаса, бу акны — кара, диюгә бәрабәр булыр иде. Ә кешенең саф намуслымы, астыртын дошманмы икәнлеге маңгаена язылмаган, белә алмыйсың. Кем ул минем эти, нигә төннәр йокламыйча борчыла — белмим. Бәлки, этинең намусы, ул үзе әйткәнчә, бөтенләй үк тапсыз түгелдер, күзәтергә кирәк, ашыкмый күзәтергә...

## 2

Сулъяк күршебез Ярулла абзыйның хатыны Хәбибә түти белән икебез генә белгән серебез бар. Инде дүртенче дистәсен тутырып килгән хатын белән ундүрт яшьлек малайның нинди уртак сере булырга мөмкин, диярсез сез. Ашыкмагыз, сөйләгәнне көтегез.

Илебездә укый-яза белмәүчелектән арыну өчен эзлекле көрәш бара. Эти, беренче бишьеллык башындагы «Надан килеш социализм төзеп булмый» дигән лозунг искермәде, ул бүген дә көн үзәгендә, бүген дә актуаль әле, ди. Авылдагы укый-яза белгән һәр кеше наданлыкка каршы көрәштә катнаша. Мәктәптә көндезләрен — балалар, кичләрен зурлар укый. Һәр мәктәп баласы укый-яза белмәүче әти-әнисенә, абыйсына яки апасынамы грамотага өйрәнергә булыша. Безнең өйдә хәреф танымаучы булмагач, мин күршеләребез Ярулла

абзый белән Хәбибә түтине укытам. Аларның бала-чагалары юк, икәүдән-икәү үзләре генә. Колхозчылар түгел, аерым хуҗалык. Ярулла абзый — сунарчы. Хәбибә түти иреннән узып колхозга ялгызы гына керүне гөнаһ саный. Бу аның үз сүзе. Ир — баш, хатын — муен, ди ул. Баш кай якка караса, муенның шул якка борылуы табигый. Халыкта тагын ир белән хатынны энә белән җепкә дә охшаталар. Энә кая юнәлсә, җеп аңа иярә. Ярулла абзый белән Хәбибә түтигә дә бу туры килә. Хәбибә түти иреннән узып берни дә хәл итми.

Кешеләрне грамотага өйрәтү җиңел нәрсә түгел икәнен үз башыма төшкәч белдем. Өлкән яшьтәге шәкертләрем белән тәмам изаландым мин. Күздән бирле азапланам, әмма аларга хәреф танытa алганым юк әле. Ярулла абзый миңа турыдан-туры:

— Мин, сунарчы буларак, нинди генә җәнлек эзен дә күзем төшү белән, моннан фәлән җанвар үткән, дип ялгышусыз әйтә алам, ә укуга булдыклылыгым җук. Синең бөтен аңлатканыңны үзең бездән чыгып киту белән онытам, хәтерем тишек. Ирек, үпкәләмә,— ди.

Хәбибә түти дә зиһене ягыннан иреннән аз гына да өстен түгел.

— Агачны чыбык чакта бөгәргә кирәк аны, чыбык чакта. Агач булгач, шартлый да сына элекке чыбык. Без дә шулай, яшь чакта уку насыйп булмады, хәзер соң инде. Син, Ирек үскәнем, азапланма безнең белән,— дип үзләренең булдыксызлыкларына мине инандырырга тырыша.

Аюны да биергә өйрәтәләр. Аларның сәләтләре аюныкыннан да түбәндер димим мин.

Ярулла абзый хәрефләрне үзенчә истә калдырырга тырыша. А хәрефе аның өчен аркылысына такта кадакланган терәүле телефон баганасы, О — боҗра, Т — түбәле киртә казыгы, Q — койрыклы боҗра, С — яңа туган ай, L (эл) — кисәү таягы һәм башкалар.

— Аркылысына такта кадакланган терәүле телефон баганасына охшаган хәрефнең исеме ничек әле, Ярулла абзый?

Абзам иңнәрен сикертеп куя да, хәйләкәр елмаеп:

— Үзең беләсең ич аны, нигә миннән сорыйсың, Ирек? — ди.

Хәбибә түтинең җавабы:

— Алла белсен...

— Алла аны күптән белә булыр, мин сезнең белүегезне телим, Хәбибә түти.

Юк, белмиләр. Әмма белмиләр дип минем аларга кул селтәргә хакым юк. Беренче кыенлык алдында ук җебеп төшсәм, нинди пионер булам мин?! Безнең мәктәп коридорында, «Революцион уяулык — хәзер большевикларга бигрәк тә кирәк сыйфат», лозунгысы өстендә «Большевиклар ала алмаган крепостьлар юк», дигәне эленгән. Аларның икесенең дә асларына И. В. Сталин имзасы куелган. Пионер да кечкенә большевик бит. Шулай булгач, мин үз өстемә алган бурычны үтәргә — Ярулла абзый белән Хәбибә түтине укырга-язарга өйрәтергә тиешмен. Большевиклар ала алмаган ныгытмалар юк, димәк, өйрәтәчәкмен. Бер ел, ике ел чиләнермен, максатыма барыбер ирешермен.

Шәкертләремне укырга-язарга тизрәк өйрәтер өчен һәр хәрефкә кич багышларга карар бирдем. Беренчесе — «А» хәрефе. Ярулла абзыйдан да, Хәбибә түтидән дә А хәрефенә башланган унбишәр сүз таптырам.

«Б» хәрефен бүредән башларга мөмкин. Ярулла абзыйның кушаматы бүре бит, ул аны хәтерендә калдыра да калдыра. Бүрек, бөре, бәрәңге, бәлеш...

Җитмәсә, сунарчы агайга яңалиф ошамый. Гарәп алфавиты, аныңча, мең өлеш җиңел булган. Үзе исә яңалифне танымаган шикелле, га-

рәп хәрефләрен дә укый белми. Яңалифнең авырлыгы турындагы фикерне ул кемнәндер ишеткән булырга тиеш. әлефне таяктан аера алмаган кешегә башкача ул кайдан килсен?.. Хәбибә түти иренең һәр сүзен җөпләп тора. Аны Ярулла абзыйның кайтавазы дисәң, һич тә арттыру булмас.

Бәлки миңа аларны аерым-аерым укытып карарга кирәкдыр? Бәлки болай бер-берләренә комачаулыйлардыр алар? Сынап карарга кирәк.

Дәрестән кайтып ашап-эчкәч, көндәгечә Ярулла абзыйларга кердем. Хуҗа үзе өйдә юк. Хәбибә түти генә өйдә икән. Алдан сөйләшенеп куйсаң да, болай килеп чыкмас иде. Өстемне чишенгәч, сәке читенә утырып эшкә керештем.

— Хәбибә түти, ягез, кабатлагыз әле, «А» хәрефенә башланган нинди сүзләр беләсез? Сез әйтегез, мин саный барам.

— Санап тормыйк аларны, Ирек үскәнем, бушка вакыт әрәм итү генә булыр ул. Син миңа кулыңдагы гәҗитеңне бир дә, аннан нәрсәне укырга икәнен күрсәт. Көн саен бер үк нәрсә белән баш томалаудан туйдым мин.

— Әй, Хәбибә түти, сез газетаны түгел, менә бу укый-яза белмәүчеләр өчен чыгарылган дәреслектәге аерым сүзләрне дә кушып укый алмыйсыз ич әле. Әйдә әйтегез, «А» хәрефеннән башланган нинди сүзләр беләсез?

— Син миңа гәҗитеңне биреп нәрсәләрне укырга икәнен күрсәт башта, аннары сүзләр таптырырсың.

— Мәгез, эре хәрефләр белән язылган сүзләрне укып карагыз алайса.

Тутам газетаны сәкегә җәеп, андагы мәкаләләрнең башларын берәм-берәм укый башлады.

— Минзәләдә чәчүлек орлыклар чистартыла... Тракторчыларның йөкләмәләре... Кырга тирес чыгару дәвам итә... Норманы арттырып үтиләр... Стахановчыларны оныттылар... Ютазы районында ашыкмыйлар...

Төшемме, өнемме бу? Хәбибә түти аз гына да төртелеп тормый шартлатып укый бит. Кичә генә хәреф танымый иде, бер төн эчендә, әйтерсең, алмаштырып куйганнар аны. Гаҗәпләнүдән урынымнан сикереп тордым.

— Хәбибә түти, вак хәрефләр белән язылган менә бу мәкаләне укып күрсәтегез әле.

— Беренче май районының Кара Чишмә авылында зурларны укытуда йөреш түбән. Йөз егерме дүрт укый-яза белмәүченең кырык дүрте ирләр. Алар берсе дә укырга йөрми... Йә, нәрсә әйтерсең, үскәнем, «А» хәрефенә сүзләр табыйммы инде хәзер?

— Кирәкми, Хәбибә түти. Әйтегез әле, сез кайчан укырга өйрәндегез?

— Күптән инде, үскәнем, моннан дүрт ел элек үк.

— Яза да беләсезме?

— Яза да беләм.

— Нигә моңарчы укый-яза белүегезне миңа әйтмәдегез соң сез? Ярулла абзый да сезнең кебек үк укый да, яза да беләме?

— Юк, ул белми. Аңа күңелсез булмасын өчен, мин дә башымны наданга салырга мәҗбүрмен. Ул балаларыбыз юклыкка үтә борлыга. Шуның өстенә, наданлыгын да күрсәтеп, түбәнсетәсем килми аны. Ул мине үзе кебек үк укый-яза белми дип йөри. Ирек үскәнем, минем хәрефләр тануым турында берәүгә дә әйтмик, сер итеп саклыйк. Бигрәк тә Ярулла абзаң белмәсен, белсә, кәефе кырылыр, борчылыр, уңайсызланыр. Әйбәт, сабый күк әчкерсез, беркатлы кеше ул, аны һич кенә дә борлыктырасым килми. Син, минем укый-яза белүемә карап, безгә кереп йөрүеңне ташлама. Ярулла абзаңны хәреф танырга икәүләп ничек тә өйрәтербез. Өйрәнер, зиһенсез бәндә түгел ул. Моннан түбән син без-

гә көн дә гәҗит алып кереп, онытып чыга торган бул. Аллаһы теләсә, Ярулла абзаңны гыйлемле итәрбез без, итми калмабыз...

Менә аңла өлкәннәрне! Хәбибә түти көздән бирле, иремнеке күк хатерем минем дә тишек, дип миемне черетте бит, ә үзе әнә ничек укый. Аның инде грамоталы булуын белсәм, бөтен игътибарымны Ярулла абзыйга юнәлткән булыр идем. Хәзер дә әле соң түгел түгелен, тик күпме вакыт җилгә киткән, күпме көннәр зая үткән... Карап карыйк, моннан соң Хәбибә түти мин Ярулла абзый белән шөгыльләнгәндә үзен ничек тотар икән? Әгәр элеккечә үк, бу нинди аваз, дип сораганда, алла белсен, дип утырса, ире алдында фаш итәм мин аны...

3

Бәеш авылының уртасында урамның ике ягын тоташтырган бер корылма бар. Аны төрле кеше төрлечә атый. Берәүләр өчен ул Октябрь капкасы, икенчеләргә Рәхи корылмасы, өченчеләргә Тәмуг капкасы, дүртенчеләргә Сталин капкасы. Бу корылма бәйрәмнәрдә бик матурлап ылыслы агач ботаклары, төрле чәчәкләр, кызыл комачка язылган лозунглар белән бизәлә. Аны утызынчы еллар башында, авыл комсомоллары төзегән. Ул үзенә генә хас җыйнаклыгы, гадилеге, авылның гомуми күренешенә ятышып торуы белән кемне дә ерактан ук җәлеп итә. Авыл халкы арасында аның төрлечә аталуының берниндидә сере юк. Октябрь капкасы диелүе уң канатына зур хәрефләр белән ОКТЯБРЬ, сул канатына КАПКАСЫ сүзләре язылуга кайтып кала. Рәхи корылмасы диелүе Бәештә колхоз төзүне башлап йөргән, аннары шуның беренче председателе булган кешенең капкага нигез салуыннан килә. Тәмуг капкасы исемен аңа кулаклар кушкан. Якуп мәзин, динчеләр, кулак иярченнәре Чепи Гайнетдин, Җырык Хәсән, Бөкре Хуҗиәхмәт, Күпербашы Сәләхиләр өчен тәмуг капкасы ул. Алар аның аша йөрмиләр, әйләнечтән юл туры, гөнаһтан читтәрәк булу хәерле, дип капканы ындырлар артына чыгып, әллә кайлардан уратып узалар. Аларча, аңа мөртәт комсомол Рәхи нигез салган булгач, баганалары бисмиллалап утыртылмагач, бу капка аша чыгу теге дөньядагы җәһәннәмтән колак кагу санала, күрәсең.

Октябрь капкасы очлары киереп ачылган зур кайчыларны хәтерләткән, сөзәк түбәләр белән бер-берләренә тоташтырылган өч өлештән тора. Урта өлеше киң, биек, читләрендәге ике канаты тар, икесеннән дә атлы арбалар гына үтәрлек.

Капканың уң канаты түбәсе астында пыялалы рамда Ленин портреты, сул канатта шундый ук рамда Сталин портреты урнаштырылган. Ленин портреты астындагы тар гына өрлеккә ОКТЯБРЬ, Сталин портреты астындагысына КАПКАСЫ сүзләре кадакланган. Шуңа күрә Сталин портреты һәм аның астындагы сүз кайберәүләр өчен капка исеме булып тоела.

Былтырга кадәр Ленин портреты астында ҮКТӘБЕР дип язылган иде. Бу сүздәге хаталарны Бәештә колхоз төзүдә катнашкан комсомоллар, ул Рәхи тарафыннан язылган сүз, аны ничек бар шулай саклыйбыз, дип төзәттермәгәннәр. Узган ел райком секретаре Җәгъфәров абый бер килүендә:

— Наданлыгыгызны авылыгызга килгән һәр кешегә фаш итмәгез, зинһар, бу сүзне мөмкин кадәр тизрәк төзәтеп куегыз,— дигән.

Шуннан соң икенче көнне үк әлеге сүз ОКТЯБРЬгә алмашты, иске язуның кирәксез хәрефләрен председательнең дуслары истәлеккә алдылар.

Капканың дүрт баганасының дүртесенә дә калайдан кисеп кызылга буялган бер үк зурлыктагы йолдызлар кадакланган. Уртадагы биек кайчы түбә өстендә кеше биеклек шома колгага зур урак-чүкеч сурәте беркетелгән. Әйткәнемчә, капка искиткеч матур, ул үзенә нигез салган

кешенең нечкә зәвыклы, тормышка гашыйк кеше булганын бераудән дә яшерми...

Комсомол Рәхине 1932 елның җәендә кулаклар үтерганнәр. Авылдашлары аны, уйлаганын эшкә ашырмыйча тынычланмый торган чая егет иде ул, дип сагынып искә алалар. Аңа багышлап бәет тә чыгарылган булган. Ул бәеттә авылда һәр яңалыкның башында торган эшлекле кешене искәрмәстән югалтуның ачы хәсрәте дә, аның өчен түгелгән кайнар күз яшьләре дә, үтерүчеләргә чиксез нәфрәт тә, мәрхүм башлаган эшнең үлемсезлегенә тирән ышаныч та, аның авылдашлары күңелендә тере булып керсез килеш яшәячәге дә тасвирлана.

Быел кыш бик көчле давыл Октябрь капкасының урта өлешендәге кайчы түбәсен каерып атты. Ул инде күптән кыйшайган, аз гына җилдә дә як-якка атынып утыра иде. Түбәнең сыек юка такталарын үз вакытында калын, нык такталарга алыштырырга бераүнең дә башына килмәгән, күрәсең. Бәлки, җимерелеп төшсен, җимерелгәч төзәтербез, дигәннәрдер. Хәзер җимерелгән кайчы түбәне нык материалдан Май бәйрәменә эшләп өлгертергә җыеналар. Шунысы куанычлы, аны бизәүгә без дә кулыбыздан килгәнчә катнашачакбыз. Хезмәт дәресләрендә укытучыбыз Кәшиф абый булышлыгы белән без яңа капка түбәсенә беркетеләсе «КЕМ ЭШЛӘМИ, ШУЛ АШАМЫЙ» дигән лозунгының яртышар метр биеклегендәге аерым хәрефләрен ясыйбыз. Мин Ş хәрефен ясыйм. Кем уйлап чыгаргандыр ул елан шикелле бөгәрләнгән сәер хәрефне. Инде өч дәрестә этләндем, әмма теләгәнемчә эшли алмадым. Йә өске өлеше алга кукрая, йә асты артка бүлтәеп чыга. Аңа чучканыкы шикелле килбәтсез койрык та асканнар җитмәсә.

Кәшиф абый, безнең эшне җиңеләйтер өчен, лозунгны «ЭШЛӘМӘГӘН — АШАМЫЙ» дип кенә яздыртмакчы иде, әмма колхозның председателе һәм авылның башлангыч партоешма секретаре Зиннәт абый аның төзәтмәсен хупламады.

— «Кем эшләми, шул ашамый» сүзләрен кем әйткәнен беләсеңме син, Кәшиф?— диде ул укытучыга, безнең якка сагаюлы караш ташлап.

— Беләм.

— Белсәң, ничек әйтелгән, шулай эшләт, дускай, синең аркада райкомнан шелтә аласым килми.

Төптән уйлаганда, «эшләмәгән — ашамый» белән «кем эшләми, шул ашамый» тәгъбирләре арасында бер аерма да юк бит югыйсә, тегеләй дә, болай да бер үк мәгънә, ә ярамый. Кәшиф абыйча түгел, әйтелгәнчә кирәк.

Без хезмәт дәресләрендә хәзер кул кушырып утырмыйбыз, һәммәбез дә эш белән мәшгуль, барыбызның да ясыйсы үз хәрефе бар. Бер безнең класс кына ясамый хәрефләрне, бишенчеләр дә, җиденчеләр дә ясый. Соңыннан лозунгны кайчы түбәгә кадаклаганда хәрефләрнең иң ыспай ясалганнарын сайлап алачаклар. Шуңа күрә мин, эшем бушка китмәсен, дип үземә бирелгән хәрефне ясауга бөтен сәләтемне җигәргә тырышам. Без әллә никадәр такта әрәм иттек инде. Кәшиф абыйның аңарда гаме юк. «Эшләгән эшегез гамәлгә яраса, такталар жәл түгел, әйебит» — ди.

## Өченче бүлек

### 1

Тышта яз. Кышның томанлы ачы суыкларында, күз ачкысыз буранnарында өзелеп сагынылган җылы яз.

Чалт аяз күктә бар табигатьне, бөтен тереклек ияләрен назлап юмарт кояш көлә. Әчкелтем исле коңгырт бөреләре тулып бүрткән, бу-

ген-иртәгә яфрак ярасы тупылларда каргалар мәйханәсе. Мәктәп түбәсендә күгәрченнәр гөрләшә, чәүкәләр чәрелди, якын-тирәдәге ишегалларында сузып-сузып әтәчләр кычкыра, дөнья кубарып тавыклар кыткылдый, казлар каңгылдаша. Урамда бала-чага чыр-чуы.

Мин дәрестә утырам. Күзләрем — тәрәзәдә, күңелем — әллә кайларда. Кипкән балык шикелле какча тәнле Һаҗәр апаның чәрелдек нечкә тавыш белән бәйлекләр турында сөйләве бер колагымнан кереп, икенчесеннән чыга тора. Җанлы итеп, кешечә сөйләсә, аны тыңлар да идең, кулындагы таушалып беткән дәфтәренә карап чәрелди. Күңелсез, класста утырасым килми.

Һаҗәр апа мине:

— Кадыйров, туры утыр, тәрәзәдән карга санама, тактага кара,— дип ике тапкыр кисәтте инде.

Алалы-колалы тактага язылган танылыр-танылмас сүзләргә карадың ни дә, карамадың ни. Тышта яз тантана иткәндә, бар табигать кышкы йокыдан уянып җанланган чакта кемгә хаҗәте бар ул бәйлекләрнең?

Мена яңадан:

— Кадыйров, сиңа ничә әйтергә мөмкин?— дигән әче тавышка мин сискәнеп киттем.

Тәки сагыз булды! Аңа чәрелдәргә комачауласам бер хәл иде, тыптын утырам югыйсә, ничә әйтергә мөмкин, ди. Кабатларга читенсенгәч әйтмә соң, бик кирәк миңа бәйлекләрең, бер дә харап...

— Димәк, җөмләнең ияргүче кисәкләрен ияртүче кисәкләргә, шулай ук иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла торган сүз бәйлек дип аталды. Мин сезгә тактадагы «Үзе усал, үзе болай бер дә усал түгел кебек шикелле» җөмләсендә «кебек» һәм «шикелле» сүзләренең бәйлекләр ролен үтәүләрен әйттем...

Шулчак класста Камчатка дип йөртелгән иң арттагы партадан Гайфинең:

— Апа, син үзең бәйлекләрнең мөстәкыйль мәгънәләре юк, дип укыдың. Такташ абыйның мисалга алган бу җөмләсендә аларның мәгънәләре бар ич,— дигән сүзләре ишетелде.

Барыбыз да Камчаткага борылдык. Гайфи, җирән чәчле зур башын бераз сул якка кырын салып, укытучыга текәлгән иде.

— Акыл сатма, Бәдретдинов, тик утыр. «кебек, шикелле» сүзләрнең бәйлекләрме, түгелме икәннәрен мин беләм. Башың яшь әле синең мине буташтырырга, борын астың юеш!— Һаҗәр апа бу сүзләрне ачулы ысылдады.— Ә сез, балалар, алдыгызга карагыз!..

— Такташ абый барыбер бәйлекләр итеп кулланмаган аларны бу җөмләдә!

Укытучының ябык чыраена тимгелләр бәреп чыкты, болай да киеренке борын яфраклары тагын да киерелә төште, ачулы күзләре кысылды. Ул, журналны ачып, кулына ручка алды.

— Кулланмаганмы? Шуның өчен зур итеп «кытый» куям мин сиңа, Бәдретдинов!

— Берне генә түгел, бишне куй, апа. Тик тактадагы җөмләдә гүпче син әйткәнчә түгел...

Гайфи сүзен бирәме? Үлсә дә бирми, хаклымы ул, хаксызмы — барыбер үзенекен тукый. Укытучы журналдан башын күтәрде. Ул, Гайфигә ашардай булып карап, янап:

— Бәдретдинов үскәнем, дәрестән соң класста калырга онытма. Ялгызыңа гына аңлатырмын мин сиңа бәйлекләрне, ишетсен колагың,— диде.

— Үскәнем дип юхаланма, апа, калмыйм. Кыш көне калдырып линейка белән кыйнаганың да онытылмый әле...

Болай да җене чыккан укытучыны бу сүзләр чыгырыннан чыгарды. Ул кулындагы ручканы өстәлгә бәреп, җил-җил килеп, Камчаткага

юнәлде. Гайфигә хәзер өлгәсен уйлап бөтен класс сагайды. Әмма Жирән ярсыган укытучының үз янына килеп җиткәнен көтеп тормады, язылган пружина сыман урыныннан ялт күтәрелде дә парталар өсләп ишеккә йөгерде.

Укытучы аның артыннан:

— Син миннән кача алмассың, Бәдретдинов, өлгерсең барыбер! — дип кычкырып калды. Аннары ул өстәле янына кайтып калтыранган кулларына яңадан дәфтәрен алды.

— Бәйлекләр үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле бер килештә торуын таләп итәләр, дидек...

Яз көне дә укырга мәҗбүр иткән кешеләрнең үзләрен утыртасы иде хәзер безнең ярым караңгы, кысан, тынчу класста. Бер сәгатькә түзсәләр түзәрләр, аннары кайда да булса шылырлар иде ул акыллы башлар. Мәктәбебез элекке мәчет бинасында безнең. Хәтта өстендә манарасы да киселмәгән, шул килеш. Бөтен әйләнәсендә каргалар патшалыгы. Тышта, тупылларда, бер-берләреннән уздырып, алар каркылдый, монда Һаҗәр апа чәрелди. Жирән дәрестән чыгып китеп шәп итте. Әзрәк тоткарланса, нык эләгә иде аңа. Һаҗәр апа чалтыратып чабып җибәрергә дә, кулына ни эләксә, шуның белән орырга да күп сорамас. Күпләргә эләкте инде аңардан. Ничек кенә ачуын чыгарсам да, миңа моңарчы кагылганы юк әле. Әти мәктәп директоры бит, аннан шөлли булыр. Әти исә Һаҗәр апаның усаллыгын әллә белми, әллә белмәмешкә салыша, аңламассың. Класста һәм мәктәптә булган хәлләрне минем өйдә сөйләгәнем юк. Сөйләсәм, әләкләү була бит ул.

Әти мәктәп директоры булмаса, төкерер идем мин хәзер дәресләргә. Өйдән иртүк чыгып китәр идем дә кичкә кадәр йөрер идем язгы матурлыкка хозурланып. Әнә Кәрим дәрестә утырудан туйса, тәнәфес вакытында букчасын тәрәзәдән ата да мәктәптән мыштым гына тая. Рәхәт аның эше, инде атнага якын мәктәпкә эз дә басканы юк, этисе белән бергә кырда сабан сөрүдә ди.

Ул:

— Безнең әти, мин гомерем буена әлифне таяк дип белмәдем, аңа карап маңгаема мөгез чыкмады, мәктәптә дин сабагы укытсалар, дәресләреңне бер көн дә калдыртмас идем, анда: «карга әйтә: кар-кар, чәүкә әйтә: чәр-чәр»ләрне генә укыткач, сабакка йөрүеңне үз иркеңә куям, ди,— дип көлә.

Шундый булса икән этиең! Мәктәпкә Һаҗәр апаның чәрелдек тавышын ишетмәс өчен генә дә аяк басмаслык бит.

Әни көн саен миңа:

— Улым, син барлык укучыларга үрнәк булырга тиеш,— дип тукып тора.

Минем аркада этинең йөзенә кызыллык килмәсен дию бу аның.

Башта, Баешкә килгәч тә, күрдем мин күрмәгәнемне! Малайлар мине кайда очратсалар да тотып тукмыйлар иде. Аларга көн бетте, эти минем аша бөтен нәрсәне — кемнең нишләвен белеп торачак, имеш. Тик авызым-борыным җимерелгәндә дә, күз төпләрем алабута күмәче төсенә кереп күгәргән чакта да өйдә, мине малайлар кыерсыталар, дип шыңшыганым булмады. Шактый вакыттан соң гына Баеш малайлары мине үз итә башладылар.

Партадашым Миләүшә янтыгыма җиңелчә генә төрткәч, аңа борылдым. Ул миңа бер кәгазь кисәге тоттырды. Анда: «Ирек, без Гайфи белән дәресләр беткәч Чүлмәк тауга барырга сөйләштек. Син дә барасыңмы? Сөләй»,— дип язылган иде.

Барам, әлбәттә. Артыма борылып Сөләйгә баш кактым.

Чүлмәк тау — Баештә иң матур җир. Язын-җәен яшьләр-кызлар кичләрен анда уенга җыйналалар. Кичкә кадәр Чүлмәк тау безнең карамакта. Без аның өстенә яссы вак ташлардан мич өеп учак ягабыз,

итәгендә шар сугабыз, кыекбаш сикертәбез, папанинчылар яки испанлылар булып уйныйбыз. Испаниядә сугыш бара бит. Без — республикачылар. Чүлмәк тауга үзебез ташып өйгән ташлар — фашистлар. «Но пасаран!»— дип кычкыра-кычкыра тетмәләрен тетәбез ул ташларның. Уеныбызда һәрвакыт республикачылар җиңә. Бу безнең барыбызны да канәгатьләндерә. Фашист фашист бит инде ул. Әнә «Штурмовик язмалары» дигән китапта аларның Германиядә ничек хөкүмәт башына килүләре язылган. Укыганда аркадан салкын тараканнар өзлексез чабышып узалар кебек. Үтерү, кыйнау, яндыру, мәсхәрәләү, интектерү — алар эше. Шуңа күрә бер генә малайның да безнең уенда фашист буласы килми.

Картлар Чүлмәк тауны, ул Алып батырдан калган, диләр. Борын заманда Алып батыр авыл читендәге Каршы тауга утырып чабаталарына җыелган туфракны каккан, шуннан тип-тигез җирдә шушы түптүгәрәк тау өелеп калган, имеш.

Чүлмәк тау биек тә, зур да түгел. Ул тарих китапларындагы борынгы курган рәсемнәренә охшаган үзенә бер төр калкулык. Аны тәүге кат күрүчене иң элек формасы җәлеп итә. Ерактан ул иләмсез зур бәлешне хәтерләтә. Әйләнә-тирәсе шәрә түгел. Бер ягында Каршы тауның иң биек һәм текә урыны Кызылъяр калкып тора, икенче ягында өстәл өсте кебек тигез кыр җәелеп ята. Кызылъяр белән Чүлмәк тау арасыннан ярыйсы ук мул сулы Чуал ага. Чуал буендагы тал куаклары күләгәсендә стеналарының кызыл балчыгы ут кызуында эреп пыялаланган известь яндыру базлары...

Уйларым чүлмәк тауда йөри, дәрестә гамем юк. Күз алдымда кояшка карап чекерәешеп утырган сап-сары тузганак чәчәкләре арасында яссы вак ташлардан өелгән кечкенә мич эчендә дөрләп янган учак гәүдәләнә. Мичнең утта кызган ташлары мылтык аткандагы шикелле ара-тирә колакны ярып шарт-шорт киләләр. Тау буенда сарыклар утлап йөри. Зәңгәр биеклектә очынып-очынып тургай сайрый. Басу ягыннан трактор гөрелтесе ишетелә. Чү, нигә соң ул чаң тавышына охшаган әле?..

— Чаң-чоң! Чаң-чоң!.. Чаң-чоң!..

Чыннан да, бу чаң тавышы ич! Аны шулай ашыгып нигә кызу-кызу кагалар, ни булды икән?

Бөтен классыбыз белән урыннарыбыздан кубып тәрәзәгә ябырылдык. Һаҗәр апа да кинәт ишетелә башлаган бу хәвефле тавышка аптырады бугай, безне тәртипкә чакырмады. Мәктәп тирәсендәге тупыллар өстендә кара болыт булып, бик яман каркылдашып, каргалар әйләнә башлады, кайдадыр эт уларга тотынды.

Урамнан:

— Пужар! Пужар!... — дип сөрән салган хатын-кыз авазы ишетелде.

— Мәктәпкә ут капкан!— диде кемдер, коты алынып.

Бер-беребезне этешә-төртешә ишеккә ташландык. Ашыкканда тиз генә үтеп буламы аннан, араннан кабаланып дәррәү чыгарга ташланган сарыклар шикелле, ишектә бөялештек. Елау, сыктау, кычкырыш китте, тоташ тыгыз төркем булып кечкә коридорга үттек. Андагы ярым караңгыда мин кемнәргәдер бәрелә-сугыла атылып тышка чыктым. Мәктәпкә берни булмаган, аңа ут капмаган иде. Кешеләр урам буйлап кайсы чиләк, кайсы көрәк, кайсы балта, кайсы багор тотып, түбән очка таба йөгерәләр. Әнә салам түбәле өйләр, карсак каралтылар, бөреләре бүртеп килгән шәрә агачлар артында күккә бөселеп-бөселеп кара төтен күтәрелгәне күренә. Бер төркем малай шул якка элдергәч, дәрестән таярга сәбәп чыгуга шатланып, мин дә аларга иярдем. Алда кызык булачак иде ич. Янгынның зур каза, коточкыч афәт икәнен уйламадым да.

Авылны икегә бүлеп аккан инеш өстенә салынган тар гына күпер төбендә акырып елаган имчәк баласын күкрәгенә кыскан бер хатын:

— Ярабби, кемнәр генә яна икән, кемнәр?..— дип үрсәләнде.

Иңенә озын баскыч күтәргән бер агай йөгергән шапкә аңа:

— Кайнар Гыйльмуллалар бугай,— дип узды.

— Балалары ишле ие, чыга алмаганнардыр, янып харап булгандыр инде мескенкәйләрем...

Кәримнәр яна, димәк. Кәримнең сеңелләре, чыннан да, янып харап булдылар микәнни?

Күз алдыма ут эчендә калган нәни кызчыклар килде. Әнә алар кулларын алга сузып, инәлеп ярдәм сорыйлар, өсләрендәге күлмәкләрен, тузгыган чәчләрен ялкын чорнаган... Күңелемне курку алды, сулышым кысыла, тыным җитми башлады, аякларым атламас булды. Янгын тирәсенә ашыгучы кешеләр мине берәм-берәм узып киттеләр.

Мин барып җиткәндә Кәримнәрнең бөтен каралты-куралары ут эчендә иде. Өйләре исән, аңа ут үрләмәгән иде әле. Халык җан-фәрман килеп янгын сүндерә. Өсләрендә исәпсез-хисапсыз очкыннарга уралып кара төтен биегән галәмәт хәтәр ялкын телләренә берәүләр су сибә, берәүләр көрәк белән туфрак ата. Унлап ир озын багорлар белән ут эчендәге мунчаны җимерәләр. Ялкын чорнаган каралтыларга якын барырлык түгел, эсседән тән куырыла, сулыш каплана. Тавыш, шаушу, утка сибелгән су чыжлавы, котырынган янгын гүелтесе барсы бергә буталып, сине чынбарлыкта түгел, ниндидер хыялый мөхиттә итеп сиземләтә. Бөтен кеше каударлана, ашыга, кабалана. Бердәнбер насос, ут үрләмәсен өчен, Кәримнәрнең өй түбәләрен, алар күршесендәге исән каралтыларны юешли. Кәримнең әнисе Мәһитап апа урамга ташылган кием-салымнары, йорт җиһазлары янында янгыннан куркып елашкан кызчыкларын юатып тора.Кызчыкларының бишесе дә аның янында. Аларны күргәч, күпер төбендә очраган апа юкка борчылган, Кәримнең сеңелләре бар да исәннәр, дип шатландым мин.

Көн тыныч, салам селкенерлек тә җил юк. Ләкин янгын барыбер котырыпмы котыра. Монда җыйналган кешеләр берсе дә янгынның үзеннән-үзе сүнгәнен кул кушырып көтмиләр, ничек булдыра алалар, аны шулай авызлыкларга, басарга тырышалар. Мин дә башта аяк астымнан такта кисәге күтәреп, аның белән утка туфрак аттым, багорлар белән ялкын эченнән тартып чыгарып кемнәрдер сүндергән кисәүләрне уттан ераккарак ташыштым. Маңгаемнан күзләремне ачыттырып тир акты, төтенгә карлыгып өзлексез ютәлләдем.

Бервакыт колак төбемдә әнинең:

— Бу кадәр этиең сыңары булырсың икән, тыкшынмаган җирең юк. Кайчан килеп өлгердең әле монда, әллә сабагыңа да бармадыңмы?— дип сукрануы ишетелде.

— Бардым, әни. Чаң сугып, урамда «пожар, пожар», дип кычкыра башлагач, чыгып йөгердек без мәктәптән.

— Янгынны синнән башка да сүндерерләр, улым. Бар кайт хәзер үк өйгә, яхшылап юын, карарлыгың калмаган.

Күр инде, монда берәүгә беркем сүз әйтми, ә мине әни куа. Нинди кеше ул? Аңа минем монда булуым да, моннан китүем дә барыбер түгелме икәнни?

— Син кайтасыңмы соң?

— Миндә эшең булмасын, син кайт! Ишеттеңме әйткәнне?

Ишетмәгән кая! Ләкин син әйтә дип китмим мин моннан. Хәзер менә ындыр ягына керәм дә, күрмисең син мине аннары...

Әни сүзенә буйсынган булып үзебезнең якка таба бераз атлагач, артыма борылып карадым. Әни калган урынында күренмәде, каядыр киткән иде инде.

Шулчак урамнан бер төркем җайдаклар чабып килгәне күренде. Авылдагы янгынны күреп, кырдан кайтучы сабанчылар иде алар. Янгын сүндерергә ашыгып, атларының мичәү баулы камытларын да салдырмаганнар. Гыйльмулла абзый иң алдан чаба, Кәрим — аның артын-

да Барысы егермелəп кеше. Атлары ак күбеккə баткан, гыжлап сулыйлар.

Гыйльмулла абзый йорты турына җитəрəк:

— Утны кем салган, белүче бармы? Хəзер шəһит җибəрəм мин ул мəртəтне, кем ул?!.— дип кычкырды.

Сөлəйнең этисе Лотфулла абзый янгын сүндерүчелəр арасыннан килеп чыгып аның башына бер чилəк су койгач кына, ул, йолкынудан туктап, лап итеп җиргə утырды да, күкрəктəй куллары белəн йөзен каплап, тавышсыз гына үкси башлады.

— Кайгырма, кордаш, өең исəн, шөкер. Янган каралтыларыңны бөтен колхоз бер булып печəнгə төшкəнче төзеп бирербез, ходай кушса. Син аерым хуҗалык түгел, колхозчы бит. Сиңа килгəн каза — бөтен колхозга килгəн каза, белəсең килсə,— дип юатты аны Лотфулла абзый.

Шунда хəтеремдə икенчеме, өченчеме класста укыганда дəрестə үтелгəн кечкенə генə бер гыйбрəтле хикəя яңарды. Күзгə төртсəң күренмəслек күзге караңгы төн. Бер агай колхозның икмəк амбарлары янында каравылда тора. Таң алдыннан авылда: «Янгын, янгын!» — дип кычкыра башлыйлар. Каравалчы агай тавыш килгəн якка карый, аның өе яна. Лəкин ул саклаган амбарларын ташлап өенə капкан утны сүндерергə чапмый, урынында кала. Кулаклар ул амбарлар янынан китсен өчен аның өенə утны юри төрткəн булалар. Алар, каравылчы киткəч, колхоз икмəген көл итəргə ниятлилəр, əмма телəклəренə ирешə алмыйлар. Каравылчыга колхоз җəмəгать милкен үз милкеннəн өстен күргəне өчен шыңгырдап торган өр-яңа өй салып бирə. Лотфулла абзый дөрес əйтə, колхозчылар ташламыйлар бəлагə тарыган иптəшлəрен. Алар бер гаилə кешелəре.

Артымда бер агайның:

— Ялкыны, сабый «өф» итсə, сүнə торган салам очы кадəр генə бер шырпы нинди көчкə ия, хəерсез! Ваемсыз сызылган шундый шырпыдан үрлəгəн гарасат бит менə бу,— дип сөйлəнүе уйларымны бүлде. Шул мəлдə үк əнинең миңа таба килгəнен күреп, тагын битəрлəү ишетмəс өчен, тизрəк өйгə чаптым. Мин киткəндə янгын инде көчсезлəнə, ялкын теллəре отыры юашлана бара иде.

2

Əни дөрес əйткəн, чыннан да карарлыгым калмаган икəн минем. Өйгə кайтып көзгегə баккач, үземне танымадым. Бөтен битем корым, чəчлəрем көйгəн, күзлəрем кызарган, бары тешлəрем генə элеккечə ялтырый. Кулларым морҗа чистарткан кешенеке шикелле, карарлык түгел, кап-кара. Янгын тирəсендə озак та юанмаган идем кебек, ə корымга өйкəлемпе өйкəлгəнмен. Əни кайтканчы чистарынырга кирəк, юкса Сафура бураннары очырыр.

Коедан су алып тагаракка салгач, билемə кадəр чишенеп, əти кебек пошкыра-пошкыра юына башладым. Əти кышның кыш буе иртəлəрен нинди генə салкыннарда да биленə кадəр чишенеп кар белəн юына. Өйгə кергəндə тəне бурлат күк кызарган була, беркайчан да туңдым дигəне юк. Мин менə кое суы белəн генə юынам, кыш та түгел, җылы, əмма чыдар əмəлем калмады инде, кулларым, битем, тəнем күшекте, калтыным, кыскасы. Ə янгын тирəсендəге эсседə бу судан тəнгə рəхəт кенə булыр иде. Теге агайның шырпы турындагы сүзлəре тəки хак бит. Башы күкертле нəзек кенə чыра кыйпылчыгы бөтен авылны борчуга салып, дəррəү аякка бастырды, аюдай таза Гыйльмулла абзыйны чүт кенə акылыннан шаштырмады, мине менə корымга батырды. Бер мине генə микəн əле?

— Портфилеңне мин мəктəптəн алып кайттым, Ирек. Керəп алырсыңмы, үзем кертимме?

Миләүшә. Корымнан арына алмавыма үртәлүдән җен ачуларым чыкканда эч пошырып ул йөри.

— Хәерче хезмәтчесе булырга кем кушты сиңа? Мәктәпкә барып кайтырга юлны оныткандыр дип белдеңме әллә мине?

— Мин ни...

— Ними тор! Үзеңне бүтән минем кәләш дип үртәмәсләр дигәнсең...

Миләүшә дәшмәде. Мин тагарак өстеннән башымны күтәрдем. Күсе койрыгы шикелле нечкә генә толым очын чәнчә бармагына урап, зур коңгырт күзләрен челт-челт йомып, иреннәрен турсайтып басып тора. Үпкәләгән, чак еламый. Үпкәләсә соң! Минем тирәмнән читтәрәк йөрер. Кем чакырган аны монда, кем аңа портфельне алып кайтырга кушкан? Класста бер парта артында утырып та туйган инде мин аңардан. Үпкәләсен, безне кабат кияү белән кәләш дип мыскылламаслар хет.

Тагарактагы пычранган суны түгеп, аңа коедан яңа су алдым.

— Бир чиләгеңне, салып торыйм...

Һәй әрсез дә соң бу кызлар халкы! Күр, тупас сүзләремне бөтенләй ишетмәгән булып кылана. Укам коелмас, салсын соң.

— Мә, аз-азлап кына кой.

— Өйрәтмә, беләм.

Кара син аны хәчтерүшне, дулап тәртә сындырырга җыенган кырыкмышмыни, сыртын кабартып маташкан була, егылып үләрсең!

— Әйдә, кәләш, кой аз-азлап,— дип юынырга әзерләнеп тагарак өстенә башымны идем. Миләүшә шуны гына көткән икән, чиләктәге суны башыма каплады да:

— Кабат үртәмәссең менә!— дип, буш чиләкне җиргә утыртып капкага атылды.

Миләүшәләр — безнең күршеләр. Аның әнисе Зада апа мәктәптә җыештыручы булып эшли, әтисе Хәйрүш абзый — көтүче. Әти-әнисенә минем кебек үк бердәнбер бала Миләүшә. Кайчан керсә дә, әни тирәсендә бөтерелә. Төрле авырулар, аларны ничек дәвалау, дарулар турында сораша. Үскәч әни кебек фельдшер буласы, имеш. Көләргә кеше генә юк. Теле бар ярый, юкса карга азыгы гына булырлык. Ябык, чандыр, буе минем иңөстеннән генә. Физкультура дәресләрендә сафка тезелгәндә иң артка ул баса. Лилипутлар фельдшеры булса гына инде. Үзе болай тырыш, бер генә фәннән дә «кытый» алганы юк. Өйләрендә бөтен эшләрен эшли: идәннәрен дә юа, сыерларын да сава, мичләренә дә яга, аш та пешерә, кер дә уа. Әтисе аңа: «Кызым, син ут борчасы»,— ди. Дөрес тә, борча шул. Кеше башына кеше салкын су коямы?..

Мин юынып өйгә кергәндә әни кайткан иде инде. Өстемне алмашкач, ул миңа кечкенә генә кәгазь төргәге тоттырды.

— Менә бу даруны Һаҗәр апаңа илтеп кайт әле, улым. Зада апаң: «Янгын чыккач, Һаҗәрнең коты калмады, башым чатный, үләм»,— дип өенә көчкә өстерәлеп кайтып китте, ди. Илтеп бир, дарулар эчсә, аруланыр, хәлен бераздан барып үзем дә белермен, шулай диярсең.

Авыртмаган башка тимер таяк бит инде бу. Мәктәптә дә туйган мин аңардан, бармыйм.

— Әнә Миләүшә генә илтсен, ул синнән авыруларны да өйрәнә, үскәч фельдшер да буласы. Хәзер кереп әйтәм аңа.

— Син бар, мин сиңа кушам, улым.

Минем әни үзенекен итми каламы? Калыр көт! Сүзен сүз итмәсә минем әни булмый ул. Әйттеме — закон. Ошыймы сиңа ул әйткән, ошамыймы, үтә. Холкы тимер аның. Авыргач медпунктка килмичә үзен имче карчыклардан дәвалатучы кешене белсә, бөтен авылга даныш чыгара. Аны, заманнан, совет медицинасыннан көләсеңме, тизрәк аяк сузасың килдеме, «кеше — иң кыйммәтле капитал», ди иптәш Сталин, үз бәяңне төшерергә сиңа кем хокук бирде, дип дер селкетә.

Мин үземнекен сукаладым.

— Дәваламасаң да чурт та булмый Һаҗәр апага. Күрерсең менә...

— Үзеңнән өлкән кешегә, укытучыңа карата шундый тупас, дорфа сүзләр әйтергә ничек телең әйләнә, ничек оялмыйсың? Ярабби, кемгә охшап туң йөрәкле булып үсәсең син? Йөгер хәзер үк. Кара аны, бер аягың анда, икенчесе монда булсын, тиз йөр!

Киреләнүем файда бирмәде, киттем.

Һаҗәр апа мәктәптән ерак түгел бер өйдә ялгызы гына яши. Ул кыз кеше әле, яше егермедән аз гына артыктыр. Чыгышы Чаллы ягыннан, диләр. Алабуга педагогия техникумын бетергән. Кыш көне әнисе белән тордылар, язга чыккач әнисе китте. Күптән түгел Зада апа безгә кергәч әнигә, тыныша алмадылар аналы-кызлы. Һаҗәрнең холкы ташка үлчим бит, тегe дә тегеләй түгел, бу да болай түгел аңа, карчыкның үзәгенә үткән, җелегенә төшкән, шуңа түзмәде Мәһитап апа, авылына олы улы янына кайтып китте бичара, дип сөйләгән иде.

Мин барганда Һаҗәр апа башына сөлге урап урын өстендә ухылдап ята иде. Өе җыештырылмаган, идәне тулы чүп, өстәленә җәелгән ашъяулыгы кыйшаеп идәнгә кадәр асылынып төшкән. Аның өстендә дәфтәрләр, китаплар, төрле кәгазьләр чәчелеп ята. Шунда ук юылмаган табак-савыт, кашыклар, чынаяклар һәм инде күптән тимгелле яшел төскә кергән җиз самавыр. Тәрәзә төпләрендә, өстәлдәге дәфтәрләр, китаплар арасында төрле зурлыктагы каткан ипи кисәкләре. Ишек төбендәге эскәмиядә ничек туры килсә шулай ташланган киемнәр аунап ята.

Ишектән кереп өй эчен күзәтеп чыккач мин:

— Менә сезгә дарулар китердем, апа. Бераздан яныгызга әни үзе киләсе,— дидем.

Һаҗәр апа күзләрен усал ялтыратып урыныннан калыкты.

— Мин биргән агуны Һаҗәр җүләр эчәр, дидеме әниең? Дөмектермәкче булдымы? Юк, үлмим әле мин, яшим, бөтенесенә ачу итеп яшим. Әйт әниеңә, агуы да, килүе дә кирәкми миңа аның!..

Күзләрем шар булды. Акылындамы ул?

— Агу түгел, дару китердем мин сезгә, апа.

— Беләм мин әниеңнең даруын. Җүнле дару бирәме ул миңа? Этиең дә миннән ничек котылырга белми йөри, син дә аның сүзе белән миңа бүрегә карагандай карыйсың. Бар, чыгып кит өемнән. Берегезнең дә эзегез булмасын монда!

Әнигә, этигә карата әйткән хаксыз сүзләре йөрәгемә кадалды. Әни аңа чын күңеленнән яхшылык эшләргә тели, ә ул... күрсәтәм мин аңа хәзер!

Кулымдагы кәгазь төргәген тиз генә сүтеп, андагы ап-ак төймәләрнең берсен авызыма кабып чәйни башладым.

— Карагыз, апа, агу булса мин үләрмен. Бөтенесен ашап бетерсәм дә миңа чурт та булмый. Сезне агуларга түгел, терелтергә, хәлегезне җиңеләйтергә бирде бу даруларны әни. Менә...— Мин авызыма тагын бер төймә каптым.

Шуннан соң Һаҗәр апа урыныннан төшеп, йөгереп яныма килде дә кулымдагы төргәкне тартып алды. Аның бөтен тәне туңган кешенеке кебек калтырый иде.

— Ирек үскәнем, ышандым, кабат ашама даруыңны. Рәхмәт әйт Мәликә апага. Көйрәклегем белән әллә нәрсәләр әйтеп ташладым, гафу ит. Яхшы кеше синең әниең, этиең дә әйбәт кеше. Мә су эч тизрәк, су,— дип өтәләнде ул.

Авызымда әрем әчесе иде, мин Һаҗәр апага бер сүз дә әйтмәдем, башымны иеп ишеккә борылдым.

Ул юлыма аркылы төште.

— Этиең белән әниеңә минем сүзләремне әйтмә, зинһар. Менә кара, мин дә ашыйм әниең биргән даруны. Йә, күрдеңме?

Мин дәшмәдем.

— Укырга кызыклы китап биримме? Нинди китаплар яратасың син? Әнә теләгән китабыңны актарып ал, башка вакытта да кер, тартынма.

Минем йоткан дару ачысыннан күңелем болгана башлаган иде, кайтырга ашыктым.

— Рәхмәт, безнең үзебездә дә китаплар җитәрлек.

— Ихтыярың...

— Әни килсенме?

— Рәхмәт, кирәкми, мин савыктым инде.

— Хушыгыз алайса. Тыныч булыгыз, апа, мин сездән берни ишетмәдем.

Һаҗәр апа мине иңемнән кочып капкага кадәр озата чыкты. Аның йөзе уйчан, сагышлы иде. Кызганыч, бик кызганыч булып тоелды ул миңа. Бераз киткәч, артыма борылып, мин аңа кул болгадым...



3

Без авыл уртасында урамнан ярыйсы ук эчкә кертеп яңы белән салынган алты почмаклы өйдә торабыз. Аны Исмай бай салдырган булган. Байны, Баештә колхоз төзелгәч, бөтен семьясы белән читкә сөргәннәр. Хәзер алар Ижаудәме, Соликамскидамы, ди. Өебез тирәсендә рәшәткә койма белән әйләндереп алынган түрбакча бар. Анда канәфер, аю баланы, чия, миләш куаклары һәм өч төп алмагач үсә. Ихатада калай түбәле зур таш амбар, берничә торык лапас, ак мунча, кое. Анда тагын бүтән каралтылар да булган, аларны колхоз кирәгенә сүтеп алганнар.

Берьяк күршебездә Ярулла абзыйлар, икенчесендә — Миләүшәләр. Миләүшәнең әнисе Зада апаның безгә керми калган көне юк. Юк йомышын бар итеп, кайчан теләсә шул вакыт килә дә керә. Бүген дә керде.

— Бик тә борчылып, сиңа эчемне бушатып чыгарга кердем әле, Мәликә,— диде ул әнигә, ишекне ачып бусаганы атлау белән.— Менә бу өйнең элекке хуҗасы Исмай кулак, чит җирләрдә бик җамансы, туган җакларны бик сагындым. Каршы тауны, Кызылҗарны, Чуалны көн дә төшемдә күрәм, авылдашлар рөхсәт итсә, Баешкә кайтып, тамак хакына чучка көтәргә дә разый мин хәзер, дип әйтә икән дип. Чәкән Мәдинәсе сөйләп торды. Эчләрем жу итеп китте шуны ишеткәч, котларым алынды, Мәликә җаным. Кайтармасалар гына җарарые шуны дим.

— Бик явыз бәндә идемени соң ул Исмай бай? — диде аңа әни.— Әйдә түргә уз әле. Аяк өсте торма, утыр.

Зада апа ишек төбендә торган агач диванга калгыды.

— Җавыз гына түгел, карун җырткычые ул, Мәликә. Безнең ише җарлы-җабаганың сәламен дә алмыйдырые. Рбәлүсиядән сүң аклар җагында җөргән Хафиз исемле әфисәр улы барые аның. Алма агачыннан җырак төшми бит, шул Хафиз мур кырган сәнәкчеләр фетнәсен башлап җөрүчеләрнең берсе булган, диделәр ул чакта. Әллә никадәр гөнаһсыз адәмнәрнең каннарын койды шул имансыз мәлгунь. Минсорур исемле мөгаллимә барые авылда. Бикләр дә уңган, балаларга илгәзәк, олыларга ачык җөзлие мәрхүмә. Шуны Хафиз, сәнәкчеләр фетнәсе иң котырган чорда, син камун дип, кышкы зәмһәрир суыкта анадан тума шәрә калдырып, урамда өстенә су сибә-сибә бозга катырып үтерде. Фетнә бастырылгач, үзе аннары бер җыллап урманда качып җатты. Хатын-кыз җиләгенәдер, чикләвегенәдер бара алмады, көпә-көндез кычкыртып

талыйдырые. Ахырда барыбер тоттылар. Авылда күргәзмә сут ясап. Каршы тау буена алып чыгып аттылар аннары. Бер кызганучы булмады зобаныйны, күптән Газраил сагалыйдырые инде аны, кирәген алды, диделәр. Исмай бай, улы дөмектерелгәч, шашарга житте. Жегерме беренче жылгы ачлыкта үзе бал-май эчендә жөзде, авылда ачтан шешенеп әжәл белән тартышкан сабыйларга кызганып бер сынык икмәк бирмәде. Жәрдәм сорап килгән кешене этеннән талаттырадырые. Чуалдагы хәзерге калхуз тегермәне элек шунықые. Ачтан интеккән кешеләр анда имән чикләвеге, агач каерысы, алабута шикелле нәрсәләр тарттырырга төшкәндә: «Жөрмәгез монда сару кайнатып, сезнең шакшыгыз белән тегермән ташын пычратып хәлем жук, сыпыртыгыз моннан, ачәрвахлар»,— диядерие. Жан һич эрерлек түгел ул карунга. Күп, бик күп канны эчте. Кайтармасалар гына жарарые шуны, дип борчылып кердем сезгә, Мәликә жаным.

— Кайтса да тора алмый ул монда хәзер, Зада. Сабир әнә, тарих тәгәрмәче кирегә әйләнми, үткәннәргә юл ябык, ди.

Зада апа диваннан торды.

— Шулай гына булсын инде кана. Тормышыбыз мактап бетергесез бит хәзер. Бай да, жарлы да жук — бөтен кеше тигез. Калхуз эшләгәненә түли, берәүне дә кыерсытмый. Без Хәйрүш белән куанып бетә алмыйбыз шуңа. Калхуз чыккач, кеше рәтенә кердек.

Зада апа, Исмай байны онытып, ире Хәйрүш абзый турында сөйләргә керешә. Кайчан керсә дә, гел мактый ул аны. Хәйрүш абзый бик шәп курайчы. Ул курай тартканда дөньямны онытам мин. Төрле үләннәр, чәчәкләр, бөжәкләр, кошлар, жәнлекләр турында сөйли башласа да авызына карата. Бик яратам мин аны.

Зада апа иреннән шактый яшь, әмма аның Хәйрүш абзыйны картым дигәнен беркайчан да ишетмисең. Киресенчә, ире аны карчыгым, дип йөртә. Зада апа Хәйрүш абзый янында әле кызлар кебек. Буйга да ул Миләүшәсеннән аз гына калку. Тик бераз юанрак кына. Сөйли башласа, аны туктар димә. Авылдагы нинди генә яңалыкны да беренче ул ишетә, ул тарата.

— Минем карчык барда радиоң бер якта торсын,— дип көлә аңардан Хәйрүш абзый.

Зада апа моңа үпкәләми:

— И-и-и, Хәйрүшкәем, әйттең сүз син дә, радио жырлый, ә мин жырламыйм бит, жырламыйм,— дип аклана.

Бик тату яши алар. Миләүшәдән бүтән балалары булмаган. Миләүшә белән без дәресләребезне еш кына бергә әзерлибез. Йә мин аларга керәм, йә Миләүшә безгә керә. Күбрәк ул керә. Әнигә аның су китерткәне юк. Ишегалдыбызда кое булса да, суны ул безгә чишмәдән алып кайта.

— Чиләкләрегез бик матур сезнең, Мәликә апа. Яратам шулар белән суга барырга. Чишмә юлында бөтен кешенең күзе гел аларда була, рас менә,— дип ялагайлана ул әнигә.

Зада апа безгә кергәндә килеп кергән кебек, сүз уңаенда сөйли башлаган төшен дә сөйләп бетермичә, кабаланып чыгып китте.

— Күп сүз бозау имезә ди, дөрес. Өйдә күптән көтәләрдер бит мин күке мие эчкән биләмчене. Ул эштә, ди торганнардыр, ә мин сездә сагыз чәйнәп утырам. Кемгә кирәк мин үзем, төшем? Әй...

«Кызыклы физика» китабын алып, өстәл артына кереп утырдым. Ләкин аны мавыгып укып китә алмадым, башымда Зада апа сөйләгән Исмай бай иде. Чиртсәң кан чыгардай кып-кызыл чырайлы, зур корсаклы, камыт аяклы булып килде ул күз алдыма. Карашында чиксез ачу, кашлары жыерылган, иреннәре бер-берләренә ябышкан шикелле кысылганнар, көрәктәй тупас кулларын алга сузып, менә-менә өскә ташланыр төсле. Фәсхи абый авылда тамыр-

лары корытылган шул җирәнгеч Исмай байларны кире кайтарырга, халыкны яңадан алардан издерергә, мәсхәрәләтергә, талатырга теләгән. Зада апа әнә, Исмай бай ярлы кешеләрне санга да сукмый, аларның хәтта сәламнәрен дә алмый иде, ди. Фәсхи абый шул Исмай байлар яклы булган. Ә мин җүләр аны һаман юксынып йөрим. Кулларына богау салып, аркасына наганнар терәп алып китеп дөрес эшләгәннәр аны. Кешеләрдән иркен, шат, бәхетле тормышны күпсенүчеләргә шул кирәк аларга, шул!..

## Дүртенче бүлек

### 1

Бүген мин «Яшь ворошиловча атучы» значогына норма тапшыра алмадым. Шуңа эчем пошып, чак кына еламый утырам. Бүтән чакта биш патроннан кимендә кырык очко чүки идем, бүген нибары утыз бер очко җыйдым. Хурлык. Миләүшә кыз башы белән миннән унҗиде очкога артыграк чәпеде. Ул күкрәгендә төз атучы билгесе йөртәсе, ә мин юк. Бер Миләүшә генәме? Кәрим, Сәләй, Гайфи, Сәүбән — һәммәсе норманы үтәделәр. Мин, колаксыз Хәбир, сул күзен йома белми торган Сәлмән, мылтыкны кулына тотарга коты чыгучы Гамбәрия белән дәрестә гел чырт-чырт сагыз чәйнәп утыручы Рәхиләләр рәтендә калдым. Тисә — тиенгә, тимәсә ботакка дип тә атмадым үзе, ләкин уңышка ирешмәдем. Значок кына түгел, малайлар белән чапаевчылар уенында пулеметчы Петька булу тәтеми дә тәтеми хәзер миңа. Вак калибрлы мылтыктан адәм рәтле ата белмисең, синнән нинди Петька, әнә капкорсак каппельчы бул, диячәкләр. Үземнең начар атуымда мин Габбас абыйны гаеплим. Атканда, кул арама кереп, эшне ул бозды. Мәрәдәге мөгезле фашистны мушкага әйбәтләп утыртып тәтене тартуыма, Габбас абый:

— Ашыгасың, Ирек, пуляңны мишеньнән ике метрга өскә җибәрдең, мылтыгыңны рәтләп төзә,— диде.

Беренче пулямның җилгә китүе гарьлегеннән күз алларым караңгыланды, тәнемә тир бәреп чыкты, кулларым калтырый башлады. Калган дүрт патронымны йокылы-уяулы кеше сыман аттым.

Мишеньны тикшергәч, биш пулямның бишесе дә аны тишеп үткәне ачыкланды. Ләкин алар мин теләгәнчә тимәгәннәр, бер пулям гына унлы боҗрасының нәкъ уртасына эләккән иде.

Габбас абый һаман:

— Гаҗәп, ничек элеккәннәр синең барлык пуляларың да мәрәгә? Беренче атуыңнан соң әнә тегеннән, өстән яр балчыгы ишелеп төште бит,— дип сөйләде.

Инде кич булып килә. Әни кече якта ашарга хәзерләп йөри, әти радионы тоташтырып соңгы хәбәрләр тыңлый. Ул, кулларын артка куеп, салмак адымнар белән, гадәтенчә, ишекле-түрле йөри. Йөзе уйчан. Битендәге яра җөе тартышып-тартышып ала. Радио Испания фронтларындагы хәлләр турында сөйли башлагач, мин алдымдагы дәреслегемнән аерылдым.

— Бискайя фронтында уникенче майда баш күтәрүчеләрнең Сольюве таулыгы районында тупланган гаскәрләре республикачыларның позицияләренә һөҗүм ясады, ләкин ахырда зур югалтулар белән чигенергә мәҗбүр булдылар. Фашист самолетлары Билбао тирәләрендәге күп кенә пунктларны бомбага тотты. Үлүчеләр бар...

Радио Испаниядәге хәлләр турында сөйли башлагач та безгә кереп ишек катындагы агач диванга шыпырт кына утырган Зада апа, яулык чите белән иреннәрен сөртә-сөртә, әтигә сүз кушты:

— Мин синнән күптән сорарга җөрим шул Спание турында, Сабир. Кемнәр ул анда рыспубликачылар дигәннәре, хөкүмәт диган-

нәре, баш күтәрүчеләр дигәннәре? Фашис дигәнен беләм инде, аны-сын кызым әйтте, алары Газраил ярдәмчеләре булалар икән.

Әти Зада апа янына диванга утырды. Ул, уң кулының бармакларын турайтып, маңгаена төшеп торган чәчләрен артка сыпырып куйды.

— Испаниядәге республика хөкүмәте — халык хөкүмәте, Зада. Баш күтәрүчеләр — син әйткән фашистлар. Төшендеңме инде хәзер?

— Төшендем, рәхмәт. Рыспулике дигәннәре кызыллар икән. Нишләп соң алар фашис җавызларга махы бирәләр? Шуны аңламыйм. Фашисларны дөмектерсеннәрие инде тизрәк...

Әти тез өстендә бармакларын биетеп алды. Гадәте ул аның. Утырганда, җавап биргәнче, башта тезендә бармакларын биетә.

— Аларга җиңел түгел шул бу, Зада. Испаниядә узган елның унсигезенче июлендә башланган хәрби-фашистик баш күтәрү, аның артыннан ук Италия һәм Германия фашистларының кораллы интервенциясе булмаса, испан халкының зур күпчелеге булышлыгында республика хөкүмәте аны бик тиз бастырган булыр иде. Гитлер Германиясе белән фашистлар Италиясе халык фронты төзегән Испания хөкүмәтен бәреп төшерү өчен бу интервенцияне башлады. Италия һәм Германия фашистлары испан халкының җиңүе үз илләрендә халык массаларының берләшүенә көчле этәргеч бирер дип курыктылар. Алар Испаниядә халык хөкүмәтенә каршы баш күтәргән генералларга ярдәмгә килделәр. Испан халкына хәзер үз илләрендәге кара көчләргә генә каршы түгел, Италия, Германия фашистларына каршы да көрәшергә туры килә.

— Нишләп шуны белә торып, спан халкына булышырга безнең Кызыл Әрмияне җибәрмиләр соң? Ник кан койдыралар?

— Ярамый, Зада. Дәүләтләр арасында Испания эшләренә катнашмау турында килешү бар.

Моңарчы әтинең сүзләрен тыныч кына тыңлап утырган Зада апа урыныннан сикереп торды.

— Фашистларга катнашырга җарый, безгә җарамый, ничек була инде ул?

Әти тирән сулап куйды.

— Четерекле нәрсә ул, Зада. Шуны аңла: Испания безгә ерак, ә Италия белән Германиягә ул күрше үк диярлек. Алар анда гаскәр һәм коралларын ачыктан-ачык түгел, качып-посып кертәләр. Әмма испан халкы иртәме, соңмы барыбер җиңәргә тиеш. Безгә гражданнар сугышы вакытында ундүрт ил бер булып ташланганнар иде әле, барысын туздырдык.

— Шулай булсын кана.— Зада апаның йөзе яктырып китте.— Барын да бик әйбәт аңлаттың, Сабир, рәхмәт. Түлке мин синнән Спание турында сорарга кермәгәнием, җомышым бүтән ие, тыңла әле. Малайлар мәктәп ишегалдында туп тибешкәндә алтынчы классның бер тәрәзәсен коеп төшерделәр. Ул хәзер тешсез авыз күк ыржаеп тора. Шуны куйдырырга кирәк. Хезмәт укытучысы Кәшиф жанында булдым мин, пыяла җук мәктәптә, дырыктырга әйт, диде. Шуны әйтергә кергән кеше мин.

Әти бармакларын яңадан тезе өстендә биетте.

— Бер өлгесе генә ватылдымы?

— Җук, Сабир, бөтен тәрәзәсе рамы-ние белән коелды. Кәшиф анда рам җасый калды.

— Кем ватканы мәгълүмме?

— Белмәдем.

Әти диваннан торып пинжәген алып киде.

— Ничә әйттем Габбаска, мәктәп янында балаларга туп типтермә, дидем, һаман үзенекен итә. Хәзер тап менә пыяла. Кайдан алырга аны? Габбас мәктәптәме әле?

— Күренмәде.

— Алайса өенә барып чакырып кил әле аны, Зада. Мин мәктәптә булырмын. Директор җир тишегеннән булса да пыяла табарга кушты дип әйт. Тапсын, тәрәзә ватылуда ул гаепле. Киләчәккә аңа бу сабак булыр.

...Кәшиф абый үзе рам ясый, үзе Габбас абыйны сүгә булыр хәзер. Ул аны ачыктан-ачык дошман күрә, Олтырак дип кенә атый бит. Алар үзләре яшьтәшләр, бер очта торалар, бергә уйнап үскәннәр. Әмма хәзер араларында берниндн якынлык та юк, очрашканда хәтта исәнләшмиләр дә. Чындырмы, юктырмы, аны Сөләй сөйләгән иде, бервакыт безнең кебек малай чакта Кәшиф абый белән Габбас абый мәзин бакчасына алма урларга кергән булганнар. Мәзин аларны тоткан. Ул «караклар»га үзе тырнак белән дә чиртмәгән, ләкин икесенең дә кулларына берәр йомры таш тоттырып бер-берләрен кыйнарга кушкан. Кәшиф абый ташын читкә томырып иптәшенә кул күтәрүдән баш тарткан. Габбас абый исә кулындагы ташы белән Кәшиф абыйның авызын җимергән. Аның өске иренендәге яра җөе, имеш, шуннан калган.

Габбас абыйны яхшы да, яман да дия алмыйм. Сәер ул. Бүген мактаган кешесен иртәгә хурлый, хурлаган кешесен иртәгә күкләргә чөеп мактый. Бер карыйсың — чырае кояштай балкыган, икенче караганда — сытылган, иреннәре ачулы бөрешкән була. Мәктәптә ике ел гына укыта әле ул. Армиядән инде әллә кайчан кайтса да, өстендә һаман хәрби кием, аякларында һәрвакыт күн итекләр. Кышның иң суык көннәрендә дә киез итекләр кимәде. Урамда бик нык кар шыгырдый башласа, кешеләр тәрәзәгә карамыйча ук Дагалы бүре үткәнне беләләр иде.

Габбас абыйны әти, әле балалыктан аерылып җитмәгән, ди. Ул буйга уртадан бераз калкурак. Көчле. Ике потлы герне кулы белән түгел, сабына кулъяулыгы тагып, тешләре белән дә күтәрә. Аннары аны эһ тә итми башы аркылы чөя. Турникта утызар тапкыр тартыла ала. Тагын кулларына басып баштүбән дә йөри. Аның дәресләре безгә уен гына. Сафка тезелеп мәктәп тирәсендә марш атлап йөрибез, противогазны, хәрби мылтыкны сүтәргә, җыярга өйрәнәбез, туп тибәбез, озынлыкка, биеклеккә сикерәбез. Физкультура дәресләрендә бөтен үткән нәрсәләребез шул. «Яшь ленинчы» газетасында районнардагы һәм Казандагы мәктәп укучылары БГТО, БГСО значокларына норма тапшырулары, хәрби уеннар оештырулары, тагын әллә ниләр эшләүләре турында язалар. Габбас абый безгә: «Сездән чын спортчылар, күпме тырышсагыз да, чыкмаячак, инде буыннарыгыз каткан, спорт белән бишектән үк шөгыльләнә башларга кирәк,— ди. Турникка менеп әйләнә башлаган малайны күрсә: «Муеныңны сындырмакчы, гарипләнмәкче буласыңмы».— дип шундук куып төшерә. Авылда аның кушаматлары берничә: Дагалы бүре, Олтырак, Куык... Фәсхи абый кулга алынганнан соң, ул беркем белән дә аралашмый, гел берүзе. Клубка керсә, башкаларның күңел ачуларын, кулларын шинель кесәләренә батырып, читтән генә күзәтеп тора.

Пыяланы тапмый да тапмый Дагалы бүре. Кемнән тапсын ул, авылда аны бирәү дә өнәми бит. Аннары Бәештә хәзер пыяла иң кадерле нәрсә санала. Әнә Сөләйләрнең бер тәрәзә өлгеләре күз көне үк ватылган иде, пыяла таба алмыйча, тәрәзәләрендәге юк өлге урынына мендәр тыгып кыш чыктылар, әле дә куйдыра алганнары юк.

Ашарга инде күптән өлгерде. Мин дәресләремне әллә кайчан карап бетердем. Ашыйсы килә, эти юк та юк, әни әйтмешли, китте дә батты. Кичке ашны без барыбыз бергә җыелышкач кына ашыйбыз. Эти исә пыяла юллап йөри булыр. Ел буе эзләсә дә, Бәештә

тапмый ул аны. Әни борчыла, күзләре гел тәрәзәдә. Ахырда түзмәде, миңа:

— Бар, улым, эзләп кайт атаңны,— диде.

Мин мәктәпкә барырга чыктым. Колаксыз Хәбирләр турына өелгән бүрәнәләр өстендә унлап ир сөйләшеп утыра иде, эти дә шулар арасында булып чыкты.

— Эзли чыктыңмы әллә? — диде ул, мине күргәч.

— Әйе.

— Хәзер кайтабыз, улым.— Эти урыныннан торды.— Авыл яме манарада түгел, җәмәгать. Түгел, аңлагыз. Тормыш үзегез күрәсез, туктап тормый, алга бара. Кичә генә яхшы булып тоелган нәрсәләребезне бүген үзебез үк ошатмыйча, башкачарак, тагын да яхшырак итеп күрергә телибез. Менә сез мисал эзләп ерак китмичә, үзегезне генә алыгыз. Сезгә аерым хуҗалык чакта җиңел идеме, хәзерме?

— Билгеле хәзер,— дип җавап кайтарды аңа берничә тавыш.

— Шул шул. Манара мәсьәләсе — ул тормыш таләбе. Бүгенге көн таләбе. Совет, колхоз авылы аның күләгәсеннән арынырга тиеш. Яңадан беркайчан да әйләнеп кайтмас иске тормышның албастысы бит ул манара. Дөрес әйтәмме?

— Дөрес, кәнишне. Бүтән авылларда күптән юк инде мәчет манаралары. Бездә генә калмас,— диде колаксыз Хәбирнең этисе Могыйн абзый.— Тик өйрәнелгән, күнегелгән нәрсә жалкы.

— Жалкысын жалкыдыр, әмма мәктәбебез өстендәге манараны киләсе уку елына калдырмыйк.

Этигә каршы сүз кайтаручы булмады.

— Ярый, хушыгыз бүгенгә, җәмәгать.

— Хуш, иптәш Кадыйров,— диделәр аңа бүрәнә өстендәге ирләр.

Без өйгә юнәлдек. Юлда кайтканда мин:

— Габбас абый пыяла таптымы, эти? — дип сорадым.

— Тапмады. Манара тәрәзәсенең берсен алып куйдык.

Арабызда артык сүз куермады. Мин юл буе мәктәбебезне манарасыз итеп күз алдыма китерергә тырышып кайттым, ләкин булдыра алмадым.

## 2

— Табигать кешегә зур юмартлык күрсәткән — акыл, аң, көч, зирәклек, түземлек, алдан күрә белү һәм башка бик күп күркәм сыйфатлар биргән. Шул ук вакытта ул аны бик нык кыерсыткан да. Моның өчен без табигатькә үпкәләргә хаклы, балалар. Табигать кешене кай яктан кыерсыткан, ягез әле кем әйтә? — Мирсәет абый, саран елмаеп, кабарынкы соры күзләрен безгә төбәде.

Башкаларга ничек булгандыр, минем өчен бу көтелмәгән сорау иде. Чыннан да, кешене кай яктан кыерсыткан табигать? Бәлки аны башкалар белә торгандыр? Мин классташларыма күз салдым. Әмма җавап бирергә атлыгып кул күтәрергә җыенучыны күрмәдем. Башымда уйлар өермәсе купты. Кеше... кеше... Хайваннар, кошлар, төрле җәнлекләр, балыклар, бөҗәкләр... Аларда бездә юк, безне көнләштерерлек нәрсә бар? Җыланнар, тюленьнәр, дельфиннар, сигезаяклар...

Әнә колаксыз Хәбир җавап бирергә җыенып кулын күтәрде.

— Әйт, Зәйнуллин.

— Кешенең йоны юк, Мирсәет абый.

— Тагын кем ничек уйлый?

— Табигать кешегә канатлар кызганган,— дип кычкырды Гайфи «Камчатка»сыннан.

— Кеше суда яши алмый,— дидем мин.

— Ул караңгыда күрми,— диде Миләүшә.

— Минем соравымны сез дөрес аңламадыгыз, балалар. Шуңа күрә җавапларыгыз да дөрес түгел,— диде Мирсәет абый, тәрәзә янына барып басып.— Сез әйткән кыерсытылуларын кеше үз акылы белән төзәткән инде аларны. Мин сезгә башка нәрсә турында әйтергә теләдем. Табигать безне, Хәбир уйлаганча, шәрә яратмаган. Күбегез белә торгандыр, борынгы бабаларыбызның тәннәре, маймылларныкы кебек үк, куе йон белән капланган булган. Тәннәрендәге ул йон гына аларны салкыннардан, төрле табигать көйсезлекләреннән саклый алмагач, борынгы бабаларыбыз үзләренә азыкка үтерген җанварларның тиреләрен салдырып, өсләренә ябына башлаганнар. Вакытлар үтү белән алар примитив киемнәр әмәлләргә өйрәнгәннәр. Аннары исә кием кеше өчен зарури нәрсәгә әверелгән. Нәтиҗәдә табигать биргән йонның кешегә кирәге беткән, ул, үзеннән-үзе кими барып, хәзерге тәнебездәге сирәк төкләргә генә калган. Гайфи, табигать кешегә канатлар кызганган, диде. Кешенең канатлары юк, бу дөрес. Тик ул моңа карап очмый торамы? Юк. Оча кеше. Күкне ул үзе тудырган аппаратларга утырып гизә. Узган ел герой-очучы Валерий Чкалов ике иптәше белән Мәскәүдән Ерак Көнчыгыштагы Удд утравына кадәр ун мең чакрым чамасы араны тукталышсыз очып үтте. Очу кешегә инде хыял түгел, ул озакламый Галәм киңлекләренә чыгып, күрше планеталарга да барыр. Кешене Ирек әйткән су да куркытмый. Диңгез, океаннарны ул күптән инде аркылыга-буйга гизә, батискафларда әллә нинди тирәнлекләргә төшеп, су асты дөньясын өйрәнә. Кеше караңгыга да аптырамый, Миләүшә. Ул караңгыны да Ильич лампалары белән яктырта — гигант электр станцияләре кора. Кешенең кыерсытылуы — гомере кыска булу, балалар. Кеше аз, бик аз яши. Попугайларның, кара каргаларның, ташбакаларның гомерләре ике йөз ел чамасы. Ә кешенең хәзерге уртача гомере кырык биш-илле. Борынгы Грециядә ул тагын да азрак — егерме тугыз ел гына булган. XVI гасырда европалылар уртача егерме бер яшькә, XVIII гасырда — егерме алтыга, XIX гасырда утыз дүрткә кадәр генә яшәгәннәр. Бөек Октябрь революциясеннән соң безнең илебездә гомер озынлыгы, әйткәнемчә, күпкә күтәрелде. Шулай да бу, кабатлап әйтәм, аз, бик аз, балалар. Әйтәсе килгән төп нәрсәм шул сезгә: тормышта һәммәгез дә матур эз калдырырга онытмагыз, гомерегез берегезнең дә зая узмасын, эшләгән һәр эшегез кешеләрне сокландырырлык булсын. Сез киләчәктә үзегезне рәхмәт хисе белән искә төшерерлек, бүгенгебезнең ядкаре булып калырлык ни эшли аласыз? Бу инде сезнең көчегездән килә торган нәрсә. Уйлагыз әле яхшылап шуны, аннары әйтерсез.

Мирсәет абый гел шулай, һәр дәресендә безне уйланырга, алдыбызга куйган сорауларына җавап эзләргә мәҗбүр итә. Аның дәресләрендә чит нәрсәләр турында хыялланып утырып булмый. Урта буйлы кечерәк кенә башлы, тар кылыч борынлы, соры күзле бу укытучының дәресләре безне ялыктырмый, һәрвакыт кызыклы, мавыктыргыч була, яңалык алып килә, хәтердә кала.

Без Мирсәет абыйны үзара Дәһәр кадаяк дип йөртәбез. Бу аның усаллыгына ишарә ясау түгел, аны үз итеп, яратып әйтү генә. Ул үтә сабыр, тыныч кеше, эшен дә, укучыларны да ярата. Мәктәптә башка фәннәрдән әле кабинетлар юк, ә биология һәм химия кабинеты бар. Нинди генә кабинет әле! Керсәң, чыгасы килми. Андагы бөтен экспонатларны, күргәзмә әсбапларны, гербарийларны укытучыбыз җитәкчелегендә без үзебез әзерләдек.

Мирсәет абый тынгысыз, эзләнүчән кеше. Дәресләрен ул мөмкин кадәр ачык һавада — табигать кочагында үткәрергә ярата. Шуңа

күрә алар яхшы үзләштерелә дә. Күлмәк сәдәфе кадәр генә бишалты вак сары чәчәк ата торган, терлекләр өчен агулы казаяк үләнен минем Мирсәет абыйның үзен онытмаган кебек гомеремдә онытасым юк. Мин ул үләннең гербариен хәзерләдем. Без зәһәр казаякны Чуал буендагы уйсулыкка барып өйрәндек. Һәрберебез аны табигый килеш күрде, үз куллары белән тотып карады. Су үсемлекләрен дә, башка үләннәрне дә, төрле бөҗәкләрне, суалчаннарны да шулай өйрәндек. Мирсәет абый — кыр ягыннан. Сөйләгәндә з авазын д-лаштыра. Зәһәр казаяк аның сөйләмендә «дәһәр кадаяк»ка әверелә.

Класс яңадан тын калды. Мин Мирсәет абый соравына тырышып җавап эзләдем, ләкин таба алмадым. Кинәт чыра шикелле ябык, камыш күк нәзек Сәлмәннең кызларныкы кебек нечкә тавышы бүлмәдәге тынлыкны бозды.

— Мин әйтәм, Мирсәет абый.

— Йә, тыңлыйбыз.

Бөтенебезнең күзләре Сәлмәнгә текәлде. Ул тотлыга-тотлыга:

— Агач утыртырга. Безнең карт бабайның талы турыбызда әле дә үсә. Үзе инде әллә кайчан үлгән, мин белмим дә аны. Талы бар, талы үсә.— диде.

Укытучы бу җавапка балаларча шатланды. Аның аксыл йөзендә киң елмаю балкыды.

— Егет икәнсең, Сәлмән! Нәкъ мин әйтергә теләгән сүзләрне әйттең, рәхмәт. Утыр.— Аннары ул өстәле артына басып сөйләп китте: — Һәр кеше үз гомерендә бер генә төп булса да агач утыртырга тиеш, балалар. Һәр елны менә безнең Бәештә генә дә утынга, бүтән кирәкләргә кимендә мең төп агач киселә. Ә Татарстанда Бәеш кебек дүрт меңгә якын авыл бар. Димәк, республикабыз урманнары бер ел эчендә генә дә чама белән ярты миллион төпкә якын агач югалта дигән сүз. Без хәзер үк инде, Сәлмән әйткәнчә, авылыбызны яшелләндерүгә өлешебезне кертә алабыз. Тышта яз, нәкъ агачлар утырту вакыты. Болай килешик әле: сезнең һәркайсыгыз бүген үк үз турларында өч төп агач утырта һәм аны, терлекләр имгәтмәслек итеп, киртәләп куя. Бу минем сезгә өйгә биргән эшем булыр. Утыртасы агачларыгызны Чуал буендагы әрәмәлектән сайларга мөмкин. Йә, ничек, эшләрсезме шуны бүген үк, балалар?

— Эшләрбез, Мирсәет абый, дәрестән кайту белән эшләрбез!

— Рәхмәт, чын күңелдән уңыш телим сезгә.

Звонок булды. Класска, Габбас абый белән бергә, кулына ике йозаклы зур сары портфель тоткан, битен кызыл бетчәләр чуарлаган, такыр башлы, калын бәдәнле, озын буйлы, хәрби киемле бер кеше килеп керде.

Физкультура укытучысы ишектән үтү белән:

— Укучылар, тәнәфескә чыкмый торыгыз, эш бар, диде.

Без урыннарыбыздан инде кузгалган идек, теләр-теләмәс кенә яңадан утырдык. Мирсәет абый чыгып китте. Габбас абый, өстәл артына үтеп, тавышын күтәрми генә:

— Безгә районнан төз ату нормасын үтәгән укучыларга «Яшь ворошиловча атучы» билгесе тапшырырга район осоавиахим оешмасы вәкиле иптәш Бикмуллин килде. Сүз хәзер аңа бирелә,— диде.

Хәрби киемле абый портфелен өстәлгә куйгач, шәрә башын алга ия төшеп, безгә күз йөртеп чыкты. Аннары бераз сакаурак тавыш белән болай диде:

— Укучылар! Сезнең класста сигез укучы төз атучы значогы алырга лаек табылды. Мин шуларны чын күңелдән тәбрик итәм!

Габбас абый бу сүзләрдән соң кул чаба башлады. Без дә аңа

кушылдык. Шул арада хәрби киемле абый портфеленнән тышлыгына «таныклык» дип язылган, икегә бөкләнгән уч төбе кадәр генә катыргылар чыгарды. Аларның берсен ачып ул:

— Бәдретдинов Гайфетдин,— дип укыды.

Җирән, «Камчатка»сыннан ашыкмый гына кузгалып, класс алдына чыкты. Хәрби киемле абый аңа башта катыргы, аннары портфеленнән значок чыгарып бирде.

— Снайпер булып үс, Бәдретдинов.

— Кем соң ул синайпр? — Гайфи хәрби абыйга сораулы текәлде.

— Снайпер — аткан пулясын очып барган чыпчыкның күзенә тидерүче.

— Була ул, абый, тырышырмын.

Хәрби киемле абый яңа катыргыны ачты.

— Лотфуллин Сөләйман.

Сөләй дә значок алды. Аннары Кәримгә дә, Идрискә дә, Миләүшәгә дә, Сәүбәнгә дә катыргы тышлык һәм значок тапшырылды.

— Кадыйров Ирек.

Мин үз фамилиям, исемем аталгач, аптырап калдым. Бер мизгелгә күңелемне шатлык биләде, әмма шунда ук тирда ничек атуым исемә төште, һәм колакларымның уттай кызыша башлауларын тойдым, башым иелде.

— Ирек, чык өстәл янына, иптәш Бикмуллин сине чакыра ич,— диде Габбас абый нииндидер ят тавыш белән.

Мин, бөтен иптәшләремнең күзләре үземә төбәлгәнен тоеп, нишләргә белмәдем. Норманы үтәмәгән килеш миңа нәрсәгә ул значок? Аны алып көлкегә калыргамы? Алмыйм. Урынымнан торып ишеккә юнәлдем. Миңа бирәү дә, Ирек, кая барасың, тукта, значогыңны ал, димәде.

Мин яңадан дәресләргә кермәдем, өйгә кайтып көрәк алдым да, Чуал буена киттем. Анда өч төп шомырт агачы казып алып, аларны турыбызга кайтарып утырттым. Мине бертуктаусыз, Габбас абый нигә миңа да значок бирергә булды икән, дигән уй борчыды. Кәефем кырылды, бөтен кешегә ачулы идем.

Кичен эти өйгә кайту белән:

— Нигә дәресләрдән качтың? — диде.

— Габбас абый төз атучы значогы биреп мәсхәрәләгән өчен,— дип җавап бирдем мин аңа, ваемсыз гына.

— Нәрсә өчен? Төшенмәдем. Юньләбрәк аңлат әле.

Этигә мин «Яшь ворошиловча атучы» значогына норма тапшырганда начар атуым, шуңа күрә төз атучы булып исәпләнергә хакым юклыгын сөйләп бирдем.

Эти иңемә кулын салып, һәр сүзенә басым ясап әйтте:

— Значок алмавыңны хуплыйм, әмма дәрестән китүең — тәртипсезлек. Андый эшең, колагыңа киртлә, яңадан кабатланмасын. Синә значоктан, мин аны тагарга әле лаек түгел, дип баш тартырга иде дә, вәссәлам, класста калырга иде. Үзеңә кагылышлы гаделсезлекләргә моннан соң да бүгенгечә җавап кайтарсаң, кем үсәр синнән? Куркак, шкурник үсәр. Мин синең гаделсезлекләрдән үзеңне генә түгел, башкаларны да яклый белүче чын кеше булып җитлегүеңне телим. Ә кеше булган кешенең бер эше дә очланмыйча ярты юлда калмый. Күңелеңә моны ныклап беркетеп куй. Яктыга, кояшка йөз тоткан кеше үз алдында күләгәсен күрми, күләгәсе аның артына төшә. Алдында шундый кеше үз күләгәсен күрсә, бу аның юлдан язуы була, улым.

Кич турыбызга утырткан шомыртларыма су сибәргә чыккач, яныма Ярулла абзый килде.

— Егет син, Ирек, тик тормыйсың, шулай кирәк, шомыртларыңа озын гомер телим,— диде ул агачларыма карап.— Тик, бигайбә, мин синең урында булсам, аларны монда түгел, амбарыгыз алдында утыртыр идем. Монда син аларны юл өстенә утырткансың, кешеләргә йөрергә комачаулаячаклар, үсмәсләр дим.

— Аларның берсе үссә җитә миңа, Ярулла абзый.

Абзам гаҗәпләнде.

— Ничек инде алай, өчне утырткансың, берсе үссә җитә? Утырткан агачны үссен дип утырталар аны.

Нигә эшемнән гаеп табып йөри әле бу агай? Монда аның фикерен сораучы юк лабаса. Гомере буе агачлар утырту белән генә шөгыльләнгән кешемени, өйрәтепме өйрәтә, үз ихатасында исә сыңар чыбык та үсми...

Ярулла абзый, үз әйткәне миңа ошамаганын аңлаптыр, сүзен икенчегә борды:

— Кәефеңне боздым бугай, гафу ит мине, Ирек. Эшеңнән гаеп табарга килмәдем, куанычымны синең белән уртаклашмакчы идем бит...

— Зарарсыз, Ярулла абзый. Дөрес әйттең, шомыртларымның урыннары чыннан да монда түгел икән шул. Рәхмәт сиңа. Иртәгә амбар алдына мин бүтән агачлар алып кайтып утыртачакмын.

— Әйдә бүген үк шушыларны гына күчереп утыртабыз...

— Икәүләпме?

— Икәүләп, кәнишне.

— Әйдәгез алайса. Мин иртәгә сезнең турга да шомыртлар алып кайтып утыртырмын, Ярулла абзый.

— Безнең турга син миләшләр утырт, Ирек. Хәбибә тутаң миләш агачларын ярата, аны сөендер.

Күп тә үтмәде, без Ярулла абзый белән шомыртларымны амбар алдына күчереп утыртып та куйдык. Шуннан соң гына мин агамның янына нинди куанычын уртаклашырга килүе белән кызыксындым.

— Хәзер укый да, яза да беләм бит мин, Ирек. Тәки наданлыктан коткардың син мине. Куанычым шул...

— Ышанмыйм мин сиңа, Ярулла абзый.

— Ышанмыйсың? Менә мин язам, син укы алайса.

Ярулла абзый шомыртларны күчереп утырткан көрәк белән аяк астына хәрефләр сыза башлады. Бераздан мин «Рәхмәт сиңа, Ирек, күземне ачтың»,— дигән сүзләр укыдым.

## Бишенче бүлек

### 1

Бәештән район үзәгенә бара торган юл читендә ялгыз нарат үсә. Карт, бик карт нарат ул. Берничә кешенең колачы җитмәслек юан кәүсәсе, яман шешләр чыккан сыман, тубырланып беткән, килбәтсез кәкре-бөкре ботакларын чәйре чаллаган, ылысы ала-кола, ни яшел, ни сары түгел. Җилдә бу нарат башка агачлар кебек шауламый, авыр ыңгыраша, нәрсәдәндер зарлана шикелле. Төбендә янтаеп яртылаш җиргә иңгән кабер ташы бар. Аңа чокып нәрсәдер язылган булган, тик ул язу инде күптән кыршылган, танырлыгы калмаган, сүзләр урынына мәгънәсез сызыклар гына сакланган. Ташның түгәрәкләнеп килгән өске өлешенә йолдыз һәм ай сурәтләре уелган. Алары исә кыршылмаган.

Берәүләр, бу ялгыз нарат төбенә Болгар баһадиры күмелгән, икенчеләр, анда изге дәрвиш җирләнгән, диләр. Өченче берәүләр,

карт нарат астында авылыбызга нигез салган кеше ята, ул Бәеш атлы булган, авылыбызның исеме дә шуннан калган, дип расларга тырышалар. Шуларның кайсы тәгаен дөрес, кайсы чын — билгесез.

Бәеш кешеләре дә, тирә-күрше бүтән татар авылларында яшәүчеләр дә карт нарат төбендәге каберне изге саныйлар, нәзер әйтеп, аның янында еш кына корбан чалалар. Кабер тирәсенә еллар дәвамында йөзләгән терлекнең каны сеңгәнгә, анда юньләп үлән дә үсми.

Халык арасында, ялгыз нарат төбенә кеше түгел, бик зур хәзинә күмелгән, дигән сүзләр дә йөри. Бу хәзинә һәр төнне кабердән зур кара эт кыяфәтендә чыгып, олы юл буенда каңгырап йөри, аны ялгызың гына очратып күсәк белән орсаң, ул алтын-көмеш тәңкәләр булып чәчеләчәк, имеш. Тик ул эткә күсәк белән органда бисмилла әйтергә онытмау һәм тамчы да курыкмау шарт, ди. Бисмилла әйтмәсәң, эткә чурт та булмый, курыксаң, сине ул күз ачып йомганчы бугазлап кабергә иңә, имеш...

Ялгыз нарат төбенә хәзинә күмелүенә безнең — Гайфи, Сөләй, Кәримнең һәм минем аз гына да шигебез юк. Чөнки авылда әллә никадәр кешеләр олы юлдан төнлә үткәндә ялгыз нарат янында бик зур эт күрүләре турында шомланып сөйлиләр. Кап-кара төндә дә елык-елык итеп әллә каян күренә, ди ул. Авызыннан ялкын бөркелеп тора, күзләре ут кебек яналар, ди аның. Өченче көн төнлә Сөләйнең этисе Лотфулла абзый да күргән аны. Башка кеше булса, алдаша, дияр идең, Лотфулла абзыйга ышанмый ярамый, Бәештә аны юкка гына Тугры Лотфый димиләр.

Аның атлар караучы Камали бабайга Чаллыдан кайтканда тылсымлы этне күрүе турында сөйләвен мин үзем ишеттем.

— Башкалар ялгыз нарат янында кара эт күрдек дигәндә, борчак чәчә болар, әкият сөйлиләр, дип йөри идем моңарчы, кичә үзем дә очраттым ул хәерсез җанварны. Бозау кадәрле эт ул. Камали абзый, күргәч имәнеп киттем. Аркамнан салкын тараканнар чабып үткәндәй булды. Шуннан соң, бәладән баш-аяк дип, белгән догаларымны укый-укый, дилбегә белән суктым бахбайга. Малкай да шуны гына көткән иде, күрсәң, кушаяклап томырылды авылга! Пошкыра-пошкыра чапты, рәхмәт төшкере... Кичә ышанмассың дип сөйләмәгән идем, ни әйтерсең, син дөнья күргән карт кеше...

— Эх, нинди зур байлыкны кулдан ычкындыргансың, Лотфулла энем,— диде аңа Камали бабай, шелтәләп.— Болай карап торуга әзмәвердәй ир бит син, ачуым килмәгәе! Атыңны туктатыргаые сиңа, барыргаые җанына, бисмилла әйтеп, арт аякларыннан эләктерергәие ул этне, аннары нарат кәүсәсенә сыларгаые. Бозау чаклы булса да, көчең җитәрие әле. Калхузда хет адәм рәтле ат абзары җиткерер, бүтән каралтыларны җаңартырыек. Файдаланмагансың форсаттан, жалкы...

Лотфулла абзый уңайсызланып калды. Аннары картка туптуры карап әйтеп салды:

— Андый нәрсәләр уема да килмәде минем, Камали абзый. Дөресен әйтәм, курыктым.

Без, дүрт дус, ялгыз нарат төбендәге хәзинәне казып алырга дигән ныклы карарга килдек.

Өйдә мин этигә:

— Олы юл буендагы ялгыз кабергә хәзинә күмелгән, бу —хак,— дидем.

Эти шаркылдап көлде.

— Кайдан белдең, төшеңә кердеме әллә?

— Төннәрен ул зур кара эткә әверелеп кабердән чыга, ди. Кичә генә аны Сөләйнең этисе Лотфулла абзый күреп кайткан, ул сөйләде.

Әти, көлүдән туктады да, дәрес аңлатkандагыча тыныч, салмак тавыш белән:

— Андый нәрсәләргә ышанма, улым. Кабер янында корбанга чалган хайванның калдыкларын ашарга барган авыл этен күргән Лотфулла абзаң, — диде.

Мин аптырап калдым.

— Ялгыз нарат төбендә бернинди хәзинә дә юк, дисең инде син алайса, әти?

— Юк, улым. Хәзинә — әкият ул. Уйлап кара, аю төбәгендәге хәерче татар авылына кайдан килсен ул хәзинә? Булса, аны күптән казып алырлар, яткырмаслар иде инде.

— Нинди кабер соң ул, әти?

— Белмим, улым. Әмма анда хәзинә күмелмәвенә иманым камил.

Ярый, ялгыз нарат төбенә хәзинә күмелмәве, әти әйткәнчә, дөрес тә булсын, ди. Тик җәмгыять белеме дәреслегендә борынгы каберләрдән әллә нинди кыйммәтле бизәнү әйберләре, савыт-сабалар, кылычлар, пычаклар, калканнар, сөңге очлары, тагын әллә ниләр табылу турында язганнар бит, дип уйладым мин. Ялгыз нарат төбендәге кабер дә бик борынгы ич, анда да нәрсә дә булса бардыр. Кабер Болгар баһадирыныкы булса, аны анда шәрә килеш кенә җирләмәгәннәрдер...

Әтидән ишеткәннәремне иптәшләремә җиткердем. Гайфинең һич тә исе китмәде.

— Сабир абый нәрсә белә ул? Безнең Бәештә туып үссә, бер хәл иде, читтән килгән кеше. Җитмәсә коммунист. Коммунистлар андый нәрсәгә дөрес булса да ышанмый алар. Минем әти, каманистлар акны да кара дип әйтәләр алар, ди.

Әтигә карата әйтелгән кимсетү сүзләре күңелемә тисә дә, бәхәскә кермәдем. Җирән безне килмешәккә саный икән, саный бирсен, аңа карап маңгайга мөгез үсми ич. Без, чыннан да, бу авылныкы түгел ләбаса. Пионер башы белән коммунистларга тел тидерә тагын, оялмый.

Сөләй дә үз фикерен кире кагарга урын калдырмаслык итеп ярып салды:

— Хәзинәне казырга булгач, казыйбыз, малайлар! Берегез бармаса да, мин ялгызым барып казыйм.

— Ә авыл халкы нәрсә әйтер? Изге кабергә чучка кебек борын тыгарга сезгә кем рөхсәт итте, дип үзебезне тереләй шул кабергә күммәсләрме? Шуны уйлагыз. Уен эш түгел бу. Мин анда бармыйм.

Бу сүзләрне арабызда җиде кат үлчәп бер кат кисәргә яратучы Кәрим әйтте.

Гайфинең ачудан иреннәре калтырый башлады.

— Бармасаң, потың бер тиен, кирәгең безгә шул кадәр генә синең, — диде ул Кәримгә, күзләрен акайтып. — Ә без барабыз. Җырларга гына оста син. Һай-вай-лә-лә-ләй!.. Нидер эшләргә булса, өч көн көтәргә кирәк сине. Эх, Шөлдер, мин лом алып барам дип шапырындың, буш куык!..

— Ярар, син әйткәнчә, мин буш куык булмыйм. Синең атаңны Хәчтери Баһави диләр, минекен — Кайнар Гыйльмулла. Аерма бармы? Бар. Мине ул изге кабергә орынганымны белү белән буачак.

— Хәзинә тапсак тамы?

Кәрим дәшмәде. Бездән аерылып калу аңа, күренеп тора, җиңел түгел, башы иелгән, чак еламый. Дустыбызның күңелсезләнүен күргән Сөләй аны тынычландырырга ашыкты:

— Кал, ирексезләмибез сине. Безгә уңыш телә, хәзинәдән сиңа да өлеш чыгарырбыз, алла боерса.

Тәкърлек ниндидер эшкә тотыныр алдыннан алланы телгә алмый

калмый. Халыкта, кош оясында нәрсәгә өйрәнсә, очканда шуны кабатлый, дигән сүз бар бит. Сөләй дә шундый. Аның әтисе, әле карт булмаса да, ярыйсы ук диндар кеше. Аларга барып керсәң, күзең иң әүвәл стеналардагы шамаилләргә төшә. Лотфулла абзый гаилә әгъзаларын, ашап туйгач, амин әйтеп бит сыпыртмый табыннан торгызмый. Ул балаларына ураза да тоттыра бугай әле. Быел Сөләйне хәтта үзе белән гаеткә дә алып барды.

Ниһаять, без, үткен тимер көрәк һәм зур капчык алып, ындыр артлап ялгыз нарат төбенә юнәлдек. Кәрим сөйләшкән урыныбызда торып калды. Мин, Шөлдер хәзинә казудан баш тартып, дөрес эшләде, дип уйладым. Чыннан да, изге каберне актарганыбыз өчен безне мактап башларыбыздан сыйпамаячаклар бит. Ярый ла анда нәрсәдер таба алсак, ә тапмасак? Изге әрвахның сөякләрен кузгатырга син кушкансың, синең коткың бу, мөртәт, дип динче картларның минем аркада әтигә бәйләнәчәкләре көн кебек ачык. Әллә миңа да Кәрим кебек берәр сылтау табып кире борылыргамы?..

Шулай уйлап бетермәдем, Гайфи миңа:

— Ирек, әллә син дә Кәрим кебек шыр җибәрдеңме, иңнәрең салынды? Курыксаң кал, барма, — диде.

Әмма мин:

— Курыкмыйм, ник куркыйм, — дидем, телемне көчкә әйләндереп.

Гайфинең үзенең дә күңеле тыныч түгел иде шикелле. Әнә бит нәрсә ди:

— Без хәзинә актарып маташканда юлдан кемнәрнеңдер үтәчәге көн кебек ачык. Яныбызга килеп, сез монда нишлисез, диюче булса, Сәлим бабай безгә кабер ташын турайтып утыртырга кушты, картларга ул эш ярамый, авылдагы алласызлардан куркабыз, сез малайларга сүз булмас, дип әйтте диярбез, яме.

— Ышанмасалар?

— Ышанмасалар Сәлим бабайдан кайтып сорарлар. Алар әйләнеп килгәнче без хәзинәне казып чыгарган булырбыз инде. Алтынкөмеш күргәч, кем аннары сүз әйтер безгә?

Башы түгәрәк Җирәннең! Бөтенесен алдан ук уйлап куйган бит чукынган!

Сөләй, башта бик батыр күренсә дә, ялгыз наратка җитәрәк туктап калды.

— Әти төнлә күргән теге әт кабердән чыгып өстебезгә ташланса, нишләрбез ә?

Гайфи шаркылдап көлде.

— Тимер көрәк нәрсәгә? Бисмилла әйтеп башына тондырабыз да казып та торасы булмый.

— Ярый ла тондырырга өлгерсәк...

— Өлгерәбез, без өчәү ич.

— Ә көрәк бер генә...

— Бер булса да берәгәйле ул.

Ялгыз нарат безне сизелер-сизелмәс кенә шаулап каршылады. Мин як-ягыма күз ташладым. Бөтен әйләнә-тирә уч төбе шикелле ап-ачык. Сулда Баеш, Каршы тау, тау итәгеннән бормаланып-бормаланып Чуал ага. Әнә тегермән буасы, тегермән үзе. Уңда урман. Урман белән Каршы тау арасында, киң тасмага охшап, олы юл сузыла. Күз иңли алган бөтен тирә-юнь шып-шыр, беркем юк. Буш кыр уртасында ялгыз нарат та без генә.

Менә Гайфи тимер көрәкне капчыктан сүтеп алып:

— Бисмиллаһираһманирраһим, — дип кабер ташы янына кадады да аягы белән басты. Көрәк җиргә кермәде, нәрсәгәдер төртелде. Гайфи аны бераз читкәрәк күчереп тагын басты. Янадан шул ук хәл. Нәрсә бу? Кабер өстенә таш түшәлгәнме әллә? Юк, таш түшәлмәгән,

нарат тамырлары икән. Гайфи көрәген кабер өстенең кай җиренә генә төртсә дә тамырларга юлыкты.

— Балтасыз эш чыгарлык түгел монда, — диде Сөләй. Гайфи шәрәләгән тамырларны куллары белән капшап.

— Безнең көрәк балтадан кимме? — Җирән кизәнеп-кизәнеп җирдәге тамырларны көрәк белән чапкаларга кереште. Ләкин тамырларны көрәк кенә җиңәрлек түгел, алар кабер өстенә үрелеп диярлек түшәлгәннәр иде.

— Теге эт ничек чыга икән моннан, үләт? — диде инде тиргә батарга өлгергән Гайфи, нарат тамырларының үзе теләгәнчә чабылмауларына үртәлеп.

Сөләй аңа гамьсез генә җавап кайтарды:

— Тылсымлы эт ич ул. Аның үзенең әфсене бардыр. Әйтик, «Гали баба һәм кырык карак» әкиятендәге кук. Йә махсус догасы. Шуны әйтә дә чыга, кергәндә дә шуны ук әйтә дә керә...

Каберне минем бер көндә генә түгел, бер ай буена да актара алмаячагыбызга шигем калмады.

— Эт тә, чурт та юк монда. Әтинең сүзләре хак, шул гына.

Дусларым минем белән бәхәскә кермәделәр. Җирән кабер өстендәге тамырларны чапкалавын белде, Сөләй, нарат кәүсәсенә сөялеп, аның эшен күзәтте. Кинәт ул өне алынып:

— Егетләр, беттек юлдан ниндидер җайдак килә, — диде.

Гайфи кабер өстенең үзе көрәге белән тырмачлаган җирләрен кабаланып күмәргә тотынды. Җайдак безгә якынлашканнан якынлашты. Мин аны озакламый танып та алдым. Ул райком секретаре Җәгъфәров абый иде. Атта аның кебек шәп йөрүче юан кеше районда бүтән юк. Әнә иярдә ул коеп куйган шикелле утыра. Ирексездән сокланасың аңа. Беттем, дип уйладым, күкрәгемдә нәрсәдер өзелеп төшкән кебек булды, әтигә әйтеп кирәкне бирдерәчәге көн кебек аның. Баешкә килгәч, безгә кагылмый китми... Эх, Кәрим кук монда килми калсам, кем әйтмешли, ашамый да тук буласы икәнмен... Кайчан акыл керер сиңа, улым, дип әни дөрес әйтә шул, дөрес. Башында акылы булган кеше киләме монда? Тиле мин, шыр тиле. Кабер актаруда катнашып Җәгъфәров абый алдында әтинең йөзенә кызыллык китердем. Хәзинә табабыз, имеш. Хәзинә эзләп башыма бәла таптым менә...

Озак та үтмәде, Җәгъфәров абый ялгыз нарат турына килеп тә җитте. Мин, аңа артым белән борылып, бөтенләй бөрешеп калдым.

— Сез нишлисез анда, оланнар?

Безгә бәлки игътибар да итми узып китәр, дип уйлаган идем мин аны, булмады.

— Эшләмибез, абый, берни дә эшләмибез, — дип җавап кайтарды аңа Гайфи, карлыккан тавыш белән.

— Ә агачка нәрсә сөядегез?

— Көрәк абый. Аның белән без кабер ташын турайтабыз.

— Кем кушты сезгә аны эшләргә?

— Беркем дә кушмады, үзебез.

— Аңлашылды, оланнар. Мин күрәм, сез хәзинә казырга килгәнсез. — Җәгъфәров абый безнең янга килеп атыннан төште. — Таш турайтучылар аның төбен генә казыйлар, ә сез бөтен кабер өстен ермачлагансыз, дөрес әйтәмме?

Мин:

— Дөрес, — диюемне сизми дә калдым.

Гайфи миңа Җәгъфәров абыйга сиздерми генә йодрык күрсәтте.

— Кабергә юкка тигәнсез, оланнар. Аның өстен хәзер үк элекке хәленә китерегез, болай калдыру ярамас.

Без, аяк асларыбызга тезләнеп, нарат төбенең актарылган урыннарын кулларыбыз белән тигезләргә тотындык.

— Монда кемнәр күмелгәнен беләсезме, оланнар?

Без, эшебездән аерылып, Җәгъфәров абыйга текәлдек. Ул, башындагы соры кубанкасын салып, кабер ташына карап тора иде.

— Бу кабергә бер генә кеше күмелмәгәнмени, абый? — диде Гайфи, гаҗәпләнеп.

— Юк, бер генә кеше түгел, күп кеше күмелгән монда. Туганнар кабере бу. Аның турында халык арасында йөргән имеш-мимешләр барысы да уйдырма. Мин анык беләм, биредә Пугачев фетнәсендә катнашкан кешеләр җирләнгән. Пугачевчылар белән әби патша гаскәрләре арасында бу тирәләрдә бик каты сугышлар булган, шактый кеше кырылган. Шыкай тавының Ямалкә тавы, ягъни Емельян тавы дип тә йөртелүен сезнең, бәлки, ишеткәнегез бардыр? Ул тау өстендә Емельян Пугачевның чатыры корылган булган. Шуннан торып ул үз гаскәрләре белән әби патша гаскәрләре арасындагы бәрелешкә җитәкчелек иткән, диләр. Мондый каберләр безнең районның тагын Чияле, Әлем зиратларында да бар. Аларның да ташлары шушындый. Кабергә тимәскә, аны карап, хәстәрләп тотарга кирәк. Авылыгызга баргач мин бүген үк бу нарат тирәсен чардуган белән әйләндереп алырга тәкъдим итәчәкмен. Бәйсез тормыш өчен баш күтәреп һәлак булган баһадир бабаларыбызга бу безнең ихтирамыбыз булыр.

— Нигә соң моның пугачевчылар кабере икәнен авылда белүче юк? — диде Сөләй, райком секретареның сүзләрен шик астына алып.

— Патшага каршы фетнә күтәргән кешеләрне әлек онытырга, истән чыгарырга мәҗбүр иткәннәр, энем. Шуңа белмиләр аны. — Җәгъфәров абый атына атланды. — Аңлашылдымы?

— Аңлашылды, абый.

— Аңлашылса, барыгыз, кайтыгыз өйләрегезгә.

Гайфи райком секретареның юлына аркылы төште.

— Абый, сезгә тагын бер сорау бар. Әйтегезче, пугачевчыларны ни өчен безнең Бәеш зиратына түгел, монда япан кырга күмгәннәр?

— Сезнең авыл зиратына мөселман динендәге кешеләр генә күмелә. Пугачев армиясе исә төрле диндәге төрле милләт кешеләреннән торган. Мөселман зиратына чит диндәге кешеләрне җирләмичә, сугышта һәлак булган пугачевчыларны япан кырга күмгәннәр. Ярый, хушыгыз, оланнар, юл кешесенең юлда булуы хәерле.

— Хушыгыз, абый.

Райком секретаре бездән шактый ук ерак киткәч, Гайфи:

— Ярый әле безне беренче Җәгъфәров абый күрде, башка берәүгә тап булсак, эшебез хөрт иде, — диде.

Кыр уртасындагы борынгы кабер безнең өчен шулай серлелеген югалтты. Берничә көн үткәч авыл яшьләре аны чардуган белән әйләндерделәр. Бу хәл Бәеш халкын бик нык гаҗәпләндерде. Яңадан әллә нинди имеш-мимешләр туды. Тик инде ышанучы бармы икән аларга хәзер? Булса да бик аз кешеләр генә ышанадыр. Иң мөһиме — инде мин аларга тамчы да ышанмыйм. Хәзер миңа басу уртасындагы ялгыз нарат бөтенләй башкача шаулый башлагандыр шикелле.

## 2

Һаҗәр апа Гайфине көзге сынауга калдырды. Ул аңа:

— Татар теле грамматикасын җәй көне бик әйбәтләп өйрән, ускәнем. Син аны начар беләсең, шулай бит? Йә, ни әйтерсең, котәм мин, — диде, ирennәрен бөрештереп.

Безнең класста җөмләнең баш кисәкләрен генә дә кара тиргә төшми таба алмаучылар азмы? Алар берниндн хәвеф-хәтәрсез җиденчегә күчтеләр, ә арабызда грамматиканы иң яхшы белүче Җирән

күзгә сынауга калды. Гаделлекме инде шул? Гайфинең Һаҗәр апага күзен сынау бирмәячәге көн кебек, бу аның класста утырып калуы дигән сүз.

Гайфи укытучыга җавап бирмәде, тын гына утырды.

— Ник дәшмисең, Бәдретдинов, әллә сөенечеңнән телеңне йоттыңмы? — Һаҗәр апа кеткелдәп көлде.

— Көлмә, апа, сиңа еларга туры килмәсен әле, — диде Гайфи аңа тыныч кына.

Укытучының йөзе җитдиләнде, иреннәре яңадан бөреште.

— Әйт әле, үскәнем, ничек елатмакчы буласың син мине? Кемгәдер җалу бирүеңнән курыкмыйм, башыма таш белән орсаң гына инде...

— Таш эрәм итеп тормам, апа.

— Соң?

— Соң түгел, вакыты килер, белерсең. Ашыккан ашка пешкән...

Һаҗәр апа мондый җавап көтмәгән иде шикелле, кызарынды. Ул үзалдына сөйләгәндәй:

— Кызык, бик кызык бит әле бу, — дип куйды.

— Кызыгы алда аның, апа, — диде Гайфи, мәгънәле итеп. — Мине син озак, бик озак искә алырсың әле! Бу мәктәпкә мин яңадан эз дә басмаячакмын, көз көне рус мәктәбендә укый башлыйм. Шуңа күрә синең фәнеңнән күзгә сынауга калдым ни дә, калмадым ни миңа.

Ярсудан Һаҗәр апаның какча чырае алаланды. Җирән аның үзенә ташлануын көтеп тормады, букчасын култык астына кыстырып, ачык тәрәзәдән тышка сикерде.

Укытучы аның артыннан тешләрен шыгырдатып:

— У-у-у, разбуйник! — дип калды.

Гайфинең әтисе Бәһави абзый — урманчы. Кайчан да аны ат өстендә күрәсең. Кызык кеше ул. Кабарынган күркә белән бер. Авылдашлары, Хәчтери Бәһавиның сүзләре авызыннан түгел, бөереннән чыга, диләр көлеп. Ябык гәүдәле, кышын да, җәен дә башына мескен бүрек киеп йөргән бу агай хуҗалыгында аркылы ятканны буйга да алып салмый. Аның өендә бөтен эш хатыны Газизә апа өстендә. Ләкин Газизә апа иреннән беркайчан да зарланмый. Кешеләр, Бәһавига ир булып селкенеп йөрү харам аңа, диләр. Бәһави абзыйның иң сөйгән шөгыле — ләчтит сату.

Гайфи тәрәзәдән сикергәч өйләренә кайтып китмәгән, безне көтеп торган. Без чыккач ул:

— Әйдәгез, малайлар, Чәтертәнгә барабыз, — диде.

— Үрдәк йомыркалары җыяргамы? — дип кызыксынды Сөләй.

— Теләсәк, аларны да җыярбыз. Тик хәзер үрдәкләр утыра, йомыркалары ашарлык түгел инде аларның.

— Башта кайтып тамак туйдырырга кирәк, — диде Кәрим.

— Кем сиңа хәзер үк барабыз ди?

Без өйләребезгә таралып ашап-эчкәч, Чуал күперенә җыйналдык.

Чәтертән — сазлык. Кыр үрдәкләре, тәкәрлекләр, тартарлар, бытбылдыклар дөнья анда. Сазлыкның бер читендә Питрәй спирт заводына ягарга торф чыгаралар. Эре саман кирпечләр кебек киселгән торф штабельгә челтәрләп өелеп, кояшта киптерелә. Торфлык — тузбашлар оясы. Анда аларның метрдан аз гына кыскараклары да, карандаш озынлыгындагылары да, чыбыркы кебек юаннары да, камчы шикелле нечкәләре дә бар. Мирсәет абый, юаннары аларның — ана, нечкәләре ата еланнар, ди.

Тузбашның агусыз икәне, тешләсә дә зыян китермәве беребезгә дә сер түгел. Әмма Гайфидән башкаларыбызның аны тотканы юк. Гайфи исә тузбашларны тотып кына калмый, тоткач муенына урый,

куенына тыга, кесәләренә салып йөри. Узган көз хәтта бер тузбашны букчасына салып мәктәпкә дә алып килгән иде. Мирсәет абый аны, фармалинлы су тутырылган пыяла банкага урнаштырып, биология кабинетындагы шкафка куйды. Былтыр җәй көне Сөләй дә Чуал буенда керәшә оясы караганда бер тузбашны белмичә тоткан булган. Көз көне укый башлагач, ул бик озакка кадәр, күзләремне йомсам, кулыма елан урала итеп тоям, дип йөрде.

Гайфи өсте капкачлы бәләкәй агач чиләк тоткан иде. Чәтертәнгә торфлыкка юнәлдек.

— Анда безгә нәрсә калган, кыр үрдәкләре камышлыкта бит, камышлыкка барыйк, — диде Кәрим, Чәтертәнгә җитәрәк.

— Тузбашлар калган, — диде аңа Гайфи. — Син телисәң, бар, кыр үрдәкләрен кара, миңа алар кирәкми.

— Мин дә тузбашлар янына бармыйм, — диде Сөләй, тукталып. — Синең ул нәҗесләр кызык булгач та, без җирәнәбез алардан.

Гайфи миңа борылды.

— Син дә бармыйсыңмы, Ирек?

— Миңа барыбер.

Кәрим белән Сөләй камышлык арасына борылдылар, без Гайфи белән ары киттек. Аяк астында дерелдәп торган бер түмгәктән, менә батам, менә батам, дип шундый ук дерелдек икенче түмгәк өстенә сикергәләп йөрергә үрдәк күрмәгәнме мин?!

Торфлыкта авыр ис. Баш өстендә генә чыелдашып тәкърлекләр оча.

Гайфи аларга:

— Ояларыгызны туздырырга килмәдек, зинһар, чинамагыз юкка, мөгезле шайтаннар! — диде, йодрык селкеп.

Тәкърлекләр Җирәнне тыңламады, баш түбәләрендәге бер тотам озын кара йоннарын кабартып, кычкыруларын белделәр.

Торф штабельләре арасында без берничә тузбаш очраттык. Ләкин Гайфи, кечкенәләр болар, миңа сазаганнары кирәк, дип аларны тотмады. Без, торфлыкны аркылыга-буйга әйләнеп, тагын ике зур, юан тузбаш тоткач, кайтырга чыктык.

— Нигә кирәк алар сиңа? — дип кызыксындым мин яңадан.

— Күп белсәң тиз картаерсың, Ирек дус. Хәзергә белми тор.

Гайфи көлде. Нигә шул кадәр кире, үзсүзле икән ул?

— Үзең дус дисең, үзең яшерәсең, дуслык шулай булмый.

— Буаз еланнар болар, үрчетергә уйлыйм мин аларны, бик беләсең килсә.

— Ник үрчетәсең?

— Кирәк.

— Әллә елан ашыйсыңмы син?

Дустымның күзләре дүрт булды.

— Җүләр дисеңме әллә мине? Акылдан шашмадым әле елан ашарга. Тик кара аны, бу тузбашлар турында берәүгә дә теш агартма. Кәримгә дә, Сөләйгә дә, бүтәннәргә дә. Кирәк алар миңа. Нигә кирәк булганнарын соңыннан белерсең...

Гайфи тузбашларны ни өчен тотканын тәки әйтмәде миңа.

### 3

Икенче көнне мин Сөләй белән Чуалга балык тотарга төштем. Кәрим белән Гайфи безгә иярмәделәр. Берсе, өйдә эш бар, икенчесе, кәефем юк, дип сылтау тапты.

Балыкка Сөләй белән генә төшсәк тә, уңдык тагын. Тын тугайдан кызыл канатлы бәртәсләрне берәм-берәм чүпли торабыз.

— Юлыма Бәдәр җиңги очраса, гел шулай минем, — ди Сөләй,

калкавычыннан күзләрен алмыйча. — Мәктәпкә барганда аны күрсәм, дәресләрне әзерләмәсәм дә, «кытый» алмыйм. Бүген дә монда төшкәндә аны очраткан идек, күрәсең, балык кабып кына тора. Әллә ни зурлар түгел түгелен, әмма кыздырырга бер дигәннәр. Тагын бер-ике чабак та капса, бүтән утырмыйбыз, кайтабыз аннары.

Рәхәт балык тотуы! Көн җылы, тын. Черкиләр дә бимазаламый. Талларда кошлар сайрый, шомыртлар бөтен әйләнә-тирәгә хуш ис таратып, ак күлмәк кигән кызларга охшап, шау чәчәктә утыралар. Кармакка селәүчән кидереп суга саласың, шундук калкавыч селкенә — балык чиртә башлый. Кармакны вакытында судан тартып чыгарырга өлгермәсәң, селәүчәннән җилләр исә. Монда гел балык капмаса да, тынчу, кысан класста утыру түгел инде бу. Безнең эшләр хәзер шәп, каникуллар башланды, дәресләргә әзерләнәсе дә, һәр иртәне мәктәпкә ашыгасы да юк.

Сиздерми генә яныбызга Миләүшә килеп чүгәләде. Яланаяк, башына тузганак чәчәкләреннән бик матур такыя үреп кигән, йөзе шат.

— Кабамы балык? — дип кызыксынды ул, шыпырт кына.

Мин чиләккә ымладым:

— Әнә кара.

— Һе, никадәр! Икегезнекедәме бу?

— Юк, минекеләр менә бәйдә, — диде Сөләй, мактанып.

— Икенче төшкәндә миңа да әйтегез яме, Ирек.

— Балык каптыра белмисең ич син.

— Өйрәтерсең.

— Мәле каптырып кара, рәт чыгарлыкмы икән?

Мин Миләүшәгә кармак сабымны тоттырдым. Ул, кармакны судан чыгарып селәүчәнен чын балыкчыларча тикшергәч, аңа төкерде дә су читенә үк басып:

— Балык кап, яр буенда ялтырап ят! — дип кармак җебен тыныч тугайга ыргытты.

— Карап карыйк, нәрсә кабар? — дидем мин Миләүшә кулындагы кармагымның калкавычына текәлеп.

Сөләй кеткелдәп көлде.

— Болай җиренә җиткереп әфсен укыгач, нәрсә капсын, бака кабар!

Шул мәлдә үк Миләүшәнең калкавычы тын тугай өстендә кечкенә бөҗралар уеп уйнаклый да башлады.

— Ал инде, ал!.. — дип инәлдем мин Миләүшәгә. — Селәүчәнне ашый да китә бит хәзер, авыз ачып каласың...

— Китми торсын!.. — Кыз кармак сабын ашыкмый гына үзенә тартты һәм зур гына бер чабак өстебездә ялтыравыклы дуга ясап, яшь үлән кыяклары арасына барып төште.

— Менә бу балык дисәң дә балык! — диде Сөләй, көнләшеп. — Хәзер минем кармакны сал син, Миләүшә. Кулың җиңел икән синең.

Кыз каршы килмәде, Сөләйнең кармагын алып, су читенә басты. Без яңадан тын да алмый аның калкавычына текәлдек.

Шулчак яр өстеннән Гайфинең:

— Менә алар кайда икән, эзли-эзли җаным чыкты, — дигән сүзләре ишетелде. — Ничек, шәп кабамы балык?

— Ярыйсы болай.

Гайфи яр өстеннән безнең янга төште һәм хәйләкәр елмаеп:

— Сезгә сөенче әйтергә килдем, — диде.

— Нинди сөенче?

— Бичура үкерә, Бичура елый, бөтен авылны сасытты.

— Нәрсә булган аңа?

— Өендә еланнар үрчегән, ди.

— Нинди еланнар?

— Нинди икәннәрен белмим, үзе кебек үк зәһәрләрдер инде.

Мирсәет абый барып икесен тоткан, тагын бар, имеш. Бичура капкасы төбендә үкереп утыра, анысын үз күзләрем белән күрдем. Өйгә кайтып керсәм, өстәлемдә елан бөгәрләнеп яткан, идәндә дә елан, дип сөйләнә. Аның сандыгы эчендә дә, күәсендә дә, бүтән җирләрендә дә бардыр әле алар.

— Мескен ничек торыр инде ул өендә? — диде Миләүшә, Һаҗәр апа өчен борчылып.

— Таптың кызганыр кеше!.. Торыр, ник тормасын. Үзе үк куып җибәргән әнисен Чаллыдан кабат чакыртып китерер, — диде Гайфи, тантана итеп. Ул елмаеп миңа күз кысты. Тузбашларны нигә тотканымны инде төшендеңме, янәсе.

Төшенмәгән кая, төшендем, Җирән. Аларны укытучы өенә җибәрер өчен тотканыңны белсәм, Һаҗәр апа нинди генә начар кеше булмасын, моңа юл куймас идем, дип уйладым мин. Чыннан да, хәзер ничек торыр ул өендә? Еланнарның анда күпме икәннәрен белсә, бер хәл иде, белми бит...

Балык каптыруның миңа кызыгы бетте. Кармагымны җыеп чиләгемне алдым да өйгә юнәлдем. Бераздан Гайфи артымнан куып җитте.

— Әгәр еланнарны мин җибәргәнне кешегә әйтсәң, үз өегезгә урманнан зәһәр еланнар алып кайтып җибәрәм, — диде ул миңа янап.

— Мине син үзең күк җүләр дисеңме әллә?

— Җүләрлек түгел бу, гаделсезлек өчен үч алу.

— Кансыз син.

— Шуны җәллисеңме?

— Җәллим. Пионерлар бит без.

— Һаҗәр апа да комсомолка алайга калса. Нигә ул укучыларны җәберли, нигә үч итеп көзге сынауга калдыра?

— Бу турыда без минем этигә, җә Җәгъфәров абыйга әйтик.

— Алар аны игә китерерләр дисеңме? Бөкрене кабер генә төзәтә, ди әнә Камали бабай.

— Мин аны игә китерерләр дим. Тик аннан алда өченче еланны Һаҗәр апа өенә кереп, үзеңә тотарга кирәк.

— Өченче елан юк анда. Аны мин кичә өйдә мәчедән будырдым.

— Алдашасың.

— Кояштыр менә! Мәчеләр елан тоталар, дигәнне ишеткәнем бар иде, шуны сынап карадым. Әһ тә итмәде мырауҗан, буды.

Минем күңелем тынычланып китте.

— Аның өенә ничек кердең соң син?

— Суга киткәнен сагалап тордым. Кергәч, бер еланны өстәленә, икенчесен гөл төбенә ташлап чыгып сыздым.

— Җүләр син, күрсә җаныңны алган булыр иде бит ул, шулай үч алалармы?

Гайфи дәшмәде, иңемә кулын салып, тирән көрсенде. Мин моны аның эшләгән акылсызлыгы өчен үкенүе дип аңладым.

## Алтынчы бүлек

### 1

Миләүшәнең иң яраткан эше — көтү куу. Һәр иртәне ул миңа да тынгы бирми. Сыерларын таң тишегеннән торып сава да, безгә кереп мине:

— Ирек, әйдә тор, көтү куабыз, — дип уята.

Мин, йокым бик килсә дә, торам. Көтү куар өчен түгел, Хәйрүш абзыйның туплауда курай тартканын тыңларга торам. Йокымны качырырга битемне бер куш уч салкын су белән чылаткач, Мүкләкне

урамга чыгарам. Миләүшәне капка төпләрендә ала сыерлары көтеп тора. Офык читеннән иренеп кенә кояш күтәрелә бара. Аяк астындагы яшь чирәм кыякларында чык бөртекләре ялтырый. Һәр йорттан берәм-берәм сыерлар, сарыклар, кәҗәләр чыгып, урам буйлап туплауга атлыйлар. Кинәт иртәнге тын һавада авыл башыннан курай тавышы ишетелә башлый. Миләүшә белән без терлекләр аяк астыннан ялкау гына күтәрелгән тузан исен дә сизмичә, сыерларыбызга тагылып, авыл башына таба сихерләнгәндәй атлыйбыз. Без туплауга барып җиткәндә көтү инде җыелып беткән була.

— Мәмрәп йоклап ятар чакта ник йөрисез сез, балалар? — дип каршылый безне Хәйрүш абзый. — Үз сыерыбыз белән сезнең Мүкләгегезне мин дә алып килә алам бит монда. Юк, сезгә таң тишегеннән күз ертып әбәзәтелне туплауга килергә кирәк. Ярар инде, бер килгәч, әйдәгез, терлекләрне тау итәгенә алып чыгарга булышыгыз алайса. Син, Ирек, әнә теге сакалбикәләрне бакчаларга җибәрмә, син, кызым, ашлык басуы ягын кара.

Көтү авылны чыгып, Чуал буендагы карсак куаклар арасыннан тау итәгенә юнәлә. Ара-тирә терлек аяк астыннан тургайлар ук кебек күккә күтәреләләр дә, биектә чикләвек кадәр генә кара ноктага калып, сайрарга керешәләр. Алар миңа зәңгәр бушлыкта ара-тирә йөзгән мендәр кадәр генә сыек болытларга эленгән көмеш кыңгырау булып тоелалар.

Ниһаять, көтү тау итәгенә таралып үлән кырка башлый. Хәйрүш абзый терлекләрне күзәтергә уңайлы урын сайлап, туктап кала.

— Тирәгездәге матурлыкны карагыз, соклангыч бит, балалар, — ди безгә көтүче, як-ягына күз ташлап. Ул башындагы киез эшләпәсен сала, кожанын җәеп җиргә җайлап кына утыра, озын чыбыркысын җыеп янына куя. Аның тирләгән чал чәчләреннән сизелер-сизелмәс кенә пар күтәрелә, калын кашлары астындагы соры күзләре кысыла төшә, битендәге җыерчыклары тирәнәя.

Без дә җиргә чүмәшәбез.

— Сез нәрсә дә булса сөйләвемне көтәсез инде, — ди Хәйрүш абзый безгә елмаеп. — Нәрсә турында сөйлим икән соң?

Мин тирәбездәге абагаларга күрсәтәм.

— Менә алар турында сөйләгез.

— Абага турында Мирсәет абыегыздан сорарга иде сезгә. Ул бик яхшы белә булыр абаганы. Ә мин фәнчә сөйли белмим. — Хәйрүш абзый янындагы бер абага яфрагын өзеп, аны җентекләп карады. — Әйдә, сорагач, үзем белгәннәрне сөйлим алайса. Безнең эти мәрхүм, абага бик борыннан килгән үлән булырга тиеш, шахтада күмер катламнарында да аның сурәтен күргәнем бар минем, дия иде. Яшь чагында шахта казыган кеше иде ул. Мал ашамый абаганы — туклыксыз, каты ул. Чәчәк атканын берәүнең дә күргәне юк абаганың, сабагы да булмый, әмма орлыклары була. Орлыклары яфрагының аскы ягына тезеләләр. Керәшеннәрдә кызык кына риваять бар абага турында. Җәй уртасында аларның Питрау дигән бәйрәмнәре була. Шул бәйрәмгә каршы төндә әлеге абага чәчәк ата, имеш. Чәчәге гади булмый, күзләрне камаштыргыч нурлар сибеп яна, аны җен-пәриләр, төрле убырлар, өрәкләр бик тә хәтәр саклыйлар, имеш. Шул шайтаный кочләрдән тамчы да курыкмыйча абага чәчәген өзеп алып авызыңа капсаң, дөньяда нәрсә теләсәң, шуңа ирешәсең, имеш. Тик абага чәчәген саклаучы җен-пәриләр, убырлар аны авыздан төкертергә тырышып таңга кадәр җәфалыйлар, шуларның җәберләүләренә түзәргә, авызыңны ачмаска кирәк, ди. Бу сөйләгәнем әкият, кәнишне. Абага турында минем бөтен белгән нәрсәм шул гына, балалар. Юк-бар такылдаганчы, тургай булып сайрап күрсәтим әле сезгә. — Хәйрүш абзый куенынан кураен тартып чыгарып иреннәренә тери.

Мин ирексездән күзләремне йомам. Колак төбемдә үк тургай моңы ишетелә. Башта талгын гына, аннары көчәйгәннән-көчәя барып, әйләнә-тирәгә тарала, башка авазлар кинәт юкка чыга. Гүя, мин күктә, биектә тургай янәшәсендә үк канат җилпим. Аста — чәчәкле болын, бормаланып-бормаланып аккан Чуал, Каршы тау, урман, иген басулары. Йөрәгем, күкрәк читлегемне ватып чыгардай булып, ашкынып тибә. Бөтен тирә-юнемдә нурлар, салават күперен хәтерләткән аллы-гөлле, яшелле-зәңгәрле, кызыллы-сарылы сихри нурлар...

Курай тавышы тынгач, мин күзләремне ачам. Хәйрүш абзый:

— Бүгенгә җитәр, барыгыз кайтыгыз инде, балалар, — дип эшләпәсен киеп, урыныннан торды.

Бик аз, бик аз уйнады ул, мин аны көне буе тыңларга да риза бит...

Миләүшә:

— Без иртәгә дә килербез, яме, әти, — ди.

Хәйрүш абзый көлә.

— Ихтыярыгыз. Көтү кууны йокыдан артык күрсәгез, килә бирегез.

Ул кала, без авыл ягына юнәләбез. Минем колак төбемдә һаман тургай тавышы чыңлый. Күктәге тургайлар тавышы түгел, сихри, бөтенләй бүтән тургай тавышы. Мин аннан озак, бик озак арына алмыйм...

Авылга җитәрәк Миләүшә миңа:

— Ирек, син сер саклый беләсеңме? — диде.

— Беләм бугай. Нигә сорыйсың?

— Мин сиңа бер нәрсә күрсәтсәм, аның турында берәүгә дә әйтмәссеңме?

— Әйтмәм, күрсәт.

— «Валлаһи» дип ант ит.

— Валлаһи. Әгәр әйтсәм, күзләрем чәчрәп чыксын.

Миләүшә, бераз икеләнеп торгач, алъяпкыч күкрәкчәсе астыннан бөти итеп төрелгән кәгазь чыгарып, миңа сузды.

— Мә, кара.

Бөтине сүткәч мин гаҗәпләнүемнән туктап калдым. Анда бик матурлап чәчәк төшерелгән һәм:

«Миләүшә! Урамнарны чыккан чакта Түгелде сәйләннәрем. Әйтче миңа, пажалысты, Кем синең сөйгәннәрең? Җавап хаты көтәм. Син аны чишмә янындагы тишекле таш астына иртәгә үк язып сал», — дип сырланган иде. Чәчәкләрне шулай матур итеп малайлар арасында тик Сөләй генә төшерә белә. Кулы да аныкы. Менә Тәкәрлек ничек килештереп язган! Аңардан көнләшеп тә куйдым. Миләүшәне кемнең дә булса сөя алуы, аңа шушындый хат язу мөмкинлеге гамемә дә керми иде. Моңарчы ул миңа классташым, күршем генә иде. Бүтән кызлардан аермасы һич юк иде, менә инде аңа гыйшык хаты язганнар. Кем язган бит әле?! Минут саен борынын тарта торган тырпык колаклы, сипкел оясы Сөләй язган. Бу сәер хатны укыгач, әнисенеке шикелле үк җыйнак гәүдәле, очы күсе койрыгына охшаган юка толымлы Миләүшәне бөтенләй алыштырып куйдылар төсле тоелды миңа.

— Җавап яздыңмы? — дидем мин аңа, бөтине кире биреп.

— Бик кирәге бар, җавабымны бөтен кешегә күрсәтеп көлер иде бугай. Минем кемне сөюемдә аның ни эше бар?

Мин көлеп җибәрдем.

— Кемне дә булса сөясеңмени инде син?

Миләүшә кып-кызыл булды. Аннары миңа әтисенеке кебек үк соры күзләрен текәп:

— Сөям шул, сөям, — диде һәм кинәт борылып Чуал буена йөгерде.

Мин баскан урынымда катып калдым. Менә, беләм дип йөр кешене!.. Кемгә гашыйк икән ул, кемгә? Авылдагы бөтен малайларны берәм-берәм күз алдымнан үткәрдем, тик алар арасында Миләүшәнең күңелен яулардай берәүгә дә туктала алмадым.

## 2

Төнге урман — сүрән ай яктысында тылсым оясы, сихри дөнья. Ул әкият патшалыгы сыман шомлы да, мәһабәт тә, куркыныч та, искиткеч гүзәл дә. Һәр агач, һәр куак, һич уйламаган җирдә кукраеп утырган һәр черек төп төнге караңгыда көндезгечә түгел, ничектер җанлы, серле булып тоела. Төнге урманда һәр адымыңны чишелмәслек табышмак сагалый кебек. Аяк астында чыртлап сынган һәр чыбык кисәге, һәр кыштырдау тавышы, һәр аваз күңелгә шом сала, сулышны кыса. Аланлыкларда ай нурларына коенып утырган яшь каеннар әйләнә-тулгана биеп китәрләр, агачларның төбәнге ботаклары көчле кулларга әверелеп сузылырлар да, искәрмәстән эләктереп җирдән аерырлар төсле. Шырлыклардагы төн карасыннан, күзләрендә ут уйнатып, шаркылдап көлә-көлә, килбәтсез кулларын җәеп, шыксыз шүрәле килеп чыгар сыман...

Камали бабай белән без, унлап малай, урманда атлар саклыйбыз. Өсләребездә барыбызның да йә иске тун, йә иске бишмәт, йә таланып беткән сырма. Һәркайсыбызның кесәсендә пәке. Урманда төнлә ни булмас, пәке — корал. Аны тиз генә язып кулыңа кысып тотасың, бүре-мазармы, бүтән берәр нәрсәме янына килеп карасын, кизәнеп кадыйсың, эх тә итәргә өлгерми аягын суза. Көлдә пешкән бәрәңге исе дә төрле ерткычларны, урман пәриләрен кеше янына якын җибәрми, ди. Ул хәзинә дә җитәрлек бездә — учак астына ярты капчык күмдек әнә.

Атларны кичтән үк Әләкси әрчүенә тышаулап җибәргәч, без караңгы төшкәнче шырлыктан төне буена җитәрлек чыбык-чабык җыеп килеп учак тергездек. Хәзер менә шуның тирәли тезелеп, бәрәңге пешкәнне көтәбез. Без — дүрт дус: Кәрим, Гайфи, Сөләй һәм мин Камали бабай янәшәсендә — иң дәрәҗәле урында. Кәрим учактагы ялкыннарга карап, бөтен урманны яңгыратып җырлый:

> Без кабызган утлар сүнмәс алар,
> Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...

Шөлдер белән күңелле. Аның җырламаган чагы сирәк. Нинди генә җырын да дөньяңны онытып тыңлыйсың.

> Без үскәндә урман, басуларың,
> Болыннарың миңа ят иде,
> Алпавытлар белән байгуралар
> Хуҗа иде сиңа, баш иде...

Кәримнең җырлавы тынып торган арада атларыбызның урман әрчүендә пошкыра-пошкыра үлән кырыкканнары, колыннар муенына тагылган кечкенә кыңгырауларның ара-тирә көмеш тавыш белән чыңлап куюлары ишетелә.

Учакка чыбык-чабык өсти торабыз, ул, шарт-шорт килеп, очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә яна.

Камали бабай:

— Утка бик якын утырмагыз, балалар, өстегезгә очкын төшәр, сак булыгыз,— дип безне кисәтә тора.

Без сабырсызланып бәрәңгеләрнең тизрәк пешкәнен көтәбез. Һай, тәмле дә була бит ул урман учагында пешкән бәрәңге! Аның үзенә генә хас исе ни тора... Кайбер атлар кушаяклап сикерәсикерә учак янына киләләр. Камали бабай шундук урыныннан калкып ат янына бара.

— Тыгызрак тышауладылармыни, җанашым, аякларыңны авырттырамыни? Кая, тикшерим әле... Тыгызрак икән шул. Хәзер бушатабыз аны. Менә булды. Бар, җанашым, иптәшләрең янына, аша, ял ит.

Ат, картның сүзләрен аңлагандай, борылып китеп бара.

Атларны Камали бабай шикелле чын-чынлап яраткан бүтән кешене очратканым юк әле минем. Камали бабай өчен һәр бахбай җанаш, ул теләсә нинди ат белән дә сәгатьләр буе сөйләшә ала. Атлар аны аңлыйлар кебек. Ат белән тупас кыланганыңны, аңа сукканыңны күрсә, елап ул. Камали бабай сине бахбайлар тирәсенә якын да җибәрми.

— Бар, наным, тай бу тирәдән, сиңа Газраил гына юлдаш булырлык,— ди.

Малайларга гына түгел, олыларга да шулай.

Менә учак янына бер колын килде. Ул утны гомерендә беренче кат күрә бугай, безнең башлар аша сузылып аны иснәргә, ялкын телләрен йомшак иреннәре белән ялмап карарга чамалый. Без аңардан тын гына көләбез.

Шулай озак та үтмәде, урман тынлыгын ярып, якында гына ат кешнәде. Кешнәү тавышын ишеткәч, колын учактан борылып, мин монда, әни, монда, борчылма, дигән кебек кешни-кешни караңгылык эченә чапты.

— Караңгыда колыннар үз әниләрен ничек бутамыйлар, таныйлар икән? — диде малайларның берсе.

— Аттан да акыллы хайван җук,— диде аңа Камали бабай, учак көлендәге бәрәңгеләрне кулындагы таягы белән уттан берәмберәм читкә тәгәрәтеп.— Җәш чакта минем бер туры алашам барые. Тышаулаганны бер дә җаратмыйдырые шул. Болында тышаулап җибәрсәм, кушаяклап сикерә-сикерә үз артымнан ук кайтып җитәрие. Бүтән комагай атлар шикелле, шуның беркайчан да игеннәр таптаганы да, эзли-эзли җыгың чыгардай җиргә олакканы да булмады. Вакыты җиткәч, турыбызга үзе кайтып капка биген авызы белән ачарга азапланырые. Бер кышны шулай Чуалдагы бөтен тегермәннәрнең буәләре китте. Суыксуның күрәзә Нәбиулла, Исмай байга ачу итеп, Чуалга терекөмеш җибәргән, буәләрне шул җарган, дип сүләделәр. Энесе Исхак байда бер җыл хезмәтче булып бернинди хак та алмаганга эшләгән ул аны, диделәр. Тегермән буәләренең терекөмештән китүләре хак булгандырмы, җуктырмы, белмим, кешеләрдән ишеткәнемне әйтәм. Берзаман безнең өйдә он бетте. Чуалда он тарттырырга бер тегермән дә эшләми. Он булмагач, арыштан ботка пешереп карадык, тәме җук, тиз җепкертте. Онсыз торып булмый бит, алашамны җиктем дә, чана төбенә бер капчык арыш салып, киттем Кесәләү тегермәненә. Анда бер тәүлек чират көтеп җаткач, тарттырдым арышны. Мин тегермәндә җаткан арада көн бозылды, чыкты буран. Кайтасы җир байтак — унҗиде чакрым. Буран басылганны көтеп җатырга чама җук, атның да азыгы бетте, үземнең дә ашарыма шымытыр. Кем әйтмешли, бүрек белән киңәштем дә, чыктым кайтырга. Караңгы төшәргә күп калмаганые инде, буран галәмәт тә көчле котыра, әйләнә-тирә түгел, атның дугасы да күренми. Алашам, тегермәннән чыгып күп тә китмәде, юлдан язды. Аны кире борырга итәм, тыңламый, корсагыннан көрткә бата-чума алга баруын белә. Караңгы да төште. Чамам буенча без инде Никкүчтемгә күптән җитәргә тиеш, җук ул. Миңа атым гел бер урында әйләнә төсле. Башыма берсеннән-берсе шомлырак уйлар керә, бетүем шушы икән, кайтырга үз башымны бетерергә чыкканмын, дип каударланам. Үкенеп бетә алмыйм буранда өйгә ашыгуыма. Атны туктатып берәр төрле ут мазар күренмәсме дип чанага басып як-ягыма да каранам, этләр өргәнне

ишетмәмме, дип тыңланам да. Җук, ут та күренми, буран улавыннан бүтән тавыш та ишетелми. Бер заманны сизәм, атым каты юлга чыкты. Әчемә җан кереп китте, булдырды малкай, җулны тапты, дип уйлыйм. Бераз баргач туктады бу. Әйдә җул табылгач туктама инде, дип дилбегәне кагам. Кузгалды да читкә борыла башлады атым. Дилбегәне тартам, тыңламый. Шуннан соң аны туктатып, чанадан төштем дә, җул катысына чыгардым. Атым, җул буйлап аз гына барды да тагын борыла башлады. Дүрт-биш тапкыр шулай итте. Ни булды моңа, дип уйлыйм. Җулны бер тапкач җугалтасы килми, аның нинди дә булса авылга илтеп кертәсен беләм. Тегермәннән чыккач, җил җүнәлешен чамалаганыем, шуңа җулыбыз Бәешкә алып кайта сыман тоела. Алашам җулдан җаңадан да читкә керә башлагач, мин чанадан төшеп, аны тезгененнән тотып бераз алып бардым. Малкай күндәм генә китте шуннан соң. Мин башыма капчык бөркәнеп элеккечә үк чана төбенә йомарландым. Сөякләремәчә туңудан тешләрем тешкә тими. Җарлы кешенең элек киемсалымы авыл эчендә генә җөрерлек булаые бит аның. Өстемдәге бөтен аламаларым буранда юешләнеп, шакраеп катты, аяк-куллрымны сизмәс булдым. Күпмедер вакыттан соң этләр өргәне ишетелде. Йә, ходай, җыясы ризыгым бетмәгән икән эле, кайтып җиттек, дип сөендем. Үзем башымны капчык астыннан чыгарып карамыйм, җатам чанада, атның капка төбенә кайтып туктавын көтәм. Туктады бу бервакыт. Капка ачарга дип сикереп чанадан төштем. Үземә-үзем ышанмыйм, безнең капка түгел алдымда, шулай да таныш капка кебек. Бәештән җегерме чакрымдагы Нажар авылындагы баҗай капкасы булып чыкты ул. Бөтенләй кире җакка киткән булганбыз. Ат Бәеш җагына борылырга иткәч, аны үзем бутаганмын. Җугыйсә ничәмә-ничә тапкыр кирегә борылырга итте, җанашым. Шуннан соң Нажарда кунып, икенче көнне буран басылгач, авылга кайттык. Ат акыллы, дөньяда иң зирәк хайван ул, балалар. Теле генә җук, кеше күк сүләшә генә белми. Аңлавын бездән күбрәк аңлый, белүен бездән күбрәк белә...

Камали бабай туры алашасы турында сөйли-сөйли ризыкны көлдән казып чыгарып бетергәч, без бармакларыбызны, авызларыбызны пешерә-пешерә бәрәңге ашарга керештек.

— Хәзер җен-пәриләр килмиләр дә килмиләр инде безнең янга,— дип куйды Идрис исемле малай, як-ягына каранып.

— Килсеннәр, кем алардан курка? — диде аңа Сөләй.— Әнә утлы кисәүләр никадәр, алдык, тондырдык. Кая керер тишек тапмаслар!

Камали бабайга җен-пәриләрне искә алу ошамады.

— Тәмле авызыгызны тәмсезләп, минем алда җук-бар турында гәп сатмагыз, балалар. Җәшем җитмештән артты менә, әмма да ки бернинди җен-пәри дә очратканым җук моңарчы. Моннан соң да очратмам, аллаһы теләсә,— диде ул.— Халыкта тагын өй иясе, абзар иясе бар, абзар иясе атларны бик җарата, аларның җалларын үрә, дип сүлиләр. Мин шулай бер заман туры алашамның җалы үрелгәнен күрдем. Сүттем моны. Икенче көнне тагын үрелгән бу. Балалардан, сез үрмәдегезме, дип сорыйм, җук, диләр. Абзар иясе үрә болай булгач, бүтән түгел, дим үземә. Сагалап җатып күрергә булдым моны. Җәйге шушындый айлы төние, абзар түбәсенә менеп җаттым. Ат улакта печән кетердәтә, мин күзәтәм. Күрәм бервакыт, тынычсызлана башлады малкай. Җалында берни җук үзенең. Күземне ачыбрак карасам, атның җалында нindидер ак нәрсә бөтерелә. Үзе чыек-чыек килә. Абзар түбәсеннән сикереп төшеп эләктереп алдым моны. Ләтчә икән, муенын борып чөйдем. Шуннан ары атның җалын үрүче булмады.

Камали бабай гел шулай, аның янында куркыныч нәрсәләр турында искә алырмын димә, сүзне шундук икенчегә бора, сөйләт-

ми. Бүтән берәү әллә ниләр ялганлар иде, ул үз башыннан кичкән, үзе күргән нәрсәләрне генә сөйли.

— Иң җавыз җан иясе — кеше. Аңардан да җаман берни җук.— ди ул.

Дәү калай чәйнеккә җиләк яфраклары салып, чәй кайнатып эчкәч, без малайлар әрчүгә төркем-төркем булып йокларга таралдык. Камали бабай учак янында калды.

— Озакламый яктыра да башлар, балалар, сез черем итегез. Атларны да, сезне дә үзем сакларммын.— диде ул.

Без, дүрт дус, әрчү читенә китеп, башкалардан аерым яттык.

Төнге күктә никадәр йолдыз! Алар учак янында гына күренмәгәннәр икән. Әнә, күкнең бер читеннән икенче читенә күзгә кара җир өстенә саран гына иңгән беренче карга охшап, Киек каз юлы сузылган. Әнә Ай янында Зөһрә йолдыз, Җидеган, Тимер казык һәм тагын әллә нинди йолдызлар.

Гайфи дә күккә карап ята икән. Ул:

— Карагыз әле, малайлар, Айда, чыннан да, көянтә-чиләкле кыз бар икән бит,— диде.

Кәрим аңа каршы төште.

— Андагы таулар сиңа кыз булып күренәләр, Гайфи дус.

— Айда нинди тау булсын, юк сүз,— диде аңа Сөләй.— Зөһрә кыз ул. Мин дә ап-ачык күрәм ул кызны. Халык белми сөйли дисеңме?

— Ялгыз нарат төбендә дә хәзинә бар диләр иде, — дидем мин, — булдымы?

Шундук күз алдыма аның Миләүшәгә язган чәчәкле хаты килде.

— Ялгыз нарат төбе — башка, Ай — башка...

— Әйдәгез, Зөһрә кыз турында Камали бабайдан сорыйбыз?..

— Җавабын сорамасак та, беләм, җук, диячәк. Яхшысы, әйдәгез, һәркайсыбыз күктә үз йолдызыбызны билгелик.— диде Гайфи.

Кәрим шундук торып утырды.

— Ай янында якты йолдыз, минем йолдызым гына...

— Синеке генә түгел ул, әллә кемнәрнеке дә. Без дүрт дус бит, бергә булсын безнең йолдызларыбыз да.— диде аңа Сөләй.

— Алайса Җидегәндәге йолдызларны билгелик.

Җидегән йолдыз койрыгы
Борыла микән таңнарга?
Булыр күктә безнең атлы
Яп-якты йолдызлар да!..

Менә Шөлдер дисәң дә Шөлдер, теләсә нинди җырның сүзләрен үзенчә үзгәртә дә куя.

Гайфи шундук:

— Мин үземә Җидегән чүмеченең астагы иң кырый йолдызын алам. Син, Кәрим, аның янәшәсендәгеен ал. Өстәге кырый йолдыз Сөләйгә, чүмечтәге калган дүртенче йолдыз Ирекка булсын. Килешәбезме шулай? — диде.

— Килешәбез,— дидек бертавыштан.

Мин үз йолдызыма текәлдем. Ул миңа елмаеп күз кыскандай булды. Шәп икән күктәге үз йолдызыңа карау! Моңарчы ничек беребезнең дә уена килмәгән ул, төнге күкне тәүге күрүебез генә түгел иде ләбаса?..

— Йоклыйк, егетләр, иртәгә сөйләшербез, әнә инде таң атып килә,— дип бүлде Гайфине Кәрим, башын тун чабуы астына яшерәп.— Сөйләргә сүз бетми ул, йокы килә.

— Бетте, йоклыйбыз.

Без дә башларыбызны өстебезгә ябынган бишмәтләребезнең чабулары астына яшердек.

Мин кайдадыр якында гына чут-чут итеп сандугач сайрый башлавын ишеттем һәм шуны тыңлап йокыга киткәнемне сизми дә калганмын.

### 3

Миләүшә миңа Сөләйнең чәчәкле хатын күрсәткәннән бирле күземә чалынмаска тырыша. Инде берничә көн иртәләрен, тор, әйдә көтү куабыз, дип уятырга да керми.

Әни миңа:

— Миләүшәне нигә үпкәләттең, керми, моңарчы бик тату идегез, нәрсә булды сезгә? — ди.

Мин, белмим дигәнне аңлатып, иңнәремне җыерам.

— Берәр авыр сүз әйттеңме әллә?

— Юк, берни дә әйткәнем юк.— дим.

Әни ышанмый:

— Әйткәнсең,— ди.

Миләүшә безнең Мүкләкне дә үз сыерлары белән бергә минсез генә көтүгә алып бара. Мин йоклап калам. Ул кызый хат турында мине малайларга сөйләгәндер дип уйлыйдыр бәлки? Сөйләдем, бик исем китте Сөләйнең сиңа язган гыйшык хатына.

Дөресен әйткәндә, чәчәкле хат та, Миләүшә дә күз алдымнан китмиләр. Миләүшәнең һич көтмәгәндә үземнән читләшүе борчый мине. Нәрсә булды аңа — үтерсеннәр, белмим.

«Ник мине көтү куарга уятмыйсың?» — дип керергәме икән әллә? Керәм, тик бүген түгел, иртәгә керәм. Бүген колхоз Гыйльмулла абзыйның янган каралтылары урынына яңа каралтылар кору өмәсе оештыра дигәннәр иде, хәзер шунда барам.

Әле күптәнме авыл урамы соры, шыксыз иде, инде танырлык түгел, ямь-яшел. Аяк астына бәбкә үләненнән затлы йомшак келәм җәйгәннәр төсле, түрбакчалардагы агачларны куе яфрак төргән...

Көн әле иртә булса да, кояш чамасыз кыздыра, бөркү. Чуал буеннан су коенучы бала-чага чыр-чуы ишетелә. Уйнаклый-уйнаклый түбәннән генә карлыгачлар оча. Күк чип-чиста, анда бер генә болыт әсәре дә юк. Карлыгачлар түбәннән очсалар, көн бозыла, ди Мирсәет абый. Ялганлый икән Дәһәр кадаяк, дип уйладым мин җир өстеннән үк тере уклар кебек очкан житез карлыгачларны күзәтеп. Аларның болай очуларына карап көн бозылса, төшкә җәй көне кар керсә, уянуга кыш булыр иде ул...

Мин Гыйльмулла абзыйларга барып җиткәндә өмәчеләр тирләп-пешеп эшлиләр иде инде. Кем багана төпләре казый, кем багана утырта, кем кайчы, өрлек, бәбкәлек юна. Маһитап апа кызлары белән йомычкалар җыеп йөри. Гайфи, Кәрим, Сөләй өчәүләшеп янгыннан калган кисәү башларын утынга турыйлар. Өмәчеләр арасында Мирсәет абый да бар. Калдырырсың аны мондый җирдән! Ул бүрәнә юнып ята. Биек маңгаенда, тар кылыч борынында тир бөртекләре, балтасын чапкан саен бит алмалары дерелдәп куялар. Өстендәге ак күлмәгенең җиңнәрен сызганган, изүе чишек. Кыска калдырып алынган сирәк аксыл чәчләре кояшта елык-елык киләләр.

Менә ул бүрәнәсен очына чаклы юнып чыкты да, билен язып, тирәсендәге кешеләргә:

— Яңгыр була бүген, көчле яңгыр.— диде.

— Күктә бияләй кадәр дә болыт юк, каян килсен ул көчле яңгыр? — дип каршы төште аңа Лотфулла абзый.

— Менә әйтте диярсез.— Мирсәет абый зур соры күзләрен бераз кыса төшеп елмайды.

— Бәхәсләшәбезме, мөгаллим?

— Оттырасың, Лотфулла, кирәкми, бәхәсләшмә. Барометр хәтта, бүген давыл була, ди.

— Кем, кем әйтә?..

— Кем түгел, һава торышын алдан күрсәтә торган махсус прибор әйтә.

— Дөньяда инде андый нәрсә дә бармыни?

— Бар, Лотфулла.

— Нindiрәк соң ул?

Мирсәет абый барометр турында сөйли калды, мин иптәшләрем янына барып, аларга булыша башладым.

Мирсәет абый, мәктәптәге кебек үк, авыл халкы арасында да үзен бик гади тота. Каникулда да эшсез ятмый ул. Йә юныша, йә мәктәп бакчасында кайнаша. Аның дүрт умартасы бар. Аларны караганда кулына төтәткеч тә алмый, йөзен битлек белән дә капламый. Ник бер корт чаксын үзен. Барысының да исемнәре А авазыннан башланган дүрт малае бар аның. Кечкенәләр әле. Ике өлкәне гел әтиләре янында чуалалар. Аларга да кортлар тими. Әниләре Мотахара апа:

— Мирсәет бал кортларының әфсенен белә бугай ул. Мине кортлар умарта янына якын җибәрмиләр, ә балалар белән аңа нишләсәләр дә тимиләр,— ди көнләшеп.

Әйе, Дәһәр кадаяк дип юкка атыйбыз биология укытучысын. Зәһәрлеген беркайчан да күрсәткәне юк аның. Һәрвакыт тыныч, ачык йөзле шәп кеше ул. Үзен зурга куймый, кешеләргә кулыннан килгәнчә файда китерергә тырыша. Әнә өмәдә бүтән укытучылар юк, ә ул балтасын тотып килгән.

Төш авышкач, Гыйльмулла абзыйның бөтен каралтылары инде эшләнеп бетеп килгәндә, кинәт кенә бик каты җил чыкты, бер мизгелдә бөтен әйләнә-тирә тузан болыты эчендә калды. Җил, көчәйгәннән-көчәя барып, аяк астындагы ваграк йомычкаларны һавага күтәреп бөтерә, өй, каралты-кура түбәләрендәге саламнарны күтәреп ата башлады. Ул да булмады, Чокырлы ягыннан бик ямьсез кара болыт килеп чыгып кояшны каплады. Болыт куерганнан-куерып, ишелеп Бәеш өстенә килде. Көн, кичке кебек караңгыланып, сизелерлек салкынайды. Җил аның саен котырынды. Өмәчеләр, эшләрен ташлап, үз хуҗалыкларына чаптылар. Кинәт күзләрне камаштырып, чалтырап яшен яшьнәде һәм аның артыннан ук бөтен әйләнә-тирәне дер селкетеп күк күкрәде. Күкрәү тынарга да өлгермәде, шаулап боз ява башлады. Урман чикләвегеннән зуррак боз кисәкләре коймаларга, ишегалдында чәчелеп яткан бүрәнәләргә, өсләре әле капланмаган каралты корылмаларына шак-шок бәрелделәр, җирдәге чирәмне тапыдылар. Шундук, бозга аралашып, тоташ стена булып, салкын яңгыр яварга тотынды. Тагын чалтырап яшен яшьнәде, тагын күк күкрәде. Тагын, тагын... Без Гыйльмулла абзыйның күршесе Закир абзыйның өе артына ышыкланган идек. түбәдән өстебезгә су ага башлагач, Кәримнәрнең өйалларына кердек.

Кәримнең сеңелләре өйалдының караңгы почмагына елышып җылашалар. Мәһитап апа белгән догаларын укып, аларны тун белән каплап азаплана. Гыйльмулла абзый белән Лотфулла абзый башларын түбән иеп, тар гына болдырда басып торалар.

— Арышларны харап итте инде бу боз, тәки харап итте,— дип көрсенә Гыйльмулла абзый.

— Бик үк зыян салмагандыр әле, алла саклагандыр, тау ягына китте бит,— ди аңа Сөйләйнең әтисе.— Мирсәет, барамыйдыр давыл буласын күрсәтте, дип дөрес әйткән икән, каһәр...

Тагын яшен яшьнәде. Бусында ул йөзләгән тәрәзәләрнең пыя-

лалары берьюлы ватылгандай итеп бик каты чалтырады.

— Нәрсәнедер сукты, алланың рәхмәте,— дип, Гыйльмулла абзый болдырдан үрелеп өй түбәсенә карады.

— Сукты,— диде Лотфулла абзый, кинәт агарынып китеп.— Бигайбә, кордаш, мин дә өйгә тәпилим әле, өй янып ятмасын анда.

— Бар, туган, бар...

Сөләй әтисенә иярде. Гайфи белән мин дә, урам иңләп аккан яңгыр суын ерып, өйләребезгә чаптык. Күңелем, әти-әни исәннәрме икән, өй янмыймы икән, дип борчылды. Өйгә кайтып кергәнче күз алдыма әллә нинди куркыныч күренешләр килде.

Әни мине:

— Балакаем, кайда йөрдең син, исән түгелсеңдер инде, дип котым калмады,— дип каршылады.

Әтигә берни дә булмаган, ул да өйдә иде.

Мин өстемдәге юеш киемнәремне алыштырганда урамнан бик ямьсез итеп сыерлар мөгрәшкәне, сарыклар, кәҗәләр бәэлдәгәне ишетелде. Тәрәзәдән карадым. Урамны тутырып, тәртипсез таралышып, чабышып көтү кайта. Боз терлекләрне нык тукмаган, ахры. Хәйрүш абзый ничек түздe икән, ул манма судыр инде, дип уйладым.

Көтү кайтып бетте. Әти, иңнәренә кожанын элеп, Мүкләкне абзарга ябып керде. Бераздан яңгыр басылды, болытлар таралды, берни булмагандай, кояш карады. Мин әкиятләр укырга утырдым.

Зада апа керде.

— Көтүе күптән кайтты, Хәйрүш үзе җук. Бер-бер хәл генә булмаса җарарые аңа,— дип борчылды ул.

— Нәрсә булсын аңа, Хәйрүш абый бала түгел, борчылма, кайтыр. Әнә мунча яга тор, яңгырда чыланып кайткан кешегә иң шәп сый булыр ул,— диде аңа әти.

— Рәхмәт, Сабир, сүзеңә, җагыйм әле алайса мунча,— дип, Зада апа ашыгып чыгып китте.

Мунчасын булдыргач, ул безгә яңадан керде.

— Сабир, Хәйрүш һаман җук бит, нишлим икән инде? Әллә кырга эзләргә чыгыйммы икән ә?..

— Син үзең йөрмә, күрше, мин хәзер колхоз идарәсенә барып Зиннәткә әйтәм, ул берничә егетне ат мендереп, эзләргә чыгарыр.

Әти аякларына күнитекләрен киеп, өйдән чыгып китте, Зада апа елый башлады.

— Җүнлегә тоткарланмый, нидер булган аңа, булган...

— Елама, Зада, кайтыр, кайтмый кая китсен Хәйрүш абый. Гадәте буенча, яңгырдан соң чишмәсе тирәләрен рәтләп ята торгандыр,— дип әни аны иңеннән барып кочты.

— Миләүшә чыгып эзләп кайтты инде аны. Чишмәсе җанына да барган, җук, ди...

Мин урамга чыктым. Кояш баеган, күктә беренче йолдызлар калка башлаган инде. Чүлмәк тау ягыннан кемнеңдер гармунда җиңел көй уйнаганы ишетелә. Ничек инде ул алай, Зада апа бездә елап утыра, ә кемдер гамьсез гармунда дәртле көй сыздыра? Нигә буталчык, аңлаешсыз, четерекле табышмак шикелле бу дөнья?..

Хәйрүш абыйны икенче көнне иртән Кизләү сыртында үле килеш табып кайттылар. Яшен бик хәтәр чалтыраганда аны суккан булган. Бөтен тәне күмер күк кара көйгән, диделәр. Мин, ул күңелемдә тере килеш саклансын дип, аның мәетен карарга кермәдем. Шуңамы, ул миңа әле һаман исәндер төсле. Аның курай тавышы һаман да колак төбемдә яңгырый шикелле. Бөтен Бәеш сагына, юксына Хәйрүш абзыйны. Минем өчен исә ул үлмәде, тере, яши...

## 1

Иптәшләрем Чуалда чыр-чу килеп су керәләр, урманда җиләк пеште, җиләккә йөриләр. Мин ул рәхәтлекләрдән мәхрүм, аягым авырта. Беркөн тегермән янында уйнаганда кадакка бастым, шуңа күрә гарип бәбкә шикелле көчкә йөрим. Ярама пычрак кергән, ахры, шеште, йөрәккә төшеп сызлый. Әни инде аңа, тизрәк төзәлсен, дип әллә нинди дарулар сөртеп бәйләп карады, файдасы тимәде, һаман шеше дә кайтмый, сызлавы да басылмый. Аяк авырта дип өйдә утырмыйм, дүрт стена эчендә ялгызыма гына күңелсез, титаклый-титаклый Чуал буена төшеп, су керүчеләрне көнләшеп күзәтәм. Чуал ярында утырып аргач, атлар абзарына Камали бабай янына юнәләм. Хәлемне ул аңлый ичмасам, төрле киңәшләр бирә, яшь тәндә нинди яра да тиз төзәлә дип юата, малай чагында атлар чабышында Исмай бай камчысы белән сугып күзен чыгаргач, ничек интеккәннәрен искә ала. Аның белән без ат җигеп көн дә кырга кәрешкә печәне алып кайтырга барабыз. Камали бабай юл буе үзенең балачагы турында кызык итеп сөйли. Йөзен тирән җыерчыклар буразналаган, сакал-мыеклары, чәчләре күптән көмешләнгән, авызында инде бер теше дә калмаган юлдашымны кайчандыр ул малай булган итеп күз алдыма китерә алмыйм. Миңа Камали бабай туганда ук карт, чал булгандыр төсле. Шулай да аның сөйләгәннәрен йотылып тыңлыйм. Ай-һай, авыр булган аның малай чагы. Җиде яшеннән үз көнен үзе күрә, тир түгеп эшләп, тамагын үзе туйдыра башлаган, әллә никадәр кимсетелүләр, мәсхәрәләнүләр кичергән. Безнең балачак белән аның балачагы арасында көн белән төн кебек аерма. Киләчәктә без дә Камали бабай кебек картаербыз микәнни? Кызык, кеше ни өчен картая, нигә ул мәңге яшь килеш калмый? Нигә гомер мәңгелек түгел? Мирсәет абый: «Кешене табигать аңа кыска гомер биреп кыерсыткан»,— ди. Ул картаюны тәндәге күзәнәкләрдә матдә алмашынуның үзгәрүе, күзәнәкләрнең акрынлап тузулары, тупасланулары, сафтан чыгулары белән аңлата. Миңа исә без беркайчан да картаймабыз, һәрвакыт яшь калырбыз, гел бүгенгедәй булырбыз кебек.

Кырдан чабып алып кайткан кәрешкәне улакларга тараткач, без Камали бабай белән Чуал буена төшәбез. Камали бабайның анда яшь таллар күләгәсендә үзе ясаган кечкенә генә күперчеге бар. Ул шул күперчектән аякларын агым суга тыгып утырырга ярата.

— Минем малай чагымда ук су коенганым булмады, шәрә калып суга керергә тәнем тартына,— ди ул.

Аякларын суга тыгып утыруны Камали бабай су керү белән бер саный.

Бүген дә шулай булды. Кырдан кайткач, атлар абзарында эшләрне бетереп, Чуал буена төштек. Камали бабай аякларын чишенеп үзенең күперчегенә җайлап утырырга гына өлгерде, тал куаклары арасыннан битләре, бөтен тәннәре елга төбендәге ябышкак лайга буялган, билләренә камыш алъяпмалар бәйләгән, кулларына ук-җәяләр, очлы озын таяк-сөңгеләр тоткан унлап малай безнең янга килеп чыкты. Алар, кыргыйларча кыланып, җиргә тезләнделәр, кулларын алга сузып Камали бабайга баш иделәр.

— Маклай! У-у, Маклай...

Карт көлде.

— Нинди бетмәгән Маклай булдым әле мин сезгә? Бүтән уеннарыгызны оныттыгызмы әллә? — Күренеп тора, янына «папуаслар» килүгә шат үзе. Мин беләм, Айдан төшкән кеше — Маклай

булу ошый аңа. Күренекле рус галиме, сәяхәтче Миклухо-Маклайның кем булганын без аңа сөйләгәнебез бар. Ул бик теләп уенга кушыла.— Курыкмагыз, дусларым, суны җандырмыйм,— ди кеткелдәп.— Сусыз көн кызуында үзем дә нишләрмен, эштән арып кайткан атларым да кипкән тамакларын нәрсә белән чылатырлар? Килегез тирәмә якынрак. Чуалның ни өчен чуалып-бормаланып акканын сөйлим...

«Папуаслар» безнең тирәгә урнашып кына өлгерделәр, яр өстеннән ниндидер малайның:

— Җараплан оча, карагыз, җараплан! — дип кычкырганы ишетелде.

Шул мизгелдә үк минем күңелемә Төньяк котып аша дөньяда беренче тапкыр Мәскәүдән Америкага алтмыш өч сәгатьтән артык тукталышсыз очыш ясап, АКШтагы Ванкувер аэродромына төшкән «АНТ-25» самолеты килде. Иртән радио герой очучылар Чкалов, Байдуков, Беляков абыйларның бу самолетта еракка очыш буенча дөнья рекорды куюлары турында сөйләгән иде. Кем белә, бәлки бу җараплан шул «АНТ-25» самолетыдыр?

Ирексездән барыбыз да күккә карадык, тик куе тал ботаклары аша берни дә күренмәде. Авыл ягыннан трактор тавышына охшаган көчле гөрелте генә һаваны тетрәтте. «Папуаслар», «Маклайны» онытып, дәррәү яр өстенә атылдылар. Алар артыннан Камали бабай белән мин дә ярга күтәрелдек. Чыннан да, аэроплан, түбәннән генә, авылдагы агачларның башларына чак тимичә оча. Үзе энә карагына охшаган — аслы-өсле канатлы. Зур кызыл йолдыз төшерелгән койрыгы гына энә карагыныкы шикелле түгел, бүтәнчәрәк.

Чын аэропланны безнең беренче күрүебез иде бу. Без аны, сикерешә-сикерешә, куллар болгап озаттык.

Бераздан «папуаслар»ның берсе:

— Никкүчтем басуына төште бугай ул, әйдәгез барып карыйбыз,— диде.

Аэроплан барыбызны да сихерләгән иде, аңа, төшмәде, дип каршы килүче булмады. Малайлар тәннәренә сыланган лайны да юып тормастан, кулларындагы ук-җәяләрен, таяк-сөңгеләрен ташлап, өс киемнәрен эләктерделәр дә бөтен төркемнәре белән аэроплан китеп күздән югалган якка йөгерделәр. Яр өстендә Камали бабай белән без икебез генә калдык.

Аягым сау булса, мин дә яр өстендә авыз күтәреп торыр идемме? Кирәк бит аякның шундый чакта авыртуы! Малайлар аэропланны якыннан күрәчәкләр, аны тотып, капшап караячаклар, ә мин... Әллә титаклый-титаклый гына булса да барыргамы икән?

Минем аэроплан карарга киткән малайлардан көнләшүемне, аягым авыртуга үртәлеп, нишләргә белмәвемне күргән Камали бабай:

— Никкүчтемгә барып җиткәнче телләре асылына әле ул папуасларның,— диде.— Җакын ара түгел — ун чакрым. Җукка җөгерделәр тиленләр, төшмәде ул анда. Безнең Бәешкә төшми үткәч, Никкүчтемгә төшәме ул? Төшми. Нәрсә бар анда? Чүп тә җук. Башларында акыллары бар бәндәләр оча булыр ул җарапланда.

Рәхмәт Камали бабайга, аның сүзләре мине тынычландырды. Соңгы аэроплан булмас, күрермен әле. Әмма шәп нәрсә икән үзе! Ничек тиз очып үтте. Үскәч, башка беркем булмыйм, очучы булам. Әйе, очучы. Аэропланым белән шушында Бәешкә кайтам да, авыл өсләп дүрт-биш тапкыр әйләнгәч, Чүлмәк тау янындагы үзебез тып тибә торган җиргә төшәм. Карасын аэропланны бөтен балачага, карасын җыелып бөтен авыл...

Шундый татлы уйлардан күңелем күтәрелеп китте. Мин инде малайларга иярә алмавыма аз гына да борчылмадым, киресенчә, үземне алардан күпкә өстен итеп тойдым.

Камали бабайның да уйларын аэроплан биләгән икән. Ул аякларын су эчендә селки-селки:

— Алланың рәхмәте, оча бит, тәки оча. Карга кадәр генә түгел, иләмсез дәү үзе, канатларын да җилпеми, ә оча,— дип сөйләнде. Аннары миңа сорау бирде: — Белмисеңме син, Ирек, нәрсәдән ясалган икән ул җараплан, агачтанмы, калайданмы?

— Корычтан,— дидем мин, уйлап та тормастан.

Карт, шикләнеп, сыңар күзен миңа текәде.

— Булмас, корыч бик авыр бит.

— Валлаһи корычтан. Камали бабай. Бер шигырьдә: «Эх, соклангыч безнең замана, корыч кошлар оча һавада, тракторлар эшли кырларда, машиналар чабыша юлларда»,— дип язылган.

Карт минем сүзләремә каршы килми, суга иелеп аякларын юа. Мин малайлар турында уйлыйм.

— Камали бабай, малайлар киткән авылның исеме ник шундый сәер, белмисеңме?

— Никкүчтемне әйтәсеңме? — ди карт, судан башын күтәрми генә.

— Әһе.

Карт, гәүдәсен турайтып, миңа карый.

— Кызык сорау биреп, күп нәрсәне искә төшердең бит әле син минем. Беләм, ник белмәскә, минем күз алдымда туды ул авыл. Әлегедәй хәтеремдә, җапун сугышыннан соң илдә төрле буталышлар китте. Әллә никадәр гөнаһсыз адәмнәр кырылды ул җапун сугышында. Аны безнең Микулай патшаның малай чакта башына җапун патшасы малае таяк белән органга башланган, имеш, дип сөйләделәр. Рәсәйдә шул сугыштан соң ризасызлыклар китте. Өстәвенә бишенче җылны патша Питрбурда байлардан үзләрен яклауны сорап сарае җанына килгән җарлы халыкны салдатлардан аттырган, күп кешене кырдырган, диделәр. Шуннан соң әле анда, әле монда бояр утарларын талаулар, җандырулар башланды. Бездән җырак түгел Мулступ бояры барые, шуның утарын төрле авыллардан җыелган халык башта талады, талагач җандырып көл итте. Күп кешеләр шуның өчен себер киттеләр. Аннары халыкны тынычландырырга манфис чыкты. Җарлы халык: «Хөррият килде, безгә дә иркен сулар көннәр җитте»,— дип сөенде. Җир җугые ул чакта крәстиәндә. Бер ир башына бер таяк җир җирмени ул?! Хатын-кыз бөтенләй өлешсезие. Чуалышлар китте җаңадан. Чуалышларны бетерергә патша хәйлә җулына басты, диделәр. Бу дөрес тә булды. Хәллерәк крәстиәннәрне хутор, атруп җирләренә күчерү чыкты. Безнең тирәләрдәге Подгурный, Винакур, Нират, Никкүчтем, Кибектем авыллары шул чакта барлыкка килделәр. Урысларга әйбәт җирләр бирелде. Падгурный, Винакур әнә хәзер бер дигән авыллар. Алар уңды. Ниратларга җирнең кашкасы, ташлысы, уңдырышсызы эләкте. Аларның авыллары шуңа Ниратупкы җөртелә. Җәгъни җирләреннән разый түгелләр авылы. Никкүчтем дә шундый ук начар җирләрне били. Анда беренче күчеп барган кеше яз көне, атын җигеп, җир сукаларга чыга. Карый, бер дә рәте җук җирләренең. Җирен бер әйләнә, ике әйләнә, шуннан соң офтанып атына: «Их, алаша, кыл тамаша, җирләр кулайһа, әрем дә кура, монда ни була, җүләр сатып бу төбәккә мин ник күчтем ичмаса?» — ди. Никкүчтем авылының исеме шуннан калды. Кибектем авылы җапан кыр уртасында калыкканые. Ул мантый алмады, тиз бетте. Суга интектеләр анда. Иң җакын инеш ул авылга дүрт-биш чакрымдаые. Су юллап бик тирән бер кое казыдылар, чыкмады су, икенчене казыдылар, анысы да өметләрен акламады, көч куюлары бушка китте. Өченче коеларыннан да тамчы да су ала алмадылар. Халык анда ике-өч җыл шулай суга интеккәч, җиренә-иненә төкереп.

киткән авылларына җаңадан таралды. Элекке Кибектем авылының җапан кырдагы каргалган урыны, галәмәт тә тирән сусыз коелары белән сәер исеме генә халык телендә утырып калды. Крәстиянгә җәшәү читение ул чакларда. Сезнең күк папуаслар булып уйнап җөрүләр тәтемидерие җарлы кеше балаларына. Минем синең күк чагымда дүрт көнемнең өчесе ач үтте. Кытлыкые Рәсәйдә. Сүләдемме сиңа, жиде җәшемнән кырга тырмага җөри башладым. Атыбыз акыллые жарый, камыт кидергәндә үзе башын иеп торадырые. Бахбай булып бахбай кызганадырые үземне. Сезгә мин сокланып туя алмыйм. Без үскәндә аптамабиллар да, трактырлар да, җараплаңнар да җукые. Сиртмәле арба әллә нинди могҗиза кебекие ул чакта. Рбәлүсиядән суң тормышлар җиңеләйгәнгә куанып бетә алмыйм мин. Элек безнең Бәештә бары жиде хуҗалыкта гына икмәк җыл әйләнәсенә җитәие. Хәзер ипекәйне куяр урын тапмый җык чыга. Җыллар гына тыныч булсын, сугыш афәте генә чыга күрмәсен инде, тормышыбыз гөрләп бара хәзер, алланың рәхмәте. Сугыш чыкса, халыкка тагын кыенлык килер, кан-җәш коелыр, толлар, җәтимнәр үрчер...

— Курыкма, Камали бабай, сугыш булмый,— дип сүзен бүлдем мин картның,— буржуйларның башлары әллә ике дип беләсеңме безгә ябышырга? Булса, үз башларына башларлар алар сугышны, үзләре дөмегергә...

— Дөмегүен дөмегерләр, анысы дөрес, тик менә дөмеккәнче суңгы сулышларына чаклы безне бетерергә тырышырлар. Әнә Спаниядә хәзер дә бара бугай бит әле ул. Уен да, мәрәкә дә түгел сугыш афәте, каза, берни белән чагыштырмаслык бәла ул сугыш, алла язмасын аны кичерергә...

— Безнең бер аэропланыбыз гына да буржуйларның ярты гаскәрен кырачак. Безнең аэропланнарыбыз биегрәк тә, тизрәк тә, ераграк та оча. Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин шулай, ди. Тагын еракка ата торган тупларыбыз, тиз йөрешле танкларыбыз бар. Аларны берни дә җәдрә дә вата алмый. Габбас абый, безнең танк броняларының калынлыгы кул яссуы кадәр бар, ди.

— Бездәге шикелле үк танклар, җарапланнар, туплар аларда да бардыр шул.

— Булсын, безнекеләр барыбер көчлерәк!

— И бала, бала,— дип көрсенде Камали бабай,— күп нәрсәләрне белмисең шул әле син. Көчкә каршы мәкер, көнчелек, итәк астыннан ут йөртү, хыянәт кебек пычраклыклар да бар әле бу дөнҗәдә. Үз илебездә дә безнең якты көннәребезне, мул тормышыбызны күпсенүче, халыкка кабат нужа камытын кидерергә хыялланучы, җөзләренә җахшылык битлеге каплаган эчке дошманнарыбызны тоту турында туктаусыз сүлиләр әнә. Күптән түгел генә аларның бер төркеменә суд та булган диделәр. Алар чын йөзләрен яшереп, әллә нинди корткычлыклар эшләгәннәр, имеш. Ул адәм актыкларының ишләре калмагандырмы әле? Көя күк бит алар, эчтән ашыйлар...

Чыннан да, дөрес бит бу. Троцкийчы әтрәк әләмнәр турында газеталарда соңгы вакытларда күп языла, радиодан туктаусыз сөйләнә. Әнә Красновидоводагы хәлләрне күз алдына китерсәң, чәчләр үрә торырлык. Анда күпме корткычлык эшләнгән — уйласаң кот очарлык. Эти, кешеләр карурман белән бер, алар арасында адашу бик җиңел, ди. Кемнең кем икәне маңгаена язылмаган. Халык дошманнарын мин Камали бабай белән шушы сөйләшүдән соң күпмедер дәрәҗәдә анык итеп күзаллый башладым. Эти белән әни арасында алар турында өйдә дә сүзләр еш була анысы, әмма менә моңарчы ул сүзләр бик аз кызыксындыра иде. Кара син, тормышның күз чагылдыргыч ялтыравыгы астында никадәр тутыгы да бар икән бит... Чын йөзен битлек астына яшергән дошманга нинди тех-

ника, нинди корал белән каршы барасың, аның дошман, корткыч икәнен кайдан беләсең?

— Рәхәт озакка китсә, тәме бетә, кузгалырга кирәк,— дип, Камали бабай күперчегеннән торды.— Безнең папуаслар әле һаман Никкүчтемгә элдерәләр булыр. Әйдә, без дә әшебезне карыйк. Мин абзарга керим, син ашарга кайт.

— Син дә ашарга кайтмыйсыңмыни, Камали бабай?

— Юк, мин чәйне шушында гына кайнатып эчәм. Карт аякларым белән киләп сарсам, кич җитәр. Син, Ирек, минем җанга иртәгә дә кил, иртәгә дә бергәләп викага барырбыз.

— Рәхмәт, Камали бабай, әбәзәтелне килермен.

Карт атлар абзарына китте, мин өйгә титакладым. Төш авышкан иде инде. Көн кызуыннан агачларның яфраклары шәлперәйгәннәр. Һавада тәтенсез учак өстеннән күтәрелгән эссегә охшаган рәшә дулкыннары тирбәлә. Әйләнә-тирә тып-тын. Бу тынлыкны тегермән арыгына шаулап төшкән су тавышы да бозмый, киресенчә, көчәйтә генә кебек.

Никкүчтемгә киткән малайлар кичкә таба гына әйләнеп кайттылар. Алар аэропланны күрмәгәннәр, ул анда төшмәгән булган, шулай да барулары бушка китмәгән, һәркайсы берәр кочак балтырган, какы, әнис җыйганнар. Сөләй миңа да бер ашарлык какы һәм әнис кертеп чыкты.

— Зрә бардык, төшмәгән аэроплан,— диде ул.— Моңарчы мин шоферлыкка укырга хыяллана идем, бүген аэроплан күргәч, очучы булырга карар бирдем. Күпме укырга кирәк икән аңа?

— Юк, белмим.

— Сабир абыйдан сора әле, ул белә торгандыр.

Мин, йокларга яткач, төне буе аэроплан белән саташтым. Төшемдә үземне дә, Сөләйне дә очучылар булганбыз итеп күрдем. Аның белән бер аэропланга утырып очтык, имеш. Аэропланыбызны йөзләренә битлек капланган кешеләр ватарга маташтылар, аларны без һавадан җиргә мәтәлдердек. Шуларның берсе һич уйламаганда Һаҗәр апа булып чыкты. Ул зур кара каргага әверелеп, аэропланның канатларын чукыды. Мин аны куып кычкыра башладым. Шулчак йөзенә битлек каплаган Фәсхи абый иңемә кагылды...

— Улым, борылып ят, саташасың.

Гаҗәпләнеп күзләремне ачтым. Иңемә Фәсхи абый түгел, әни кагылган икән. Инде яктырып килә, чолан тәрәзәсеннән кояшның беренче ал нурлары өй стенасына төшкәннәр. Аэроплан да, янымда битлекле кешеләр дә, Сөләй дә юк.

Мин, башыма юрганымны каплап, яңадан йокыга талдым.

Кич. Безнең өйдә ишек тә, урам як тәрәзәләр дә ачык. Чүлмәк тау ягыннан тонык кына булып яшьләрнең җыр тавышлары ишетелә. Өй эчендә сизелер-сизелмәс искән үтәли җил тәрәзә пәрдәләрен бер эчкә, бер тышка кабарта. Әни кече якта үз эшләре белән кайнаша. Мин өстәлдәге аяклы лампа яктысында китапка карап утырам, аны бирелеп укып китә алмыйм, мавыктыргыч түгел. Радионы тоташтырырга базмыйм, әти белән Зиннәт абыйга сөйләшергә комачаулармын, дим. Алар ишек катындагы диванда гәпләшәләр. Мин, бераздан алдымдагы китабымны ябып, аларның сүзләренә колак салам.

— Бүтән авылларда мәчет манаралары күптән юк. Бәештә алар нигә киселми калганнар, аңламыйм,— ди әти. Ул, өйдәге гадәтенчә, майкадан гына. Чалбарын да өй арасына гына кия торганына алмашкан. Аякларында йомшак чүәкләр. Сүрән лампа яктысында ул күпкә яшь күренә. Озын кара чәчләре һәйбәтләп артка таралган, сул битендә йөзен ярыйсы ук шыксызлый торган яра җөе бүген ничектер күзгә ташланмый диярлек.

Зиннәт абый кесәсеннән папирос чыгарып кабызды.

— Ныклап тотынып кеше булмады аларга, Сабир абый,— диде ул этигә, авызыннан чыккан тәмәке төтенен уң кулы белән ялкау гына таратып.— Дөресен әйтергә кирәк, авылда берәү дә ул эшне үз өстенә алырга батырчылык итмәде. Аннары элекке елларда Баештә фиркалеләр дә, комсомоллар да аз иде. Авылда һәр яңалыкны башлап йөрүче иптәшебез — колхозның беренче председателе Рәхи Шәкүров үтерелгәч, без, турысын әйтим, югалып калдык. Шуңа сакландылар, киселмәделәр, дип уйлыйм мин ул манараларны. Иптәш Җәгъфәров та килгән саен битәрләп: «Кайчан сүтәсез инде шул күз көекләрен?» — ди. Әшебез ул гынамы безнең? Аннары хәзер аларга менүче дә юк. Ул манаралар безгә яңа тормыш төзергә комачауламыйлар да бит...

— Менә иске авыздан яңа сүз! — Әти урыныннан торып Зиннәт абыйның каршысына басты.— Комачаулыйлар алар, иптәш парторг, ялгышасың. Дингә, буржуаз идеологиягә, яңалыкларга бару юлында киртә булып яткан искелек калдыкларына каршы көрәшергә тиешме без? Тиеш. Менә син ул көрәшне шушы сүзләреңнән соң ничек күз алдыңа китерәсең, шуны беләсем килә минем.

Зиннәт абый кулындагы папиросын тәрәзә төбендәге гөл савытына илтеп басты.

— Көндәлек үгет белән, әлбәттә. Кычкырып газеталар уку, көн кадагына суга торган өндәмә-лозунглар, тагын төрле кичәләр оештыру, җанлы әңгәмәләр белән. Партоешманың планы бар бит, шуның нигезендә...

Әти салмак адымнар белән бер-ике тапкыр ишекле-түрле әйләнде.

— Без көндәлек үгет алып барабыз, анысы дөрес. Ә авылда ир балаларны һаман сөннәткә утырталар. Бу юк диген? Бар. Корбан чалу мәсьәләсе ничек тора, бәлки ул искелек калдыгы бездә беткәндер инде? Юк, бетмәгән, ул да чәчәк ата. Без аңа ничек карыйбыз? Бармак аша. Безгә корбан чалу ни зыян китерә, һәр корбан чалуны колхоз терлеген түгел, үз терлеген суя, дибез. Тагын бер сорау: без оештырган кичәләргә күпме кеше килә дә, гаеткә күпме кеше бара? Шуңа өстәп, уразаны да алыйк. Өлкәннәр генә түгел, хәтта балаларның да чиреге ураза тота авылда. Без исә бу чатак күренешне читтән килеп кемнеңдер бетереп киткәнен көтеп ятабыз. Минемчә, Баештә искелек калдыкларына каршы көрәшне кичекмәстән нәкъ менә мәчет манараларын кисеп төшерүдән башларга кирәк. Аларның икесен дә, минем уемча, иртәгә үк тәкмәрләтү зарур.

Зиннәт абый, кулларын очлы тезләренә таянып, башын иеп уйланып утырды.

— Алайса болай килешәбез, Сабир абый, мин иртәгә таңнан ук коммунистларны, комсомолларны, авыл активын җыям. Иптәшләр алдында чыгыш ясау синең өстә. Авылда шау-шу булыр, билгеле. Бүредән курыксаң, урманга барма, дигәннәр. Шауларлар, шауларлар да тынарлар.

— Бу инде менә бөтенләй икенче сүз. Ник аягыңа бастың, әйдә, утыр әле, ашыкма.

Зиннәт абый белән әти яңадан диванга утырдылар. Алар арасында җыелышта нәрсәләргә күбрәк басым ясарга кирәклеге, анда авыл активистларыннан кемнәрне чакыру-чакырмау турында сүзләр башланды. Парторг әтинең һәр сүзе белән килешеп утырды.

Зиннәт абый йомшак холыклы кеше. Камали бабай аның турында:

— Безнең персидәтел җикән камыш шикелле, җил ары иссә ары, бире иссә бире бөгелә,— ди.

Аңардан авылдашлары, өйләнгәнче Зиннәтнең чәче тубал кадәр иде, өйләнеп бер ел да тормады, башы такырайды, акылга өйрәтәм дип Хөршидәсе йолкып бетерде бугай чәчләрен, дип көләләр. Кем белә, бәлки дөрестер дә бу. Бик чая бит Хөршидә апа. Ул безнең класс җитәкчесе. Аның дәресләрендә йә түшәм санап, йә берәр чит нәрсә белән шөгыльләнеп утырып кара, хәзер күреп ала. Күрә дә, чәр-чәр килмичә генә бастырып, үзе яңа әле нәрсә сөйләгән булса, шуны кабатларга куша. Бер сүзен ике әйтер димә аны, бер әйтә — бер гәйле әйтә. «Тешләгән җиреннән өзә торган хатын Хөршидә»,— ди Зада апа аның турында. Дәрестә кирәгенчә утырмаган укучының дәрестән соң өенә барып, эти-әнисенә балаларының мәктәптә үз-үзен тотышын бәйнә-бәйнә сөйли. Тәртип бозган укучы шуннан соң, кем әйтмешли, майлаган каеш кебек була. Шуңамыдыр укучылар, «прокурор» кушаматы биргәннәр аңа. Начар укытучы түгел үзе, әмма югары билгеләр куярга үтә саран. Ул укыткан рус теленнән «бик яхшы» билгесе алу өчен бер генә түгел, биш кат тирләргә кирәк.

— Гаҗәпләнәм, безнең Бәешкә ике мәчет нигә кирәк булгандыр,— диде Зиннәт абый, яңадан тәмәке кабызып.

— Халыкны томалар өчен кирәккәннәр алар, парторг. Шунысына аптырыйм мин, аларны төзергә материаллар да, осталар да табылган, ә безнең бу көнгә кадәр ул мәчетләрдән кешеләрнең күңелләрен кайтарырдай клубыбыз юк. Борын төбебездә урман, авылыбыз читендә өстебезгә авам дип Каршы тау калкып тора. Шул таудан гына да бөтен районыбыз авылларына җитәрлек таш чыгарырга, таштан шыңгырдап торган өр-яңа клуб, бер дигән терлекчелек биналары салырга була. Без исә, алма пеш, авызыма төш, дип көтеп яткан хөрәсән сыман, кыл да кыймылдатмыйбыз. Клубыбыз тавыклар көләрлек. Ул — бүген-иртәгә җимерелергә торган иске бер амбар әсәртәсе. Аңа адәм рәтле тәрәзәләр уйдыру да кулыбыздан килми, башкасын әйткән дә юк. Ул абзар белән бер. Аңа үзен-үзе хөрмәт иткән, башында азмы-күпме акылы бар кеше йөрми дә йөрми, билгеле. Яшьләребез кышын кара мунчаларга, аулак өйләргә, җәен Чүлмәк тау итәгенә җыелып күңел ачалар.

Эти бер кызса, хәтер саклыйм дип тормый, күңелендәгесен ахрынача әйтеп бетерә. Зиннәт абый әнә аның сүзләреннән тиргә батып, пеләшен таушалып беткән кульъяулыгы белән сөрткәләп утыра. Этинең исә туктар исәбе күренми.

— Без коммунистлар — авылыбыздагы һәр яңалыкны башлап йөрүчеләр. Әмма без әле кумәкләшеп, кулга-кул тотынып эшләү урынына һәрберебез тик үзебезне генә кайгыртабыз. Үземә җил-яңгыр тимәсә, башкаларда эшем юк, һәркем үз-үзен кайгыртсын, дип карыйбыз...

Көтмәгәндә әни кече яктан этигә:

— Сабир, кешечә генә сөйләшә аласың ич син, туктаусыз без дә без, дисең. Кигәвеннәрнең көтүдәге сыерлар өстендә генә безелдәүләрен исеңә төшер. Син дә бүген «без»ләрең белән шуларга охшый башладың түгелме? — диде.

— Бетте, Мәлика, аңлашылды,— диде аңа эти.

Зиннәт абый урыныннан торып, чөйдән салам эшләпәсен алып киде.

— Мин син әйткәннәрнең барысы белән дә килешәм, Сабир абый. Алар бөтенесе дә дөрес, син хаклы, җитте безгә кыл да кыймылдатмый яту. Иртәгә җыелгач, һәммәсен уртага салып сөйләшербез. Мин китим, өйдә югалткан нардыр. Тыныч йокы сезгә!

— Үзегезгә дә,— диде аңа әни, кече яктан чыгып.

*Ахыры киләсе санда*

# Эдуард Мостафин

## Мин бәләкәй чакларда...

ЗАМАН ФРАГМЕНТЛАРЫ

Март аенда мин дә — сабый бала,—
еладым бит бөтен ил белән.
Башка язлар инде килмәстер дә,
шытмас сыман иде гөл, үлән.
...Күл ырылдап куйды боз астында,
төпсез күкләр уфылдап алды.
«Беткән башлар беткән инде»,—
диеп,
күрше соңгы сарыгын чалды.
Мескен хайван буаз булган икән —
бәтиләре чыкты карыннан.
Шушы елны, язга чыдый алмый,
авыл күле ашты ярыннан.
...Ә ул карый кара каймалардан —
барлык балаларның атасы:
төрепкәсен тоткан, галифедан,
аннан аста — илнең картасы.
Ул картада аның җиңүләре,
шәһәрләре, завод, ГЭСлары.
Ай-һәй житез, эшчән, батыр булган,
даһи булган иптәш Сталин!

— Әгәр ул булмаса, агай-эне,
капут иде Сәүит, имандыр!
(Әйдә, абзый, кайгы исәбенә
теләгәнчә безне инандыр).
— Атакага бардык аның белән,
аның белән алдык Берлинны.
Әнә, контр, кулсыз Күркә Гаяз
үзе теләп плен бирелгән.
Хәзер башы Себерләрдә чери,
халык дошманына ул да аз!
Менә туган, мәйтәм, нигә әле
ул үлгәчтен, бүген, көн аяз?

Вредительләр эше, понимаешь.
Нигә әле Кояш елмая?
Ул чыкмаска тиеш бүгеннән соң...
Их, төшеп үлим микән елгага.
Инде хәзер ничек көн итербез,
билләһи, кул салам үземә.
Алыгыз, ал күктән бу Кояшны,
мәңге күренмәсен күземә...

Сынып ирләр елый, без үксибез,
бер авылдаш җирдә тырнаша...
Ул вакытта салкын җил искәндер
карлы-бозлы шыксыз кыр аша.
Ач каргалар җирдә чокынгандыр,
чукынгандыр урыс кешесе.
Безнең бабай һушсыз, күккә карап,
ирен кыймылдатты:— ишетсен!
...Теге, Берлинны алган илереп
елый.
Әти әйтә: «Качып яткан ул —
сугышка да бармый, әллә кайда...
Әтәчләнә — шактый капкан шул.
Алла да юк аңа, мулла да юк,
күз буярга гына елавы.
Үзе турында сүз әйтеп кара!
Шундук
чага башлар теле-еланы...
Әти еламый — ул уйга баткан.
Бераз чамалыймын халәтен.
Үзе җилкәсендә татыган шул
бар ачысын нахак әләкнең.
Белмим, шпионмы, корткыч дипме,
төнлә белән килеп алганнар.
Шул төннән соң, бәлки, әтием дә
еламаслык булып калган да...

---

Эдуард МОСТАФИН (1945) — *шагыйрь, «Бишенче фасыл», «Туасы көн» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Тик азактан, үзе кайткач, белдек —
«Берлин алган» язып җибәргән...
(Шундыйларның «хәер-фатихасы»
миллионнарны
олактырды кайтмас җирләргә.
Күпме булды Берлин «алучылар»,
Рейхстагка байрак «элгәннәр».
Күпме шундый... Хәтта Гитлерны да
тота язган, үзен күргәннәр...
Азмы шундый «Берлин алучылар»
имә ветераннар кибетен...
Нигә әле бу аяусыз тормыш
вөҗдан дигәннәрен кимсетте?)

Матәм айнытмаган шөһрәтле ил
ач күзләрен төбәп ни көтә?
Нинди тәкъдир һаман кешеләрне
канлы тәрмәсендә йөткертә?
Дөреслеккә әле юллар ерак,
аңа житү җәберләр аша.
Кем ул,— үзе чаршау артындамы,—
корбаннардан кыла тамаша?
Дөнья дигән нинди сәхнә соң бу,
кешеләре бар да актермы?
Вакыт ачкан тарих галәмәте
сәхнә артын шактый актарды.
Кайбер затлар салгач битлекләрен,
үрә торды халык чәчләре.
Сак мәркәзнең салкын ташларын да
тишеп чыкты «даһи» чәчкәннәр.
Дөнья өнсез калды — ачыласы
фаҗиганың сизеп зурлыгын.
Ничә буын мие агуланган —
хәтер күтәрмәслек хурлыгы!
Халык күтәрә ул, халык түзә
башын иеп, бөгеп билкәен.
Маңгаена мылтык төзәсәң дә:
«Яшәсен»,— дип, «туган илкәем».
Суксаң бара, тартсаң туктап кала,
сүгенә-сүгенә керә утына,
суга чума йөзә белмәсә дә
йә саламга барып тотына.
Лидер фаш булганчы түзә халык.
Аннан соң да түзми нишләсен...
«Чорның дошманы»ннан арындыра
диварларын, китап киштәсен.
Иске рамга тагын урнаштыра
бердәм берне — яңа хуҗасын.
Шул рамга карап сөйли башлый
булган кайгыларын, нужасын...

...Пионерлар, бергә, лагерьларда
ял итәбез Чулман ярында.
Болай булгач дөнья матур, дуслар,
яшел җиләк пешә карында.

Шулай бер көн отряд вожатые
безне җыеп тизде аланга.
Кояш үзе күктән тәгәрәп үк
төшкән кебек безне карарга.
Лагерь начальнигы бер мәл сүзсез
басып торды, башын кашыды.
Һәм аннан соң аяз күккә карап
болайракмы сүзен башлады:
— Кайгылы көн бүген,
ай, юк, гафу...
Тарихи көн бүген, балалар.
Арабызда һаман дошман яши,
уяу булыйк, күрик чаралар.
Бүген менә Лаврентий Па... э-һем...
Берияны тотып атканнар.
Америка шпионы булып,
чыккан явыз, ләкин тотканнар...
Көлергә дә, еларга да белми
безнең халык басты да катты.
Шунда:— Иптәш пионерлар,
дуслар, ура!—
Дигән сүзе белән уятты...
Эшләпәле, һәр чак күзлек кигән,
шундый була микән шпион?
(Газеталардан укып белә идек).
Шпионга да, димәк, эш кыен.
— Сталин булса, бик тимәсләр иде.
Якташы ич, дусы, җитмәсә.
— Шундый башы белән шул еланны
ничек белмәгән ул, вәт нәрсә!
— Каян барын күреп бетерсен ди,
бер үзе бит илкәйне тартты.—
Вакытында шулай сөйли иде
хатын-кызы, ире, ил карты.

Сөйли иде. Әле юкмы алар?!.

Берияны тотып аттылар...
Ә ул тотып җибәргәннәрдән соң
күпмеләре исән кайттылар?
Исемнәре кайтты күпме урап.
Җисемнәре кайда калганнар?
Алар, димәк, билгесез солдатлар —
сөякләрен күмгәч кылганнар.
...Себер кары изгән сөякләрен,
басып киткән тайга агачы,
шахталарда калган гәүдәләре...
Ул елларның хәтере ачы.
Иске шахталарны актаралар
Алтын тауда[1], Шершин янында.
Алтын ята анда, иң зур алтын —
күрсәң, туңар кайнар каның да:
өем-өем кеше сөякләре,
култык таяклары, чәйнекләр...
Патронын да кызганган — садистлар,

[1] Чиләбе өлкәсендә элекке шахталар. Үтерелгәннәр, хәтта тереләр дә шунда күмелгән.

көрәк, ломнар белән чәрдәкләп,
шул көенчә күмеп киткән алар...
Үлгәнме ул, тере калганмы —
җирне генә ишеп чыкмасын тик...
Кызыксындырмаган калганы.
Мәхшәр көнен көтеп ятмый ләкин,
чыга алар Куропатлар[1] дан,
Калитников[2] зиратыннан чыга —
димәк, яши торган затлардан...
Кампучия, Чили, Сальвадор, дип,
тетрәнгәндә барлык кешелек,—
үзебезнең хәтер, көтмәгәндә,
төште менә өскә ишелеп.
«Мемориал» гына юса икән
тереләргә сеңгән каннарны,
бүгеннән үк күпме җәлладның дим
оҗмах күрер иде җаннары...
Тентүләр һәм көтүләр чорына
туры килгән икән балачак,
безнең аша эзсез узмагандыр
бу зилзилә — сиздерә кайчак.
Сиздерә ул безнең холыкларда,
монафикълык, ялагайлыкта...
Бүген бәлки вакыты җиткәндер
барына да куярга нокта?!

...Лаврентийны алып җәй дә китте...

Сак кешеләр үзләре дә сизми
бераз иркен сулап куйдылар.
Төнен һәрбер ишек шакулардан,
сискәнүдән ахры туйдылар.
Күрше белән күрше ымлап кына
исәнләшеп йөри башлады.
Күтәрелә төште шик-шөбһәләр
белән җыерылган кашлары.
Ничә еллар зиһеннәрне каплап
торган пәрдә ачылды бераз.
Фаҗигаларны да үзе белән
алып китсә икән шундый яз...
Давыл булса, шушы авыл күле
дулый, сыймас булып ярларга.
Үлгәннәрне, исәннәрне табып
вакыт җитте кебек барларга...
...Ярты кило арыш урлап «янган»
Гариф абзый кайтты утырып.
Плен төшкән кулсыз Күркә Гаяз
исән кайтты срогын тутырып.
Кеше үтереп эләккән Салих
тәмам дуңгыз булып симергән.
— Ну, без теге «идейный»лар белән
күп сөйләшми идек Себердә.
Если чуть што, перо в бок, вәссәлам.
Хуҗа күрми, хуҗа үз кеше.
Ха-ха-ха!
Безнең корсакта ул вредительләр —
то есть «идейный»лар өлеше...
Тәмләп сөйли кеше үтерүче
«халык дошманнарын» бөккәнен.
Авыз ачып тыңлый халык аның
«батырлыгын», «данлы» үткәнен.
Күз дә йоммый катыйль ышандыра
сугышларны үткән агайны.
Ил эчендә булган фаҗиганы
азлар гына әле абайлый.
Илдә амнистия...
Бандит, карак кайта.
Алар эше җиңел каралган.
Урамнарны рецидивист баса.
«Идейный»лар — һаман каргалган:
алар дошман, алар көтеп торсын,
алар белән эшләр катлаулы.
Тикшерергә, тикшерергә кирәк...
Шикле, шикле алар катламы...

Тикшерәләр, озак тикшерәләр,
инәсеннән җебенә кадәр.
Алар тикшергәнче, еракларда
казыла тора яңа каберләр.
Түзәргә!—
Тешне кысып, иреннәрне чәйнәп,
йөрәкләрне йомып кулларга...
Күпләр инде: «Ирек, ирек», диеп,
бүре булып әзер уларга.
Уларсың да, уйларсың да, брамат,
чирек гасыр үтсә нахакка.
Туган якта түшәк булыр иде
монда яткан салам, туң такта.
Ирек барын хәтерлисең, күреп
күктә очкан киек казларны.
Исән булган бер әйләнеп кайтыр,
кабул итмәсмени Казаны?!
Казан, Казан — ерактагы сагым,
дошманы да, дусы да анда.
Көйрәтергә иде махрасын, әй,
ансы да юк йөрәк янганда.
...Тикшерәләр, ай-һай озак, кәбәм,
йөрәк кенә түзсен... Түзәргә!
Ә аннан соң халык белән бергә
яңабаштан барын төзергә.
Ялалардан калган кара тапны
иң авыры булыр юарга.
Мөмкин булсын иде, дөньясыннан
китеп торып, кабат туарга...

Бер кат үлеп, кабат туарга?

Бер гомердә юньләп торып булмый.

[1] Куропаты — Белоруссиядәге зират урыны.
[2] Мәскәүдәге зират исеме.

бу сулышың житми яшәргә.
Ә үзебез акыл өйрәтәбез,
ничек яшәргә дип, яшьләргә.
Безгә юк та, ә аларга ничек?
Ул яшьләр бит безнең балалар.
Тарихка ут төртсәң, алар да шул
безнең белән бергә янарлар.
Тарихларның шактый гына битен
шәхес ясый, шәхес туздыра.
Власть башына килгән тираннар ич
бер-берсеннән ныграк уздыра.
Сталинмы, Ежов, Бериямы,
Адольфмы, Гиммлер, Мюллермы,—
алар бар да халык палачлары,
алар бар да политик шулерлар.
Бар нәрсәне картка сала алар:
язмышларны, акыл, холыкны.
Аларга тик манкорт арту кирәк,
үзләре имеш, мие халыкның.
Иелмәс баш чери төрмәләрдә,
кыю фикер яна учакта.
Тираннарның алымнары бер үк,
аерма юк, баксаң, пычак та.
Мәрьям улы Гайса пәйгамбәрдәй,
үзләрен, әй, куя беләләр.
Тормышларын бер легенда ясап,
рухи яктан тәмам үләләр.
Аннары корт җәмгыятькә күчеп,
бик тирәнгә кереп урнаша.
Иң зәһәре шул корт инде аның,—
ул вөҗданга кереп... урлаша...

Көтә Туфан, көтә Ибраһим[1]нар,
Көтә бар халыклар... Көтәбез...
Барында да бер борчылу: «Кемнәр
аркасында шундый хәлдә без?»
Берияны, Ягоданы гына
ишетеп белә күпләр әлегә.
Калганнары? Шул берничә кеше
салдымыни илне бәлагә?
Алар гына булдыралмас иде
шуның кадәр явыз эшләрне...
Тагын кемнең?
Кемнәрнеңдер булган
озын куллар, үткен тешләре.
Буталган бу дөнья, дөресрәге,
бутаганнар «ил аталары»...
Бу тәмугны кабызучы ул бит —
«Корыч» атлы баш атаманы...
...Җавап көтә моңа Вакыт, Тарих,
җавап көтә Рухы мәрхүмнең.
Арабызда масаеп яшисең —
тере килеш таптап, син күмдең...
Бар бит әле партбилетлылар да,
«Юлбашчы»ны әлеп түрләргә,
яшәр иде алар элеккечә
кешеләрне күмеп гүрләргә.
Лексиконнары да үзгәрмәгән,
чуплнмәгән гади сүз белән:
«Даһи ата», «халык дошманнары»,
«падло», «сука» —
шулар — сез белгән.
Аждаһаның башын өздек, дисәк,
яңасымы үсеп тиз чыккан?
Бер яман чир генә түгел икән,
бу бозыклык тәмам чыныккан.

Урладылар... таладылар илне,
казналарың түзсен тик, абзый...
Җаныңны да талар иде ваклап;
Нәфес котырына:— Аз, аз,— ди.
Милли байлык — бөтен ил байлыгы
азмы киткән чит-ят җирләргә.
Бәһасе юк без югалтканнарның —
утта янган, очкан җилләргә...
Ә булганы җиде йозак салган
сандыкларда бикләп саклана.
Ярый әле бераз сулыш алдык —
чак кузгалып киттек, сак кына.
Исхакыйлар, «Идегәй»ләр кайта,
йолдыз булып калса, нур булып.
Ә чын тарих — үзебезнең Тарих —
ята бәхәс булып, сер булып...

Рухи байлык калса, кайтыр иман —
күккә ашар биек манара...
Тираннарны сытып, тарих кайтыр
халыкка — чын, бөек манзара!

[1] Ибраһим Салахов күздә тотыла.

## Җәвад Тәрҗеманов

# КИЧЕРЕРГӘ МӨМКИН ТҮГЕЛ

ПОВЕСТЬ

### Беренче хат



Сәлам Балтик буеннан!

Исәнмесез!

Бүгенге көнгә кадәр миңа таныш булмаган сезки-сезләргә, нурлы йөзләргә, сөрмәле күз — кара кашларга, рөхсәт итегез, сәлам белән хат яза башларга. Сезки, ирекле илнең иркен кочагында яшәүче, туган як табигатенең барлык гүзәллеген үзенә җыйган сайраучы кошка охшаган чибәр кыз Сания, эшегездә һәм киләчәк тормышыгызда һәм яшьлек көннәрегездә яңадан-яңа уңышларга ирешүегезне чын күңелдән теләп, кабат кайнар сәламнәр белән бу хатны язучы сезгә таныш түгел совет солдаты Фәрит дип белерсез.

Бу танышу хатын язар өчен
Алдым кулга корыч каләмем.
Укыганда иптәшләрең булса,
Аларга да минем сәламем.

Сәлам соңында, рөхсәт итегез, алдагы юлларда түбәндәгеләрне язып китәргә.

Ну, Сания, сезнең исемгә колак ишетмәгән Н. шәһәреннән, бер дә белмәгән кешедән хат килеп төшкәч, бәлки, аптырап калырсыз. Мин үзем хәзерге көндә Балтик буенда Совет Армиясе сафларында хезмәт итәм. Без бит, дидем, икебез дә гап-гади кешеләр. Чәчәк кебек яшьлек гомеребезне күңелле, шатлыклы, бәхетле уздыру өчен хатлар язышыйк, дидем. Бәлки, киләчәктә фотолар аша бер-беребезне белербез. Хат алышу — ярты кавышу.

Ну, Сания, сез, бәлки, бу хатны укырсыз да, көләрсез бер туйганчы — анысы сезнең эш. Кәнишне, бүгенге көнгә кадәр мин сезне белмим, ә сез мине белмисез. Бәлки, сезнең яратып йөргән егетегез бардыр. Ничек булса да, үзегезнең уегызны әйтеп языгыз.

Әгәр, Сания, минем белән хат язышырга риза булсагыз, үзегез

---

Җәвад ТӘРҖЕМАНОВ (1920) — *шагыйрь, прозаик һәм галим. «Лобачевскийның яшьлеге», «Көмеш дага» исемле романнар һәм башка китаплар авторы. ТАССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе. Казанда яши.*

турында ачыграк язып салыгыз. Сездән хат килмичә, үзем турында хәзергә башка берни дә әйтә алмыйм.

Шуның белән хатымны тәмам итеп, уң кулыгызны кысып, түземсезлек белән хат көтеп калучы, инде сезгә билгеле Фәрит дип белерсез.

Язылды 12 ноябрь, 1964 ел. Кичке 8 сәг.

## Икенче хат

Сания, исәнмесез?!

Солдатларча кайнар сәламнәребезне авиапочта белән сезгә җибәреп, бу хатны Фәрит яза. Иптәш кызларыгызга да шулай ук күп сәлам.

Ну, Сания, мин сезгә, ялгышмасам, уже хат салган идем. Сез аларны алдыгызмы, юкмы? Или, алып та, җавап язмадыгызмы? Или, вакытыгыз булмыйча, ирендегезме? Әгәр хатны алган булсагыз, бик авыр тоелдымы «незнакомый» солдаттан хат килеп төшкәч? Дөрес, бащта — незнакомый, аннан соң бик ратканың була инде ул. Мин — Туймазыныкы. Бәлки, сез уйлагансыздыр, мин моның белән хат алышсам да, кайчан соң күреп сөйләшәм, дип. Күрешербез-сөйләшербез. Бу дөньяда тау белән тау гына очрашмый, ә кеше белән кеше очраша болай. Безгә кем комачаулар икән? Сезнең күрше районда, туган авылым Димескәйдә минем бабакайның кардәшләре яши. Менә, Сания, шулай. Киләчәктә очрашмый калмабыз.

Ну, Сания, үзегез ничек яшисез? Кем булып, ягъни кайда эшлисез? Буш вакытларыгызны, ягъни кичләрен ничек уздырасыз? Анда һавалар ничек тора?

Үзем пока әйбәт кенә служить итеп ятам. Караулга, нарядка йөрим. Безнең көннәр киеренке хезмәт белән әкренләп үтә тора. Өч ай узды да инде. Тагын ике ел да тугыз айдан соң туган якка, ягъни сезне күрергә кайтабыз.

Хатымны шушында тәмамлыйм, чөнки хәзер отбой. Ну, Сания, исән булыгыз! Жду ответа.

25.XI.1964.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

## Алтынчы хат

Исәнмесез, Сания!

Башка язмам. Монысы соңгы хат.
Масаймыйча гына укып бак.
Теләмисең икән — черт с ним!
Укып тормый, ерт та утка як.

Почта алгач, уйлар чуалды әле — нәрсә язарга да белмим. Ә иптәш егет икенче хатны тәмамлап килә. Мин аннан элегрәк язарга керешкән идем. Әйе, баш кәбестә кебек. Минем соңгы хатымны алуыгыз турында уведомлениене кулыма китереп тоттыргач,ниләр генә уйлап бетермәдем мин. Җитмәсә, якташлар ачуымны чыгаралар: «Егет түгел, дегет син! Биш хат язып, уведомление генә алдың. Неужели башка кызлар беткән сиңа!» — диләр. Бик горур бәндә булып чыктың әле син: безнең ишеләргә нишләп хат язып торырга сиңа. Солдат дигәч тә, миндә дә бит нервылар бар. Нигә җавап бирмисең? Нигә мыскыл итәсең? Нигә?!

...Ну, Сания, ачуланма. Салкын су белән юынып кердем әле.

кызуым бераз басылмасмы дип. «Синдә этәч каны бардыр».— ди торган иде миңа бабай. Мин сезне тиргим, үзем җүләр булганга. Бәлки, сез авырыйсыздыр?.. Уведомлениегә расписаться иткәндә кулыгыз дерелдәгән бугай. Шулай сизелде. Әллә, чыннан да, авырыйсызмы??? Бәлки хатларымның, үзем кебек, ата-анасы юктыр. Анысы өчен гафу итүегезне сорыйм. Мин бер тамчы да ачуланмыйм хәзер Сезгә. Хат башындагы шигырьне онытыйк. Бигрәк әллә нинди бу тормыш. Юк, минем кебек җүләр кеше юктыр, бер дә кирәкмәгәнгә ачулана торган. Шулай бит, Сания?!

Җырлар идем, җырлый белмим. Эч пошудан, ак яканы сүтеп алып, яңадан тегеп куйдым әле. Минем моңа кадәр бу ак яканы текканем юк иде, ә хәзер өйрәндем шул иң ирендерә торган нәрсәгә. Текмәс идең, идән юарга туры килә.

Ну, Сания, син бу хатны җавапсыз калдырмассың, яме?

Фәрит.

Язылды 11.XII.1964.

## Җиденче хат

Исәнме, Сания сеңлем!!!

Ачулансаң ачуланырсың, мин тагын язарга утырдым. Хатны алгач та җавап язарсың кебек тоела миңа. Ләкин, атна артыннан атна узып китсә дә, минем көткәнем бушка гына булып чыга. Һич аңламыйм, бер бит кәгазьгә ике-өч сүз язып җибәрергә вакытыңны нигә жәлли торгансыңдыр инде?

Иртән торсам, кояш көтәм,
Кич булдымы — ай көтәм.
Кояш белән ай көткән көк,
Дустым, синнән хат көтәм.

Сания, моннан алдагы хат белән фотомны җибәргән идем — алдыгызмы?

Сагынычлы сәлам күндереп, Фәрит.

17/XII-64 ел.

## Сигезенче хат

Салам сыйрак, сәлам!

Тәбрик итәм үзеңне, теләгеңә ирештең бит: мине «ял итеп» чыгарга «губа»га утырттылар. Анда, каешсыз килеш, гимнастерканы җилфердәтеп йөрим хәзер. Шәп бит, ә?! Шулкадәр кире беткән булгач, бөтенләй җавап бирмиләр аны. Бу Саша ни пычагыма дип синең адресны биргәндер? Бик кирәгең бар иде, чикерткә! Барлык хатларны сержант Әхәт Кәримов әйтеп яздырды. Ә ул, беләсең килсә, үз отделениесендәге җүнсез солдатны, ягъни мине, синең ярдәмеңдә дөрес юлга кертергә теләгән. Бушка гына! Синең кебекләрне бик күп күрдем мин. Һәммәгез дә бер үк камырдан.

Син үзеңнең бердәнбер хатыңда: «Ике газиз телебезне бутама, йә татарча, йә русча гына яз».— дип акыл сатасың. Ләкин ул акыл үзеңә дә җитеп бетми икән әле. Машинкада басып җибәргән хатың бәкедән алынган тимер кебек салкын иде, өрә-өрә көчкә җылыттым. Моннан соң, кемгә генә хат язсаң да, болай эшләмә. Әгәр ручка белән каләмең яки карандашың юк икән, үзем җибәрермен. Бигайбә!

Тагын нәрсә турында язарга соң әле?.. Әйдә, белеп тор. Сине «фәрештә» дип санавы аркасында Саша аккордеонсыз калды. Юк, аны мин кыстамадым — үзе бәхәсләште. «Берәр кыздан берәр хат кисәге ала алсаң, аккордеонымны бирәм».— дигән иде, чукынчык. Шул инде, сез чикерткәләр турында сүз чыккач инде. Көлгән идем мин аларның мышный-мышный кызларга хат язып маташуыннан. Вәйт,

шулай ди бу, үзең бер хат алып кара әле, ди. Адрес табып бир, минәйтәм, кыз — минеке булачак! Бәхәсләштек шулай, ә ул синең адресны биргән.

Әйе, миңа синең адресны Саша бирде. Быел җәен Казан педагогия институтының музыка факультетына бергә экзаменнар биреп йөргәнсез, ләкин икегезне дә алмаганнар. Шулай булып та аңлаша алмадыгызмы?! Бер үк хәсрәт йөрәкләрне якынайта, диләр бит.

Үзе чибәр булса да, юк шул, куркак ул Саша. Чиле-пешле кызый күрсә дә коты алына аның. Башка мари егетләре дә шундый булса, кызларга күңелсездер анда.

Ул гыйшык куяны сине, Сания, бик ошаткан булгандыр, күрәсең. Миннән хат яздырыр өчен хәтта аккордеонын да җәлләмәде. Үрти бит: «Барыбер җавап бирмәячәк».— ди. Башкалар да канга тоз салды. Ә минем үз гомеремдә берәүгә дә хат язганым юк иде әле. Отделение командиры Әхәт Кәримов әйтеп торгач, экренләп өйрәндем шунда: тора-бара үз сүзләремне дә кыстыргалый башладым.

Җавап бирми җен ачуымны чыгармаган булсаң, бер-бер артлы хат язган булыр идем мени мин сиңа. Яздым ди! Әле моңа кадәр бер генә кызның да миңа каршылык күрсәткәне юк иде. Карточкамны җибәреп, сине дә сындырдым бит!

Синнән хат килеп төшүгә, Сашадан аккордеонын сорыйм. Бик кәперәеп йөргән егетем коелып төште бит. Малайлар аны яклый башлады, «Шаяртып кына бәхәсләште бит ул»,— диләр. Шаяртуны аңламыйсың, дип, утка бензин гына салдылар. Аңламыйм, минәйтәм, аккордеонны давай, дим!

Бәлкем алмаган да булыр идем. Ләкин казармадагы барлык солдатларның Саша турында гына уйлавы кәефемне бозды. Хет берсе минем яклы булсын! Барыбер үземнекен иттем!

Аракы эчәргә яратсам да, тәмәке тартканым юк иде. Ә менә хәзер берсе артыннан икенчесен суырам да суырам. Сигаретларны да караульный латыш бирде. Безнең отделениедән һичкемнең килгәне юк. Әйдә килмәсеннәр! Шайтаныма кирәкме алар миңа! Үзләре дә әйбәт: сине, имеш, миңа тәрбияче-нянька итәләр. Ә син, имансыз, миңа сержант Кәримов хатын укып кына җавап язгансың икән. Ярый әле, Сашаның аккордеонын алгач моны миңа ефрейтор Кузин үзе дә сизмәстән әйтеп ташлады. Ә мин: «Ячыга миннән кияү бүләге булсын!» — дип, Кәримовны күтәреп бәрдем. Ярты сәгать буена аңына килә алмый ятты. Аннан соң иптәшләр суды булды.

Бөтен полк алдында тикшерделәр мине, җебен дә, җөен дә калдырмадылар. Штрафбатка озатасылар иде. Шунда бер егет яклап чыкты. Әрмән егете, Гурген Атаян. Мине монда, частьта калдыруга иреште бит тәки...

...Көндез бераз туктап торган иде дә, менә тагын кар катыш вак яңгыр сибәли.

Хатымны тәмамлыйм. Караульный алмашынырга тиеш. Ул почтага барам диган иде.

Моннан соң сине хат язып борчымам. Гомумән, сезнең хатынкыз халкын күрәсем, хәтта сезнең турыда ишетәсем дә килми. Җитте!!!

Гауптвахта солдаты Фәрит Айтуганов.
1964, 23 декабрь.

## Ефрейтор Гунар хаты

Сезнең алда тез чүгәм, Каракашлы авылында яшәүче олы күңелле, горур татар кызы!

Болай дип мөрәҗәгать итүем өчен ачуланмагыз. Бу нинди тиле, мескен бер дәрвиш икән, дип тә уйлый күрмәгез. Юк, юк! Зур бәхетемнән исергәнмен икән, бу әле акылымны югалттым диган сүз ту-

гел. Бөтен Җир шарын күкрәгемә кочарлык көчем бар. Ул куәт — безнең мәхәббәтебез, бердәнберем Лаума белән булган мәхәббәтебез. Әнә шундый кодрәткә ия булмасам, ихтимал, сезгә хат язарга батырчылык итә алмас идем.

Мин — латыш, сезнең танышыгыз Фәрит Айтуганов хезмәт итә торган частьның ефрейторы Гунар Дунис.

Кичә мин гауптвахтада каравылда тордым.

Фәрит үзенең сезгә кичә язган хатында «Солдат из гауптвахты» дип кул куйган иде. Юк, юк! Аны да, мине дә әдәпсезлектә гаепли күрмәгез. Кулыма икмәк тотып ант итә алам: ул миңа бары тик шул ике сүзне генә укытты. Шуннан чыгып кына ул хатның эчтәлеген азмы-күпме төсмерлим.

Түбәнчелек белән кабат-кабат үтенәм сездән, үзегезне кулга алыгыз һәм, ялыктырсам да, әйтергә теләгән фикерләрем белән танышып чыга күрегез. Зинһар өчен!

Ничек кенә аңлатыйм соң, нәрсәдән башлыйм икән?

«Язмыш авазлары» исемле фильмдагы үзен кая куярга белмичә йөргән «җинаятьче» филне хәтерлисезме? Ничәмә кешене тегe дөньяга җибәрде ул. Джунгли халкының гына түгел, шул фильмны карап утырган тамашачыларның да җен ачуын чыгарды. Ә соңыннан, «җинаятьче» фил үтерелгәч, безнең кайсыбыз аны кызганмады икән? Кайчандыр шәфкатьсез аучы тарафыннан тәненә кадалган сөңге аны шулай шашындырган, кешеләрдән үч алырга мәҗбүр иткән икән ләбаса!

Әмма күңел җәрәхәте тәндәге яра гына түгел бит ул, аны май сөртеп кенә төзәтеп булмый. Аның газабын үз башыннан кичергән кеше генә белә.

Тарту университетында укыган чагымда булды бу хәл. Кышкы имтиханнарда иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән өчен безнең группаны Ригага экскурсиягә җибәрделәр. Бер кичне ничектер филармониянең концерт залына килеп эләктек. Бахның «Месса си минор»ы башкарыла иде. Иптәшләр үзләрен ничек хис иткәннәрдер, белмим, әмма мине тылсымлы авазлар үз кочагына алды. Бу тормыш үзе: газаплану һәм рәхәтлек, борчылу һәм шатлык, өмет һәм олы батырлык. Тирән фәлсәфәле музыка җанымны тетрәтте. Әйтерсең лә Бах, чиксез катлаулы математик машинаны җайлый белүче оста кебек, миемне камилләштерде һәм аңа өстәмә биотоклар җибәрде.

Шул концерттан башлап, мин аның әсәрләрен йотылып тыңлый башладым.

Бөркү җәйге көн иде. Җиһазлары белән безнең университетның актлар залына охшаш базница (гыйбадәт йортын бездә шулай дип атыйлар). Озын-озын эскәмияләрдә аллага яки Бахка табынучылар утыра. Беренчеләре, имән кафедра артындагы чем-кара мантиягә төренгән мацитайска ияреп, Лютерның катехизисларын укый. Икенчеләре исә, бу пышылдаулардан кайчан туктарлар икән дип, түземсезлек белән көтеп тора. Менә, ниһаять, пастор: «Амин!» әйтә. Зал берничә секундка гына тып-тын кала. Кинәт кайдандыр югарыдан, әйтерсең лә күкнең үзеннән, сихри моңнар агыла башлый. О, бу — орган, музыкаль инструментларның падишаһы! Аның симфоник сулышы аша Бах көйләрен тыңлаганда нинди генә хисләргә бирелмисең, хыял канатларыңны җилпеп кайларга гына очмыйсың. Син үзеңнең дөреслеккә омтылучы кеше, зур хәреф белән языла торган Кеше икәнлегеңне аңлый башлыйсың. Алай гынамы әле! Үзеңдә әниең кочагындагы рәхәтлек, пакьлек, гаҗәеп җиңеллек сизәсең.

Әнә шулай тормышка гашыйк булып, зур эшләргә рухланып, мин беренче сентябрь көнне җәйге ялдан университетка әйләнеп кайттым. Анда минем өчен агулы ук әзерләнеп куелган дип кем уйлаган соң?! Сабакташларның минем белән кешечә исәнләшергә теләмәүләре шик

тудырган иде инде. Тәнәфестә комсомол комитетына чакырдылар. Секретарь, стенада эленеп торган фотогазетага ымлап, кырыс кына:

— Моны ничек аңларга? — дип сорады.

Иң уртада — миңа таныш базница һәм пастор рәсемнәре. Алар тирәсендә уннарча фоторәсем. Һәммәсендә — мин, мин, мин. Гыйбадәт йортында булган чакларымдагы нинди генә әчке кичерешләремне төшереп алмаганнар: уйланам, борчылам, кайгырам, гаҗәпләнәм, елмаям, шатланам...

— Ректор исеменә җибәргәннәр,— диде секретарь.— Хурлык, бөтен университет өчен зур хурлык бу! Күкрәгеңдәге комсомол значогыңны алып ташларга да оныткансың, икейөзле алла колы... Менә сиңа исемле стипендиат, комитет әгъзасы! Кыскасы, сәгать өчкә комитет утырышына...

Миңа каты шелтә бирделәр. Университетны ничек ташлап китүемне үзем дә сизми калганмын. Күрәсең, ул чакта мин, теге «Язмыш авазлары»ндагы фил кебегрәк, ярым шашынган хәлдә булганмындыр.

Дусларыңнан, иптәшләреңнән аерылсаң, төшенкелеккә биреләсең, кешеләрдән көннән-көн читләшә барасың һәм мәгънәсез бер җан иясенә әвереләсең икән.

Зинһар гафу итегез, аһ-зарларым озынгарак китте. Хәер, бәлки кирәктер дә. Ә бәлки йөрәгемнән ташып чыккан бу сүзләр сезгә бик сәер тоелыр. «Моның миңа яки Фәриткә нинди бәйләнеше бар соң?» — диярсез.

Бар шул, бар. «Төп геройны аңлау өчен, романдагы башка персонажларны да яхшы белергә кирәк»,— ди торган иде безнең әдәбият профессорыбыз. Мин дә ярдәмче персонажларның берсе бит.

Белмим, минем язмышым кайсы якка тәгәрәгән булыр иде, ярый әле, солдатка алдылар. Шунда мин тормышымдагы төп кешемә юлыктым.

Әхәт Кәримов белән мин частька килгән көнне мунчада очраштым. Читтәге сәкедә берүзем генә юынып утыра идем, яныма тәбәнәк буйлы бер егет килде.

— Хочиш, спину мою,— диде ул, рус телен вата-вата.

— Не понимаю... я вас не просил,— дип дорфа гына җавап кайтардым.

Ул минем сүзләремә игътибар итмәде:

— Зачем всегда один... Плохо быть один, очень плохо... Ни надо, ни надо так...

Минем нәрсә әйтүемне дә көтмичә, ул үзенең мунчаласы белән аркамны шатырдатып ышкыды. Аның бу кыланышына ачуым чыгып, кулымдагы мунчалам белән битенә шапылдатыйм дигәндә, кинәт бөтен тәнемә һәм җаныма әллә нинди, әйтеп кенә аңлатып булмый торган, гаҗәеп бер җылылык йөгерде. Сугыш елларында әниемнең мине (ул чакта миңа 3-4 яшь кенә иде әле), зур табакка утыртып, акырта-акырта юындыруы хәтеремә килде. Әниемнең тере кыяфәте беренче мәртәбә күз алдыма килеп басты. Моңа кадәр бары аның ялангач килеш телеграф баганасында асылынып торуын гына хәтерли идем. Әтиемнең партизан отряды командиры булуын белгәч, фашистлар аны шулай мәсхәрәләгән иде. Мин бу турыда берәүгә дә, хәтта Лаумама да сөйләгәнем юк әле. Менә хәзер йөрәгемне бушатмыйча булдыра алмадым.

Әхәт мине сабый бала кебек юындыра, ә ирексездән күзләремә килгән яшь бөртекләре битләремнән тәгәриләр. Үземне кулга алырга тырышсам да, булдыра алмыйм: елыйм да елыйм...

— Извини... Больше не буду...— диде ул, өтәләнеп. Әйтерсең лә, күзләремә сабын күбеге кергән дә, шуңа гафу үтенә.

Атна-ун көннән соң мин аны янә очраттым. «Ленин бүлмәсе»ндә берүзем генә уйланып утыра идем, кемдер йомшак кына кагылды:

— Здрастуй, дорогой...

Тавышыннан таныдым. Әхәтнең кулында дәреслек һәм дәфтәр. Рус телен өйрәнергә дип килгән икән. Ярдәм итүемне үтенә. Мин шатланып риза булдым, тора-бара без дуслашып киттек.

Аннан соң, тагын бер вакыйга хәтергә сеңеп калды.

Җәйге лагерьга чыгарга әзерләнеп йөргән көннәрдә, бездән утыз километрдагы порт шәһәрчегенә татар артистлары гастрольгә килде. Әхәтнең ничек шатлануын белсәгез иде! Яңа елда чыршы бәйрәменә барырга җыенгаг сабый бала кебек, авызы колагына җитте егетнең. Очрашкан саен ул ял көне булачак зур саубуллашу концерты турында гына сүз алып бара. Һәркемне концертка барырга өнди.

Менә якшәмбе көн килеп тә җитте. Төшке аштан соң, увольнение алгач, без капка янында очрашырга тиеш идек. Бик ашыксам да, Әхәт миннән өлгеррәк булып чыкты. Аны танырлык та түгел, парадка әзерләнгән диярсең. Ялт итеп кырынган. Шикәр төсле ап-ак яка. Теш порошогы белән шомартылган җиз төймәләр нур чәчеп тора.

— Бармыйсың икән инде, дип торам. Башкалар күптән китте. Әйдә тизрәк! — дип ашыктырды ул мине.

Әхәтнең каударлануы юкка гына булмаган икән. Тукталышка җитәбез генә дигәндә, автобус китеп барды. Икенчесен ярты сәгать көтәргә кирәк иде. Олы юлга кадәр атлый торырга булдык.

Ул адымнарын тизләткәннән тизләтә. Мин дә калышмыйм. Шулай ашыгып барганда, юл читендә бер инвалидлар мотоколяскасы очраттык. Ике аяксыз фронтовик (күкрәгендәге орден-медальләре шуның дәлиле иде) җиргә тезләнгән, инде бите-кулы кара майга буялып беткән хатынына «Тегеләй ит, болай ит».— дип өйрәтеп тора. Икесе дә ирекка чыгар өчен тәрәзә пыяласына бәрелә-сугыла хәлдән тайган бал корты кебек алҗыганнар.

— Нәрсә булды? — дип сорады Әхәт, без мотоколяска янына туктагач.

Ләкин теге инвалид, Әхәтнең русча ярым-йорты әйтелгән соравын аңламаганга күрә, күзләрен миңа текәде. Үз милләтеннән икәнлегемне төсмерләде булса кирәк. Без латышча сөйләшеп киттек.

Алар үз хуторларыннан портка, игезәк оныкларының туган көненә барырга дип чыкканнар икән. Менә шунда җиткәч, хәрәкәт чылбыры өзелгән.

Мин тегеләрнең аһ-зарын тәрҗемә иткәч, Әхәт әйтте:

— Син, Гунар, соңга кала күрмә тагын, бара тор.— диде.— Минем татар концертында булганым бар. Синең өчен зур яңалык! Бар тизрәк... Урынымны бераүгә дә бирмә, мин хәзер килеп җитәм.— диде. Ә үзе коляскага иелде.

Әмма күршемдәге урын концерт тәмамланганчы буш торды. Автобуста кайтырга чыккач кына, ярты юлда миңа таныш мотоколяска очрады. Шосседан портка таба тыр-тыр чаба иде.

Шул вакыйгадан соң Әхәт Кәримовка гына түгел, бөтен татар халкына карата хөрмәтем икеләтә артты. Мин сезнең милләтнең тарихы, культурасы белән тирәнтен кызыксына башладым. Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил шигырьләрен татар телендә уку бәхетенә ирешү өчен тырышам. Ә Салих Сәйдәшевнең дәртле көйләре күңелемнең бер хәзинәсе булып китте.

Менә ни өчен бик кадерле безгә сержант Әхәт Кәримов. Фәрит, аңа сукмыйча, миңа тамызган булса, бу вакыйга, ихтимал, болай ук күңелсез тәмамланмаган да булыр иде. Мин үзем Фәриткә гафу итә алмыйм. Хәер, аны «губа»га китергән сәбәп — характерының дуамаллыгы түгел, ә егетне шулай ярсыткан ачы «язмыш авазы», әле бер яшендә чакта ук аны әнисе ташлап киткән. Хәзер Фәрит, гомумән, хатын-кызга ышанычын югалткан. «Иблис» токымы» дип кенә җибәрә.

Хатым чамадан тыш озынга китте бугай. Сезне тагын да ялыктырмас өчен нокта куярга кирәк икәнлеген дә беләм, әмма иң кирәген — сезгә хат язарга мәҗбүр иткәнен әйтергә өлгермәдем бит әле.

Кичә Фәритнең Сезгә язган хатын почтага илткәч, Лаумам (ул шунда эшли һәм читтән торып Тарту университетында укый) квитанция биргәндә адресыгызны укыды да:

— Каракашлыдан посылка килде. Сезнең дустыгызга түгелме икән? — дип сорап куйды.

— Кайда?.. Күрсәтче! — дип чәчрәп чыктым. Бу — сез салган посылка иде.

Посылкадан бер төргәк чикләвек һәм йон оекбашлар белән бияләйләр тартып чыгаргач, Фәрит сабый баладай куанган иде. Шулчак кинәт агарынып китте:

— Гунар, минем хат кайда?..— ди.

Аның үтенече буенча, яңадан почтага йөгердем, ләкин хатны җибәреп өлгергәннәр иде инде. Шуны кайтып әйткәч, Фәрит кинәт кенә үксеп елап җибәрде. Көч-хәл белән тынычландырдык үзен.

Менә шул.

Сезне борчуым өчен тагын бер мәртәбә гафу үтенәм.

Түбәнчелек белән Гунар Дунис.

24 декабрь. 23 сәгать.

P. S. Сезгә хат язуым турында һичкемгә дә әйтмәячәкмен.

*ТЕЛЕГРАММА*

*Татария Бавлы деревня Каракашлы Закировой Сании Получил первый номер журнала «Азат хатын» тчк Спасибо тчк Также большое спасибо за посылку тчк Какой я дурак тчк Фарит*

## Тугызынчы хат

Сания!

Бернинди хакым булмаса да, менә мин яңадан, бөтен көчемне һәм кыюлыгымны туплап, сезгә хат язарга утырдым. Гауптвахтадан язган хатым өчен үземне һичничек тә аклыйсым килми. Алай кылану ахмаклык булыр иде. Мин бит сезгә яңадан язмам дип сүз биргән идем. Ләкин, нихәл итим, язмый булдыра алмыйм. Хатымны ачып карамыйча ук ертып ташласагыз да, минем сезгә бернинди үпкәм юк. Ә шулай да укып чыгачагыгызга ышанам, чөнки сез башкалар кебек түгел.

Сания, «Азат хатын» җибәрүегез өчен рәхмәт. Авылдан качып киткәннән бирле татарча юньләп укырга туры килмәгән иде. Журнал башта ничектер ят нәрсә булып күренде. Хәер, егетләр белән андагы рәсемнәрне кабат-кабат карадык.

Журнал Әхәтнең күзенә чалынмаса, бәлкем, шул рәсем карау белән чикләнгән дә булыр идек. Ә ул, гомерендә татарча китап-фәлән күрмәгән кеше шикелле, аңа ташланды: киного да бармыйча, ике сәгать буена баш күтәрми укып утырды. Бу хәл башка милләт егетләренә җитә калды. «Шулкадәр кызык булгач, безгә дә тәрҗемә ит!» — дип тынгылык бирмәделәр үзенә. Ә «Солдатым» дигән җырның көен Саша үзенең аккордеонында уйнап күрсәтте.

Кыр казлары китте
Диңгез буйларына,
Кыр казлары китте тезелеп.
Син дә, багърем, киттең,
Бик ямансу иттең —
Мин озатып калдым өзелеп...

Менә хәзер ачык тәрәзәдән кергән җил бу хатымны сезнең

янга алып китәргә тели. Ә мин язганны иптәшләр читтән генә күзәтеп торалар. «Әгәр иртәгә хат салмасаң, бездән яхшылык көтмә!» — диләр.

Үземнең хәлләргә килгәндә, бу атнада бездә өйрәнү «сугышы» үткәрелде. Гадирәк әйткәндә, соңгы ике айдагы тактик күнегүләргә йомгак ясалды. Учениедә солдат гомерендә әйтмәгән сүзләрен дә ычкындырып куя икән. Җитмәсә, аның көннәре дә бик салкын булды. Сез җибәргән йон оекбашлар да, бияләйләр дә бик-бик ярап куйды.

Ярый, Сания, сау бул. Ә минем хәзер, башкалар йокларга яткач, идән юасым бар әле. Ул идәннәр теңкәгә тия. Ни өчен дисәң, старшина белән бераз «әләгешкән» идем...

Фәрит. 31 январь, 1965.

## Сержант Әхәт хаты

Исәнмесез, Сания?!

Әшегездә һәм киләчәк тормышыгызда ак бәхетләр теләп калучы, сезгә таныш Фәрит хезмәт итә торган подразделениенең бер вәкиле сержант Әхәт Кәримов дип укып узарсыз.

Сания, сезне гаҗәпләндереп уйга калдырмас өчен, башта ук ни өчен хат язуым турында әйтәм.

Сания, зинһар, үзегезне кулга алыгыз, бу хәбәрне ишетү сезгә мөгаен, авыр булыр: ут эчендә калган сукыр бер әбине коткарганда Фәрит шактый нык пеште. Ул әле госпитальдә ята. Хәле болай яхшыра бара. Терелеп чыгачагына шик юк, врачлар шулай ди.

Фәритнең батырлыгы турында безнең хәрби округ газетасында яздылар.

Менә шундый хәл бездә, Сания. Сезнең Совет Армиясе көне белән тәбрик итеп җибәргән чәчәкле телеграммагызны, шулай ук Галимҗан Ибраһимовның өч томлык «Сайланма әсәрләре»н алдык. Алар өчен Фәрит һәм башка солдатлар исеменнән, шулай ук минем үземнән бик зур рәхмәт.

Сания, хушыгыз хәзергә. Фәрит өчен бик борчылмагыз, ул тиздән аякка басар.

Кабат өстәмә кайнар сәлам белән, сержант Кәримов.

28 февраль, 1965 ел.

## Унынчы хат

Исәнме, Сания!

Сиңа күптән язганым юк бугай. Әллә яздыммы?.. Больница койкасында айдан артык уйланып ята торгач, үзем өчен зур ачыш ясадым: синнән дә якынрак кешем юк икән. Менә шуны бүген генә белдем. Хат язарга керешер алдыннан янә уйланып утырдым: чын күңелдән, һәммәсен уртага салып, кемгә сөйли алыр идем икән мин бу газаплы уйларымны? Юк, мондый йөрәк әрнеткеч серне синнән башка берәүгә дә әйтеп бирә алмыйм, мин аны бары сиңа гына ача алам икән. «Син» дип язуым өчен дә ачуланма, башкача эндәшә алмыйм. Син, дим мин, үз итеп әйтәм.

Кыймылдарга да куркып, үз тәнеңнең әче көек исен иснәп ятуны иң явыз дошманыма да теләмәс идем.

Катлаулы операциядән соң беренче төнне, иң-иң авыр минутларда күзалдымда син булдың. Аңыма килгән мизгелдә сине күрәм дип, саташам икән дип уйладым. Медсестра икән... Бөтен көчемне җыеп, күзләремне янә ачам — янә сине күрәм... Тагын көчемне тупларга тырышам...

Сания, синең турыда Саша сөйләгәннәрне онытырга мөмкинме соң? Ничек ул беренче күрүендә үк сиңа гашыйк булган, ничә мәртәбә сине озата барган (ләкин син белмәгәнсең). Нинди генә хәл-

ләрдә төшенә кермәгәнсең, ничек ул, синнән күзләрен ала алмыйча, сочиненисен дә юньләп яза алмаган, музфакультетка керә алмый калган... Сәгатьләр буе янымда утырып, ул сине шундый итеп тасвирлады, хәзер менә бөтен кыяфәтең күз алдымда балкып тора.

Шулай да, Сания, фотоңны җибәр әле.

Миңа сөйләшергә ярамый иде. Әхәт һәр килүендә миңа шигырьләр укый. Баштарак алар минем бер колагымнан керәләр, икенчесеннән чыгып китәләр иде.

Әхәт Такташның «Киләчәккә хатлар»ын күңелдән белә икән.

Дустым Гунар сөйгән кызы Лауманы да минем янга алып килде. Бу кадәр дә пар килерләр икән: төсләре, үз-үзләрен тотулары, сөйләшүләре, елмаюлары, фикерләүләре, теләкләре — һәммәсе бер төсле! Икесе дә укытучы булырга хыяллананалар.

Әле иң олысын әйтмәгәнмен икән: мине үлемнән коткарып калу өчен, безнең частьтагы ничәмә солдат үз канын, ә кайберләре хәтта тиреләрен биргәннәр.

Менә шулай... Уйланып яткан көннәремнең берендә кинәт кенә башыма керебеткән бәйләнчек уй килеп керде: «Ә син, Фәрит, бу дөньяда ни өчен яшисең, нинди олы максатың бар? Һич югында, нәрсә белән булса да тирәнтен кызыксынасыңмы, мавыгасыңмы?..»

Мин нәрсә әйтим соң? Ни дип тә җавап бирә алмыйм. Язмыш гаепләме? Юк! Һәркем үзе өчен үзе җаваплы. Алай булгач, нигә бу көнгә калдым?

Өченче көн инде палатада үземә урын таба алмыйм. Кая барып бәрелергә, нәрсәгә тотынырга белмичә азапланам. Юк кына вакыйга да миңа нык тәэсир итә. Китап укыганда да эч поша.

Менә бүген дә, дежур врач һәм сестра төнге обход ясагач, торып утырдым. Ике кешелек бүлмәдә хәзергә мин бер үзем. Тып-тын. Күрше палаталар инде йоклый.

Теге йөрәк әрнеткеч сорауларга җавап бирер өчен, мин узган гомер юлымны кабат кичерергә һәм язарга утырдым. Ә хәзер вакытым бар минем — учениегә дә, нарядка да, караулга да чыгасым юк.

Сания, бу хатымны мин үзем өчен генә язам. Аны син көтмисең, мин аны сиңа салып җибәрмәм дә. Юк, мин синнән берни дә таләп итмим. Авыр уйларымны, чуалчык фикерләремне бер тәртипкә китерер өчен генә язам мин моны.

Авыртулар бераз гына басыла төшкәч, көне-төне ак түшәмгә карап ятудан тәмам туеп, яткан урынымнан гына «фотография» белән шөгыльләнә башладым мин. Ә син, Сания, андый әкәмәтләрне беләсеңме?

Гаҗәп нәрсә икән ул — «хәтер фотоаппараты» дигәнең! Һич кенә дә сиңа буйсынмый, үзенеке итә. Менә хәзер, бабайны чагылдырган кадрларны күрәм дип ашкынып көткәндә, күз алдымда унбер-унике яшьләрендәге бер кызыйның сыны пәйда булды. Сөйкемле йөз, чишмәдәй күгелҗем күзләр, озынча нәфис борын, чәчәк бөресе кебек күпереп торган күркәм иреннәр, алтынсу чәчләр...

Йөрәгем атылып чыга дип торам — дүртенче класста минем белән бергә укыган Нәзирә ич бу! Ә юк, Нәзирә турында уйласам, үткән тормышымның истәлекләрен бүген иркенләп сөйли алмам. Таң атып килә. Тиздән сестра градусник куярга керер. Төне буе язып утыруымны белсә, ачуланыр...

Ярый, әлегә хатымны тәмамлыйм. Хәерле иртә, Сания! Ә син миңа тыныч йокы телә, хәзер минем өчен иң шифалысы шул.

Фәрит. 15 апрель

## Унберенче хат

Сания!

Менә тагын йокысыз төн килеп җитте, тагын язарга утырдым. Кө-

не дә аның бүген бик борчулы булды. Иң зур серемне сиңа ачып салыргамы-юкмы дип, озак икеләндем. Янә җиңдең, Сания!

Мин ул — мин түгел бит!!! Фәрит Айтуганов дигән етет юк ул Җир йөзендә, тумаган ул. Авылымнан качып киткәч, үзем-үзем биргән бер җәфа кушамат кына ул. Минем чын исемем — Барый, ә фамилиям — Абдуллин. Бабакаем әтисен Габдулла дип йөрткәннәр, шуннан инде безнең фамилия килеп чыккан. Айтуган атлы кеше бабамның бабасы булган. Ни өчен ФӘРИТ дигән исемне алуымны соңыннан үзең үк аңларсың. Шундый искәрмә ясамый торып, тәүге мәхәббәтем Нәзирәне күз алдыңа китереп бастыра алмам төсле.

Сөйлисе сүзләрем бик күп, шулкадәр күп бу юлы, әле кичке аштан соң ук, койкама ятып, һәммәсен бер җепкә тезәргә озак маташып карасам да, файдасы тимәде. Ул гына да түгел, кайдан башлап китәргә белмичә, бөтенләй югалып калдым.

Мин тумбочка янында утырам. Кулымда каләм, ә күңелем әллә кайларда. Үземне Нәзирә каршында басып торгандай сизәм. Яңадан күз алдыма шул сабый чагымны китерәм. Күзләремне йомып, онытыла башлаган вакыйгаларны хәтерләргә тырышам.

Ничек, кайчан очраштым соң әле мин Нәзирә белән?.. Әйе, әйе, әбием үлгән елны булды ул. Андый хәл истән чыгамы соң?

Ярый, шул көздән яза башлыйм. Бәлки, искә төшерә-төшерә, һәммәсе ачыкланыр.

Тукта, аз гына артка чигенеп керешим әле.

1945 елны, әтием авыр ярадан вафат булгач, аның өчен фашистлардан үч алырга дип фронтка киткән әнием хәбәрсез югалгач, мин бик яшьли әбкәм белән бабакай кулына калганмын. Хәер, бу кадәресен авылдашларым сөйләве буенча гына белә идем — вакыт соңыннан кайбер төзәтмәләр кертте.

Шыгырдап торган нарат бүрәнәләрдән салынган безнең өй, узган гасыр истәлеге булып, әле һаман авылыбыз уртасында балкып утыра. Айтуган бабай искиткеч балта остасы булган диләр.

Мин монда ялгызым үстем. Бабай, колхозда умартачы булганлыктан, җәй көннәрендә, бигрәк тә корт аерган чакларда, авылдан дүрт чакрым ераклыктагы умарталыктан кайтмый ята иде. Әбкәм, этәч белән бергә уянып, үзенең сыеры, сарыклары, үрдәк-казлары, тавыклары белән кайнаша. Җитмәсә, йорт янындагы умарталарны да ул карый. Ятим бала дип кызганамы, миңа эш кушмый. Алай гынамы, тезгенне тәмам кулыннан ычкындырды. Иртәдән кичкә кадәр мин үз иркемдә. Зур колаклы, озын йонлы Дүрткүзне ияртәм дә, Димгә яки наратлыкка, аннан — болынга, печән чабучылар янына яисә басуга элдертәм. Арыш башаклары чайкала. Чишмә чылтырап ага. Урман шаулый. Мин шулар эчендә яшим. Ару-талуны белгән юк, чөнки җәяү йөрмим — таяк атыма яки хыялымдагы аргамакка атланып чабам. Кылган шуклыкларым сөйләп бетерерлек түгел. Һәрнәрсә төштә кебек кенә.

Бары тик көз килү белән генә тормыш үзгәрә. Игеннәр җыелгач, бабакай авылга күчеп кайта, ә мин мәктәпкә йөрим.

Шулай дүртенче класска да килеп җиттем. Ул көзне, бичара әбкәм яман чир белән үлем түшәгендә ятканга күрә, баштагы атналарда укырга бара алмадым...

Әбкәйне җирләгәч, болай да зуп-зур өебез шыксыз, буш булып тоелды.

Бабакаем азрак сулу алгач, укырга йөри башладым. Янә тәрәзә буендагы иң арттагы партада утырам. Укытучыны тыңлыйм, күктә йөзгән әкәмәт болытларны күзәтәм.

Бервакыт шулай, дәрес барган чакта, безнең класска яңа гына килгән таныш түгел кызыйның, әледән-әле артка борылып, миңа оялып кына күз сирпүен сизеп алдым. Йөрәгем дөп-дөп тибәргә тотынды.

Ул көнне, бәхеткә туры килеп диимме, минем кепкам югалды. Шуны эзли-эзли, класста ялгызым гына калганмын. Менә шулчак теге кызый килеп кермәсенме! «Нәрсә эзлисең?» — дигән була, ә үзе очкынлы елмая. Минем җавап бирүемне дә көтмичә, тиен кебек житез сикергәләп, парта араларыннан йөгереп узды, кепкамны каяндыр табып та алды.

— Менә ич!.. Башка югалтма, яме... Әбәү, берүзебез калганбыз мәктәптә... Йөгердек!

Без кайтырга чыктык. Кайчандыр әби патша өчен махсус салынган таш юлдан барабыз. Башлар иелгән. Мин бер-ике адым гына читтәнрәк атлыйм. Әз генә кала төшеп. Ул дәшми, мин дәшмим. Кинәт туктап калып, ул миңа янә сүз кушты:

— Әйдә, икәү сабакташ дуслар булыйк!

— Китсәнә, мин синең исемеңне дә белмим ич әле,— дип телгә килүемне үзем дә сизми калдым.

— Нәзирә-ә... Әтием геолог, ә әнием фельдшер. Без әле яңа гына бирегә күчеп килдек. Менә бу тыкрыктан төшкәч, Арт урамда, Фәрхия әбидә торабыз! Синең исемең Барый бит?!

Мин бик гаҗәпләндем:

— Ә син минем исемемне кайдан белдең?

— Ничек тә булса беләнә инде ул, тик беләсең генә килсен... Мин синең дәү әниеңне күрми калдым. Бик яхшы кеше булган ул, әйеме?.. Хәзер сыерыгызны кем сава, идәнне кем юа?

— Бабай.

— Бабай?! — Нәзирәнең болай да зур күзләре тагын да ачыла төште.— Нинди бабай?!

— Әтиемнең әтисе бит ул бабакай.

— Юк, алай ярамый, яхшы түгел,— диде Нәзирә. Аннан соң әйтте.— Беләсеңме, Барый, син аны бабакай-әтием дип йөр. Әйтерсеңме?.. Ә идәнегезне үзем кереп юармын. Сыердан гына куркам мин...

Түбәсе салам белән ябылган кечерәк бер иске өйнең капкасы янына җиткәч, Нәзирә туктады.

— Менә без шунда торабыз. Хуш!..

...Хатымны дәвам итәм. Бая язып утырганда, гүя Нәзирәнең иреннәрен битемдә яңадан тойдым, фикерләрем чуалып китте. Тәрәзә капкачларын ачып, башымны җилләттем. Янә тумбочкам янына килеп утыргач, язганнарымны кабат-кабат укыдым. Белмим, Сания, син аларны ничек кабул итәрсең, ә үземә — чиксез зур куаныч китерде алар. Димескәй малае Барый Абдуллин әле дә булса яши икән!

Мактанып әйтүем түгел, мәктәптә мин рәсемнән һәм әдәбияттан беренче укучы идем. Күп кенә язма эшләремне бәйрәмнәрдә декламация итеп сөйләттеләр. Җиденче класста чакта «Имән белән ак каен» дигән рәсемемне Мәскәүгә балалар иҗаты күргәзмәсенә җибәрделәр.

Рәсем... Миңа олы бәхетнең нәрсә икәнен белдерткән рәсем! Юк, болар — купшы сүзләр генә түгел, инде еллар узганнан соң да мин моны бөтен барлыгым белән тоям. Ә ул чакта... Хәтерлим. Яңгырлы көз. Ләкин минем өчен ямьле яз иде ул. Белмим, рәсемме, әллә Нәзирәме сихерләде — мин матурлык дөньясына килеп эләктем.

Үзлегемнән, укытучы кушмыйча ясаган беренче рәсемем безнең өй алдындагы нечкә ак каен булды. Аны акварель буяулар белән кәгазьгә төшергәндә мин Нәзирә турында уйладым, ә икенче көнне мәктәптә Нәзирәне күргәч, күз алдыма ак каен килде. Бу искитмәле тәэсирләнүем көннән-көн көчәя генә барды. Чишмәдә — Нәзирәнең тавышын, Зөһрә йолдызда — аның карашын, тирә-юньдәге һәммә нәрсәдә аның сөйкемлелеген тоя башладым. Туган табигатемне Нәзирәдән башка, ә ул кызны туган табигатемнән башка күз алдына китерә алмый идем инде. Рәсем аларны бербөтен итте. Мин тулы бәхетемне татып яшәдем, хәтта әтисез-әнисез ятим малай булуымны да оныттым.

Мәнә хәзер, палатада бер үзем генә хат язып утырганда, балачагымның әнә шул онытылмас көннәре турында уйлыйм да, күзләремә яшь килә. Рәхмәт, мең-мең, рәхмәт аңа, Нәзирәгә... Белдеме икән ул үзендә шундый илаһи зур көч барлыгын?! Ә бит дөньяга яратыр һәм яратылыр өчен килгән күпме җан иясе ялгызлыктан сусап үлә.

Соңгы сүзләрне кемнеңдер китабыннан күчереп язган, дип уйлый күрмә, Сания. Шулай ук мин философ та, язучы да түгел. Үземне дә гаҗәпләндергән бу фикерем — Нәзирәне искә төшерү нәтиҗәсе. Сабый чакта бер ел буе йөрәгемә язылып килгәннәрне мин хәзер укыйм, кабатлыйм, кәгазьгә төшерәм.

Шулай түбәм күккә тигән чак булган, көз, кыш, яз узып, җәй килеп җитүен сизми дә калганмын. Ә ул җәйне үлгәнче онытачагым юк.

Безнең колхоз умарталыгы Суыр тавы урманы итәгендә, тирәягы юкәләр, ак каеннар белән уратылган Якты аланга урнашкан иде. Без Нәзирә белән икәү көн дә шунда, бабакай-әтием янына барып йөрибез. Чәчәкләр никадәр матур булсалар да, өзеп алырга кулым бармый. Шулчак һәр җан иясенә, агачларга, хәтта мүкләнеп беткән ташка да сокланып карыйсың: бөтен дөньяны кочаклап алып, чын күңелдән яратып бер үбәр төсле буласың.

Нәзирә белән без дә шул хәлдә идек. Үзебез сөйләшмибез, әмма күңелләребез, кем әйтмешли, күкнең җиденче катында.

Мәңгегә килгән сыман тоелган дуслыгыбызның гомере бик кыска булыр дип кем уйлаган.

Печәнгә төшәр алдыннан Гөлниса әбиләргә Мәскәүдән үз «Победа»ларында кунаклар кайтты. Шулар арасында миннән ике яшькә зуррак Фәрит исемле малай да бар иде. Чыра кебек юка булса да, озын буйлы, бөдрә чәчле. Җитмәсә, скрипкада шундый итеп уйный: тели икән — әбиләрне елата, тели икән — кызларны җырлата. Өс-башы да безнең авыл малайларыныкы кебек түгел: ботларының югарыгы өлешен генә томалап торган кып-кыска ыштан, матросларныкы төсле буй-буй сызыклы майка.

Мәнә шул Фәрит безнең авылга кайтып төшкәч тә, Нәзирә белән минем арадан кара мәче йөгереп узды. Ничектер гел шулай туры килә, аның умарталыкка барырга вакыты җитми: йә әнисе эш куша, йә балалар бакчасында нәниләргә концерт әзерлисе була. «Скрипач малайның кунакка кайтуыннан файдаланып калырга кирәк,— ди.— Ә ул үзе җырлый да, бии дә белә...»

Мине утлы табага бастырган бу концертны Сабан туе мәйданында да уздырырга булдылар. Анысына безнең колхозга керүче авылларның барча укучы балалары җыелырга тиеш иде.

Һич исемнән чыкмый: Нәзирәне күрү теләге йөрәгемне ашкындырганга, концерт башланырга күп әлек үк, мин инде тал агачлары белән уратылган Ике күл аланлыгында идем. «Артистлар»га киенерясаныр өчен чатыр коручыларга барып кушылдым. Нәзирә дә безнең белән. Әмма аның малайлар янында кайнашуы, мине дә шуларның берсе итеп кенә санавы күңелемне рәнҗетә. Бераз шунда буталгач, аңар һичбер сүз әйтми, исәнләшми, акрын гына киттем дә, иптәш малайларым янына барып утырдым. Янәсе, бик исем китте менә!

Концерт башланды. Чатырдан матур киенгән Фәрит белән Нәзирә килеп чыкты. Минем кат-кат юудан уңып, төссезләнеп беткән өсбашым янында алар аеруча аерылып торалар иде. Ирексездән күземә яшь килде. Әтием-әнием булса, бәлкем, мин дә болай йөрмәс идем. Нәзирәнең җырлап бетерүен генә көттем дә, үксеп елап җибәрүемнән куркып, тизрәк качып китү ягын карадым. Ләкин, торып берничә адым атлауга, Нәзирәнең ялварулы тавышы ишетелде:

— Барый... Барый дим, мине көт!... Умарталыкка бергә барабыз...

Коелдым да төштем. Көч-хәл белән янә үз урыныма барып утырдым.

Концерттан соң ничектер шулай килеп чыкты: умарталыкка безнең белән Фәрит тә барырга булды. Башта ул, өйләрендә затлы киемнәрен калдырып, матрос майкасы белән кыска чалбарын киеп чыкты. Аннан инде Нәзирәләргә киттек. Аның әнисеннән рөхсәт аласы бар икән.

Кояш шундый кыздыра иде, күлмәгемне салдым да билемә бәйләп куйдым. Миннән күреп, Фәрит тә шулай эшләде. Сизәм, Нәзирә дә безгә кызыгып бара. Әмма кыз бала күлмәген алай гына сала алмый шул.

Фәриткә әллә ни булган: бертуктаусыз сөйләп кенә тора, миңа авыз да ачтырмый. Аның Мәскәү хәлләре турында такылдавын тыңлый-тыңлый, килеп җитүебезне сизми дә калганбыз.

— Хәзер чыгам,— дип, Нәзирә читән аша гына өйләренә кереп китте.

Нәзирәнең күздән югалуы булды, Фәрит авызына су капкандай тынып калды. Күзебезне генә түгел, үзебезне дә кая куярга белмичә, шулай берничә минут аптырап торганнан соң, Фәрит көтмәгәндә болай дип әйтеп куйды:

— Нәзирә качыш уйнарга ярата бит ул. Әйдә, яшеренәбез!..

«Нәзирә качыш уйнарга ярата бит ул!» — бу сүзләр, тигәнәк орлыклары төсле, үпкәләремә ябышып калдылар, сулышым кысылды. «Икәү уйнамасалар, кайдан белсен икән?!.»

— Әнә теге үлән арасында посып утырабызмы?! — дип сүзен дәвам итте Фәрит, читән буендагы кычытканлыкны күрсәтеп.

Мин, алдын-артын уйламастан, тегене котырттым:

— Әйдә, чум, Фәрит!

Зур начарлык эшләвемне аңлап җиткергәнче, кычыткан арасыннан Фәритнең йөрәк яргыч тавыш белән кычкырып җибәрүе ишетелде. Аннан үзе дә күренде. Күзләре акайган, үзе үрле-кырлы сикерә. Әче итеп чәрелди-чәрелди, өйләренә йөгерде.

— Нәрсә булды Фәриткә?.. Барый, ник җавап бирмисең?

Нәзирәнең бу сораулары өстемә салкын су сипкәндәй тәэсир итте — акылыма килә башладым.

— Ул... син... синнән качып, кычытканлыкка...

Шулай аңлата башлавым гына булды, Нәзирәнең йөзе кинәт кырысланды, күзләре мине тишеп үзардай усал карадылар.

— Ник әйтмәдең, Барый?! Явыз ниятлеме син, әллә шыр тилеме. Мәскәү урамнарында кычыткан үсмәвен белмәскә... Ә мин сине...

Ул кулын гына селтәде дә Фәрит артыннан чапты.

Әйе, шул көннән соң без көрешми башладык.

Икенче, өченче көнне дә көттем мин аны. Гөлләргә су сибәр, яисә умарталыкка бергә барырбыз дип, зарыгып көттем. Нинди генә начарлык эшләсәм дә килер төсле иде. Килмәде.

Ә җәй азагында Нәзирәләр безнең авылдан бөтенләй күченеп киттеләр. Истәлеккә бергә ясаган рәсемнәр генә калды.

Сания! Бик озын һәм буталчык хат язуым өчен рәнҗи күрмә. Мин монда көне-төне хат язып утырырга кушсалар да — риза!

Бүген мин туктый алмам, ахрысы, бакылдык үрдәк белән бер булдым.

Бетте... бетте... Хуш!

Сиңа сагынычлы кайнар солдат сәламнәрен җибәреп калучы... Бу хатны кем язды соң әле: Фәритме, әллә Барыймы? Шул сорауга, никадәр генә баш ватсам да, ачык җавап таба алмадым. Шуңа күрә «Барый-Фәрит» дип атыйм үземне.

20 апрель. Таң атып килә. Сәгатем туктаган икән, ничә икәнен белмичә генә йокларга ятам.

Сау бул!

## Уникенче хат

Җомга көн

Сәлам сезгә Балтик буйларыннан!

Госпитальдә хезмәт итүче якташым удмурт егете белән бүген кичке аш алдыннан мунчага бардым, чиста киемнәр алдым. Хәзер кәефем шәп, кояшлы яңгыр кебек.

Тумбочкамда синең рәсемең тора.

Сания, бик зур, бик зур рәхмәт сиңа дәү әниең белән төшкән фотокарточкаң өчен! Әбиегез дә Сания исемле икән.

Саулыгым югалуга карамастан, мин хәзер үземне дөньяда иң бәхетле кеше дип саныйм. Бүгенге көндә мин өч кояштан нур алып яшим. Аның берсе — җир йөзендәге барча халыкка уртак күк кояшы, икенчесе — Совет Армиясе, ә өченчесе — синең күңелең җылысы.

Хисләргә бирелеп киттем ахры. Гафу итә күр, бүген кәефем шундыйрак. Башымда әллә нинди уйлар кайный, ә янымда уртаклашыр кешем юк. Синнән башка кем аңласын минем бу хәлемне?! Кәефем яхшы булса да, күңелемдә ниндидер шик-сорау. Күрә алырмын микән сине? Үтенеп сорыйм, сакла үзеңне...

Шушы вакыт эчендә мин бик күп нәрсәләр турында уйлап бетердем, күп кичердем һәм үземдә шактый зур үзгәрешләр тоям. Мин хәзер бик күп укыйм. Син аңларсыңмы, Сания, белмим, әмма минем ниндидер акыл ирешмәслек бер зур эш башкарасым килә. Ул шундый гаҗәеп эш булсын иде дә шуның могҗизасы белән күңелемдә моңарчы яшәп килгән барлык җан әрнеткеч шик-шөбһәләр һәм әшәке уйтеләкләр, төбе-тамыры белән йолкынып, юкка чыксын иде. Юк, булмады, аңлатып бирә алмадым, ахры.

...Тәрәзәмне ачып җибәрдем, тагын шул сихри табигать тәэсиренә биреләдем. Ләкин ул мине уйларымнан аермый. Һәм кинәт кенә миндә ниндидер сәер хис уяна: имеш, менә хәзер, менә шушы минутта синең белән минем арада икебезнең күңелләрне тоташтыручы ниндидер җепләр сузылган. Карасам, алар тәрәзәм каршында әкрен генә гүелдәп торган телеграф чыбыклары, гап-гади тимерчыбыклар икән.

«Правда» газетасының узган якшәмбе санында Чыңгыз Айтматовның «Солдат улы» исемле хикәясен укыдым. Күңел тетрәткеч хикәя. Укып чыккач, миндә тел белән әйтеп биргесез авыр уйлар кузгалды. Дөресрәге, күп еллардан бирле күңелемдә таш булып яткан һәм моңарчы һичкемгә әйтелмәгән-сөйләнмәгән җан газабы хәрәкәткә килде. Сиңа гына әйтәм, мондый газапны дошманыма да теләмәс идем. Үзең уйлап кара: кайдадыр сиңа әни тиешле кеше яши, аңа карата синдә көчле нәфрәт уты яна, һәм шул ук вакытта синең аны бер генә мәртәбә булса да бик-бик күрәсең килә.

Тукта, ник сиңа боларны язам соң әле мин? Күрәсең, күңелне бушату өчендер. Шундый истәлекләрне якын кешеңә сөйләгәч, ничектер авыр йөктән арынып, чистарып, сафланып калгандай буласың.

Узган хатымда мин сиңа гомеремнең иң матур еллары — авыр, ләкин мәңге онытылмаслык балачагым, сабакташ дустым Нәзирәне яратуым турында язган идем. Нинди кыска булды ул еллар, аларны сагыш, кайгы — җан өшеткеч кара кайгы басып китте.

Таң атты инде. Бәлкем йоклап китәрмен. Тагын ятып карыйм әле...

...Хатым ике тәүлек бүленеп торды. Инде дәвам итәм. Кеше гомерендә өермәдәй ябырылып килгән кара көннәр була, әлеге өермә аның язмышын үзе белән бөтереп алып китә дә әллә кая илтеп ташлый икән. Нинди көн соң ул дисәң, Сания, туган авылымнан качып киткән көн ул. Әни дигән кешедән өркеп киткән көнем.

Әйе, мин аңа әни дим, чөнки аны башкача атый алмыйм. Әмма ул... ул минем иң татлы хыялларымны, саф хисләремне, кешеләргә сабый-

ларча ышануымны. Нәзирәгә булган беренче мәхәббәтемне кадерсезләде.

Син, Сания, бу сүзләрне язу миңа җиңел булгандыр дип уйлама. Бик каты ачуыңны китерермен кебек. Ә шулай да ялганлый алмыйм: синнән башка бер генә хатын-кызга да ышанмыйм мин. Барысы да әни аркасында. Миңа аны сугышта һәлак булган дип сөйләделәр...

Минем күңелдә әнием турында әллә нинди хикәятләр, әллә нинди легендалар туа иде. Мин аларны дус малайларыма да сөйли идем. Һәм алар мин үзем уйлап чыгарган шушы кыйссаларны авызларын ачып тыңлыйлар иде.

Хыялымда туган ул анам дөньядагы барлык хатын-кызлардан да матур, һәммәсеннән дә сылу, барча аналардан да шәфкатьле, изге иде.

Ничә мәртәбә мин аны төшемдә күрдем, төн уртасында уянып, ничә мәртәбә аңа иркәләндем, бабама яки әбиемә әйткән авыр сүзләрем өчен гафу үтендем, күпме кайнар яшь койдым.

Менә бүгенгедәй күз алдымда: коеп яуган салкын яңгыр астында, йөзгә бәргән әче җилгә каршы бер ялгызым басу юлыннан йөгерәм, үзәгем өзелеп, өзгәләнеп кычкырам: «Әни! Әни! Әнием-м-м!..» Күрәсең, гомеремдә бер генә мәртәбә дә әйтә алмый калган шул сүзне мәңге онытылмаслык итеп хәтеремдә калдырырга, шуңа телемне, иреннәремне күнектерергә тырышканмындыр.

Безнең мәктәптә Дан музее бар иде. Анда укучы балаларның сугышта катнашкан аталары, абыйлары, апалары турында төрле белешмә-истәлекләр, ул батыр сугышчыларның фотокарточкалары, фронттан җибәргән хатлары саклана. Әтиемнең дә мәктәпне тәмамлагач төшкән бердәнбер фотосын, зурайтып, шунда урнаштыргач, мин хыялымдагы әниемнең сурәтен кәгазьгә төшердем: пилотка һәм шинельдән, бер җилкәсендә санитар сумкасы, иңенчесендә — автомат, ә билендә — гранаталар... Ул портретны, улы — бишенче класс укучысы Барый Абдуллин ясаган рәсем, дип, Дан музеена әтием рәсеме белән бергәттән элеп куйдылар.

Июньнең беренче көннәре иде. Әйе, җәй башы иде. Сигезенче класта сынаулар биреп йөргән чагым. Бабакай-әтием, инде атнадан артык умарталыкка бармыйча, авылда яши. Кинәт кенә чирләп китте. Ул үзе, мәрхүм, гомерем буена авыруның нәрсә икәнен белмәдем, ди торган иде. Мин дә аның сызлануын хәтерләми идем. Әмма эшкә йөрми башлаганнан бирле еш-еш ыңгырашуы. «Уф, алла, билем... аякларым»,— дигәне ишетелеп торды. Җитмәсә, авыр сагыш баскан иде үзен — уйланды да уйланды.

— Бүген төшемдә әнине күрдем,— дип сөйләп китте бабакай-әтием, шул соңгы сынау бирәсе көнне иртәнге чәй эчеп утырганда.— Әңгер-меңгер вакыт икән. Каршыма килеп чыкты да, миңа озак кына карап торды. Бер сүз дә әйтмәде. Тоныкк сурәтен генә күргән кебек булдым... Мин дәшмәдем, телсез калдым. Гүргә кергән көненнән бирле төшемә кергәне юк иде. Тиздән очраштыргадыр инде бу...

Йөрәгем жу итеп китте. Нәрсә бу?.. Әллә бабакай-әтием акылга җиңеләя башладымы? Әллә башка берәр сәбәп бармы? Яз башыннан бирле ул үзен бик тә сәер тота иде. Бервакыт шулай. Май бәйрәме алдыннан, аның янына алтынчы класс пионерлары килде. Колхозлашу чорында беренче трактор янында төшереп алынган күмәк фото белән. Безнең авылдашлар. Шуларның һәркайсының исем-фамилияләрен белергә дип килгәннәр иде бабакай-әтием янына. Ул, бик җентекләп караса да, хәтта үз абыйсын да таный алмады,— мин күрсәттем. «Бергә уйнап үскән иптәшләреңне ничек инде танымаска кирәк?!» — дип гаҗәпләнде вожатый апа. Шунда бабакай-әтием кызып китеп: «Минем яшькә җитеп карагыз әле! — дип кырт кисте.— Анамны да таный алмам инде хәзер. Бик яшьли гүргә керде шул. Әмма шулай да, менә

хәзер килеп тотса, кулыннан, бармакларыннан белер идем...»

Әле дә күз алдымда: гомер буе тик тормаган, зур кан тамырлары бүртеп торган кулларын өстәлгә сузып салган да, авызын ача төшеп, йокыдан айный алмаган бер кыяфәттә утыра. Әллә кая текәлгән күзләрендә тимер салкынлыгы. Гел бергә яшәячәк (мин башкача уйлый да алмый идем) бабакай-әтиемнең шулкадәр картайган, өшәнгән булуын беренче мәртәбә күреп, күңелем тулды. Күземә килгән яшь бөртекләрен күрсәтмәс өчен, тизрәк чыгып киту ягын карадым.

...Хатымны дәвам итәм. Нәрсә турында язган идем әле мин? Ә, бабакай-әтиемне җәлләп, елый-елый мәктәпкә киткәнмен икән.

Ул көнне, соңгы сынауны бишкә биреп кайтып керсәм, өй эче ялт иткән: тәрәзәләрдә — әбкәм үлгәннән бирле сандык төбеннән кузгатылмаган пәрдәләр, өстәлдә — борынгыдан калган кызгылт киндер эскәтер, стенада — тәрәзә араларында — әби үзе тукыган озын сөлгеләр, ә идән чип-чиста итеп юылган.

Ике учы белән сәке кырыена таянып утырган бабакай-әтием, мине күргәч, бераз гына авызын чепелдәтеп торды да, үксеп елап җибәрде.

Үзем дә сизмәстән, йөгереп барып, кочаклап алдым аны. Гомеремдә беренче мәртәбә шулай нык иркәләп, бөтен җаным-тәнем белән яратып сөйдем.

Ул көнне безнең өйдә шатлык белән хәсрәт йөзгә-йөз очрашты. Шатлыгы шул — соңгы имтиханны да «биш»кә бирдем. Әмма нәрсә ишеттем мин...

— Үзем чакырттым... Нишлим... үлем түшәгенә ятыр вакытым җитте... Мин үлгәч, сезне кем таныштырыр. Кара-каршы очрашсагыз да, күрми узарсыз. Шуңар эчем поша... Дөнья хәлен белеп булмый. Минә сине иртәрәк калдырып китәм, балалыктан чыгып өлгермәгәнсең... дип, гаепле кеше кебек, үзалдына сөйләнде бабакай-әтием калтыранган тавыш белән. Юк, тавышы гына түгел, бөтен гәүдәсе калтырый иде аның. Мин аңа тагын да кысыла төштем. Сөякле бармаклары башымнан сыйпый, үзе һаман шул дерелдәгән тавыш белән акрын гына сөйләнә:

— Сугыштан кайтмады шул, нишләтәсең аны!.. Әмма дөньяныкы дөньяда кала. Атаң үлсә, анаңны башка бирәү ала...

Әтием турында әйтелгән бу җан әрнеткеч сүзләрдән әллә ничек өшеп, калтыранып киттем.

— Нәрсә сөйлисең, ә?..

— Менә телеграммасы... Кычкырып укы!

Зәңгәрсу телеграф кәгазенә сузылып яткан ак тасмадагы сүзләрне (мин аларны соңгы сулышымача онытмаячакмын) каударланып укып чыктым:

*«Сегодня выезжаю из Москвы Челябинским поездом Вагон девятый — Аусма»...*

— Әсма,— дип төзәтте бабакай-әтием.— Анаң кайта...

— Әнием?! Ә-ә...

Шулчаклы куанып кычкырып җибәргән идем дә, кинәт, кемдер бугазымнан будымыни, тыным кысылды.

Әйе, ул көнне минем тормышымда шатлык белән хәсрәт, сөенеч белән көенеч бергә буталды. Искиткеч сөенечем шул — әнием үлмәгән икән, исән-сау икән... Ләкин ул моңа кадәр кайда булган соң, нигә хәбәр итмәгән? Анаң сугышта үлде, дип бабакай-әтием ни өчен алдашты икән? Башкача әйтергә ярамаганмы?

Бу җан әрнеткеч сорауларга җавап ишетергә теләп, бабакай-әтием каршына килеп бастым. Ул, мескенем, башын аз гына күтәрә төшеп, миңа карады, сәлпе иреннәрен акрын-акрын кыймылдатып

куйды, тик бер сүз дә әйтә алмады,— яшен суккан агачтай сүнеп калган иде.

Шулчак безнең күрше, хат ташучы Камилә апа килеп керде. Әтием белән бергә уйнап үскәнгәме, әллә яхшы күңелле булгангамы, аны бабакай-әтием үз кызы кебек күрә һәм аннан сер яшерми иде. Әле беренче класста укыган чагымда да, җае туры килгәндә, Камилә апа мине кочып-кочып үбә, ә үзенең күзләре дымлана торган иде. Минә тагын, килеп керүенә, миңа бик ягымлы карап:

— Кайттыңмы, егеткәй,— диде.— Тамак ялгап алгач, күкәй салмый торган бер тавык тотып бирерсең. Иртәгә сез станциядән кайтышка аш өлгертермен... тутырган тавык, карабодай бәлеше... Чиләбе поезды унике тулгач килә, диделәр. Иртән, Бөгелмәгә барышлый, почта машинасы сине кереп алыр. Әзер булып торырсың, егеткәй, ярыймы?.. Тик атаңны шулай каршы алырга насыйп булмады...

Камилә апа, яшенә тыгылып, ишеккә юнәлде.

Һичкемне күрәсем, һичкем белән сөйләшәсем килмәгәнгә, ул кич әйтеп бетергесез озын тоелды. Ниһаять, яфрак та селкенмәгән тып-тын, үксеп елыйсын китерә торган җәйге ямансу төн җитте.

Юрганга башымнан ук төренеп, мендәргә йөзтүбән капланган килеш, озак яттым. Үксүем бетеп, тынычлана башлагач та, һаман йоклап китә алмадым. Бабакай-әтием дә түшәгендә төннең-төне буе ухылдап, боргаланып ятты.

Ниһаять, таң атты. Бабакай-әтиемнән дә иртәрәк торып, малтуарга азык биреп, абзарны тазарттым да, зиратка барып кайтырга булдым. Әбкәмне бик күрәсем, аны иркәлисем килдеме, әллә инде килене кайтуга каберен матурларга теләдемме, үзем дә белмим. Әтинең кадерле истәлеге — сугышта һәрчак янында йөрткән кыска саплы корыч көрәге белән флягасын, Нәзирә бүләк иткән исле гөлне алып, арт капкадан гына яшелчә бакчасы аша чыгып киттем. Берәрсе очрамаса ярар иде дип. Дөньясын күрәсем килми иде...

Әбкәм каберен тиз-тиз генә җыештыргач, алып килгән исле гөлне чүлмәгеннән кабер өстенә күчереп утырттым да, кайтырга чыктым. Күңелем тынычланган кебек булды. Тик минә авылым гомеремдә беренче мәртәбә ничектер чит булып тоелды: анда мине һични кызыксындырмый, бернәрсә дә үзенә тартып тормый.

Ишегалдына кайтып керсәм, келәт янындагы озын эскәмиядә Камилә апа җиз ләгәнгә тавык йолкый.

— Син кайда йөрисең, егеткәй? — дип каршы алды ул мине.— Карабодай коймагы пешергән идем. Кайнар килеш аша... Бабаң да борчыла анда...

Чәй эчәргә утырган гына идем, почта машинасы килеп җитте. Мин җыенган арада бабакай-әтием, Бөгелмәдә тәмле ризыклар алырсың дип, миңа өч унар сумлык акча тоттырды. Инде чыгып китәм дигәндә генә, үз янына чакырып, колагыма болай дип пышылдады:

— Сабырлык кирәк, улым,— диде.— Дуамалланудан файда юк. Госпитальдә үләр алдыннан атаң: «Әсма минем гомерне бер елга озайтты, инде минә улым бар... Димескәйдә Барый Абдуллин яшәячәген белгәч, тынычлап үлә алам»,— диде. Атаң дөнья куйгач, Әсма килен үзенең сугышка кадәр яратып йөргән егетенә иргә чыкты. Минә шул кешедән кыз бала тапты. Хәзер сеңлеңә унике яшь булыр. Үги атаң Балтик диңгезе буендагы бер шәһәрдә хирург, ә әниең шунда пешекче бугай. Ярый, юл кешесенең юлда булуы хәер...

Машинаның ярсып улавына йөрәгем дулавы килеп кушылды. «Анамның исән-сау булуын белә торып, ничек инде ундүрт ел әйтмичә түзәргә кирәк?.. Бик яратсам да сине, бабакай-әтием, йөрәгем гафу итми...»

Машина кинәт кенә тизлеген үзгәртә дә, мин сискәнеп китәм. Әйтерсең, бу олы юлда әле генә мине талап киткәннәр. «Әни, бәгъ-

рем, ташлама мине!» — дип тилмереп елаганмындыр ул чакта. Ләкин ана кешедә бала кайгысы булмаган. Ул тизрәк яшь кияү кочагына ташланырга ашыккан. Шулай уйлыйм...

Менә шушы әрнү йөрәгемнән сызылып үтәргә өлгермәде, шундук әни дигән кешене каршыларга баруым исемә төште, күземә килгән яшь бөртеген күрсәтмәс өчен, башымны кабина тәрәзәсеннән тышка суздым.

Утыз чакрым араны шул уйлар эчендә үттем. Машина, серкәдә утырган хуш исле арыш басуын узып соңгы калкулыкка күтәрелгәч, Бөгелмә күренде.

Станция алдындагы мәйданда мин төшеп калдым. «Поезд килешкә машина шушында булыр»,— диде шофер абый.

Сәгатькә якын көтәсе бар иде. Ашамлык кибетенә барырга кирәклеген онытып, таушалып беткән таш басмалардан вокзалга күтәрелдем дә, аны бер әйләнеп чыккач, платформага юнәлдем. Тугызынчы вагонның кай тирәдәрәк туктаячагын чамаларга булдым. Ләкин моны белү ансат эш түгел икән. Арлы-бирле йөрергә тотындым. Товар поезды да узмый ичмасам. Аннан соң паровоз кайда туктар бит әле...

Ниһаять, экиятләрдәге аждаһа сыман ыжгырып, поезд килгәне күренде. Каршы алучылар вокзал алдына ябырылдылар.

Станциягә Мәскәү — Чиләбе поезды килеп туктады. Платформа халык белән тулды. Ыгы-зыгы, шау-шу артты. Халык бәрелә-сугыла, поездан төшүчеләрне каршы алу өчен үзенә кирәкле якка ташлана. Мин дә... Йөрәгем талпынып-талпынып тибә. Тугызынчы вагон янына ничек барып җитүемне хәтерләмим. Каршысында гына газета-журнал киоскасы бар иде. Шуның артыннан күзәтә башладым.

Вагоннан иң элек киндер чехол кидерелгән чемодан тоткан бер солдат чыкты. Аның артыннан офицер күренде. Майор. Ул, сикереп төште дә, унбер-унике яшьләрдәге, озын алтын чәчле кызыйны баскычтан күтәреп алды. Күңел сиземе белән мин аның үз сеңлем булуын таныдым. Әйе-әйе, менә әлеге офицер аңа «Иоланта» дип дәште, аннан үзе артыннан төшкән хатынга кул сузды. «Аусма»...— дигән сүзләрен тел аңламаган колагым ап-ачык ишетте. Озата чыккан ике абый да, офицер да аның янында биеп кенә йөриләр. Төшкәч, бераз як-ягына карангалап торды. Каршы алучылардан берәүнең дә аңар игътибар итмәвен күрепме, кызына нидер әйтте. Нәрсә соң бу? Анам немецча сөйләшә түгелме?.. Мин баскан җиремдә таш сын шикелле каттым да калдым. Күз алларым караңгыланып китте, башым берни уйлый алмас булды. Шулай күпме торганмындыр, кинәт ниндидер хатын-кызның:

— Мальчик, помоги! — дип ялварып кычкырган тавышына сискәнеп киттем. Борылсам, бер яшь кенә татар апасы. Бер кулында бәби, ә икенчесендә зур гына чемодан. Тагын — дүрт-биш яшьләрдәге бик әйбәт киенгән малай. Йөгереп килеп, чемоданны алдым.

— Кайсы вагон?

— Унберенче... Йөгерик...

Без барып җиткәндә поезд кузгалырга тора иде инде. Апа вагон баскычына сикереп менде дә, мин аңа бәбине тоттырдым. Проводникка башта — малайны, аннан чемоданны бирдем. Йөгереп барган килеш, үзем дә баскычка сикереп мендем. Поезд шактый кызуланып бара иде инде.

— Син бу поездданмыни? — дип сорады миннән теге апа, бераз сулыш алгач.

— Әйе,— дидем мин кыюланып.

— Кайсы вагоннан?

— Тугызынчы.

— Сиңа, энем, бик зур рәхмәт инде. Син булмасаң, поездан калган идек...

Тугызынчы вагонга барып житеп булмады. Күршесендә генә ресторан икән, шунда тукталдым. Юлым уңды, чиратта басып торатора, үземне чып-чын пассажир төсле тоя башладым.

Мәнә бер ялгызым ашап утырам. Мәскәү — Чиләбе поезды алга чаба. Шунда гына төшендем: Уралның кайсы да булса бер шәһәренә китеп барам икән. Әйе, мин — ярым шашынган хәлдә — анамнан, мине тудырган кешедән, аның сүзләрен ишетмәс өчен, качып китеп барам.

Мәнә ни өчен анам минем йөрәгемә таш булып утырды. Берәрсе аны телгә алды исә, чыраем сытыла. Мәнә ни өчен немецча сөйләшкәнне ишетсәм, сискәнеп-тетрәнеп китәм.

Аннан соң ни булды, Мәскәү — Чиләбе поездында кая барып життең? — дисең инде син, Сания. Ул турыда киләсе хатта. Арыдым, бик арыдым бүген. Фотодан миңа карап, көч биреп тормасаң, әле монысын да яза алмаган булыр идем. Хуш!

Барый.
28 апрель.

## Унөченче хат

Исәнме, Сания!

Уянып киткәч, фотоңа карап тордым-тордым да, синең белән гәпләшергә булдым. Җидедә градусник куярга кирәргә тиешләр. Ике сәгать тыныч кына язып утыра алам әле.

Күптәннән инде болай төш күреп, тәмләп йоклаганым юк иде. Бабакай-әтием белән умарталыкта кортлар карап маташабыз, имеш. Нәзирә дә безнең белән икән. Кулында тәтен өрдергеч. Шундый көчле итеп өрдерә, хатта үзен күреп тә булмый. Мин аңа кәрәзле бал бирергә телим... Ә Нәзирә дигәнем сеңлем Иоланта булып чыкты... Нәрсәдер немецча әйтә — аңламыйм гына бит...

Шунда уянып киттем.

Син, Сания, минем Барый икәнлегемне беләсең инде. Әмма күңелемдә язылып килгән бик күп сүзләрне, өтерләрне, нокталарны һәм дә сорау билгеләрен белмисең әле. Мәнә бүген шуларның кайберләрен күңел хәзинәсеннән бушатасым килә.

Сания! Өч кенә сүзгә кереп беткән иң кадерле уем бар: мин сине яратам... Бу сүзләрне әйткәч, үземдәге авыр бер йөкне бушаткандай, җиңеллек сиздем.

Ә уйларым поезд кебек чаба.

Поезд... Мине, үндүрт яшьлек малайны, туган авылымнан, бабакай-әтиемнән аерып, Чиләбегә алып киткән поезд...

Уралның төрле шәһәр-авылларын гизеп туйганнан соң, мин — Фәрит Айтуганов (качып киткәч, үземә шундый исем-фамилия алуым турында язган идем бит) — яңадан үзебезнең якларга килеп чыктым. Шулай товар вагонының түбәсендә бөгәрләнеп ята идем, иртән йокы аралаш бабакай-әтиемнең кытыршы кулы белән башымнан сыйпавын тойдым, ягымлы тавышын ишеттем: «Тор инде, улым, тор...» Уянып китсәм, янымда таныш түгел бер абзый утыра. Ул — Туймазы профессиональ-техник училищесы директоры Юлай абый булып чыкты. Узып барышлый мине күреп алган.

Бу изге җанлы кешене гомергә онытасым юк. Документсыз-нисез, үзләренә укырга урнаштырды, балта остасы булырга. Соңыннан гына белдем: Башкортстанның барча районнарына һәм Себернең һәммә өлкәләренә фотокарточкаларымны җибәреп, ул минем ата-анамны, туганнарымны эзләткән. Тегe чакта, дала кояшы, Урал җилләре тәэсирендәме, әллә өч ай мунчада булмагангамы, каратут йөзем белән мин аңа башкорт яки себер татары булып тоелганмындыр, күрәсең.

Минем хәбәр-хәтерсез юкка чыгуым бабакай-әтиемне гүргә керт-

кән. Күңелемдә ничәмә-ничә тапкыр язылган хатымны, һич югында исәнлегем турында кош теле хәтле генә язу кисәген җибәрергә кирәк булган да бит — терсәкне тешли алмыйм. Югыйсә, бабакай-әтиемне авыр сүз белән дә рәнҗеткәнем булмады. Ул шактый кырыс табигатьле, әмма бик тә кешелекле иде, мәрхүм...

Юк, бүген төнлә йоклый алмам. Госпитальдә утлар сүнүен көч-хәл белән көтеп алдым да, торып утырдым. Аякларым сап-салкын. Каһәр суккан үлем бөтен гәүдәмә хуҗа булырга җыена, ахрысы...

...Явыз үлем! Миңа тагын бик аз гына вакыт бирче, шушы хатымны тәмамларга гына. Язмышымдагы иң-иң әшәке көннәрем турында сөйләргә өлгермәмен дип куркам.

Училищены тәмамлап, төзелештә эшли башладым. Кичке мәктәпнең унберенче классында укыйм.

Шулай әйбәт кенә эшләп йөрим. Кичләрем мәктәптә һәм уку залында уза, киногa барган юк. Хәер, вакытын таба алган булыр идем, әмма йөрисем килми, кызлар бик чакырып торсалар да. Әнинең хыянәте ирек бирми...

Гөрләвекләр ага башлаган чак иде. Төзелеш кранында эшләүче апа декрет ялына чыккач, аның урынына чибәр генә бер кыз килде. Эльвира. Өстендә телогрейка гына булса да, ирләрнең игътибар үзәгендә ул. Үзен һәркайда иркен тота, һәрвакыт — шат күңелле, уенчак табигатьле.

Менә әллә кайдан югарыдан Эльвираның көмеш тавышы яңгырап китә:

— Әй, кем бар анда-а-а?

Ирләр заты, бөтен эшләрен ташлап, кран янына йөгерә.

— Фәрит!.. Фәрит Айтуганов! Миңа буфеттан кефир һәм пирожкилар алып мен... Тиз бул! Премиясе — горячий поцелуй! Озакласаң, суынып...

Шайтан алгыры, кайдан белгән ул минем исем-фамилиямне? Шундый йомышны үтәми кара — иптәшләрдән яхшылык көтмә аннары!

Әйе бервакыт... Мин кефир белән пирожкилар алып менгәч, Эльвира кайнар кулы белән иңемә кагылды:

— Сигездәге сеанска «Космос»ка кил... Фәрит дим... Бүген укырга барасың юк бит... Көтәм...

Кичен «Космос»ның уку залында утырганда шул сүзләр колак төбендә гел яңгырап тора, башыма берни керми. Әледән-әле тәрәзәгә карап куям: килмәдеме икән? Әмма, үзен күргәч, янына чыкмыйм.

Шулай тәрәзәгә карап көтеп утыра идем, кинәт арттан берәү кайнар куллары белән күзләремне каплады. Эльвира!

— Куянкаем, мәхәббәттән качып котылып буламыни!..— дип пышылдады ул колагыма.

Аннан соң ул мине туган көненә кунакка чакырды: җомга көнне сәгать җидегә Нариман урамындагы фәлән-фәлән йортка килергә, бер генә секундка да соңга калмаска!

Эшемнең рәте булмады, башымда бер генә уй: март азагында бу бәләкәй шәһәрдә нинди дә булса чәчәк сатып алырга мөмкинме?.. Юк, кысыр хыял икән. Ярый әле тулай торагыбыз тәрбиячесе Хәдичә апай берәүнең адресын бирде — ул кеше парникта чәчәкләр үстерә, ди. Җомга көн, эштән соң, шунда элдерттем. Чәчәкләр булуын булды, әмма тулай торакка җидедә генә кайтып кердем. Юынып-киенеп, кунакка барырга чыкканда инде сигез иде.

Эльвира әйткән адрес белән килсәм, ни күрәм: биек койма белән уратылып алынган төзелеш мәйданы. Шаяртты микәнни? Чәчәкләрне кая куярга белмичә, ачык капка янында аптырап торганда, әле салынып та бетмәгән биш катлы торак йорт артыннан Эльвира килеп чыкты.

Төзелеш мәйданының иң түрендә, авыл мунчасыннан аз гына зуррак бер өй ишеренгән булып чыкты. Эльвира үзенең әнисе белән вакытлыча — яңа йорт өлгергәнче — шунда тора икән.

Өйдә ул үзе генә иде. Әнисе берничә көнгә авылга кайтып киткән.

— Кунаклар, сине көттеләр-көттеләр дә, кайтып киттеләр,— дип шаяртты Эльвира һәм, кефир шешәсенә су салды да, мин китергән чәчәкләрне шуңа утыртып, табынга куйды. Ә табын тәм-томнан һәм төрле эчемлектән сыгылып тора иде.

— Безнең дуслык өчен!

— Туган көнең котлы булсын!..

Эльвира алдында сынатмаска теләп, аягүрә торган килеш үк, эчемлек тулы фужерны төбенә кадәр бушаттым. Моңа кадәр сыра да эчкәнем булмагангамы, әллә иртәдән бирле рәтләп ашарга туры килмәгәнгәме, мин шунда ук изрәп киттем — бөтен тәнемне талдырып әллә нинди сихри рәхәтлек йөгерде. Әйе, бу мәлдә миңа инде ничәмә еллар кайдадыр адашып йөргән куанычларым табылган кебек тоелды. Икенче тост әйтелдеме-юкмы, хәтерләмим...

Башым чатнаудан уянып китсәм, Эльвираның кайнар куенында ятам.

Ике тәүлек — шимбә һәм якшәмбе — өйдән дә чыкмыйча тоташ мәхәббәт диңгезендә йөздек. Аннан соң эш көннәре китте... Эштән соң — тагын бергә. Кичке мәктәп онытылды. Бер атна дигәндә туган көнгә алынган шешәләрнең һәммәсен бушаттык. Аннары Эльвирага авылдан хат килде. Ул, өй ачкычын миңа калдырып, кинәт кенә авырый башлаган әнисе янына кайтып китте. «Тынычлап укы инде, егеткәй»,— диде ул миңа, автовокзалга озата төшкәч.

Ләкин мәктәпкә бүтән барырга туры килмәде миңа. Якшәмбе көнне, иртәдән кичкә кадәр «Космос»ның уку залында дәрес әзерләп утырганнан соң, Эльвирадан хәбәр юкмы икән дип ялгыз йортка сугылсам, идәндә бер язу ята. Форточка яртылаш ачык калган — димәк, шуннан ташлаганнар.

Укыйм — үз күземә үзем ышанмыйм: Эльвирага — «Амура-Мурага» нииндидер «Ә-сабака» язган. Хәтеремә мәңгегә сеңгән ул оятсыз сүзләрне сиңа әйтергә, Сания, хәзер телем бармый, тик кайбер нәрсәләр турында гына сөйли алам.

Эльвираның ире бар,— ул «бозау» (Женя-Җәмил) икенче ел инде солдатта икән. «Ә-сабака»ның «бәби-копия»сен бик тә күрәсе килә икән. Ләкин «Маму проводила деревню» дигән телеграмманы ике атна элек үк алса да, командировкага чыга алмый интеккән. Ах, Амура-Мура! Син булмагач, бүген ул үзенең ничә төннәр хатыныннан саклап килгән «ялкынлы теләген» ресторанда аракы белән генә сүндерә алачак...

Бу әшәке хатны кем язган?.. Мәкерле шаяртумы бу? Безнекеләрнең берәрсе монда кереп чыкмадымы икән?..

Мене шундый сораулар тынгылык бирмәде миңа ул чакта. Хатны кесәгә тыктым да, өйнең ишеген бикләргә дә онытып, капка янындагы будкага йөгердем.

— Син килер алдыннан гына Эльвираның летчик абыйсы кереп чыкты,— дип сөйләп китте каравылчы апа.— И туганчыл җан да инде: сеңлесен дә, пләмәшкәсен дә баштан-аяк киендерде... Ә син, егет, яхшы авылдаш булсаң, Эльвира тирәсендә башка буталма! Үзең беләсең, аның армиядәге ире тиздән кайтырга тиеш. Каргышы төшмәсен...

— Ник бөтен дөньясы чәнчелеп китми шунда!

Җитте, шунда туктасын! Уйларым мине тәмам арыттылар. Теге чакта Эльвира җаныма ут салды. Ул ут иң татлы, иң матур хисләремне көйдерде-яндырды. Бүтән бу хакта сүз кузгатасым, искә аласым килми. Мәхәббәттән беркайчан да уңмадым мин.

...Исәнме, Сания! Соңгы өч төнне синең белән гәпләшә алмадым.

Ни өчен дисәң, укол салып йоклаттылар. Ә көндезләрен иптәшләр килде. Миңа иртәгә янә бер операция, соңгы операцияне ясап караячаклар.

Ә шулай да, Сания, син мине үлемнән алып калырсың кебек тоела миңа.

Теге чакта, ресторанга «Ә-сабака»ны эзләп табып кабыргаларын сытарга дип ашыктым мин. Анда ни булганын язмый торып, барыбер йоклап китә алмам.

Шау-шулы музыка, бәйрәмчә киенгән, хушбуйланган хатын-кызлар, кочаклашып-үбешеп утыручы исерек ирләр арасында мин башта югалып калдым. «Ә-сабака»ны ничек табарга? Инде чыгып китим дигәндә, ишек янындагы бер өстәл артыннан таныш тавыш ишеттем:

— Айтуганов! Менә сиңа мә!.. Нинди җилләр ташлады? Әйдә, тарттыр бирегә!

Өстәлнең миңа каршы ягында, үзенең бригадиры Степан агай белән кочаклашып, слесарь Ваня утыра, үзләре янына дәшеп, кул изи. Мин уңайсызланып калдым. Чыгып китәргә үк җыенган идем, бригадиры тотып калды.

— Ир кеше бул!

Ул Ваняга, миңа, үзенә аракы салды. Нәрсә хөрмәтенә икәнен дә уйлап тормыйча, бокалларны чәкештердек. Табындашларым шунда ук күтәреп капладылар. Мин яртысын гына эчтем дә, бокалны кире куйдым.

— Эш түгел бу! — дип кыстады бригадир.— Әгәр син безнең белән бер сүздә икән, тигез эч.

— Син, Фәрит, безнең күңелне күтәрергә теләмисең, ахры? — дип мыскыллагандай елмайды Ваня.

Эчеп бетерергә туры килде.

Шунда битемә Степан агайның күптән кырынмаган чәнечкеле яңагы килеп сыланды.

— Дустым минем... былбылым, әйдә үбешәбез,— дип мыгырданды ул, төкерекләрен чәчеп.— Синең ише каттә егетләрне үлеп яратам мин...

Ачудан һәм җирәнүдән сулышым кысыла башлады, бу бәйләнчекне төртеп җибәрәсем килде, тик моңа ихтыярым, көчем җитмәде.

Тагын күпме вакыт узгандыр — белмим, тик шунда мин кинәт кенә бар дөньяның үзгәреп киткәнен тойдым. Бина эче язгы кояш чыккандай балкый, зал сабан туе мәйданы кебек гөрли, айкала. Тирә-ягымдагы кешеләр шундый сөйкемле, шундый мөлаем!..

— Чибәркәйләр, икегезгә генә ямансу түгелме? — дип дәште Ваня күрше өстәлдә утырган кызларга.— Күчегез безнең янга... или лучше без сезнең янга...

Без, үзебезнең бөтен сый-хөрмәтебез, бөтен мөлкәтебез белән кызлар янына күченергә карештек. Тегеләр, ап-ак симез кулларын сузып, шешәләрне, бокалларны, тәлинкәләрне кабул итә тордылар. Без, иңнеиңгә терәшеп, бишебез бер өстәл артына урнаштык.

Ваня барыбызга да аракы салды.

— Әйдәгез, дуслык өчен! — диде ул.— Бетереп! Төбенә кадәр!

Үземнең бирегә нинди ният белән килгәнемне тәмам оныткан идым. Әллә каян телгә килгән бер җырны сузып җибәрдем:

Урысларның сөйгән аты
Иван белән Ычтапан.
Үзем җырлыйм, үзем эчәм,
Үземә тигән стакан.

Кызларның берсе серле генә елмаеп куйды.

Исеме Раузамы, Розалияме, әллә Розамы — хәтерләмим. Медучилищеның соңгы курсында укый икән. Күкрәгән миңа терәп үк бии. Бу миндә Эльвирадан үч алу теләге уятты.

— Әйдә качабыз! — диде ул миңа, ишеккә таба ымлап.

Мин аны арткы урамнан, төзелеш коймалары аша, ялгыз йортка алып кайттым...

Иртән уянып китсәм, алтын сәгатьтән дә (аны миңа балта осталары конкурсында беренчелекне алуым өчен биргәннәр иде), костюмымның эчке кесәсендәге янчыктан да җилләр искән. Кыз да үкчәләрен ялтыраткан...

Шулай эчә башладым мин... Ә аннан соң, кичке мәктәптән куылар. Хәер, ялгыш юлда булуымны, кешене хурлый һәм түбәнсетә торган эшләр белән мавыгуымны аңлый идем мин. Тормышта һичбер максаты булмаган, бар сәләтен, бар көчен ваемсыз рәвештә әрәм-шәрәм итүче бер кешегә әверелә баруымны да күрә идем. Ләкин болай яшәү җиңелрәк бит! Җиңелрәк тә, һәм уңайрак та! Һичнәрсә турында уйлыйсы, һичкая омтыласы юк.

...Элеккеге елларда ничек булгандыр, белмим, ә менә быел безнең частьтә Яңа елны утызынчы декабрьдә бәйрәм иттеләр. Май заводыннан кызлар килгәч, лотерея уены оештырганнар һәм ун тиенгә «Шампанское» отарга мөмкин иде. Унбиш билет сатып алсам да, миңа ике карандаш, кесә көзгесе белән тарак һәм ирен буявы гына эләкте. Ә «Шампанское»ны майор бичәсе отты. Ачуымнан бер чибәрне вальс биергә чакырдым. Таныштык. Ул иреннән аерылган, өч яшьлек кызы белән генә яши икән. Мине үзенә чакырды. Увольнениегә чыгармагач, юк инде ул кунакка йөрүләр. Ә шулай да ике атнадан соң, старшина үз авылына әнисен җирләргә дип кайтып киткәч, бер төнне шәһәргә качып чыктым.

Шуннан соң тынычлыгым югалды. Көннәрдән бер көнне, кичкә таба, старшина белән Кәримов партҗыелышта чакны, казармабыз яныннан койма аша тагын качып чыктым. Ләкин, шәһәргә килеп керүгә, патрульгә эләктем. Соңгы мәртәбә кисәтү ясап, биш көнгә кухняга бәрәңге әрчергә җибәрделәр.

Хәтерлисеңме, Сания, син башта миңа хат-хәбәр салмый идең. Сиңа үч итеп, янә теге хатын янына бардым. Ул кичне без бер тамчы да вино эчмәдек. «Сиңа охшаган матур улым булуын телим»,— диде ул...

Таксига ышанып, шактый соңга калып чыктым. Әмма урамда да, вокзал янында да ник берсе күренсен. Тиздән кичке барлау. Җан-фәрманга йөгерсәм дә, кайтып өлгермәячәкмен. Юк, инде бу юлы гафу итмәсләр, дип уйлыйм.

Вокзалга ни өчен керүемне хәтерләмим. Озын эскәмиядә йоклап ятучы бер бабайга күзем төште дә, аның янындагы буш урынга барып утырдым. Шулай күпме утырганмындыр, кинәт башыма үтә кыю фикер килде: сукыр эчәге приступы булгандай, эчемне тотып авып төштем. Җан әрнеткеч ыңгыраша башлагач, бабай сикереп торды, сөрән салып кычкырды: «На помощь! Помогите! Солдат умирает...»

Ашыгыч ярдәм машинасы мине хәрби госпитальгә илтеп тапшырды. Анда мин үземне тагын да кызганычрак тоттым. Врачлар алай-болай итте, әмма операция өстәленә салмый булдыра алмадылар. Шунда гына бераз шүрләп калдым. Чөнки мин уколдан курка идем.

Аннан 4—5 тәүлек урын өстендә ятып кына торырга куштылар, беркая чыгармадылар. Йөри башлауга, мине баш хирург үз кабинетына чакыртты. Ул шактый өлкән яшьтәге элеккеге фронтовик икән. Миңа текәлеп карап торды да, ничектер үз итеп:

— Синең әниең Паланга курортында эшләмиме? — дип сорады.

Бөтен тәнем эсселе-суыклы булып китте. Көч-хәл белән әйтә алдым:

— Юк, ул сугыштан кайтмады...

Баш хирург — медицина подполковнигы — язу өстәле артыннан

чыгып, минем янга диванга килеп утырды, кулын җилкәмә салды:

— Ничек син, Фәрит, үз теләгең белән пычак астына кердең? — диде.— Ә бит операция өстәле янында үлем үзенең яңа корбанын көтеп тора... Кызганыч, мине операция ясый башлагач кына чакырып алдылар... Яшь хирург әле ул, беренче елы гына... Синең шундый коточкыч алдашуны аңламаган, аптырап калган... Сукыр эчәк үсентесен профилактик чара рәвешендә генә кисеп алуыбызны әле хәзергә дүрт кенә кеше белә, шуларның берсе — син үзең... Ә хәрби трибунал мондый җинаять өчен сине хөкем иткән булыр иде.

Мин бу кешегә, Сания, үземнең баштан кичкән кайбер нәрсәләрне сөйләми кала алмадым.

Аннан соң янадан йомшарды һәм, ярым шаяртып, ярым җитди итеп әйтә куйды:

— Хезмәтеңне тутыргач, театр училищесына укырга кер: синнән бер дигән артист чыгачак. Ә уставны моннан соң һичкайчан бозмаячагыңа ышанам... Килештекме?..

Тагын бер атнадан частька кайтырга рөхсәт иттеләр.

Автобуста туп-туры шәһәргә кайттым. Янәсе, увольнениегә кайчан чыгаралар әле, бу мөмкинлектән файдаланып калырга кирәк. Бәлкем, теге чибәр өйдәдер. Барам шулай тар гына урам буйлап. Сәгать унбер тирәсе. Берәү дә юк, тып-тын. Кинәт аргы очта, зур тирәк янындагы агач йортта ут ялкыны үрләвен күрдем. Йөгереп барсам, өйалды ишеге ачылмый — эчтән бикләнгән, ә аннан җан өшеткеч тавыш ишетелә. Тәрәзә янагына беркетелгән тимер рәшәткә бирешми. Ниһаять, юл ачылды, әмма өй эчендә сары төтен, күзне ачарлык та түгел. Суларга һава юк. Авыру әбине тәрәзә янына күтәреп килүем генә хәтердә — шунда аңымны югалтканмын...

## Соңгы хат

Исәнмесез, безнең өчен бик кадерле булган өлкән киңәшчебез-остазыбыз Сания түти!

Күктәге йолдызлар, судагы кондызлар санынча ялкынлы солдат сәламнәребезне таң җилләре аша озатып, хәерле теләкләр күндереп калучы Әхәт Кәримов дип укып узарсыз. Оныгыгыз Саниягә исә бездән аерата кайнар сәлам, аңа консерваториядә укуында зур уңышлар телибез!

Сания түти! Телефонга чакыртып, минем белән сөйләшүегездән соң шактый озак вакыт узып китте. Командировкадан әйбәт кенә кайтып төшсәм, мендәремдә сез җибәргән хат ята. Шунда ук конвертны ачып, сез язганнарны укып белдем, бик зур рәхмәт! Әлегә кадәр сезнең белән хәбәрләшә алмавым өчен гафу итегез инде — йомышларыгызны бүген генә башкарып чыктым.

Телефоннан сөйләшкәннән соң, иң элек үзебезнең генерал янына бардым. Фәрит хакында сүз башлауга, хәбәрдар булуын белдертте. Әле теге чакта — Совет Армиясе көне алдыннан сукыр әбине ут эченнән алып чыккан батыр солдатның хәлен белергә дип госпитальгә баргач — аңа баш хирург Янис Августович, бөртеген дә төкми-чәчми, Айтугановның ачы язмышы турында сөйләгән булган. Ләкин ул ата-анасыз үскән егетнең чын исем-фамилиясе Барый Абдуллин икәнлеген белмәгән. Шуны әйтүемә, генерал урыныннан торып йөренә башлады.

Шуннан соң, Сания түти, мин аңа сезнең Димескәйгә барып хат ташучы Камиләдән сорашып белгәннәрне, ягъни Барыйның әнисе Аусма Алттоаның Палангада кондитер фабрикасында эшләвен әйттем.

Генерал шунда ук үзенең шоферын чакыртты һәм миңа, Палангага барып, Барыйның әнисен алып килергә кушты. Кош теле хәтле генә хат та язып бирде.

Паланга шәһәренә кичкә табарак кына барып җиттек. Озак эзләп

йөрисе булмады: анда хирург Юхан Освальдович Алттоа билгеле кеше икән.

Ишекне бер чибәр генә кызый ачты. Бик тә Фәриткә охшаган. Болай булгач, минәйтәм, дөрес кергәнбез. Ул арада хуҗа үзе дә килеп чыкты. Таныштык. Фәритнең сеңлесе Иоланта атлы икән. Атасы белән гел немецча сөйләшүе миңа ифрат сәер тоелды. Бу минем чыраема да чыкты булса кирәк.

— Хатыным Аусма — литва татарларыннан, ә мин үзем — эстон, беренче очрашканда икебез дә немецча яхшы сөйләшә идек — шул уртак телебез булып китте,— дип аңлатты хуҗа.

Без, ирләр халкы, чистарынып-юынып алганчы, Иоланта зал якта олы табын әзерләп куйган иде. Утырыштык. Аусма апа гына һаман да юк. Аның хакында сүз кузгаткаласам да, ачык җавап булмады.

Кичке аштан соң Юхан Освальдович мине үз кабинетына чакырды. Менә шунда аңлаштык.

Башта ул Барый турында сорашты. Чәчми-түкми һәммәсен сөйләп бирдем. Аның күзләренә яшь тулган иде. «Суга төшкәндәй юк булды шул»,— дип кенә әйтә алды.

Алар Мәскәүдә, Зур театрга билетка чират торганда танышканнар. 1941 елның гыйнвар аенда, кышкы каникулда. Аусманың кулинария техникумы студенты, ә Юханның медицина факультетын (хирург Янис Августович белән бергә укыган ул) тәмамларга йөргән чагы икән. Җәен Балтик диңгезе буендагы Паланга курортында очрашырга сүз куешканнар, чөнки анда ачылачак пионер лагерена Аусма үз авылларыннан бер төркем балалар алып килергә тиеш булган.

Ачылуына әле өч кенә атна тулган пионер лагерена немец самолетлары беренче бомбаларын ташлый. Андагы балаларны кичекмәстән тылга озатырга карар була. Аусма да үз авылының пионерлары белән озын юлга кузгала. Латвия җирендә алар авыр яраланган солдатларны һәм командирларны алып китеп баручы эшелонга эләгәләр. Бер станциядә, Аусма үзенең авылдашларына һәм дусты Юханга телеграммалар җибәреп йөргән арада, поездга «юнкерс»лар һөҗүм итә. Шунда пионерларның күбесе һәлак була.

Шул коточкыч көннәрдә Аусма үзенең сугышчан юлын башлый. Башта — санитарка, аннан медсестра була һәм старшина дәрәҗәсен ала. Ул, тормышын куркыныч астына куеп, бик күп ярalыларны үлем кырыннан алып чыга. Аннан үзе дә, яраланып, госпитальгә эләгә һәм, янә аягына баскач, шунда повар булып эшли башлый.

Ә Барыйның әтисе Аусма белән 1943 елны, авыр яраланып госпитальгә эләккәч таныша һәм, аягына басуга, үзен үлемнән тартып алган бу бик тә чибәр кызга өйләнә. Аннан янә сугыш дәһшәтләре...

Иртәгесен Юхан Освальдович эшенә китте, ә Иоланта, мәктәбенә кереп чыкканнан соң, абыйсы янына госпитальгә барырга булды.

Юлда, машинада барышлый, мин Иолантага «әнием», «әтием», «абыем» һәм шундыйрак башка татар сүзләрен өйрәттем.

Сеңлесе белән очрашып сөйләшкәннән соң әтисенең батырлыгы турында белгәч, Барый: «Әнием нигә килмәде?» — дип сораган, диделәр. Мин үзем ул көнне аның янына керә алмадым.

Ә улы югалу кайгысыннан тагы да ныграк эчә башлаган Аусма апаның бүген кайда, ничек яшәвен хәтта аның үз ире дә, кызы да белмәвен Барыйга әйтеп буламыни?! Ул моннан ике ел элек бөтенләй эчүгә сабышкан, ниндидер бер иргә ияреп, юкка чыккан...

Сания түти, сез ничек алдан күреп бу кадәр хак әйткәнсез: «Фашист илбасарлары башлап җибәргән икенче бөтендөнья сугышы Япониягә мәңге онытылмас Хиросима фаҗигасе алып килде, ә безнең халыкка — моңарчы ничәмә-ничә гасырлар аракыга һәм азгынлыкка җирәнеп караган татар халкына — кешелекнең иң әшәке, иң йогышлы чирләреннән берсе булган эчкечелек китерде. Барыйның анасын

да шул яшел елан чаккан булырга тиеш, чөнки аларның ачы язмышында ул еланның зәһәр угы да сизелә...»— дип язасыз бит сез.

Сания түти! Бүген ниһаять сезнең иң авыр йомышыгызны үти алдым: яшьтәшебез Сания белән түгел, ә аның дәү әнисе, ягъни сезнең белән хат алышкан булуыбызны, ә оныгыгыз Саниянең ата-анасы янында шәһәрдә яшәве, консерваториядә укуы һәм безнең турыда һични белмәвен Барыйга белгертү җаен уйлап таптым. Әйе, җаен! Чөнки бу хәбәрне дуамал гына әйтеп ташласаң, аның болай да кыл өстендә генә торган гомерен өзүебез ихтимал.

Барыйның, Сания түти, йөрәге электән җәрәхәтләнгән булган аның. Беркемне дә кичермәслек итеп җәрәхәтләнгән. Хәтта әнисен дә. Ләкин аның әнисе үзе дә яралы җан бит. Әгәр уйлап карасак, Сания түти, бу язмышларда бары тик сугышны гына гафу итеп булмый. Әйе, сугышны кичерү мөмкин түгел.

Ә Барыйның бер өмете бар, Сания түти. Үзе ачык кына әйтергә кыймый...

Сания түти, оныгыгыз белән ничек тә булса килеп китсәгез иде,— бу сезгә барчабыз исеменнән иң зур, иң гозерле үтенечебез. Мәгәр, нишләмәк кирәк, адәм баласы бит, көннән-көн матуррак чәчәк ата баручы бу дөньядан кемнең китәсе килсен.

Үзебезнең хәлләргә килгәндә, исән-сау хезмәт итеп ятабыз. Тиздән җәйге лагерьга чыгабыз.

Кабат өстәмә кайнар сәлам белән — өлкән сержант

Әхәт Кәримов

*1970—78 еллар*

*Әсәрнең журнал варианты*

## Энҗе Мөэминова

# ИКЕ ҖЫР

## Уятырмын үбеп кенә

(БИШЕК ҖЫРЫ)

Баш астында мамык мендәр,
Өстеңдә мамык юрган.
Тыныч йокы теләп сиңа
    Бар дөнья тынган.
    Әлли, бәлли, бәү.

Йокың тыныч булсын диеп,
Йолдызлар тора сакта.
Җемелдәшеп сөйләшәләр
    Гел синең хакта.
    Әлли, бәлли, бәү.

Йокла инде, йокла, балам,
Матур төш күреп кенә.
Уятырмын үбеп кенә,
    Бер үбеп кенә.
    Әлли, бәлли, бәү.

## Көмеш кебек сафлык ул

*(Көмеш туйга, 25 елдан соң)*

Көмеш — көмеш булып кала,
Нинди генә шартта да.
Саклый ул көмеш сафлыгын,
Тоныкланган чакта да.
  Яши белгәнегез өчен,
  Тормышның кадерен белеп,
  Гомер иткәнегез өчен
  Пар күгәрченнәр кебек,
Көмеш туй — Сезгә бүләк ул!—
Җиңеп яшәү шатлыгы.
Гомерегезнең балкып торган,
Көмеш кебек сафлыгы!
  Хәтерләтеп челтерәп аккан
  Көмеш чишмә җырларын,
  Көмеш сафлык бәркеп торсын,
  Гомерегезнең киләчәктә
  Бергә үтәр еллары!
Котлы булсын туегыз!
Гел янәшә булыгыз!

# Фирая Зыятдинова

## Ташкын

Каян ала ташкын мондый көчне,
Каян ала мондый ярсуны?
Каян ала мондый кайнарлыкны?
Кар суы бит үзе, кар суы!

Бар нәрсәне юып алып китә —
Саламың ни аңа, ташың ни...
Язлар җиткәч, елга бер булса да,
Булмыйдыр шул инде ташымый.

Бер гөнаһсыз ак кар бөртекләрен
Кояш, күрче, әнә нишләткән!
Бөтереп алса язмыш үз куенына,
Булмыйдыр шул инде нишләп тә...

Бөтерелеп ага болганчык су,
Танымыйм мин анда ак карны.
Китеп барды ташкын әллә кая,
Күңел диңгеземне актарып...

## Ашыгам...

Көннәр көнне ашыктырган төсле,
Әй ашыга уйлар, ашыга.
Нәрсә кирәк җанга, нәрсә җитми,
Алда минениләр каршылар?

«Кунак кына» бит без бу дөньяда,
Ашыгабыз шуңа микәнни?
Юргаларың читтә торып торсын,—
Тизлекләргә күзләр иярми.

Әй ашыгам инде, уйлаган юк
Иртәгесен нәрсә көтәсен.
Үзем ашыгам, бүтәннәрне куам,
Әйтерсең лә дөнья бетәсе...

Шау-гөр килә егерменче гасыр,
Шул гасырның мин бер баласы.
Дөнья кайный зур бер казан сыман,
Башны гына кая саласы?!.

❁

Нигә тыныч яши алмый минем күңел?
Кемнәр салган күңелемә бу давылны?
Җиде буын бабамнармы, атам-анам,
Әллә җаннан газиз күргән авылыммы?

Өзелеп төшкән яфракка да күңел әрни,
Чәчәкләрдә тузан күрсәм, эчем поша.
Сабыйларның елаганын тыңлый алмыйм,
Үзем дә бит сабый булган инде, юкса...

Әле һаман сабыйлыктан чыгып булмый,
Һаман елыйм сабыйларча үксеп-үксеп.
Ә сөенсәм, күзләремнән нур түгелә,
Нигә тигез була алмыйм, алла белсен!

Актарыла, бөтерелә, әйтерсең лә
Боз кузгалган язгы елга минем күңел.
Кемнәр салган күңелемә бу давылны?
Ник ярсый ул, нигә сабыр, тыныч түгел?!.

## Арткан саен

...Кирәк булса, диңгез кебек
Актарылып дулармын.
Кирәк икән, ташка ятып,
Бер туйганчы елармын.

Кирәк булса, елгаларын
Кирегә дә борырмын.
Кирәк икән, давылларда
Кыя таштай торырмын.

Сәерсенмәгез, күрсәгез,
Нигә, дип, шулай ярсый?
Миндә — давылларның шавы,
Кайнарлыгы Кояшның.

Миндә — Җиремнең ныклыгы,
Уйламагыз: «Кыз бала...»
Авырлыклар арткан саен,
Мин ныгый гына барам.

*

Яшьлегемдә җыр башладым:
Дәвамы бул син җырымның.
Ерактагы йолдыз бул син —
Тигез генә сип нурыңны.

Якын килмә — көнчегермен,
Йә бизәрмен, күзем чагылып...
Ә минем уй — дөнья көтү,
Гомер буе сине сагынып.

## Бикә Рәхимова

### Кирәк түгел фал ачулар

Мин күргән-белгән, кичкәннең
Болар әле бер каты,
Асылына төшәсе бар —
Төш-чикләвек бик каты.

Асылына төшәсе бар
Гамьнәрнең, уйларның да...
Ерак-еракта күңелем,
Диңгезнең буйларында.

Акшынулары диңгезнең
Күңелгә тәңгәл килгәч,
Төпкелдән чыккан дулкыннар
Йөрәккә килеп тигәч,—

Тирәнлеккә баш июләр,
Шаккатып аһ итүләр
Чоңгылларга тарта икән,
Шул икән баш китүләр...

Безнең кайнап торган заман —
Менә шушы бүгенге —
Алдагының, давылларның
Җиле генә түгелме?..

Ә шулай да кирәк түгел
Ашыгып фал ачулар,
Күрәзәлек итүләрдән
Җанда бары — ачулар...

### Ил-көн өчен

Иркен сулыш алыйм дисәм,
Сулышым иркен түгел,
Ил-көн өчен яшим дисәм,
Алдымда ил-көн түгел.

Ил-көн түгел, әллә нәрсә
Тузгыган ул, болгана,—
Адәмнәре чәбәләнә,
Аергандай корт ана.

Бер әз белән үткәнемә
Кайтыйм дисәм тагын да,
Сукмаклары тармаклана,
Икеләнү җанымда.

Ә шулай да мин кайсысын
Сайларга белер идем:
Кояш балаларын җыйган
Мәйданга килер идем.

...Үткәнемә юлларымны
Чын дөресен сайласам,
Гаҗәпкә, дим, калмассыз бит,
Сандугачтай сайрасам...

*

Арам, ял итеп алам,
Тагын торам, кузгалам;
Эшем шундый якын миңа,
Гүя минем үз балам.

Җәберсетү, кимсетүләр —
Әллә бар ул, әллә юк.
Бирешмимен, корычландым,
Холкым хәтта корыч күк.

Адымнарым авырайса,
Сискәнеп китәм дә мин,
Шуып кына китә йөгем,
Бар көчкә этәм дә мин.

Җир дә тизрәк әйләнә күк —
Шулай миңа тоела,
Мин дә этеп барам сыман,
Тик... күз яшем коела...

Барам, барам максатыма,
Юлда тукталаммы соң?
...Их, дускаем, син дә шулай
Максатчан булсаңчы соң?

Безнең ул чак — һәммәсенең —
Олының, нарасыйның
Күз яшьләрен киптерүдән
Күңелебез арырмы соң?!

Өләшкәндәй итәм сезгә
Хатын-кыз акылымны...
Дөнья уңаенамы ул,
Әллә ул аркылымы?

Юк, юк, дөньяның җаена
Игелекле нур булыр.
Безме сөймәгән тормышны...
Сүзем яклап гел торыр.

Кайдан килгән, кая күчә
Безнең уй һәм теләкләр?—
Әнкәйләрдән килгән гамьнәр
Безне һаман җитәкләр.

Алармы тырышмаганнар,
Көчсез иңгә йөк салып,
Үтәргә тайгак кичүне,
Үткәндәй аннан Алып.

Әллә уйларга, әллә юк
Башсыз калуны хәтта —
Атылган йолдызлар кебек,
Кылыч уйнаган чакта...

Хатын-кыз ул акыл бирер:
Ак кылыч буялмасын,
Анадан туган балада
Ерткычлык уянмасын.

*

Тирә-юнем гөлчәчәк дип,
Инде күпме җырладык,
Без җырлаудан үскән «чәчәк»
Булыр меңәр олаулык.

Чәчәк диеп җырлаулардан
Чәчәккә әйләнмәдек,—
Тигәнәкне күреп һаман
Кемнәргә бәйләнмәдек...

Үткән эшкә салават дип,
Кулны болгап югалыйк?
Юк инде, туган-кардәшләр,
Соң булса да, оялыйк...

...Тирә-юнем гөл диюдән
Гөл булса икән илләр...
Чәнчешеп, әрнеп авырта
Кычыткан чаккан җирләр...

*

Иртә таңда кояш белән
Мин дә торам, җыенам,
Җәмәгать арбасының бер
Почмагына сыенам.

Халык та шулай сыена:
Басканнар, оеганнар;
Һәрчак миңа юлдаш була
Сөмсере коелганнар.

Мин менә аңларга тиеш
Аларның күңелен дә:
Миңа сөеп караганның,
Бик алай түгелнең дә.

Иң кара болыт тарала,
Нурдай балкып карасаң,
Җылы сүзне, киң күңелне
Бер дару дип санасаң.

Шул уйларым белән генә
Халләренә керсәм дә,
Бәхет ачкычын янымда,
Йөртәм гүя кесәмдә...

Шул ачкычны алып кына
Юлдашларга бирәсе.—
Йөзләрендә елмаюны
Күрәсе иде, күрәсе...

# Халисә Мөдәрисова

## Көмеш дага

Исемдә иске алачык,
Учакта күмер яна,
Алачыкта картәтием
Атларга дага кага.

Үзе сөйли:— Гел көмештән
Бар бәхет дагасы,— ди,—
Бик бәхетле кеше генә
Даганы табасы,— ди.—
Яу җиңеп агаңнар кайтыр,
Даганы тапсаң, хәтта...

Ә җиңгиләр сабан сөрә —
Дагасыз арык атлар...

Мин бер сабый, мин ышанам,
Эзләмим мин яңасын,—
Менә-менә табармын, дип,
Эзлим бәхет дагасын.

Эзләсәм дә табалмадым
Шушы көмеш даганы.
Тапмасам да ул даганы,
Тынды сулыш яланы.

Табылмаган дага кебек,
Агаларым кайтмады.
Сандык төбендә саклана
Агайларның хатлары.

Сынык дага кебек ятим
Тугры җиңгәм antлары...

Бала чагым күптән үтте,
Хәзер башка заман да...
Ләкин мин һаман ышанам
Шушы матур ялганга.

Миңа кирәкми даганың
Алтыны, көмеше дә:
Төшәре төште, барыбер,
Үземнең өлешемә.

Тик шулай да дага эзләп
Юллардан үтәм менә:
Тапсам, элеп китәр идем
Җиңгиләр читәненә.

*

Ул синең ялгышың, диләр,
Таплаучың, кара таңың.
Ул синең нахагың, диләр,
Бәхетең түгел, кайгың.

Кара кайгым да кадерле —
Иң зур бәхетем кадәр.
Таңнарым кара булса да,
Төннәрем — тоташ зәңгәр.

Ялгышым булса да — якын:
Синеке, минеке ул.
Үзем сайлап алган бәхет,
Өлешкә тигән түгел.

Син минем кара таңым да,
Кояшлы ахагым да,
Таплаучым да, аклаучым да...
Хагым да, нахагым да.

## Шәмәхә төн

Шәмәхә төн, алчак күңелемне
Тагын адаштырдың, күпкә микән?
Тиле йөрәк, сагыну, әрнүләрең
Әле күптән генә үткән микән?

Шәмәхә төн, алмаз йолдызларны
Кабат җанда минем кабызмачы,
Март аеның салкын тамчыларын
Туңган йөрәгемә тамызмачы.

Шәмәхә төн, үтәрсең син тиздән,
Беләм синең күпкә түгеленне,
Алгысытма — югалтулар белән
Өзгәләнеп беткән күңелемне.

Шәмәхә төн, мине адаштырма,
Салма мине килер газапларга...
Шәмәхә төн, коткар, дия-дия
Үзем керәм синең кочакларга.

*

Тол хатындай моңсу ак болытлар,
Шәфәкъләрдә ялкын-яралар.
Кошлар китә, ә агачлар җирдә
Сары шәлен болгап калалар.

Табигатьнең соңгы күкрәве бу,
Хушлашуы бүген үзара.
Кан саркыган яңа яра кебек
Куаклыкта балан кызара.

Язмыш кебек үрелеп-үрелеп үскән,
Талгәшләре тора тын гына.
Ак болыттай моңсу тол хатыннар,
Җырлый-җырлый колмак сындыра.

Кайда икән, кайда яз айлары,
Кәккүк көткән чаклар үз парын,
Чәчкәйләрен ярның җил тузгытып,
Иярләгән чагы толпарын?

Кинәт җырны бүлеп, җир тутырып,
Яңгырап, чыңлап китте тын бушлык.
Бар дөньяны сихри моңга күмде
Бөре кебек кенә бер кошчык.

Күзләр түгел, язлар кайтты җиргә,
Күкрәүләрне күмде бу йөрәк,
Әйтерсең лә яшәү матурлыгын
Исбат итә бүген табигать.

Яшәр әле, яшьнәр яз айлары,
Кәккүк чакырыр тагын үз парын...
Бөреләнер өчен яфрак коя
Тол хатындай сабыр урманым.

# Дилә Булгакова

●

Вакытның минутын санап,
Яңгырлар тамчылады.
Яшеннәр, гүя, ярышып
Болытны камчылады.

Кургаш болытларны, җайлап,
Әйдәде җилләр ары,
Әмма йөрәгемдә калды
Яшеннең чаткылары.

Ашыга тулып ташырга
Күптән көтелгән минут...
Мин үзем — атылган яшен,
Үзем — тулышкан болыт...

●

Берәм-берәм йолдыз җыйдым сихри күктән.
Соңлаганмын — бүләк иткән берәү күптән.

Мин аларны күккә түгел, җиргә аттым.
Синең өчен таш өстендә чәчәк аттым!

Гөлгә карап сокландың да калдың моңсу,
Гөл өстенә ник салмадың бер йотым су?

Берәм-берәм җыйган идем йолдыз күктән,
Соңлаганмын — бүләк иткән берәү күптән.

Соңлаганмын, аңламадың гөлләр телен,
йолдыз серен,—
Аларда бит минем яшәү, минем сөю,
минем үлем.

*Уфа.*

# Фәйрүзә Мөслимова

## Олы кое

Олы кое дип йөртәләр аны.
Булган, димәк, бездә кечесе дә.
Ә монысы Олы килеш яши,
Изге килеш — авыл кешесенә.

Таң кызының серле көзгеседәй
Тау астында калган онытылып...
Бизәнешеп торган тупыллардан
Көлеп узган була ап-ак болыт.

Ындыр артлап сукмак салынгандыр
Без яшәгән гасырлардан элек.
Төшкәннәрдер кызлар безнең кебек
Көянтәгә чиләкләрен элеп.

Юкка гына күк йөзедәй зәңгәр,
Жырдай моңлы булып тумагандыр:
Олы кое — тирәнлеге белән —
Бик күпләрнең серен тыңлагандыр.

Шул коеның агач улагыннан
Шук егетләр атлар эчергәндер.
Үлеп бара торган Олы кое
Шул чакларны искә төшерәдер...

Урамнарда хәзер — колонкалар...
Ул — барыбер керсез балачакның,
Яшь гомернең ихлас матурлыгы,
Горурлыгы булып калачактыр.

Хәзер, әнә, сиртмәләре яңа.
Юлларында — култыксалы басма.
Читкә киткән егетләре шулай
Юаналар монда, ялга кайтса.

Туган жирне жирсеп кайтканнарга
Олы кое мөлдерәмә тулы.
Күк йөзедәй якты көзгесендә
Балкып уйный назлы кояш нуры.

Көязләнеп, әнә, сихерләнеп,
Тупыллары тора онытылып.
Сукмак буйлап кызлар төшеп килә.
Йөзеп килә күктән ап-ак болыт...

## Кайтырсың

Сукбайлыкка чыктыңмы?
Оттырдыңмы, оттыңмы?

Арандагы ат идеңме?
Ирек сиңа ят идеме?

Тезгенеңне чиштеңме?
Жилләр булып истеңме?

Кояшка үрелдеңме?
Нурга әверелдеңме?

Чәчәкләргә кундыңмы?
Үзең чәчәк булдыңмы?

Асылыңа кайтырсың.
Оттырырсың, отырсың...

## Дулкынланам

Дулкынланам? Сиңа гына
Тоелгандыр шулай.
Тавышыңнан каушар өчен
Сәбәп тә юк болай.

Дулкынланам? Әйтер сүзем
Оныттырдың кебек.
Көтмәгәндә юлыкканга
Калдым, ахры, жебеп.

Дулкынланам? Менә кызык.
Идел кебек, имеш.
Язгы жилдән чайпалган чак
Инеш кенә килеш.

Синең тавыш давыл кебек.
Чайпалмаска өйрәт...
Ахрысы, хак: Идел кебек
Дулкынландым кинәт.

## Үзем өчен

Эндәшергә кыймадым шул,
Изгедер, дип уйладым.
Үзем күтәрдем күкләргә,
Ничек җитсен буйларым?

Инде дә сиңа багышлап
Җырлар яза алмамын:
Пакьлегеңә инанганга
Өметемне алдадың.

Ә шулай да рәхмәтлемен —
Моңнарымны уяттың:
Ихтыярсыз елмайттың да,
Күлдердең дә елаттың.

Тетрәндереп кагылдың да...
Йоклап яткан җаныма
Бәреп кердең. Шул мизгелне
Хиссиятем сагына.

Изгедер дип санаганга
Эндәшергә кыймадым...
Синең хакта дип уйлама —
Үзем өчен җырладым!

## Алтын йозак

Тыңлаучылар кирәк безгә —
Аңлаучылар серебезне.
Аударасы килә тизрәк
Җанны кыйган йөгебезне.

Сөйләүчеләр күбрәк чакта
Тыңлаучылар кадерлерәк.
Канатланып китәр өчен
Бушанырга әзер йөрәк.

Сер сыйдыру — сәнгатьтер ул.
Тыңлаучыны таптык инде.
Серебезне ачу белән
Алтын биккә яптык инде.

Җиде күккә күтәрелдек.
Кул изәде җирдән безгә!
Аның гына... үз хәлләрен
Сорашмады беребез дә.

## Мәгъсум Хуҗин

# КУЛАКЛАР КОЛХОЗЫ

ХИКӘЯ



Юртай авылы малайлары, сабан чәчүе беткәч, атларны Ерак елга үзәненә төнге көтүгә алып чыгалар иде. Борын заманнардан килгән бу рәхәт хезмәт, печән өстендә тукталып тора да, уракка төшкәнче тагын дәвам итә иде. Атларның бергә көтүгә китүе-кайтуы бөтен авылга шатлык иде.

Быел исә, кырда язгы эшләр беткәч, төнге көтүгә чыгучы атлар нибарысы унике башка калды, унике аерым хуҗалык атлары алар. Кичен һәм иртән кабатлана торган җәйге бәйрәмнең көтмәгәндә кечерәюе Юртайның уйлы кешеләрен пошаманга салды — мал авызына йозак элү адәмне ачка интектерүгә китерәчәк ләбаса!

Кичә исә төнге көтүне авыл власте башында торучылар бөтенләй тыйдылар. Юртайга Бикмураев дигән вәкил килеп төшкән икән, бик усал кеше, ди, төнге көтүне туктату турында шул вәкил башлап әмер биргән.

— Калхуз җирләрендә аерым хуҗалык атлары йөрмәскә тиеш! — дип аяк тибеп кычкырган Бикмураев.

Бәйрәмхан, шул хәбәрне ишеткәч, Бикмураевны яман сүзләр белән сүгеп ташлады:

— Атасының...— Гражданнар сугышында берсеннән-берсе хәтәр сүзләрне өзлексез тезәргә өйрәнгән иде ул. Шөкер, бу гадәте яу кырында калды, тик Бикмураев әмере сүгенү сүзләрен янә теленә салды. Бераздан хурлап тиргәүдән туктады. Шулай да сүгенүе сүрәнәеп бетмәгән иде: — Ананның... Аякларың башыңа уралгыры! Ич югы — күнитегеңнең табаны купкыры!..

Вәкилнең әмеренә каршы дәлилләр эзләргә кереште Бәйрәмхан. Һәм, үзенчә, тапты да: колхоз атларын да төнге көтүгә алып чыксыннар соң, җаен ат малын утарда тоту чеп-чи ахмаклык ләбаса; Юртай җирләрендә гомер-гомергә уртак файдаланылган көтүлекләр җитәрлек, аларны колхозныкы иткән игълан яңгырамады әлегә, бәлки, киләчәктә мондый хәл дә булыр, ә хәзергә көтүлекләр — авылныкы, без томана затлардан түгел, җирнең кемнеке булуын беләбез, вәкил агайне; аннары да килеп, безнең Юртай малайларының авылны яратуын аңышмыйсыңдыр син, вәкил кеше, минем Корбәтне

---

Мәгъсум ХУҖИН (1930) — прозаик. *«Авылым урамнары», «Өч каен шышгы», «Урак өсте болытлары» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

дә төнлә ат көтү бәхетеннән мәхрүм итәсең... Әмереңнең шундый аяныч якларын уйлап бак!..

Начар йоклады Бәйрәмхан. Сискәнеп уяна да Бикмураев белән күңелennән сүз көрәштерә. Вәкилне егып салган кебек була да тагын йокыга китә. Тик авылга таралган яңа хәбәр һәм Бикмураевның үз әмерен кирү алмавы аны тагын куркындырып уята.

Инеш буена төнгә җибәргән атлары янына өч тапкыр төшеп менде. Кара бия өчен борчылды, колынлар чагы җиткән, аны төнге көтүгә быел чыгармаган иде, кичә, атларын инеш буена гына җибәрәсе булгач, буаз бияне дә иярткән иде. Абзардан чыгарасы калмаган икән, дип уйлады, әмма инеш буена төнлә төшүләрендә бияне алып та менмәде, төнге көтүне сагынгандыр, быел бөтенләй чыкмады, яшь колын белән Ерак елга үзәненә җибәреп булмаячак, аннары ат көтүен тыйды бит теге ... аты киткере вәкил, дип фикер йөртте. Һәм, таң атмастан, бөтенләй үк торды Бәйрәмхан.

— Син йокла, иртә әле,— дип пышылдады ул кузгала башлаган хатыны Хуриягә.— Балалар уянмасын. Икәүләп йөрергә тотынсак, теге өйгә дә ишетелер, эти белән әнигә дә тынгы бирмәбез. Минем йокы югалды.— Тукталып торды да — Нишләптер...— дип өстәде.

Ишегалдында йөренә торгач, башына мондый уй килде: Бикмураев әмеренә каршы фикерләрен аның үзенә барып әйтергә булды. Вәкилгә әйтәсе дәлилләре турында, тезләренә таянып, башын тотып, баскычта кабат уйланып утырды. Хуриянең:

— Сиңа әйтәм, самавыр кайнады, чәй эчеп алыйк,— дигән сүзләре аның аңына тиз генә барып җитмәде. Хатыны: — Бәйрәмхан, чәй ясадым, әйдә, чәй эчәбез,— дип кабатлагач кына, уйларыннан бүленде.

— Син дә тордыңмыни? Йоклыйсы идең, миңа карамаска идең.

Ире торганнан соң авыл хатынының йоклап ятмаячагын искәрмичә әйтелде бугай бу сүзләр: әллә гаилә тынычлыгын бозуга үзен гаепле санадымы шунда — шәт, шулайдыр.

— Ни, Хурия, бар, Корбәтне уят.

— Баланың таң йокысын бүлдермик. Ашыгыч эш юк ич.

— Уят! Атны алып менәр. Алашаны. Биясе йөрсен, тынычлыгын бозмыйк, тиздән уйнак колын алып кайтыр, шулай боерган булыр, дим.

Бәйрәмхан Коба алашаны һәм Кара бияне инеш буена кичтән тышаулап җибәргән иде. Аңардан күреп, колхозга кермәгән тагын өч кеше атларын төнгә инеш буена төшереп тышауладылар. Берсе Хуриянең абыйсы Шәйхетдин иде.

Чәй эчелде. Бәйрәмхан аның тәмен тапмады. Тугыз яшьлек малае Корбәт Коба алашаны атланып алып та менде. Йокысы ачылыр-ачылмас иде малайның, атны йөгәнен салдырып ишегалдына җибәргәч, өйгә кереп, түшәгенә чумды, атның нигә иртүк кирәк булуы белән кызыксынмады — йокы тәмлерәк. Әтисе атка тагын йөгән кидереп, аны тезгененнән җитәкләп капкадан чыкканда, малай йоклый иде инде. Ә Бәйрәмхан Коба алашаны урам уртасына төшерде, авыл советы һәм колхоз кәнсәләре урнашкан элекке каравыл өенә таба китеп барды. Күршесе Шәйхетдин ул узганда урамга чыгып тамак кырган иде — туктамады Бәйрәмхан, ишетмәгәндер. Шәйхетдин дә колхозга кермәгән һәм керер исәбе дә юк. Авыл башлыклары кәнсә диганнәренә чакыртып әгиткә керешкәч, аларның сүзләрен тыңлап та бетермәстән:

— Кыеш эшкә тотындыгыз,— дип әйтеп салган иде Шәйхетдин.— Көчли башладыгыз. Хәтерегез тишек-тошык. Бүтән чакта Ленинны мисал итәсез, ә хәзер нигә аның әмерен онытасыз? Крәстиянгә мөнәсәбәттә көчләү кулланырга ярамый, дигән идеме Ленин бабай? Шулай тәгаенләп әйткән иде. Минем кендегем җиргә береккән,

ә сез мине, калхузга тыгып, җирсез калдырырга ниятлисез. Калхузга башлап кем керде? Ярлы-ябагай. Революция булып унөч ел узгач та үзләренә бирелгән җирнең файдасын күрергә иренгән булдыксызлар, калхузга сыенып, тамак туйдыру җаен эзлиләр. Ә сез шундыйлардан яңа бер изүче сыйныф әвәләмәкчесез — Ленин бетергән изүче сыйныф урынын буш тотмаска исәбегез. Үкенечкә каршы. Мине кыеш әгитегезгә бүтән дәшмәгез. Мине кулак ясап куу белән дә өркетмәгез. Революция биргән җирнең файдасын табып яшәвемне беләсез. Акны кара дип атый алмассыз. Вөҗданыгыз булса. Сау булып торыгыз...

Кәнсәдә бу сөйләшү кичә генә булган иде. Вәкил булып килгән Бикмураевны күрмәмешкә салынды Шәйхетдин, сүзләрен авыл башлыкларына төбәп әйтте. Шушы кискенлеге турында Бәйрәмхан белән сөйләшүне иртәнгә калдырган иде ул. Тик өлгерә алмады, Бәйрәмхан атын җитәкләп каядыр китеп барды әнә. Инде тыкрыкка борылды, кычкырып туктатырга соңрак, хәер, таңнан авыл тынлыгын бозып сөрән салу да килешми. Кияүне әйтәм, Бәйрәмханны, дип уйлады ул, кояш күтәрелмәстән ат җитәкләп урам йөри, тагын ни әкәмәт кылмакчы икән. ат көтүен туктаттыруга үзенчә баш күтәрүедер. кирәкмәсне майтарып ташлавы ихтимал кызыш җанның; һай, кияү балакай, синең холкыңа түзеп яшәгән сеңелгә чыдам бирсен, шөкер, җаеңа төшенде, шуңа акылы җитте, безнең нәсел шул, сеңелне әйтәм, Хурияне әйтәм...

Нәселен акыллы санауда мактанып җибәрүе булса да, хак иде бу, нәселгә бирелгән «Акыллы» кушаматы Шәйхетдиннең бабасыннан ук килә иде. Нәселнең һәр кешесенә шушы кушамат тагыла бара: Акыллы Шәйхетдине, Акыллы Хуриясе; Шәйхетдиннең хатыны һәм балалары да шушы кушаматны йөртәләр, боерган булса, балаларының балалары да мактанычлы кушаматтан йөз чөермәсләр. Ә Хурияне... Хурияне хәзер Акыллы кушаматы белән атамыйлар икән ич, әй; кияүгә чыкканнан бирле ул Бәйрәмхан Хуриясе булып китте. Алай, нәсел кушаматы ир затларында гына нык саклана шул.

Кушаматы белән мактанып куярга яратса да, һәм кияве аңардан ун яшькә кечерәк булса да, Шәйхетдин Бәйрәмханны үзеннән акыллырак саный, шушы көчне тануы ук аның акылы ныклыгын сөйли. Кичә ул, колхозга димләүче авыл башлыклары һәм вәкил Бикмураев белән бәхәс тотканда, Бәйрәмхан әйткән дәлилләрне дә китергән иде. Изүче яңа сыйныф ясалырга торуы да — кияве сүзләре. Бикмураевның, бу турыда ишеткәч, колаклары тонып, күзләре акайды бугай, дошманына ташланырга җыенган ерткычтай үкереп куйды, әмма Шәйхетдин аның ягына барыбер карамады. Кәнсәдән кайтуга керәсе калган икән дә бит Бәйрәмхан янына, соң иде шул. Шәйхетдинне кәнсәгә төн урнашкач кына чакыртуы вәкилнең хәйләсе булган икән, Бәйрәмхан белән киңәшергә вакыт калдырмый ягъни, аннары иртүк Бәйрәмханны дәштерә — әнә бит, таңнан аяк киенгән кияү балакай, вәкил катына барышыдыр.

— Имансыз! — дип, вәкил Бикмураевка хәзер генә бәясен чыгарды Шәйхетдин.

Ә Бәйрәмханга авыл башлыкларының җыелуын көтәргә туры килмәде, алар кәнсәләрдә иде, озын эскәмиягә тезелешеп утырганнар, каршыларында берәү йөренә — вәкил шул булыр, авылныкы түгел, уң кулын салмак селтәп сөйли, сүзләрен аңлап булмый, ачык тәрәзәдән күнитегенең шыгырдавы сүзләренә караганда ныграк ишетелә. Атын багана башына бәйләгәч, кулларын бер-берсенә кага-кага, баскычка таба атлады Бәйрәмхан. Шыгырдавык ишекне каерып ачты, әчкә тиз генә кереп, юка киез эшләпәсен салды:

— Әссәламегаләйкем!

Авыл башлыклары — авыл советы һәм колхоз рәисләре, авыл со-

веты сәркәтибе һәм колхоз хисапчысы — аның сәламен алдылар, алар каршына басып калган таныш түгел кеше эндәшмәде. Бәйрәмхан аңа атап кына сәламен кабат бирмәде. Бикмураевны башта җентекләп күздән кичерде, аннары аңа туры карап:

— Мин шушы Юртай авылы крәстиәне Уразман улы Бәйрәмхан булам,— диде. Тавышы тыныч иде.— Сине кем дип белик?

— Ә-ә, син буласыңмыни авылның кулаклар башлыгы?! — дип кулларын җәеп алды Бикмураев. Сөенә иде ул, әйтерсең, көтмәгәндә мул хәзинә тапты, әй.— Нәкъ сине чакыртырга тора идем.

— Мин үземне, Юртай крәстиәне, дидем. Мин кулак түгел. Шулай булгач, кулаклар башлыгы да була алмыйм.

— Һа! Кулак түгел, ә?! Нигә алайса, кулак булмагач, калхузга кермисең? Башкаларны күмхуҗга каршы котыртасың?

— Котыртмыйм. Тукта, шулай да сине кем дип белик?

— Бик беләсең киләме?

— Әдәпсез кыланасың.— Бәйрәмхан тәрәзә янына барды һәм:— Әнә, күрәсеңме? — дип урамга ишарәләп сорады.

— Нәрсәне?

— Ат башын!

— Сүгенмә, кулак калдыгы!

Авыл башлыклары, урыннарыннан сүзсез генә кузгалып, ишек катынарак елыштылар, өй түрендә, ачык тәрәзә каршында, Бәйрәмхан белән Бикмураев кара-каршы басып калдылар.

— Күрәсеңме, дим?!

— Күрәм, ди. Шуннан ни булган?

— Җан иясе ул. Ашарга кирәк. Сорап ала алмый. Нигә төнге көтүне тыйдың? Безнең Юртайга нигә хуҗа булдың әле син?

— Ә-ә, менә нәрсәдә икән дәгъваң! Тыйдым, ат көтүен мин тыйдым, кулак атларын көтүне! Чөнки миңа, калхузцентр вәкиле буларак, шундый вәкаләт бирелде, калхузга кермәүчеләрнең мал-терлеген көтүгә чыгармаска кушылды. Сыер-сарыкларыгызны да көтүгә чыгартмам!

— Анысы булмас! — дип кычкыруын сизмичә калды Бәйрәмхан.

— Булдырырмын! Әлегә менә бу җебегәннәрегез,— Бикмураев авыл советы рәисе һәм сәркәтибе, колхоз рәисе һәм хисапчысы ягына башын какты,— каршы төшеп маташалар. Авылдашларын рәнҗетергә теләмиләр, имеш! Ярлы калхузчыны кулактан аерырга башлары җитми!

— Алай калхузүзәктән үк килгәнсең, инде дә бик белдеклесең икән, әйтеп бир: мин бу атны нәрсә ашатып асрарга тиешмен?

— Үз җиреңдә үстергәнне ашат!

— Чирәм күпереп үскән чакта атка бодай ашатыйммы? Аннары минем ашлыгым да яңа җиткәнчегә таман гына. Бүген-иртәгә колынларга торган биям дә бар. Анысы төнге көтүгә быел йөрмәде.

— Ике атың бармы?!

— Ике атым бар. Кара бия исән-сау колынласа, ат малым өч баш булыр.

— Сез, булдыксыз җаннар,— Бикмураев авыл башлыкларына борылып кычкырды,— нигә әйтмәдегез аның ике аты булуын? Сез үзегез кулак тегермәненә су коясыз икән монда! Үзегезне шушы кулак белән бергә сөрергә кирәк сезнең!

— Маңгайга тамга сугарга әвәс икәнсең, калхузцентр,— диде Бәйрәмхан һәм, эскәмиянең урта төшенә утырып, сул аягының чабата киндерәсе башына эләгеп калган чалбар балагын төшерде, кыска кара чәчләрен алга сыпырды, шулар яткач, озынча йөзе түгәрәкләнә төште.— Тамганы, көтүдән кайтканда адашкач, табып аерыр өчен, малга гына сугалар. Ә мин — кеше! Алар да,— дип авыл башлыклары ягына учларын җәеп күрсәтте. Куллары зур, йонлач иде, күлмәк

җиңнәре тартылгач, беләкләрен дә куе йон каплавы күренде.— Ләкин хәзер син минем белән генә сөйләш. Ә сез,— дип авыл башлыкларына тагын карады ул,— чыгып торсагыз да була, үз хуҗалыгызда эшегез бетмәгәндер, инде калхузыгыз эшенә тотынырга да вакыт, кояш калка, калхузга кергән кешенең дә эше крәстиән хезмәте булып каладыр, шәт. Югыйсә, төн йокламыйча каравыл өе саклаган кыяфәтегездән авылдашлар куркып качар.

— Бар, кайтыгыз,— дип боерды авыл башлыкларына Бикмураев, үзе кулак дип атаган Бәйрәмхан тәкъдименә ризалашуын абайламыйча калды.— Озак юанмагыз. Миңа май яккан бер-ике телем икмәк, шешәгә тутырып чәй алып килерсез.

Бәйрәмхан, башын акрын чайкап, елтыр зур күзләрен уйнатып алды да, авылдашлары ашыгып чыгып киткәч, көлемсерәп әйтеп куйды:

— Фатирга төшәргә дә вакытың булмаган, ахрысы.

— Кая вакыт ди сиңа! Эш муеннан! Һәм ашыгыч!

Бикмураев өстәл артындагы урындыкка утырды, учлары белән йөзен сыпырды, кул аркалары белән батынкы күз төпләрен озаклап ышкыды, авызын учы белән каплап иснәде. Кинәт җилкәләрен кызулап селкеткәләде һәм кулларын селеккәләде, бераз тыныч торды. Аннары шулай ук кинәт болай да юка иреннәрен кысты, бөгелмәле кашларын — сәер, мондый нечкә кашлар ирлек кыяфәтен хәйран боза иде — җыерды, батынкы күзләре ярдагы янәшә кош ояларына охшап алды. Аның хәрәкәтләрен күзәтеп утырган Бәйрәмхан, йөзендә иман юк моның, дип уйлады: йөзе... кырт кискән яр сыман.

— Җебегәннең дә җебегәннәре синең авылың башлыклары! Йөз хуҗалыклы авылда калхуз төзеп бетерә алмасыннар инде, йә!

— Минекеләрме? Калхузга житәкчелек итәргә алынучыларына мөнәсәбәтем юк. Ә авыл советы башлыкларын мин дә сайладым. Илдәге властька каршы түгел мин. Каршы була да алмыйм, чөнки революция куйган власть астында рәтле яши башлаган кешемен. Мин өйләнгәч кенә атлы булдык без! Ат... Ә, әйе, мин тигезлекне, дөреслекне яратам. Шулай булгач, әлегә тагын бер нәрсәне искәртим: Юртайда йөз түгел, ә йөз дә сигез ихата бар.

— Шуның уникесе кулак хуҗалыгы. Тоташ күмәкләшүне шулар тоткарлый. Һәм алар синең коткыңа бирелгән!

— Алар кулак түгел. Әйткәнемчә, мин дә кулак исәбенә кермим, вәкил агайне, революциягә чаклы безнең гаилә ярлы иде.

— Менә-менә, синең авыл башлыкларың да шуны тукый!

— Хак әйтәләр. Унике хуҗалыктан кулак буларак сөрелерлек бер генә кеше дә юк. Революциягә чаклы хәлле саналганы — авылыбызның хәзрәте. Аны да эшләмичә баеганга исәпләп булмый. Авыл халкы аңа шәригать нигезендә сәдакасын бирде. Әмма, моңа җавап итеп, хәзрәт халыкны бер иманда тотты. Димәк ки, аңа хезмәте өчен түләнде. Шулаймы?

Бикмураев урыныннан торды, өстәлгә кул аркасы белән суккалады.

— Син нәрсә, мине дә үз ягыңа аудармакчы буласыңмы? Намуслы совет работнигын төпсез сазлыкка өстерәргәме ниятең? Үз арбасына мине — чын совет кешесен утыртмакчы, әй!

— Ашыкма, калхузүзәк вәкил, минем арбамда сиңа аталган урын юк,— дип тынычлыгын җуймыйча туктатты аны Бәйрәмхан.— Без иплән сөйләшик, кычкырышырга тотынсак, хаклыкка житмәбез. Ә миңа хаклыкның өстенлек алуы кирәк. Утыр син, югыйсә, миңа өчып кунарга торасың. Бу әзмәвер гәүдәң белән мине чебен урынына сытуың мөмкин.

— Кирәк икән — кунармын! Синең кебекләрне авылдан сөреп, күк түбәсенә дә кунармын!

— Ә минем ниятем — синең миңа, минем кебекләргә, үзебез теләгәнчә яшәргә юл куюыңа ирешү. Син безне авылдашлар каршында, район һәм Татарстан җөмһүрияте каршында, ахыр килеп, ил каршында якларга тиешсең. Үзебезчә яшик без. Юл бирегез.

— Мин синең кебекләрне якларга тиешме?! Ю-ук! Калхузга керегез! Безнеңчә яшәгез — мин вәкил булып килгән Юртай тоташ күмәкләшергә тиеш! Райбашкарма рәисенә сүз бирдем, Юртайны тоташ күмәкләштерәм, сөрсәм дә, ике кулактан арттырмам, дидем.

— Мин калхузга кермәячәкмен.

— Димәк, сөрәбез сине!

— Сөргенгә җибәрерлек гаебем юк. Мин җинаять кылмадым.

— Калхузга кермисеңме? Кермисең! Җинаятең бу синең. Башкаларны, унбер хуҗалыкны, калхузга кермәскә котыртасыңмы? Котыртасың! Монысы тагын да зуррак җинаятең, Совет властен санламавың! Бик беләсең килсә, җәһәннәмгә үк сөрербез!

Бәйрәмхан, ә бит, чыннан да, шундый гаепләр ташларга күп сорап тормас бу калхузүзәк вәкил, дип уйлады. Маңгаен, чәчләрен ышкыштырды, бераз вакыт җавапсыз торды.

— Тавышны күтәрмичә сөйләшергә килешкән идек,— дип тураеп утырды ул.— Сүздә тору кирәк. Кызып китсәм, холык пырдымсыз, син мине түгел, мин сине чебен урынына сытуым ихтимал, күреп торасың, гәүдәм кукраеп катмаган. Тагын бер кабатлыйм: хөкем чыгарырга ашыкма. Мин коткы белән шөгыльләнмәдем. Совет властен сан итүем хакында шулай ук анык әйттем. Инде бүлдермичә тыңла. Мин җиткелекле яшим. Калхузга кушылмаган унбер хуҗалык та ким-хурлардан түгел. Безнең ишеләрдән калхузга керүчеләр булды, шактый алар. Авыл гел ярлылардан гына тормый, совет корылгач, авыл ярлылыктан тизрәк чыга барды. Белдергәнемчә, мин үзем дә совет булгач кына тамагы туючылар исәбенә керәм. Моны бөтен Юртай белә. Ләкин мин үзем үз гаиләм турында кайгыртам, мин башкаларга хуҗа түгел.

— Чеп-чи кулак идеологиясе! Авылыгыз ярлылары турында кем кайгыртырга тиеш? Аларны хөкүмәт җилкәсенә атландырмакчы буласыңмы?

Бәйрәмхан, йодрыкларын селтәп, Бикмураевка таба атлады, вәкил ул якынайганчы ук урындыгында артка кайшалды. Шул чакта өйалдында идән шыгырдады, Бәйрәмхан кинәт туктап калды, кулларын уа-уа урынына кире барып утырды. Шыгырдау тынды, керүче дә булмады.

— Ата ялкауларны үз җилкәмә атландырмам! Эшләрен эш итеп эшләсеннәр! Совет рәхәт яшәргә җир бирде, шөкер. Әмма эшләп аша, диде. Минем җилкәмә йөк җитәрлек өелгән, туачак балаларыма гына буш урыннар бар анда, шуны бел, калхузүзәк вәкил! Инде тагын шуларны да белеп тор, безнең гаиләне авылдан сөрү ниятеңә керешсәң, бик тә кирәк булыр болар сиңа. Гаиләмдә минем сигез җан: әти, әни, үзем, хатыным һәм дүрт балам. Әти-әни картайды, малай мәктәпнең икенче сыйныфына күчте, сеңелләре аяксыздан-кытсез, дигәндәй, кечесе бишек юешли. Безгә бер сыерның сөте җитми. Шөкер, кышлаган танабыз бар. Тормыш бит, әле картлыкка чыкмадык, тагын балаларыбыз булыр, миңа да, хатыныма да утыз ике генә яшь. Ике сыер асрап җибәрербез, дибез. Сарык малы ишле, кошкорты да җитәрлек. Атларыбыз, әйе, икәү. Шөкер. Хәзергә.

— Анысын ишеттем. Калхузга атлар күп кирәк. Иң киме — бирсен бүген үк алырбыз. Кулак буларак кумаган очракта да, дим.

Бәйрәмхан көлеп җибәрде.

— Ала алмаячаксыз, чөнки Кара биябез — инче. Ә әнә ул Коба алаша — Кара биянең беренче колыны. Бүген-иртәгә көткән туагыбыз шулай ук инчедән була.

— Инчесе нәрсә тагын?

— Бәрәкалла, син үзебезнең татар адәме ләбаса! Кайда үстең соң син? Инчене белмә инде, әкәмәт!

— Син минем кайда үсүемне тикшермә! Шул ук син әйткән татар арасында үстем.

— Димәк, татарның гореф-гадәтен белергә мәҗбүрсең. Хатынга үз ата-анасы ягы биргән аяклы мал инче була. Бу аяклы мал гомере буена аның үз милкендә исәпләнә. Хәтта син дә, калхузүзәк вәкил булсаң да, инчене хатыннан тартып ала алмыйсың.

Бикмураев, башын иеп, озын кара чәчләре арасына бармакларын тыкты. Уйлана иде. Әллә шәһәрдә яшәүче гаиләсе исенә төште дә шуның иминлеге өчен хафаландымы — балаларына сауган шәбендәге бер касә сөт юнәтүе дә кыен бит бу бичаракайга; яки Бәйрәмханга ишле гаиләне алып баруы авырлыгына төшендеме — колхозүзәк вәкиле дә кешелек сыйфатларыннан мәхрүм түгелдер ләбаса. Ләкин аның аска карап утыруына икенең берсе дә сәбәп булмаган икән.

— Син миңа яшьтәш икәнсең үзең, әмма аң дәрәҗәң бик түбән синең,— дип тагын иснәнде вәкил. Төн йокламавы сиздерә.— Гәзитләр дә укымыйсың икән. Хәзергесе вакытта кайсы гына гәзитне кулыңа алсаң да, кулакларны бетерү турындагы чакыруларны күрерсең. Кулакларга юлбашчыбыз иптәш Сталин бәясе һәр санда бар. Иптәш Сталин яза, партия авылда кулакларны чикләү политикасыннан бетерү политикасына күчте, ди. Менә без шушы сүзләргә таянып эшлибез. Җитәкче күрсәтмәләр язылган гәзитләр менә монда йөри.— Бикмураев өстәл почмагында яткан күн сумкага кагылып куйды.— Үземнән калдырмыйм мин аларны! Ә син кулакларны бетерү турындагы карарны да укымагансың. Хәреф танымыйсың, ахрысы. Юртай авылында бу карар үтәлми. Әле мин, авылыгыз башлыкларының, бездә кулаклар юк, дигән сүзләренә ышанып, Юртайны тоташ күмәкләштермәкче идем. Хаталык кыла яздым. Үземне дә... Синең кебек ата кулакларның калхузга нигә кирәге бар ди?! Сезне калхузлар-савхузлар алыштыра. Иптәш Сталин шулай дигәнме? Дигән! Кулакларны бетерергә, дигәнме? Дигән! Бөтен партия әйтте моны! Мин менә шушы карарны үтәргә җибәрелгән вәкил.

Ул күн сумкадан торба итеп төрелгән газета алды. «Кызыл Татарстан» газетасы иде бу.

— Менә ул сезгә аталган карар. Татарстанда кулакны сыйныф булу ягыннан бетерү турында ТССҖ — Татарстан Совет Социалистик Җөмһүрияте, ягъни, Үзәк Башкарма комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы карары, диелгән. Монда, беләсең килсә, кулакларны еракка сөрү яки башка торак урыннарына күчерү турында сүз бара. Баштагы ике пунктын укыйк. Беренчесе болай. Татарстан Җөмһүриятендәге барлык кулакларның, шулай ук Татарстан Җөмһүриятеннән сөрелә торган кулакларның бөтен милкенә конфискация ясарга, диелгән. Икенчесендә, кулак хуҗалыкларның милекләренә конфискация ясаганда, аларга йорт кирәге әйберләре (кием, урын, савыт-саба һ. б.) һәм шулай ук өч-дүрт айлык азык продуктлары калдырылырга тиеш, дип билгеләгәннәр. Тиеш, тиеш... монысын мөмкин дип тә аңлап була. Ары таба синең кебек тәгаллек яратучылар игътибарына санап та күрсәтелә: ике-өч хуҗалыкка бер ат һәм бер сыер, бер хуҗалыкка икешәр сарык һәм ким дәрәҗәдә кирәк булган авыл хуҗалыгы кораллары калдырыла. Аңладыңмы?

Бикмураев соравына җавап көтмәстән укуын дәвам итмәкче иде дә, Бәйрәмхан аны:

— Йөгерек укыдың, дөрес укыдың, хәрефне әйбәт танысың икән,— дип бүлдерде. Аның кулында да «Кызыл Татарстан» газетасының шул ук саны иде, һәм ул Бикмураевның укуын чагыштырып барган иде. Моңа вәкил аптырап калды.

— Син яңалифне таныйсыңмы? Тиз өйрәнгәнсең.

— Нигә танымаска? Аңгыра зат түгелмен. Яңалифнең кирә башлавына ике ел, аны танырга өйрәнергә бик җитә бу вакыт. Тик хикмәт — карарның төгәл булмавында. Менә син нәрсәне аңлатып бир миңа,— Бәйрәмхан газетасына уң кулының имән бармагын төрткәләде,— бер ат һәм бер сыер ике хуҗалыккамы әллә өчкәме калдырыла? Бер хуҗалыкка икешәр сарык, дигәнен ничек аңларга? Бөтен җөмһүриятта бер хуҗалыкка гына ике сарык калдырыламы яисә һәр хуҗалыкка ике сарыкмы? Өч-дүрт айлык ризыкка күпме нәрсә кирә?

— Юкка башыңны катырма, Бәйрәмхан! Син кулакларның ничек сөрелгәнен белергә тиешсең. Аларга бер нәрсә дә калдырылмый!

— Кулакларны куучылар карарны боза! Карарда бер нәрсә дә калдырылмавы әйтелмәгән!

— Анысы безгә әйтелгән! Карарда инче-минче турында сыңар сүз дә юк! Халык гадәте, фәлән-төгән, дип сайрап, атлы булып калмакчысың, ә! Хәйләкәрсең! Ата кулак!

— Димәк, син мине башка авыл кешеләрен куган кебек кумакчы буласың? Кичә син минем атымны ач калдырдың, бүген минем авызымнан ризыгымны тартып алырга исәбең!

— Нигә мин куам ди? Авылдашларың карар чыгарып сөрәчәк.

— Алай... Шулай да син, калхузүзәк вәкил, байлыгым турында минем үз авызымнан ишет.

— Кәгазьгә терки барыйммы?

— Анысы синең эш. Әйе. Минем каралты-курам төзек. Урусуыру машиналарым бар. Бурыч биреп тору ширкәте акчасына алган идем аларны, бурычым вакытында кайтарылды. Өйләребез каракаршы, урам ягындагысын әти салды, анысының аскы ниргәләре туза башлаган, егерме биш ел торган йорт чөнки, тәрәзә яңакларын былтыр гына кабат алыштырдык, түбә тактасы черемәгән. Эчкәрге йортны мин җиткердем. Өйләнгәч. Ике балабыз тугач кына әле. Анысы яңага исәпләнә, димәк. Хәзергесе көндә мин шул өйнең икенче катын күтәрәм.

— Ике катлы йорт саласыңмы?! Авылның башлыклары шуны да яшергәннәр бит миннән! Астыртын җаннар!

Бәйрәмхан вәкилнең авыл башлыкларына кагылышлы сүзләрен бу юлы игътибарсыз калдырды. Бикмураевка карамыйча сөйләвен дәвам итте.

— Әйе, йортның икенче катын күтәрәм. Нигезен шуңа исәпләп салган идем. Гаилә ишле. Кысан. Балаларны укытасы, әйбәт тәрбияне иркенлектә бирәсе иде үзләренә. Укымышлы, дәрәҗәле гаиләләрдәге кебек. Хыялда гына калыр микәнни болар... Их-х, баш эшләп җиткермәде, алдан башка кермәде шул фикер, хәзер соңдыр. Карале, вәкил иптәш,— дип Бикмураев каршына җәһәтләнеп барды Бәйрәмхан,— болай эшләсәк, ни... Болай итик без,— дип буталып алды, шул арада фикерен авылны тоташ күмәкләштерергә килгән вәкил һичшиксез аңларлык итеп түгәрәкләргә тырышты: — әйе, нәкъ шулай итик: бүгенгә чаклы калхузга кермәгән кешеләрдән аерым калхуз оештырыйк!

— Бер авылда ике калхузмы? Хәзерге калхуздан... тәк... сигез тапкырга кечкенәрәк калхузмы? Кемгә керәге бар ди ул сезнең бәпбәләкәй калхузыгызның? Болай да калхузыгыз зурдан түгел.

— Безгә — унике хуҗалыкка кирәк! — дип үзенең тапкыр фикеренә рухланып китте Бәйрәмхан.— Җирне йөз дә сигез ихатага уртак иткәнче, аның бер өлешен унике гаиләгә тоташ итү хәерлерәк. Бәлки, унике генә гаилә булып калмас идек. Башта төзелгән калхуздан кайберәүләрне үзебезгә алыр идек. Теләкләре булса. Үзебезгә тиңнәрен.

— Баеракларын, шулаймы?
— Нигә баеракларын? Эш сөючеләрен.
— Син калхузның персидәтеле булыр идеңме?
— Нигә мин рәис булырга ди? Әнә...— диде дә капылт тукталды Бәйрәмхан, колхозүзәк вәкиле алдында кемне дә булса тәгаенләп атавы әләк-ошак булып аңлашылуы башына китереп сукты, ә рәислеккә хатынының абыйсы Шәйхетдинне исендә тоткан иде.
— Йә, йә, кемне?
— Кемне, дип... Кемне сайласалар, шул булыр иде безнең хуҗалыкның башлыгы. Моны хәл кылырга ялгызымның вәкаләтем юк.
— Бушка хыялланма, Бәйрәмхан! Сөрәбез сине! Авылдан берәүне булса да сөрмәсәм, минем үземә гаепне тау итеп өячәкләр. Кулаклардан калхуз оештыру өчен җибәрелмәгән мин монда! Калхуз кулактан башка гына була! Кулаклар өереннән калхуз оештырмакчысың, ә?! Барып чыкмас! Мондый коткыңа бүген үк берәр чарасын күрербез! Күрермен! Кулаклар калхузы оештырмакчы, әй!
Бәйрәмхан монысына нинди җавап кайтарырга белмәде, башын чайкап аптырап калды.
— Мәрхәмәт белмәс бәндә икәнсең,— дип ишеккә таба юнәлде ул.— Син кешене тереләй тунарга әзерсең. Революция, дидек, совет, дидек, тигез хокук, дип мактандык.— Бәйрәмхан кире борылды да: — Гражданнар сугышында революцияне яклап сугыштым мин! — дип күкрәк какты.— Революция кешесе мин!
— Шапырынма! Мин дә гражданнар сугышында кулга кылыч тоттым. Мактанмыйм бит. Ә синең гражданнар сугышында кайсы яклы булуыңны тиз ачыкларбыз! Хәер, аклар ягында инде, югыйсә хәзер кулаклар калхузы оештырырга җыенмас идең.
— Мин аклар ягындамы?! Их-х, ата-бабаңны!.. Кем үстерде икән сине?! — Бәйрәмхан, йодрыкларын йомарлап, Бикмураевка таба атлады.— Совет тәрбияләде микәнни соң сине миһербансыз итеп? Юктыр, алай түгелдер! Бүгенге көнгә каян табылдың икән син? Чепчи җәллад бит син!..
Ачык тәрәзәдән:
— Әти-и! — дигән тавыш ишетелде.
Малае Корбәт тавышы иде. Бәйрәмхан тәрәзәгә атылды.
— Әти! Кара бия колынлыйсы итә!
— Тезгенен ычкындыр алашаның! — дип кычкырды малаена Бәйрәмхан һәм, кабаланып, тәрәзәдән төшә башлады, киндер алъяпкычы кадак башына эләгеп ертылды, шуны ычкындырганда, терсәге бәрелде дә, бер өлге пыяла челтерәп-чыңлап коелды.
Малае Корбәт үзен тыныч тота, бик әһәмиятле эш башкаручы кеше кебек җитди иде.
— Ашыкма, әти. Пыяланы әрәм иттең, үзебез куясы була бит аны,— диде ул. Бер уңайдан әтисе әлегә белмәгән эшен мактанып хәбәр итте: — Әти, Кара бияне мин алып мендем. Алашаны алырга төшкәч, аның ялваргандай торуы күз алдыма килеп уяндым. Ашыкма син, әти. Кара бия янында бабай белән Шәйхетдин абый калды. Әни синең кая киткәнеңне белмәде. Шәйхетдин абый, кәнсәдә түгел микән, дигәч, мин туры монда йөгердем.
Малаеның сүзләре Бәйрәмханның аңына барып җитмәде. Ул атка инде атланган иде, тезген очы белән Коба алашага уңлы-суллы сукты, һәм ат урыныннан ук чабып китте. Корбәт арттан йөгерде. Бикмураев ачык тәрәзәдән:
— Аты шәп күренә кулакның! Мондый атлар калхузга бик тә кирәк,— дип карап калды.
Авылда беренче төн ат көтүе чыкмаса да, Коба алашаның тояк тавышлары иртән атларның юыртып-сөенешеп кайтуларын искәртте. Кайдадыр — әллә колхоз атлары ябылган утарда, әллә колхозга

кермәгән хуҗалык ишегалдында — Коба алашаның тояк тавышлары ишетеп, ахрысы, ат кешнәде. Аннары аңа тагын, тагын кушылдылар. Зур булмаган Юртайда бер мәлдә ат кешнәүләре тоташ җыр булып яңгырады. Моңсу иде бу җыр. Моңсулыкка авылда беренче тапкыр ат көтүе чыкмавы сәбәпче иде. Юк, алай гына түгел икән. Кара биянең колынларга торуы авылда күмәк кешнәү кузгаткан икән! Тик Коба алаша гына кушылып кешни алмады, ул томырылып чаба иде...

Колын туды. Бия колын. Аңа исем кушарга Бәйрәмхан, әтисе белән киңәшкәч, Корбәткә әйтте:

— Колын үсеп җиткәндә, син дә ат җигәргә ярарсың,— диде ул.— Аны үзең карап үстерерсең.

— Әти, мин аны иң элек тырмага җигәрмен, яме!

Бәйрәмхан, колынга сокланып торган Корбәтнең җилкәсенә кулын салып, аны үзенә елыштырды.

— Атны башта сиртмә арбага җигеп өйрәтербез, улым. Шулай кирәк.

— Алайса башта тарантаска утырып урам әйләнәм!

— Монысы бөтенләй дә ярамый! Сөрхәнтәйлеккә йөз тотуың булыр иде монысы, тырай тибеп йөрүче малай итеп үстермим ләбаса мин сине. Атка элгәре җиңел йөк тарттырырсың. Кара биянең соңгы колынлавыдыр бу. Шуңа күрә колынга исемне син куш. Үз атыңа.

Малай, үзенә аталган колыны булудан дулкынланып, югалып калды, исемне тиз генә таба алмады. Беравыктан:

— Кара... Кара...— дип кабатлады. Кара бия, дияргә иде исәбе. Исем табышуда булышып җибәрүен көтеп, әтисенә карады, әмма әтисе малаеның үз башын эшләтүен көтте.— Кара... Кара... Юк, аның әнисе Кара бия... Әти, таптым! Бәләкәй бия!

— Ярар. Тик, улым, колын гәүдәгә, сөбханалла, Кара биянең үзеннән кечкенә булмаячак.

— Кара биянең колыны булгач, анасыннан барыбер бәләкәй була ич инде ул.

— Мин риза. Шулай уйлавың хәерле.

Төш узгач, Корбәт Шәйхетдин абыйсын чакырып чыкты. Бу йомышны үтәгәч, әтисе аңа уенга онытылып югалмаска, өй тирәсендә булырга кушты. Ә Бәйрәмхан һәм Шәйхетдин баз өстенә корылган такта алачык эченә кереп сөйләштеләр. Монда бөркү түгел иде, аннары кергән-чыкканның күзенә чалынмыйсың, алачык түр өй каршындагы җимеш бакчасы почмагында, урамнан узучыларга тавышлары ишетелмәячәк.

Бәйрәмхан, кәнсәдә соңгы мәлдә кызышып сикереп торуын һәм ашыгудан тәрәзә ватуын да әйтеп, колхозүзәк вәкиле белән әңгәмәсенең эчтәлеген сөйләде.

— Тәрәзәдән йөрергә яратасың инде син,— дип көлеп куйды Шәйхетдин.— Андый гадәтең бар.

— Нәрсәгә ишарәләвең булды бу?

— Сеңелгә өйләнергә теләвеңне безгә ничек ирештергән идең? Оныттың мәллә? — дип һаман да көлемсерәде Шәйхетдин, аның шаяртырга тырышуы Бәйрәмхан сөйләгән сүзләрне күңеленә сеңдереп өлгерү өчен кирәк иде.

— Әй, ташлачы!..— дип кул селтәде Бәйрәмхан.— Аңлап торасың лабаса, шаяртыр чак түгел! Безне авылдан сөрергә торалар! Ашыгыч чарасын күрергә кирәк! — Һәм, өйләнүе күз алдына килде дә, үзе дә елмайды.— Ә-ә-ә... инде хәтереңә төгәл төшерәсең килсә, Шәйхетдин абзыкай, Хуриягә өйләнәчәгемне тәрәзәдән кереп әйтүем мәсьәләне ашыгыч хәл итәргә кирәклектән иде, урамнан әйләнеп ишегездән керергә вакыт калмаган иде!

...Хэтерендэ... Ян бакчага бэрэңгене кичэ утыртып бетерделэр. Күрше Шэйхетдиннэн ат алып торып, сука белэн ярдырып салдылар. Булышырга күрше-тирэ керде. Хурия дэ бар иде. Соңгы ике елда Хурия Бэйрэмхан белэн бик аралашмас булды, бала чакта, буйга җиткэндэ дэ. Бэйрэмхан тирэсендэ чэтелдэп йөрер иде үзе югыйсэ. Эле быел, кар эреп беткэч инде, кичке уңайда очраштылар да. Хуриялэрнең капка төбендэге эскэмиядэ утырып тордылар. Гаҗэп тэ булды инде: элек чэте-чэте кылэ торган Хурия ни сөйлэшми, ни кереп китми, утыра шунда телен йотып. Бэйрэмханга туры карамаган булып. Кичэ бэрэңге салганда да гел Бэйрэмханның энисе янында булды, егетне күрмэмешкэ салышты. Күрше Хуриянең. Акыллы Хуриясенең үзен тотышы нигэдер үзгэрде. Эллэ Бэйрэмханга гына шулай тоеламы соң бу...

Бэйрэмхан белэн этисе бүген иртэдэн бэрэңге бакчасының түр киртэсен яңартып кора башлаганнар иде. Озакка сузылды, баганалары черегэн икэн, яңа баганаларга ырмау алу кулны тотты, э югыйсэ баганаларны алыштырырга исэплэмэгэннэр иде. Шулай инде: искегэ тимэ... Соңгы багананы утырткач, этисе ишегалды тирэсендэге эшлэрне карарга кереп китте, соңгы торыкны Бэйрэмхан үзе генэ тотып бетерэ иде инде. Киртэлэр арасына куярга тезлэнеп шакмак кискэндэ, янына энисе килде.

— Күршелэргэ димче керде.

Егет эндэшмэде.

— Эллэ ишетми инде. Хурияне димлилэр! Чукрак!

— Э-э?!

Бэйрэмхан кашларын җыерып, күзлэрен акайтып энисенэ карады, эйтерсең, күршегэ димче килүенэ энисе гаепле иде. Кул пычкысын селтэп атты, сикереп торды да, үзлэренең һэм күршелэренең бакчаларын кисеп, Хуриялэргэ таба йөгерде. Алты почмаклы йортның түрдэге урта тэрэзэсе ачык иде, өйдэ табын янына утырырга җыенып торучыларны сискэндереп, шул тэрэзэгэ килеп капланды, өйдэгелэр аны-моны аңышып өлгергэнче, кереп каршыларына да басты.

— Хуриягэ мин өйлэнэм! — дип ярып салды ул. — Димчегэ ризалык бирмисез! Күрегезче бу күршелэрне, астыртын эш йөртмэкчелэр!

— Кыз димлэү турында сүз булмады бит эле, Бэйрэмхан энем,— дип күрше егетен дуамалланудан туктатырга тырышты Шэйхетдин.

— Булырга тора! Эмма булмаячак! Син, Шэйхетдин абый, Хуриягэ этисе урынына калган кеше, мин җибэрэчэк димчене каршыларга эзерлэгэн күр!

— Бэйрэмхан, безнең өйнең ишеге дэ бар, ишектэн керэсе идең.

— Ишегегездэн кергэнем бар, Шэйхетдин абый. Килэчэктэ кияү булып керермен! Шулай боерган! Э син нигэ терэлеп каттың?— дип эндэште аннары аралыктан чыгар-чыкмас торган Хуриягэ.

— Мин...

— Мин дэ мин! Менэ шул: мин сиңа быел өйлэнэчэкмен! Алла боерса, быел игеннэребез уңар да көзге байлык мул булыр. Быел гына, димим, гел тук-рэхэт яшэрбез. Аңладыңмы шуны, Хурия?

— Мин...

— Йэ, ярар, син дэ мин!

— Син... Син, Бэйрэмхан, шуннан да соңга калдырмассың инде, яме...— дип пышылдады Хурия. Бэйрэмхан ишек катына якынайгач, үзенең авыз читлэре калтыранды, күзлэре челт-челт йомылып ачылды, егет тупсаны атлаганда, аңа омтылмакчы булды, эмма егетнең барыбер туктамаячагын сизде, дымсу күзлэрен яшереп, йөзен каплады...

— Хуриягә өйләнәчәгемне тәрәзәдән кереп әйтсәм дә, сеңлең белән әйбәт яшибез, Шәйхетдин абый,— дип хәтерләүләргә чик куясы итте Бәйрәмхан.— Беләсең, мин хатынны какмыйм. Аннары да килеп, Хурия үзен беркайчан да кактырмаячак.

— Менә, кияү балакай, синең уникe хуҗалыктан калхуз оештырырга уйлавың, берәүләр ишектән йөргәндә,— дип аңгәмәнең үзәгенә төште Шәйхетдин,— икенчеләрнең тәрәзәдән керүе кебек булмас микән? Властьлар бер авылда ике калхуз ясауга бармастыр.

— Ялгышасың, Шәйхетдин абый! Ишектән куганда, тәрәзәдән керергә җыенмыйбыз! Без икенче ишек кисәбез! Ә властьлардан күмәкләшеп рөхсәт сораганчы, аерым хуҗалыкларның кечкенә калхузга берләшергә ризалыкларын белергә кирәк. Аларга мин йөри башласам, вәкилгә барып ирешәчәк тә котқы таратуга санаячак моны вәкил.

— Бу йомышны миңа йөкләргә җыенасыңмы?

— Сиңа да ярамый.

— Кемгә ярый соң?

— Эти әйтә, өчебез, ди, син, мин һәм эти үзе, һәркайсыбыз берәрсенә барыйк, аннары бүтәннәрдән алар белешер, ди.

— Кода дөрес әйтә.

— Ләкин һәркайсына уйлану өчен аз булса да вакыт кирәк. Җавапны белер өчен чылбырны буынлап сүтәбезме? Безнең кайда аяк басуыбызны да күзәтеп торачаклар. Төннең дә күзе бар хәзер. Ашыгырга кирәк безгә, вәкил бик коры тотмакчы, әйтәм ич, сезнең өйләргә, ди, авыл советы һәм калхуз кәнсәләриләрен күчерәчәкбез, ди.

— Тәгаенләп тә куйган. Башкаларның йортларын нишләтер икән соң?

— Юкка пошынма, таркату җаен андыйлар тиз таба. Сизеп торам, Шәйхетдин абый, терелә́й тунаячаклар безне! Кая гына сөрсәләр дә, көн күрсәтмәячәкләр. Үз иледә яшәргә урын бетте. Җәллад кулыннан узганчы, бисмилләңны әйт тә, хет үзеңне үзең...

— Әстагъфирулла, диген!

— Гаиләмдә тагын җиде җан... Үзем генә булсам, һич кичегүсез үземә үзем кул салыр идем...

— Туктале, кияү, ялгыш-яман уйга керәсең.

— Көн бетте безгә...

— Бәлки, синеңчә булыр — аерым калхуз оештырырга рөхсәт итәрләр. Нигә куркырга икән миңа, барысын да үзем йөреп чыгам! Бәлки, оешкан калхузга керергә кирәктер, ни язганын авылдашлар белән бергә күрербез.

— Юк инде, абзыкай, кермим мин анда! Аннары да килеп, мине ул калхузга алмыйлар. Бүген инде алмыйлар! Миңа кулак тамгасы сугылды. Ә кулакларны төзелгән калхузга алмыйлар. Аларны бетерү турында гына сүз бара. Ә бетерүне ничек аңларга? Үтерүме?.. Минем хатынның бертуган абыйсы булганың өчен, сине дә алмаулары бик ихтимал. Менә нинди заманнар җитте!..

Җимеш бакчасында аяк тавышы ишетелгән кебек булгач, алар икесе дә алачык ишегенә карадылар. Бәйрәмхан ишек янына ук килде, бакчада кеше-кара күренмәде, аяк тавышы кабат ишетелмәде. Кемдер йөргән кебек тоелган гынадыр, күрәсең.

— Мин менә болай уйлаган идем,— диде Бәйрәмхан, бүкәнне Шәйхетдин янынарак күчереп утырды. Алъяпкычы кесәсеннән кәгазь чыгарды.— Монда бер генә җөмлә: «Сез уникe хуҗалыктан авылда аерым калхуз оештырырга ризамы?» Шушыны һәркайсына укытырга кирәк. Бүген малайның башы күккә тигән көн, кемгә кереп сөенечен әйтсә дә, гаеп саналмас. Җавабын һәркем үзе җаен табып ирештерер.

— Баланы катыштыру дөрес булмас.

Алачыкның арткы ягында тактага шакыдылар. Бәйрәмхан язуны оекбаш куныычына бөгәрләп тыкты. Шәйхетдин, тәмам каушап, урынында боргаланды.

— Әти... Әти, дим, мин ул өйләрне хәзерендә йөгереп кенә йөреп чыгам! Әти...

— Ах-х, синмени әле анда малай актыгы! Кер монда!

Корбәт алачыкка керүгә үк, Бәйрәмхан аның колагын борды.

— Алла-а!.. Әти, колакны өзәсең!..

— Өзелсен! Яшертен сүзне качып-посып тыңлый торган колакның булмавы хәер!

— Мин туакка, Бәләкәй биягә инде, үлән өзәргә дип кергән идем ич! Үзегез ишетелерлек итеп сөйләшәсез бит...

— Яңа туган колын үлән ашаган ди сиңа, аңгыра баш!

— Бәләкәй бия минем кулны ялады бит, мин аны ашарга сорый дип белдем...

— Син менә шушы кәгазьне кемнәргә укытачагыңны бел — булырсың егет!

— Бәйрәмхан, баланы бутамыйк бу эшкә. Уйла әле.

Ләкин Бәйрәмхан Шәйхетдин ягына кул гына селтәде.

— Башын эшләтеп үссен минем малай. Инде сабый түгел.— Аннары Корбәтне колынга исем кушкандагыча үзенә елыштырды.— Улым, шушы язуны калхузга кермәгән кешеләрнең йорт башлыкларына укыт. Анда латин һәм гарәп хәрефләре белән бер үк сүзләр язылган. Риза булганнары сиңа әйтеп үк җибәрсеннәр, калганнары үзләре миңа хәбәр итәр. Туктале, син калхузга кергән кешеләрнең дә кайберләренә сөенечеңне әйт, тик аларга кәгазьне укытма. Бутый күрмә, яме. Йөгереп кенә йөр...

Корбәт йөгереп кенә йөргән иде, кәгазьне тиешсез кешеләргә укытмаган иде, әтисе кушкан йомышны төгәл үтәвенә сөенә иде ул. Әмма өйдә аны көенечле хәл көтте. Үзе барган кешеләрнең барысының да авылда аерым колхозга берләшергә ризалыкларын әтисе белмичә калды. Бәйрәмханны, район үзәгеннән килеп, алып киткәннәр иде. Вәкил Бикмураев, Юртайдан район үзәгенә телефон чыбыгы сузылмаган булса да, милициягә хәбәр салу әмәлен тапкан, димәк. Бәйрәмхан әйткәндәй, әшәкелек кылуда җәһәтлеккә һәм үҗәтлеккә кем шушылай ныклап өйрәтте икән бу бәндәне...

Уразманов Бәйрәмханны раймилициядә тынчу һәм караңгы келәткә яптылар. Кулга алынуының иртәгесен үк күкрәк баласын күтәреп килгән хатыны Хуриyaне аның белән очраштырмадылар, китергән ризыкларын алмадылар. Хурия ире ябылган келәт янына бара башлагач, аны, җилтерәтеп, милиция башлыгы бүлмәсенә алып керделәр. Мондый түрәләрне күреп белмәгән авыл апасының начальникка үтенечен әйтергә көче җитмәде. Ул, иданнан түшәмгәчә тәрәзәле зур бүлмәнең тупсасын атлап керүгә, телсез калды, баласын, тартып алуларыннан куркып, күкрәгенә ныграк кысты. Каты ук кысты бугай, сабый елап җибәрде. Хуриянең авыз читләре калтырана, күзләре челт-челт йомылып ачыла иде. Тик аның бу хәрәкәтләре Бәйрәмхан өйләнәчәге турында хәбәр иткән чактагыдан үзгә иде, ул чактагы шатлык урынына хәзер кайгы иде. Озакка сузылачак һәм онытылмас кайгы иде...

Бәйрәмханны ябылудан атна туласы көнне иртән чыгардылар. Хурия аны, кууларына һәм үзен дә ябып кую белән куркытуларына карамастан, милиция бинасы янында беркая да китмичә көтте. Ирен күргәч, кулындагы кечерәйгән төенчеге төшеп китте, баласын ычкындырмаска көче җитте. Бәйрәмханга таба берничә адым атлагач, акрын, бик акрын сыгылып җиргә утырды. Аның каршына әле атна элек кенә кодрәт иясе булган Бәйрәмханы килә иде. Килә иде? Юк.

килми, ә инде ап-ак чәчле, җилкәләре салынган, аяк буыннары тотмаучы Бәйрәмханы сөйрәлә иде — бер атнада кешене нинди хәлгә калдырып була икән... Хәлсез ир хатыны белән баласы янына егылды.

— Исән...

— Исән, Хурия... Тик... бу кызыбыз төпчегебез булыр инде...

Хурия, баланы әтисе алдына куеп, төенчекне алып килде, ашъяулыкта моннан ике төн элек абыйсы Шәйхетдин качып кына китереп киткән ризыклар бар иде әле. Каршыдагы тыкрыкка керделәр. Киртә буена утырып, тамак ялгадылар. Кайту ягына атладылар. Хурия шул чак теге көнне Корбәтнең йомыш белән барган кешеләрдән аерым колхоз төзергә ризалык алып кайтуын әйтте.

— Алайса,— дип туктады Бәйрәмхан,— алайса, алайса... райбашкармага кереп, үз калхузыбызны оештырырга рөхсәт алыйк. Тагын кайчан монда килермен аннары, эшне бетереп кайтырга кирәк.

— Әйтәсем калмаган икән.

— Юк-юк, алай димә, Хурия. Безнең бит әле Юртайда яшисебез бар. Безне төзелгән калхузга инде алмыйлар. Унике ихатадан ширкәт булып, кендегебез киселгән төштә яшәрбез, шат.

— Әллә кермисеңме соң, Бәйрәмхан? Киемнәрең керләнгән. Дәү кешеләр янына болай керү уңайсыз. Яланбаш килеш тагын.

— Ә-ә, эшләпә онытылган икән. Мин аны баш астына салып йоклый идем.

— Чәчләрең ап-ак...

Бәйрәмхан чәчләрен сыпырды.

— Агарганмы... Ярар, кайчан да булса барыбер агарасы инде алар. Баш исән булсын.

Райбашкарма рәисе катына ук керә алды Бәйрәмхан, авылдан олы үтенеч белән килгән ярлы кешегә санап, аны тоткарламадылар. Тик йомышы уңмады, райбашкарма башлыгы Юртайда тагын бер колхоз оештырырга рөхсәт итмәде.

— Социализмга кулаклар калхузы кирәкми, Уразманов! — дип кырт кисте ул.

— Без кулаклар түгел, үз көчебез белән көн күрүчеләр. Без аерым ширкәт булырга телибез.

— Телисез? Ә син башкаларның теләген каян беләсең?

— Мин барысының да ризамы-юкмы икәнлеген белешергә малайга кушкан идем. Алар риза булган, хатыным шуны әле әйтте. Мин моны вакытында белмәдем, малай кайтып өлгергәнче, мине милиция алып китте.

— Их син, мескен кулак калдыгы! — дип көлде райбашкарма рәисе.— Кыяфәтеңә кара, хөрәсән бит син! Нинди калхуз оештыра аласың ди син! Калхуз оештырырга Бикмураевлар кирәк! Малае да калхузга каршы үгеткә керешкән икән моның, ә! Аннары,— дип тавышын тагын кискенәйтте рәис,— авылың хәлләрен белмисең икән син, авылыңнан аерылгансың.

— Ябылуда идем.

— Сине авылдан аерып торган арада, Уразманов, вәкил Бикмураев шәп эшләде Юртайда! Авылны тоташ кумәкләштерергә тырышуыбыз сезнең өчен ләбаса! Калхузчылар сөрелмәячәк. Ә син, аңгыра баш, шуны аңламыйсың. Күмәкләшергә тешең-тырнагың белән каршы торасың. Бикмураевны кыстык бераз, ату бит башта барган авылының яртысын кулак буларак сөрде, чамасыз кыланды. Юртайдан бер-ике хуҗалыкны гына сөрермен, алай да булдыра алам, дип сүз бирде. Тәк. Юртайда кичәгесе көнгә... Тәк-тәк...— Райбашкарма рәисе өстәл өстеннән бер бит кәгазь аерып алды.— Тәк... Юртай мөнә монда икән... Юртайда кичәгесе көнгә күмәкләшмәгән өч кенә хуҗалык калган. Димәк ки, син кулаклар калхузы оештыру турында тилереп кенә йөрисең.

«Сындырганнар икән күбесен».— дип уйлады Бәйрәмхан.

— Әсез өч хуҗалыктан калхуз булып берләшергә рөхсәт итегез! Бер авылда ике калхуз ярамый, дисәгез, без ширкәт булыйк соң!

— Әйтәм ич, тилермә, Уразманов! Иртәгә Юртайда калхузга кермәгән бер син калачаксың. Яхшылыгым тисен үзеңә — тизрәк Юртаеңа сыпырт та сөрелереңә әзерләнә тор!

— Хәзергә кыласыз да кыласыз, кайчан да булса башыгызны тотарсыз. Ә бит элгәре, кылганчы, дим, башыңны тотып уйлану мәслихәт...

Алар авылга кичкырын кайтып керделәр. Капка төбенә җиткәч, урам як өйдән Бикмураев тавышын ишетеп туктады Бәйрәмхан: «Ни кыла монда бу җәллад?»

Тәрәзә турына барды. Өй эчендә элекке җиһазлар сирәк күренде. Бикмураев һәм авыл башлыклары каршында Шәйхетдин белән Юртайның хәзрәте калтыранып утыралар иде.

Эчкәрге өйдә тын. Мунча тәрәзәсендә тонык ут күренә.

Бәйрәмханнарның ике өен дә колхозга алу турында, үзләренә, сөрелгәнчегә чаклы мунчада яшәргә боерып, авыл җыены бүген карар чыгарган икән. Абзар-курага, мал-туарга әлегә тимәгәннәр. Мунчада бүген сигез җан кунарга тиеш иде. Ләкин Бәйрәмхан, авыл җыены карары белән ризалашмыйча, барысына да йоклау урынын келәткә күчертте. Әле төн озынаюга керешмәгән, төнгә көндезге җылы мулдан кала, келәттә туңмаслар.

Болай булгач, китәргә әзерлек күрергә кирәк иде. Бәйрәмхан, үзләренә нинди маллар — атларның берсенә булса да төянеп китәргә кирәк ләбаса — калдырылачагын белергә теләп, авыл башлыклары янына керергә теләгән иде дә, Хурия, телеңне әрәм итмә, дигәч, бу фикереннән кайтты.

Шулай шул, колхозүзәк вәкиле Бикмураев, кулакны сыйныф булу ягыннан бетерү турында карарда бер хуҗалыкка ат калдыру турында әйтелмәгән, дип кенә авызыңны йомачак. Әллә соң... Әллә соң, тукмап акылга утыртыргамы бу вәкилне?!. Юк, дип башын чайкап уйлануында булды Бәйрәмхан, әти әйткәндәй, ишәкне колагын кисеп кенә чапкын итеп булмый. Ишәк шулай ук түшәк кадерен дә белмәс, ишәккә алтын ияр куйсаң да һаман ишәк булып калачак ул. Гаҗәп бит, әй, мин дә, Бикмурай да революцияне яклаганбыз. Ә хәзер, ил тынычлангач, бер-беребезгә дошманнар...

Билгесез сәфәргә әзерләнә башладылар. Карт белән карчык та күтәрә алырлык төенчекләр төйнәделәр, киемнәренең яңаракларын киделәр. Балаларын йоклаткач, Хурия дә җыенды. Бәйрәмхан җыенуга катнашмады, мунчада су җылытып юынып алгач, келәтнең ишек яны стенасына сөялеп, сүзсез утыра бирде. Әти-әнисенең, Хуриянең, синең аркада шушы хәлгә төштек, дип рәнҗүләреннән курка иде ул. Ләкин аңа берсе дә үпкә белдермәде. Малае Корбәт йокламый икән, урыныннан торып, әтисенең тезенә таянды:

— Әти, без барачак төштә мәктәп бармы соң? Мин татарча гына укый беләм бит. Аннары тагын. Бәләкәй бия арыр инде ул, име. Аны арбага яткырып булмыймы соң?

Бәйрәмхан Корбәтнең башыннан сыйпады, малай йокыга изрәгәнче озаклап сөйде.

— Шундый сорауларың булуы хәерле, улым. Мәктәп... Татарча... Бәләкәй бия арыр, дисең инде. Үзебез арымагаек...

Төн уртасында капка төбенә җигүле ат килеп туктады. Ишегалдында ят тавышлар ишетелде. Бәйрәмхан келәт ишеген ачты.

— Менә кайда качып ята икән ата кулак! — диде милиционерларның берсе.— Бездән кача алмассың! Киен! — дип боерды ул Бәйрәмханга.— Тизрәк бул! Малаең кайда! Кечкенә агентка да дөнья күрсәтик!

Бу юлы, Бәйрәмхан белән бергә, аның тугыз яшьлек малае Корбәтне дә алып киттеләр.

...Утызынчы елның июнендә таркатылган бу гаиләдән Юртайга кайтып йөрүче булмады. Бәйрәмханның әти-әнисе, хатыны Хурия һәм Бәйрәмхан үзе инде вафат, гүрләре Юртай каръясе каберстанында түгел, төрле төбәктә. Корбәтнең сеңелләре, хәтта өлкәне дә — Юртайдан киткәндә алты яшь тулганы да — авылны хәтерләмиләр. Ә Корбәт авылын онытмый, аның анда бик кайтасы килә.

Кайтыр да иде... Ләкин әтисе белән аны алып киткән чакта бер йөз дә сигез ихатадан торган Юртай авылы беткән икән инде. Шулай да Корбәткә Юртайда хәзер дә атларны төнге көтүгә алып чыгалардыр кебек. Тын кичләрдә малайлар, атларына атланып, авыл башындагы күпер төбенә җыелалардыр... Көн узып бер-берсен сагынышкан атлар кешнәшәләрдер... Иртән тук атлар Юртай урамына юыртып килеп керәләрдер... Алар арасында Корбәтләрнең Юртай ихатасында туган соңгы колын — Бәләкәй бия дә бардыр кебек.

*1988*

# ЯСИН

хикәя



Шәһәр өстен киезләнеп беткән йолкым-йолкым болытлар томалаган. Кич. Вак кына яңгыр сибәли. Ярымагач-ярымташ йортларның муртаеп каралган такта түбәләренә шәрә тупыллардан эре-эре тамчылар коела. Бу дым инде өйләрнең эченә үк саркып кергәндер шикелле.

Тоташ күлләвеккә әверелгән, ермачланып беткән пычрак урамның сайлап басардай каты урыны да калмаган. Аяк астындагы балчыкны тая-тая ерып, Ясәви әкрен генә бара да бара. Егылып китмәс өчен коймага тотынгалый, бармак битләрен уа — юеш такта черекләрен коя. Авыраеп калган көзге пәлтәсенең су саркып торган чабуы итек кунычына ябыша.

Бу урамның һәм тоташ сибәләгән яңгырның алда да, артта да чите юктыр кебек. Урамның теге башында ике катлы соры кирпеч йорт абайлана.

Ясәвинең көн буена валчык та ризык капканы юк дисәк, гөнаһ булыр. Иртән карчыгы белән чәйләп алган иде ул. Мае да, вареньесы да, хәтта колбаса кисәге дә бар иде өстәлдә. Ясәви берсенә дә орынмады. Бер телем ипинең читен генә сындырып алды да чәй чөмерүен белде. Тамактан ризык үтәрлекме?!

Кайтканына инде айдан артык, акчасының беткәненә атна булды, ә ул һаман эшсез... Хатынының тапканы, хезмәт хакы, хәзерге бәяләр әргәсендә балыклы чиләк янында тулганган мәче кебек ялманып йөрерлек кенә. Нигә кирәк булды яңа костюм? Ә ул телевизор тагын ни чуртыма? Янәсе, ирекле кеше! Ни тели, шуны эшли. Ни тели, шуны ала... Теге кесәдә дә акча, монысында да. Уңга да чәчә, сулга да сибә. Кавказдан баеп кайткан диярсең. Кесәсеннән чыгып очкан һәр унлыкка карчыгының күзе әллә кая чаклы иярә бара. Мөлдер-мөлдер. Ясәви күрә һәм елмая (эчтән генә). Менә ничек без аны: табабыз да, сибәбез дә. Ул — ирекле кеше!

Ирек... Ул аны тегендә чакта бөтенләй башкача күз алдына китерә иде. Менә ул үзенең эш урынына — тынчу-дымлы подвалына килеп керер, ачкычы белән шалтыр-шолтыр килеп торбаларны, краннарны тикшереп йөрер. Биредә ул — хуҗа! Мастер аңа бер кочак үтенеч китереп бирә икән, ул шат. Кабаланмый гына эш коралларын барлар, үз дәрәҗәсен белеп кенә квартирдан квартирга йөрер. Ялганган торбалар, тамчылаудан туктаган краннар, кабаттан җылыта башлаган батареялар, ачылып киткән йөзләр, күңелләре рәхмәт тулы хуҗабикәләр,— болар бит күңелдә саклanучы хатирәләрнең һәм хыялның иң яктысы, иң рәхәте...

Аны күргәч, начальникның йөзе беренче мәлдә яктырып китте шикелле.

---

Әхмәт ХӘММӘДИШИН *(1949) — яшь язучы. Чаллыда яши. Журналда проза әсәре белән беренче тапкыр катнаша.*

— Ә-ә, Ясәви! Кайттыңмы?

— Исәнмесез...

Таныш кабинет. Таныш өстәл. Кырыйдан агач чөйгә кигезеп куйган бер тактасы төшеп йөдәтә иде. Әнә ул хәзер дә өстәл янында, стенага сөяп куелган. Кыршылып беткән, борылмалы таныш кресло. Холкы — начальникның нәкъ үзе инде: кузгала башласа, ризасыз тавыш белән чыелдап куя. Кресло тавыш бирсә, йомышның уңмасын көт тә тор.

Биредә бернәрсә дә үзгәрмәгән диярлек. Шул ук обойлар, стенага ябыштырылган шул ук йөкләмәләр. Төсе уңа башлаган язуның фәкать баш өлешендә генә күзгә ташланып торган 89 саны — иске чалбар өстеннән буып куйган иске каешның өр-яңа аелы кебек. Тагын нәрсә? Каршы якта үзгәртеп кору һәм демократия турында стена тутырып язылган кызыл лозунг. Тагын портрет.

Начальник үзе дә үзгәрмәгән. Гаҗәп зур осталык белән җентекләп эшләгән, һәр сыры тырышып шомартылган битлек-маскага тартым чырай; гәүдәсенең бер өлеше булып тоелган нindider мәңге тузмас материалдан тегелгән костюм. Өстәлдә яткан ручкасы да, хәтта ручкага урап куелган зәңгәр изолента кисәге дә Ясәвигә таныш иде.

— Ну, ни йомыш?

— Менә кайттым...

— Күрәм...

Беренче мәлдә ятырып киткән чырай сүрелә башлады. Андагы таныш сырлар, тирәнәеп, үз рәвешен алды. Начальник кыймылдап куйды; кресло, йөз елга бер ачыла торган тутыгып беткән тимер капка кебек, ыңгырашып куйды.

— Менә... эшли башларга дигән идем.

Кресло тагын чинап җибәрде. Ясәвинең сөмсере коелды. Яраткан уенчыгын икенче бер бала кулында күргән сабый кебек, тамагына төер тыгылды.

— Видишь-ли, кем, Ясәви... синең урынга кеше алган идек шул инде без.

— Алай икән...

— Ну син ни... нитмә... Берәр атнадан кереп чык. Эш тапмый калмабыз.

Бер атнадан килде. Паспортын, хезмәт кенәгәсен, тегеннән бирелгән белешмәсен чыгарып салды.

—Тә-әк.

Начальник күзлеген алып киде, ашыкмый гына документларны актарырга керeште.

— Тә-әк,— дип янә кабатлады ул.

Бу сүздән Ясәвинең йөрәге кысылды. Гәрчә кәгазьләрендә берниндi ялгыш яки ялган булмаса да, ул үзен нindider җинаять өстендә тотылган кеше итеп тоя башлады.

— Тә-әк. Прапискаң юк икән бит синең.— Күзлек өстеннән Ясәвигә текәп карады.— Ә?!

— Ни бит, Гали Сәрвәрич... эшкә урнашмыйча торып, пропискага кертмиләр.

— Эшкә алырбыз, алырбыз. Бездән сиңа полный гарантия. Түлке... башта син пропискага кер.

— Соң бит, Гали Сәрвәрич...

— Бала-чага булма инде, Ясәви. Законны син миннән яхшырак беләсең. Тегеннән кайткан кешене прапискасыз-нисез эшкә алсам, баштан сыйпамыйлар бит. Беләм, яхшы сантехник булуыңны да, намуслы кеше икәнлегеңне дә — барысын да беләм. Но...— начальник имән бармагын югары күтәреп, иңсәсе аша артка күрсәтте: — Анда мине дөрес аңламаулары бар. Кстати, ник синең үзеңә

трестка барып кайтмаска? Минем җилкәдән дә отбетственнес төшәр, үзең дә тынычланырсың.

— Ярар соң, Гали Сәрвәрич. Түлке...

— Нәрсә?

— Бәлкем... Сез... гаризаның бер почмагына язып куярсыз: шулай-шулай, мин каршы түгел, дип...

— Э-һе-һеһ, Ясәви. Картаеп барасың, тәки акыл керми сиңа. Андый сүзне соң мин яза аламмыни инде, йә? Трест директоры әнә шулай итеп язып бирсә — пажалысты. Рәхим ит. Аңладыңмы?

—...

— Ярый, бар. Кыюрак бул анда.

Соңгы киңәшен бирмәгәндә яхшырак буласы икән, югыйсә. Җилкенеп китеп, Ясәви анда артык кыюланып ташлады; хәтта һавалырак та сөйләште бугай. Көндәлек мәшәкатьләреннән, телефон хәбәрләреннән айнып җитмәгән идарә башлыгы аны аскы иренен бүлтәйтеп, гаҗәпләнебрәк тыңлады.

— Сезне кем җибәрде?

— Ни... Гали Сәрвәрич.

— Нәрсә, дөньяга бүген туганмы әллә ул? Эшкә алу-алмау аның җилкәсендә бит.

Башлык күнегелгән хәрәкәт белән телефонга үрелде, телефонның саннар тәгәрмәченә бөтен усаллыгын салды. Юка тиреле симез бармагының очы, тәгәрмәчне әйләндергән саен, агарып-агарып кала. Кул аркасындагы алтынсу төкләре тәрәзәдән төшкән кояш яктысында җемелдәп-җемелдәп китә.

— Баймуратовны!!!

Мәгарәдәй зур кабинетта гөрселдәгән көр тавыштан Ясәви телефон трубкасыдай бөгәрләнеп килде, кечерәеп калды. Күңеленең әллә кайсы төшендәге ниндидер бер бик әһәмиятле әгъзасы (әллә йөрәге инде?) өзелеп төште. Ә башлыкның күзендә уйный башлаган шаян чаткыны күргәч, башының арт чүмече җылынып китте. Әмма бер генә мизгелгә. Икенче мизгелдә башлыкның карашы хөкем карары укучы судьяныкы кебек төссезләнде. Ясәви аркасының тирләп чыкканын тойды. Бераздан аның күкрәген тагын өмет җылыта башлады. Идарә башлыгының сизелер-сизелмәс кысылган, уйчанланып калган күзләре аның күңелендә, баш миендә барган ниндидер көрәшхәрәкәтне чагылдыра кебек иде.

Ниһаять, карашы аязып китте. Ниндидер фикергә килде булса кирәк.

— Ярар.

Шул бер генә сүзне әйтте дә, күнегелгән-илтифатсыз хәрәкәт белән трубканы ташлады. Хикмәтле караш белән Ясәвигә озак кына карап утырды. Аннары карашын гаризага күчерде. Кулына озын кара ручка алды. Бераз уйлап торгач, ручкасын кинәт кире куйды.

— Гаризагызны калдырыгыз. Пропискага кергәч килерсез.

Бу инде — акланып бетә язган кешене үлемгә хөкем итү белән бер иде. Үз хәлен аңларга, куерганнан-куера баручы кургашын болыт шикелле уйлары арасыннан күренеп китәргә тиешле яктылыкны тотып алырга теләп, Ясәви бөтен ихтыярын бер ноктага тупларга тырышты. Калтыранып-калтыранып куйган күкрәгеннән чигәләренә тере кыллар сузылды. Ул кыллар мең аваз белән зыңларга кереште. Һәм ул кылларның зыңлавы, авыр корыч скафандр диярсең, аны төреп алды, мохиттән аерды, күзен күрмәс, колагын ишетмәс итте.

Чигәләрне ниндидер бер авыр чүкеч кыйный: нишләргә?! Нишләргә?! Аңында әлеге сорау яңгырап киткән саен, Ясәвинең акылы бөгәрләнә, кечерәя, кабыкка төрелә бара. Менә ул кечкенә бер төенгә, ноктага әверелде һәм бөтенләй юкка чыкты. Ә гәүдәсе, мең-

ләгән тәрткеләргә — тузан бөртекләренә әйләнеп, һавага, тирәлеккә тарала башлады. Узгынчылар, машиналар аны урап түгел, аның гәүдәсе аша уза, ләкин аңа һич тә кагылмыйча үтәләр.

Ә бит тирә-юньдә тормыш кайный. Коточкыч катлаулы, акыл ирешмәслек капма-каршылыклар белән тулы тормыш. Гүя кыршылып, ярылып беткән тәлинкәне иске тутык патефон әйләндерә. Күпме тыңласаң да бер үк көй, бер үк җыр... Шул көйгә, шул җырга берничек тә таңгал килми торган эш-хәрәкәт. Әмма... ничек кенә мәгънәсез тоелса да, бу бит — тормыш. Чын тормыш. Кайнап торган тормыш! Ә Ясәви — шул тормыштан, котырып әйләнгән иске ярык тәлинкәдән мәтәлеп төшкән бер тузан бөртеге. Аны кабат тартып алу өчен инде берәү дә ярдәмгә кулын сузмас, ахры.

Бервакыт аңа ванна төбендә чабулап йөргән тараканны күзәтергә туры килгән иде. Артына ут капкандай бер якка китеп бара да, кинәт туктап кала. Мыеклары белән уңлы-суллы ванна төбен кыйный. Ары тартыла, бире борыла, тагын йөгерергә тотына. Стена буйлап бераз менә дә аска тәгәрәп төшә. Ванна төбендә җирән корсагын күрсәтеп, җирән тәпиләре белән шактый чәбәләнә. Аягына торып баскач, мыекларын боргалап, тагын юнәлеш эзли башлый. Ничә мәртәбә менеп җитә язып, ничә тапкыр егылып төшкәндер...

Уйламаганда исенә килеп төшкән бу «вакыйга» Ясәвине кабыргасына төртеп уятты. Башына Ньютон алмасы төште диярсең, зиһене аязып китте. Нәрсә дип әле ул, алланың кашка тәкәседәй күреп, шул Баймуратовка табына?! Беткәнме бүтән эш! Муеның исән булса, камыты табылыр...

РСЖУ... Бу исемнең русчасын да, татарчасын да озынайтып укый белми иде Ясәви. РСЖУ — бары тик шулай гына.

Игътибар өмет итеп ишек төбендә шактый басып торды. Кечкенә генә бүлмәгә шыплап тутырылган өстәлләрнең үз тәртибе, үз хуҗалары бар, билгеле. Әнә, Ясәвигә бәрелеп узган хезмәткәрләр өстәл читләрендә ишелеп төшәргә җиткән кәгазь өемнәренә дә, ярты-лаш диярлек өстәлдән чыгып торган шома төймәле чутларга да, аяк астында кайнап утыручы чәйнекләргә дә кагылмыйча туп-туры өстәлләре янына узалар, үз эшләре белән мәйханә киләләр.

Әһем...

Гөжләп торган иҗат атмосферасы Ясәвинең тамак кырган тавышын үзенә йотты.

— Ой, кызлар чәй кайнаган!

— Тр-р-рь!!! (телефон)

— Әйе!.. Юк!.. Әйе! Сан-саныч, сезне!

Әһә, монысы башлыклары икән. Ясәви, итәк-җиңен җыеп дигәндәй, кырын-кырып басып, «Сан-саныч» янына китте. Ничек кенә сак барырга тырышса да, итек башы белән ниндидер шнурны элэктерде. Бер хатын алдында яткан яшел күзле электрон машинка, кәгазь өемнәрен ерып, өстәл читенә тартылды.

— Әй, мужик! (ниһаять игътибар иттеләр).

— Гафу итегез...

— Гафуыгыз белән сату итегез. Безгә кергәндә арбаңны калдырып керергә кирәк!..

— Исәнмесез...

— Ни йомыш?

— Менә... эшкә урнашырга йөри идем.

— Һөнәрегез?

— Сантехник.

— Сантехник? — начальникның кашлары чәченә кадәр үк сикерде.— Гаризагыз?

— ...

— Башта кадрлар бүлегенә керегез. Коридорның теге башында.

— Рәхмәт.

Кадрлар бүлеге. Монысы Ясәвигә, нишләптер, таныш тоелды. Аннары аркасы чымырдап куйды: койма! Бүлмәдә утыручы белән аның арасында койма тотылган иде.

Койма артыннан озынча тырнаклы нәфис кул сузылды:

— !!

— Ә?

— Документларыгыз!

Койма аша үрелеп, кул иясенә карады Ясәви. Чибәр генә ханым. Әмма күзләрендә иман әсәре юк. Болай, югыйсә, үзе сиңа караган шикелле. Ләкин каршында сине түгел, бушлык күрә. Һәм шул бушлык эченнән (түш кесәңнән) документлар чыкканны көтә.

Паспортны ачып карады да, дүрткә бөкләнгән ак кәгазь битенә үрелде (милиция кәгазе!). Таралып торган коңгырт-җирән чәчләрен колак артына өя-өя кәгазьне шактый җентекләгәч, кәрт уенында оттырган бәндә шикелле, документларны уч төбенә өйде. Озынча тырнаклы нәфис кул тагын Ясәвигә сузылды:

—!!!

— ?..

— Алыгыз!

— ?..

Кулның түземе бетте, документлар шапылдап койма өстендәге киң тактага килеп төште. Ясәви тагын койма аша үрелде:

— Ә... нишләп?..

Ханым туп-туры Ясәвинең күзенә карады (беренче мәртәбә):

— Язу таныйсызмы?

— ...

— Бу — РСЖУ. эР-Се-Же-У. Ә сезнең монда — ЖКУ. Же-Ка-У. Аңладыгызмы?

Контордан чыгып барышлый, Ясәви ишек төбендә кем беләндер бәрелешә язды. Башын күтәрмичә генә юл бирде. Ләкин теге узып китмәде. Алай гынамы, кинәт учы белән Ясәвинең иңбашына шапылдатты:

— Һа! Ясәви!

— ...

— Нәрсә, танымыйсыңмы әллә?

Авызы тулы алтын теш тегенең. Канәгать, тук чырай. Таныш кебек үзе.

— Соң, Әмиров бит мин. Танымыйсыңмыни?

— Ә-ә, Әмиров...

— Чыктың дамыни инде?

— Чыктым...

— Ну и молодец!.. Эшкә урнашмадыңмы әле?

— Юк.

— Во! Миңа какрас синең кебек бер пробивной кеше кирәк. Кирәсеңме?

— Нинди эш?

— Нинди булсын... Үзең беләсең инде. Бездә бит шул: тегесен тап, монысын юнәт.

— Ю-ук, андый эшкә кул ятмый.

— Хотя... бер авызың пешсә...

— Шул-шул менә.

— Ну, алайса, слесарь булып. Все-таки иске таныш.

— Анысы ярый.

— Яраса, иртәгә кер. Хотя юк. Иртәгә мин Чаллыга китәм. Шимбәсез кайта алмам. Так что, понедельник — рәхим ит, татарча әйткәндә.

...Әмировның кем икәнлеге турында да, Ясәвинең ничек тормәгә эләгүе хакында да язарга исәп юк иде: хикәя озынга китә. Эләккән. Утырган. Чыккан. Ничек эләксә дә — эләккән. Күпме утырса да — утырган. Чыкканмы — чыккан. Җәзасын алган. Хәзер яшәргә кирәк. Тормышны дәвам итәргә. Ник үткәннәрне айкарга? Булган — беткән...

Менә, шайтан алгыры, алтын тешләрен ялтыратып, килде дә басты Әмиров! Язмышның нәкъ үзе диярсең. Сорап тормый ул синнән. Телисеңме, юкмы — култыклый да билгесезлеккә алып китә. Ә син. Ижау базарына баручы арба артына бәйләнгән мүкләк сыер шикелле, мыш-мыш борын тартып, күндәм генә атлыйсың. Атлыйсың, атлыйсың... Берзаманны башыңны күтәреп карасаң, бугазыңа чалгы чаклы пычак терәгәннәр. Җәмәгать! Нишлисез сез?! Мине түгел, әнә, Әмировны!.. Ләкин пычаклы кеше берни күрми. Бауны кысып эләктергән дә, бисмилласын укый. Тыпырчынырлык та түгел ичмасам! Аркан, аллага шөкер, фил тышауларлык. Ярар инде, дисең, хәерле каза булсын. Тик... пычакның үткен йөзе генә чиркандырып тора. Авыртыр кебек. Авыртмый ла ул! Кайнар гына була. Пычак йөзен әйтүем. Утта кыздырганнар диярсең.

Ә шулай да, күкрәк эчендә әллә нәрсә (йөрәк лә инде, бүтәнчә нәрсә булсын!) арканы, җилкә тамырларын, тагын әллә кайсы турларны тырный. Сиңа карап торган меңләгән күзләр, юк, күзләр түгел, әнә шул исән, тере, җанлы күзләрнең ияләре — кешеләр — (шул исәптән Әмиров та) дөньяның бу ягында калачак бит инде. Берни булмагандай өйләренә кайтып ятачаклар. Хатыннарын, ирләрен, сөяркәләрен кочаклап, телевизор караячаклар, иртән торып эшкә китәчәкләр, эшләгән атлы булып йөриячәкләр... Болар инде синең өчен юк. Чөнки син үзең юк. Юк? Ничек юк? Менә бит син — бар! Менә гәүдәң. Менә башың... Үзең бар, үзең юк. Чөнки бу — дөньяның икенче ягы. Тегеләр икенче якта калды, ә син бу якта. Әле дә ярый бөтенләйгә түгел. Срок. Срок үтте — син тагын теге якта (Бу якта!) Их... Ах... Бу яктагылар сине әле һаман теге якта дип исәпли икән шул! Әмировлар өчен генә син — үз кеше. Чөнки алар — табигатьләре белән теге як кешеләре.

Дүшәмбе көн иртән (хикәя башында ул көннең ахыры җиткән иде инде: хәтерләсәгез, шәһәр өстен киезләнеп беткән йолкым-йолкым болытлар томалаган иде) Ясәвинең күңелен ниндидер шик кимерә башлады. Артык гади, артык шома, артык җайлы килеп чыга. Әмировның эшне җайга салырына тамчы да шиге юк Ясәвинең. Чөнки Әмиров — көч. Бу дөньяда, бу җәмгыятьтә ул — үз кеше. Хуҗа кеше. Киндек кеше. Тотка кеше. Әмиров канаты астында дөньяны имеп ятарга була. Аныңча яшәсәң. Ул дигәнчә эшләсәң. Аңа ярасаң. Ләкин... бу шома юл аны тагын ТЕГЕ якка илтә түгелме соң? Ижау базары. Пычак. Күзләр. Күзләр арасында — Әмировның алтын тешле тук чырае... Кемдер, күзен күккә текәп, талгын гына дога укый. Ясин сүрәсе...

# ӘТКӘЙ СӘГАТЕ

НӘСЕР



Әткәй туган елны бабасы Солтан хәзрәт Минзәлә ярминкәсеннән стена сәгате сатып алган. Ул аны, өченче малае белән котлап, улы Фазыйлга бүләк иткән. Шул көннән башлап әлеге сәгать безнең әткәй Әхмәтфатыйхның гомер елларын саный башлаган.

Туктала-туктала санаган ул әткәйнең гомерен. Беренче тукталуы — 1919 елда...

Аңа чаклы, бер-ике сүз белән генә, әткәйнең үз малайчагы турында сөйләгәннәрен искә төшерергә кирәк әле.

Уфа губернасының Минзәлә өязе, Әмәкәй волостена керә торган Жылан авылына терәлеп Калмия суы ага. Калмия — Сөнгә, Сөн — Агыйделгә, Агыйдел — Чулманга, Чулман Иделгә коя, мәгърур Идел Каспий диңгезенә барып тоташа. Шулай итеп, малайларның тубыгына гына житәрлек Калмия елгасы да үз сулары белән тирән диңгез суларын арттыруга булыша.

Әткәйдән калган бердәнбер ядкаребез булган шушы сәгатькә карыйм да, ул санаган секундларны Калмия суларына, минутларын — Сөннекенә, тәүлекләрен — Агыйделнекенә, айларын — Чулманныкына, елларын — Идел суларына, ә чал Каспий диңгезе суларын гасырларга охшатам. Диңгез инешләрдән җыелган кебек, гасырлар да секундлардан тора бит.

Һәр кешенең гомере беренче секундлардан башланган кебек, әткәйне дә әүвәл Калмия суында юганнар, ак биләүгә биләгәннәр. Бер-ике елдан, ыштан кию бәхетенә ирешкәнче үк, Калмия суларында чыпырдау бәхетенә ирешкән ул. Аннары Калмия белән Сөн арасындагы болында тәгәрәгән, олылар печән чапканда чүмәлә тарттырган, иген урганда көлтә ташыган.

Әткәйгә унҗиде тулган елны Октябрь революциясе булган. Унсигезе тулгач, авылларына аклар килеп кергән. Кергәннәр дә, атка атланырлык, кулына корал тотарлык яшүсмерләрдән башлап, сәламәтрәк булган картларга чаклы өй рәтеннән армиягә яза башлаганнар.

— Без — Габитләр, Сабирлар, Ханнаннар, тагын әллә кемнәр — атка атландык та Ишмәнгә качтык,— дип сөйли торган иде әткәй.

Ишмән дигәне — бик куе бер урман. Салкын сулы чишмәләре дә, баткаклы сазлыклары да, матур аланнары да бар Ишмәннең. Әмма Ишмән коткара алмаган аларны. Ике-өч көннән барысын тотып алганнар да, атлары-ниләре белән алып киткәннәр.

Кайсы юллардан булгандыр — әллә әткәй сөйләмәгән, әллә ул сөйләп тә онытылган — алып киткәннәр аларны Урта Азия якларына. Ә унтугызынчы елда авылга әткәйнең үлде хәбәре килгән.

---

Индус СИРМАТОВ *(1937) — повестьлар, хикәяләр авторы. Журналда беренче тапкыр басыла. Казанда яши.*

Әткәй сәгатенең беренче тапкыр тукталуы дип шуны әйтүем. Улы рухына багышлап, бабабыз Фазыйл мулла ясин чыккан.

Әмма сәгать ялгыш кына туктаган булган икән. Унтугызның ахырында, берничә иптәше белән аклардан качып, әткәй Калмия буендагы Җылан авылына кайтып төшкән. Стена сәгате тагын келт-келт итеп аның гомер секундларын саный башлаган.

Егерменең башында исә әлеге егетләр, Кызыл Армиягә язылып, Бөгелмә ягына чыгып киткәннәр.

Шул елның җәендә сәгать икенче тапкыр туктаган. Бу юлы әткәйнең Сембер тирәсендә үлеп калуын үз күзләре белән күргән кеше кайтып әйткәч, улы Әхмәтфатыйх рухына багышлап, Фазыйл бабакай икенче тапкыр ясин укыган.

Юк, сәгать түгел, кайчакта еш кына кешеләр ялгыша. Җәйгә — корылык, көзгә ачлык алып киләсе егерме бернең башында аксаклый-туксаклый әткәй кайтып кергән.

— Үзе исән вакытта үлде хәбәре килеп ясин укылган кешенең гомере озын булыр, дигән борынгылар. Әхмәтфатыйхка инде ике ясин укылды. Аның гомере икеләтә озын булыр,— дип шатланышканнар гаиләдә.

Тик алар үзе исән чакта әткәйгә өченче ясин да укыласын белмәгәннәр әле.

Өченчесе әткәй утызынчы еллар башында авыл советы секретаре булып эшләгәндә укылган...

Ансын әнкәй сөйли:

— Әткәгез, үзе коммунист булмаса да, гел актив булды бит ул. Авылда мәктәпне алар салды. Үзе Минзәлә техникумында укып кайтты да, олысын-кечесен укытты. Колхоз төзелә башлагач та гел алар башлап йөрде инде. Авыл советында аларның ярты төнгә чаклы утыруларына без күнегеп беткән идек. Ачу да килә, сүз дә әйтеп булмый. Берсендә ярты төн үткәч тә кайтмый бу, таң атар вакыт җиткәч тә күренми. Сыер сава башлаганчы пыр туздырып алып кайтыйм әле, дип, авыл советына киттем. Барып җитеп, совет өенең ватык тәрәзәсен, киереп ачылган ишеген күргәч, йөрәгем «жу!» итеп куйды. Акны-караны күрмичә эчкә йөгереп керсәм, әткәгез ватык тәрәзәгә аркасын куеп урындыкка утырган көе өстәлгә башын салган да йоклап ята. Йоклап ята дип торам инде. Уятырга да кызганам, уятмый да булмый. Әкрен генә җилкәсенә кулымны тигерсәм, башыннан кан агып төшкән. Үзенең тыны да юк. Өзгәләнеп кычкырып җибәрүемне хәтерлим дә, караватка сузып салынган әткәгезнең баш очында ясин укып утыруларын хәтерлим. Башкалары — мин кычкырып җибәргәч бөтен авылның совет өенә җыелуы да, кемнәрнеңдер кабер казырга китеп барулары да, кайсыныңдыр, милиция килеп тикшергәнче күмәргә рөхсәт юк, дию дә томанла гына истә калган. Милициягә чаклы ук фельдшерны, врачны килеп җитте.— Ул чакта аларның барсын да духтыр дибез инде. «Бәй, нишләп исән кешенең баш очында ясин укып утырасыз?» — дип ачулана бу корткаларны. Юри әйтәме әллә дип торам. Юк икән. Терелде әткәгез. Ярты елдан чаптырып йөри башлады. Бишегез аңа чаклы булса, дүртегез шуннан соң туды әле.

Шулай шул, әткәйнең гомер сәгате киселмәгән икән әле!

Кырык бердән соңгыларын үзем дә хәтерлим.

Укытучыга бронь бирелгәнгә күрә, безнең әткәй сугышка башкалар кебек беренче көнне үк түгел, октябрь тирәләрендә генә китте. Әткәйнең! «Мәскәү читендә ятабыз, бик салкын, ботка белән щи дигән ашларын казаннан штык очы белән генә чокып чыгарабыз»,— дип язган хатларын укулары һаман хәтердә әле.

Ул елны Мәскәү янында булган галәмәтләрне кем генә белми хәзер! Андагы батырларның исемнәре тарихларга керде.

Ә безнең әткәй андый батырлыклар эшләргә өлгерә алмады. Тәүлекләр буе салкын окопта ятып, туңган ботка белән салкын щи суырудан үпкәсе шешеп авылга кайтты ул.

Ярый әле әнкәй бик уңган безнең. Тартылмаган бодай һәм солы пешереп, шуның суын эчетеп эчертү дисеңме. Ишмәннән җыелган әллә нинди чәчәкләр, үләннәр төнәтмәсе белән дәвалау дисеңме, берәр төрле дару барын ишетсә, салкын кышта кырык чакрымдагы район үзәгенә көнендә җәяүләп барып кайту дисеңме — ниләр генә эшләмәде ул әткәйне терелтү өчен.

Әткәй аякка басты. Бераз гына мәктәптә укытып та алды әле. Мәктәпкә йөткерә-йөткерә бара, йөткерә-йөткерә кайта торган иде.

Икенче тапкыр сугышка китәсе көн иртәсендә әткәйнең стена сәгатен дөресләп торуы хәтердә. Минутлар күрсәтә торган угын бора да сәгать сукканын көтә, тагын бора да тагын көтә.

Әткәй өйдәге балаларын күкрәгенә кысып кочты да ни өчендер башын читкә борды. Аннары буяулы тунын чөйдән алып киде. Әткәй өйдән чыгып китеп бераз торгач, сәгать алты тапкыр сукты. Иртәнге алты.

Аннан соң сәгатебез күпме тапкырлар суккандыр, кем санап бетергән! Ә менә ул вакытта әнкәйнең безнең өчен күпме җәфалар күргәнен, күпме кан-яшь түккәнен уйласаң... Үгез җигеп симәнә алырга баргач, Сөндә боз кузгалып, бил тиңентен салкын судан күтәреп капчык ташулары, урак урганда, сутый куабыз дип, эссе кояшта янулары, без туңмасын өчен бәләкәй чана тартып урманга киткәч буранда адашып йөрүләре, сугышка чаклы җыелган запас беткәч, безнең ач тамакны туйдыру өчен сәрдә, балтырган, кычыткан кебек үләннәрне сыек сөт кушылган бәрәңге кәлҗемәсенә болгатып ашатулары — инде хәзер без аларны бик еш искә алмасак та, әткәй сәгатенең секундлары-минутлары ил тарихына теркәп калдырган аларны.

Җиз чылбырлы, җиз тукмаклы, җиз телле сәгатьнең төп-төгәл вакыт күрсәтеп сугулары безне бик кызыксындыра иде. Ике ашау арасындагы ачлыкны онытгырыр өчен кызык эзләп өстәлгә менеп баса идек тә сәгать угын бора башлый идек. Ә ул моңлы тавыш белән «даң-доң», «даң-доң» итеп суга иде. Берсендә сәгать угын кире якка борып суктырып карыйсым килде. Бер борам — сукмый, ике борам — юк. Өчме-дүртме боргач, «дыңк» итеп куйды да йөрүеннән үк туктады бу. Телен дә кузгатам, тукмагыннан да тартып карыйм — йөрми.

Яз көне колхоз басуына сибәргә өй рәтеннән көл җыеп кайтып кергән әнкәй сәгатькә карады да:

— Бәй, биш кенәмени әле? Мин инде сигез тулгандыр дип торам,— диде. Безнең дәшми тору өстенә сәгатьнең «тек-тек» итмәвен күргәч, әйтеп салды:

— Аһ шилмалар, әткәгезнең сәгатен ватќансыз бит!

Күпме генәborгалап, телен кузгатып караса да, җан кермәде сәгатькә. Шул көннән соң әнкәй гел пошаманда йөри башлады. Аның җан-бәгырьләрен кыйган булган икән бу.

— Әткәгезгә генә бер-бер хәл булмаса ярар иде инде,— ди ул әледән-әле, ватык сәгатькә карап.

Көннәрнең берендә әткәйдән «Пруссия җирендә сугышабыз, озак калмады бугай инде»,— дигән хат килгәч кенә әнкәйнең чырае ачылды.

Сугыштан контузия алып кайткан әткәйгә сәгатенең ник йөрмәвен сөйләгәч, әткәй көлеп җибәрде. Аның шулай кычкырып көлүен элек тә ишеткәнем юк иде, соңрак та ишетмәдем бугай.

— Сәгатьне кирегә борып, вакытны кирегә җибәрәсе килгән аның. Сармат бабалары белән көрәшәсе килгән.

Моңа әнкәй дә кушылып көлде.

Сармат бабаларыбызның кем икәнен белми идем әле ул чакта. Мин сигезенчедәме, тугызынчыдамы укыганда сөйләде аны әткәй:

— Сезнең бабагыз — Фазыйл, аның атасы — Солтан, аның атасы — Мәрдән. Әнә шулардан башлана безнең фамилия. Аның атасы Ханнан бабагыз, аның атасы Хаммат бабагыз фамилия белән йөрмәгәннәр. Сарматныкылар дигән нәсел кушаматы белән генә йөргәннәр. Кабилә исеме. Бик борынгы заманда Урта Идел буенда сармат дигән төрки кабиләләр яшәгән. Шулардан килә безнең нәсел. Сармат Сирматка әйләнгән.

— Нишләп «а» хәрефе «и» хәрефенә әйләнгән соң? Укытучылары надан булганмыни? — дип көлдем мин.

Әткәй дәшмәде, әнкәй йодрыгы белән баш түбәмә менеп төште.

Әткәй сәгатьне бер остага биреп төзәттерде. Оста моның өчен эш хакы итеп сугыш буена безнең өйне җылыткан плитә тимерен сорады. Плитә тимере кызганыч булса да, аның каравы сәгатебез яңадан «келт-келт» итеп йөри, «даң-доң» итеп суга башлады.

Әткәебез күптән вафат инде. Гражданнар сугышында Сембер тирәсендә алган ярасы, колхозлашу елларында башына кирпеч белән тондырулары, кырык бернең салкын кышында Мәскәү яныннан үпкәсен шештереп, эчен өшетеп кайтуы, Пруссия җирендә алган авыр контузиясе эзсез калмаган инде, күрәсең. Барысы да бер кеше гомеренә бит аның!

Шулай итеп, сәгатебез әткәй гомеренең секундларын санаудан туктады. Гап-гади минутларны, көннәрне, елларны санауга күчте. Озак санады, озак хезмәт итте ул безгә.

Әле яңарак кына, тагын ни өчендер көйсезләнгән, үзе гомергә мастерскойда эшләмәгән, әмма иске сәгатьләргә җан өрә торган бер оста барын ишеттем дә аңа киттем. Ислам исемле.

Күз алдымда ук шөребен шөрепкә сүтеп ташлады да, сәгатьнең тактадан эшләнгән арткы стенасын, берни булмагандай, миңа тоттырды. Анда зәңгәр карандаш белән «Годъ изготовльнія 1898» дип язылган иде.

Әткәй туганчы ике ел алдан эшләнгән сәгать сатып алган булган икән Солтан бабабыз. Ә теге оста әлеге санның минем өчен гади сан гына булмавын аңлап алган, күрәсең.

Ничә гасырлар элек яшәгән сармат бабаларыбыз мирас итеп калдырган секундларны әткәй үз гомере аша үткәреп безгә тапшырган, бездән соң балаларыбызның, оныкларыбызның гомер секундларына илтеп тоташтырачак урталыктагы бер мизгел иде ул 1898 саны.

Рәхмәт остага! Әткәй сәгате хәзер дә, «тек-тек» итеп, безнең нәсел секундларын саный, егерме беренче гасырга күчә баручы гомер юлларыбызны хәбәр итә! «Даң-доң!»

# Ләйсән

*Шагыйрьне, гадәттә, табигать баласы, диләр. Чыннан да ул — табигать баласы.*

*Ә безнең Ләйсән (Ләйсән Рафикъ кызы Юнысова) — шәһәр баласы. Бу аның шигырьләреннән дә бөркеп тора. Каядыр кысалардан чыгарга теләү, урамнар эзләп йөрергә теләү, урамнардан, подъездлардан моңа кадәр татымаган яңа дөньяны ачарга теләү. Табигатькәге ихласлылык каядыр артта калгандыр сыман. Бу беренче карашка гына шулай. Әти-әнисенә табигатьтән бирелгән шигъри көч аңарда шәһәр холкы белән көрәшә. Ул аны әле үзе дә аңлап бетерми. Бу әле — яшьлек. Яшь шагыйрә үзе әйткәнчә:*

*Яшьлектән узмыш юк,*
*узмыш юк!*

*Әнә шул сикәлтәле юлдан узгач, ул табигатьтә бирелгән шигъри агымга әйләнеп кайтачак. Сезгә тәкъдим ителгән шигырьләр шул хакта сөйли.*

*Бу кечкенә генә кереш сүземдә шуны да әйтәсем килә: халкыбызның шигъри дөньясында якты йолдыз булып калган Саҗидә Сөләйманова «шагыйрә» дигән төшенчәне яратмый иде.*

*Ул үзен шагыйрь санады. Һәм үзенең шигъри дөньясында шул дәрәҗәгә иреште дә. Ләйсәнгә дә шуны телим.*

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ**

## Бүләк

Җилләргә ияреп,
Котырып, ярсып,
Хәсрәтнең китте
Очып яртысы.

Сайлап чишмәнең
Сафын, көмешен,
Суларга акты
Ярты өлеше.

Мин әнә шулай
Бушандым инде.—
Алтын наз булып,
Калган бушлыкка
Кояшым иңде.

## Мизгел өчен өзелсәм дә...

Өзәм сезне, ромашкалар,—
Өзелмәсен үзәгегез.
«Кем өчен?»,— дип сорашмагыз —
Бу бүлмәнең бизәге сез.

Сезнең моңсу нәфислектән
Ялгыз йөрәк бизә алмый.
Ник бер генә күңелне дә
Минем сурәт бизи алмый?

Бизәр идем, түзәр идем
Үзәкләрем өзелсә дә.
Чәчәк булып үсәр идем
Мизгел өчен өзелсәм дә...

## Сары моң

Сагынамын...
Сагынамын...
Сары моңга манмамын...
Зарларыма уралып,
Сарыларга мана моң.

Сагынамын...
Сагынуларым
Сагышлардан сары ла...
Соралмаган сорауларга
Сап-сары моң сарыла.

## Пәрдәсез

Минем янда ни калган соң:
Ни күреп, әрсез генә
Маңгай терәп каплангансыз
Күңелем тәрәзенә?!

Әллә ниләр эзләмәгез —
Күңелем тулы яралар.
...Тәрәзәләре пәрдәле —
Һәр күңелдә бар алар.

## Ай ял итә болытта...

...Ай болытта ял итә.
Каеннарны тал итә,
Назлы җилне кол итә...
Ай ял итә болытта.

Яңгырларны кар итә,
Ялгызларны пар итә,

Дөньяларны тар итә,
Өзелмәслек зар итә...

Айның нуры наз икән,
Җиргә — моңлы саз икән,
Көмеш сагышы белән
Төннәр өчен яз икән.
...Ә Җиргә ул аз икән.

*

Яшел үлән бүләк итәм —
Кем генә алыр икән?
Күңелемдә урын табып
Кем генә калыр икән?

Яшел үлән матур була
Яше кипмәгән чакта.

Янып бер сөясе килә
Яшьлек китмәгән чакта...

Яшел үлән бүләк итәм
Чәчәк кебек чагымда...
Йөрәгемә чыклар төште,
Чалгыда эш... чалгыда.

*

Җилләрдән мин тормыйм качып,
Тәрәзәм минем ачык.
Я, яшен, суксаң сук —
Язмыштан узмыш юк...
Узмыш юк...

Тормыштан да тормыйм качып —
Күңелем минем ачык.
Я, кайгы, суксаң сук —
Яшьлектән узмыш юк...
Узмыш юк.

Миргазиян Юныс

# ТЕЛСЕЗЛӘНҮ: ТАМЫРЫ ҺӘМ ҖИМЕШЛӘРЕ

Чаллы язучылары оешмасында җыелыш. Алып баручысы — Рахмай Хисматуллин. Җыентык чыгару турында сөйләшәләр. Катнашучыларның тугызы — татар, өчесе — рус телле. Рус телендә язучылар арасында татарлар да бар. Көн тәртибенең икенчесенә күчкәч, Рахмай әйтте:

— Хәзер без җыелышны татарча алып барабыз.

Рус телле язучылар матур гына урыннарыннан тордылар да чыгып киттеләр. Юк, протест йөзеннән түгел. Гадәти хәл иде бу. Ара бозылмады.

— Нишлисез сез, егетләр? Әгәр киләсе җыелышта русча сөйләшә башлагач, татар телле язучылар чыгып китсә? Телләрнең бит хокуклары тигез. Бу соң татар телен кимсетү түгелме? — дип сорарга авызымны ачкан идем, өлгерә алмый калдым. Соравымны оешманың җаваплы секретаре Рахмай Хисматуллинга бирергә туры килде.

— Бер дә хафаланмагыз,— диде Рахмай.— Без инде мондый хәлгә күнеккән. Аларга рәнҗемибез. Табигый хәл. Шунысын да аңларга кирәк: әгәр җыелыш русча барганда, без ташлап чыгып китсәк, безгә милләтчелек мөһере сугарлар иде. Аларның бездән аерылып китүләре — интернационалистлык санала...

Мин безнең Татарстандагы интернационалистлык белән таныш түгел диярлек. Европадагы интернациональ мөнәсәбәтләр бөтенләй башка. Франция мәктәпләрендә, гадәттә, инглиз яисә алман телен өйрәнәләр. Инглизләрдә, киресенчә, йә француз, йә итальян телен үзләштерәләр. Европаның югары белем алган кешесе ике-өч, хәтта дүрт телдә рәхәтләнеп сөйләшеп йөри ала.

Интернационаллык — милләтләр арасындагы мөнәсәбәт дигән сүз. Интернационалист булу өчен иң беренче шарт — үз телеңнән тыш башка бер милләтнең телен белү. Ни өчен алай? Чөнки аралашу бары тик тел аркылы гына эшкә ашырыла ала, шунлыктан, үзен интернационалист санаган кеше, ким дигәндә, ике тел белергә тиеш. Европа интернационалистлыгы менә шушы кагыйдә нигезендә исбат ителә.

Интернационаллыкны аңлау мәсьәләсен җиңеләйтү өчен милләтләрне елга ярлары итеп күз алдына китерик. Ярларны үзара нинди юл белән тоташтырып була? Билгеле, күпер. Ярларның ике ягыннан да күпер сала башладылар, ди. Елга уртасында күпер тоташты — интернационаллык барлыкка килде. Әйтик, елганың бер як ярыннан күпернең яртысы өлешен салдылар, икенче як яр күпер салудан баш тартты. Бу очракта элемтә һәм аралашу мөмкинме соң? Ә бит безне шушы көнгә кадәр күперне бары тик бер яктан, бары тик безнең яктан гына салырга өйрәтеп киләләр...

Туган ягыма соңгы тапкыр кайтуымда мин Баулыда, Чаллыда һәм Түбән Камада булдым. Шул өч шәһәрнең күңелемә иң хуш килгәне — Түбән Кама. Бу шәһәрдә халкымның милли йөзе күзгә ныграк чалына. Урамнарында рәхәтләнеп татарча сөйләшеп йөриләр. һәм, ялгышсам, төзәтерләр, бу шәһәрдә яшәүчеләрнең күңелендә башка төбәкләрдә инде бөтенләй юкка чыгып килгән милли горурлыкны тояргa була. Бу куанычлы хәлнең каян туганын ачыклау өчен, билгеле, фәнни тикшерү уздырырга кирәк булыр иде. Мин сәбәпләрнең берсен генә әйтә алам — шәһәрдә сигез ел буе «Җидеган чишмә» оешмасының эшләп килүе. Шәһәр башлыкларының, андагы завод-фабрика җитәкчеләренең бу ан-

самбльгә мәрхәмәтле булулары һәм, ниһаять, Түбән Камада Рахмай Хисматуллин, Азат Зыятдинов бөеклегендәге фидакяр җаннар яшәве.

Татарстанымның җитәкчеләренә, интеллигенция катламына, зыялыларга мөрәҗәгать итеп, шуны әйтәсем килә: респуб икаהың башка шәһәрләрендә һәм авылларында да Түбән Камадагы шикелле чишмәләр чыга башласын иде! Үз эшемдә мин утыз елга якын коллективларны берләштерү, аларны бердәм, тату яшәтү өчен тәрбия алып бардым. Кешеләр коллективын боерык белән дә, үгетләп тә, камчылап та чын-чыннан берләштереп булмый. Культ һәм торгынлык елларындагы ысулда берләшкән коллективлар, тышкы яктан гына укмаша да, иң беренче сынау вакытында ук таралып, таркалып төшә. Адәм баласын нәкъ менә Түбән Камада кулланган чаралар — бергәләп халык моңнарын тыңлау, серләшү, бәхәсләшү, бергәләшеп «Туган тел»не җырлау берләштерә. Мондый берләшү рухи мәҗлес, бергәлек гыйбадәте вакытында барлыкка килә, шунлыктан күңелгә — күңел, йөрәккә — йөрәк, хискә хис тоташа.

Түбән Камада йөргәндә туган телемдә сөйләшүгә шулкадәр күнегеп киткәнмен, бер кибеткә кергәч, сатучыга татарча дәшкәнмен. Ул мине ишетмәде дә, хәтта минем якка борылып та карамады. Күңелемә хуш килгән калада мондый кешеләр барлыгына ышанасым килмәде. Борылып чыгып киттем. Бер тын йөреп кердем дә шул ук сатучы хатынга инглизчә дәштем. Сатучының кабалануын күрсәгез иде! Бөтерелеп йөри. Бүлек мөдирен җилтерәтеп алып килде: «Баш өсте! Нәрсә телисез, мистер? Рәхим итегез!..»

— Теләгән нәрсәм шул,— дим итагатьле апаларга.— Татарча сөйләшәсем килә.

Елмаюлар сүнде, йөзләренә шундук кыргый фанатиклардагы кырыслык бәреп чыкты.

Инглизчә дәшүем шаяру да, аны хәйран калдырырга ниятләгән алым да түгел иде. Фәнни сынамыш иде бу. Бу хатын, үз теленнән тыш, башка барлык телләргә карата да шулай дорфамы, әллә Татарстандагы җирле халык теленә генә шундый шапшак битарафлык белән карыймы икән, дип кызыксынуны ачыклау өчен кулландым мин инглизчәне. Һәм ачыкладым. Тарихның фаҗигале елларында ата-бабаларымның каннары коелган, туфрагында аларның сөякләре яткан җирдә туган телебез ят телгә әйләнеп киткән. Аны ихтирам итми башлаганнар. Аның абруе югалган. Кем гаепле? Сату эшендә нервлары бозылып беткән мескен хатыннармы, без үзебезме? Без үзебез. Саклый алмадык телебезне. Кадерен белмәдек. Аның бөеклеген аңлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмадык. Милләткә карата булган ихтирамның телдә икәнлеген әйтмәделәр безгә галимнәребез. Адәм баласының кешелек тамгасы телдә икәнлеген дә аңлатучы булмады.

Америкага килгән мигрантка иң беренче итеп инглиз телен өйрәнү шарты куела. Аннан соң бу илнең законнарын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә тиешсең. Әгәр син шушы шартларны үтәмәсәң, бигайбә, сау бул. Һәр илдә шулай. Италиягә килгән кеше — итальян, Франциягә килүче француз телен өйрәнә. Японнядә японча сөйләшеп йөриләр. Безнең, территориясе һәм халык саны буенча, урта бер Европа иле зурлыгындагы республикабызда исә туган телебезгә якын да килмәгән, бөтенләй башка, һинд-Европа семьясына кергән телдә сөйләшәләр һәм бездән дә шул телдә сөйләшүне таләп итәләр. Гомумән, тарихта мондый гадәтнең булганы юк иде. Кайдан килеп чыкты икән бу? Нинди шартлар тудырды икән бу парадоксны?

Туган телне саклау кешелек экологиясен саклау дәрәҗәсендә тора бүгенге көндә. Тел — кеше рухының формасы, эчтәлеге һәм аның яшәү шарты. Тел — рухи экология. Туган телдә мең еллар буенча гореф-гадәтләр хәзинәсенең сөземтәсе, әдәп һәм әхлак кануннары, мең еллар туктаусыз язылып торган тарихның хакыйкый эчтәлеге. Тел тудырган топонимнар аша ата-бабаларыбыз моннан мең ел элек яшәгән җирләрнең табигатен, хәтта географиясен реконструкцияләп өйрәнергә була. Иван Грозный чорында һәм аннан соңгы гасырлардагы катаклизмнар иң чыдам, иң түзем генотип вәкилләрен генә исән калдырган. Минем милләтем менә шундый шартларда барлыкка килгән һәм аның ыругларыдан милләткә әверелү юлы туган телебездә сурәтләнеп калган. Бүгенге көндә без шул телне югалту куркынычы алдына килеп басканбыз.

Тел югалту фаҗигасенең нәрсә икәнлеген аңламаган кешеләр, бу нигә безне куркытырга тели, без бит бөтенләй телсез калмыйбыз, киресенчә, Советлар Союзының теләсә нинди төбәгендә теләсә кем аңлый торган җиңел һәм кулай тел вәкилләренә әйләнеп киләбез, дип юанулары мөмкин. Без, татарлар, русчага кайда һәм нинди шартларда өйрәнәбез? Уку йортларында, шәһәр тормышында, армия хезмәтендә, партия һәм администрация эшендә. Рус гаиләсендә туып, русның бишек җырларын, әкиятләрен тыңлап, рус фольклоры тәэсирендә үсканнәрнең теле бөтенләй үзгә. Ул — чын халык теле. Толстой, Достоевский,

Чехов, Лесков, Андрей Платонов теле — халык теленең байлыгын туплаган әдәби сөйләм безнең арабызда бөтенләй очрамый диярлек. Без үзләштергән тел — административ-бюрократлар теле, культ чорында безне камчылап эшләткән, торгынлык чорында ялганларга, урлашырга, аракы эчәргә, зина кылып йөрергә өйрәткән тел. Бу телдә рухны җанландырып торган шифалы көч, хисләр сизгерлеген сакларлык моңлы яңгыраш һәм әхлакны бөтенәйтүче ашламалар бармы соң? Административ-бюрократлар телендә каян булсын ди?! Шушы хәлне аңласаң, соңгы елларда кеше үтерү, йорт басу, гаилә таркалу статистикасының кинәт үсеп китүенә төшену бер дә катлаулы эш түгел.

Японнарның электроника, машиналар ясау, фән, техника буенча беренче урынга күтәрелүләре турында сөйләп торасы юктыр. Хикмәт нәрсәдә? Телне саклау буенча, башка халыклар арасында, Япония беренче урында тора. Ярлыландырылган телгә яңалык кертүе кыен икән ул, японнарга исә һәр яңалык үзеннән-үзе агылып тора.

Тел саклауга, тел байлыкларын халыкка җиткерү өчен тотылган акча Япония дәүләтенең бюджетында икенче урында тора. Кешене хезмәт сөяргә, һөнәргә, эшне җиренә җиткереп башкарырга өйрәтү туган телдә төрле әйтемнәр, табышмаклар рәвешендә яши. Аларның тәэсире махсус кулланмалар, инструкцияләр белән чагыштырганда көчлерәк тә икән. Туган телдә кешене тәртипкә, җыйнаклыкка, тугрылыкка өйрәтү кануннары да яшәп килә икән. Бүгенге һәм борынгы катламнарны эченә сыйдырган киң диапазонлы бай телне өйрәнү процессы үзе дә зур бер белем икән һәм туган телне үзләштерү вакытында кешенең фикер йөртү сәләте көчәя, эрудициясе киңәя һәм теләсә нинди фәнне тирәнтен аңлау мөмкинлеге ачыла икән. Японнар шушы хакыйкатькә башкалардан алда төшенгән, телне кадерләп, саклауга, аны баетырга киткән чыгымның керем булып кире әйләнеп кайтуын аңлаган. Японниядә ясалган әйберләрнең сыйфаты, эстетик камиллеге безне хәйран калдыра. Шулай сокланып карап торганда без Япониянең техника һәм производство буенча беренче урынга чыгуына туган тел ярдәм итүен күз алдына китерә алмыйбыз, чөнки безгә бу турыда аңлатканнары юк.

Татар телендә мәктәпләр ачу, балалар бакчасында туган телдә тәрбия бирү турында шактый яздык шикелле. Дөресен әйткәндә, бу турыда никадәр сөйләсәң дә, күп булмас. Ата-ананың газиз балаларын рус мәктәбенә бирә башлавы күп гасырлар буе татар телен бетерү юлында кулланылган чараларның бер нәтиҗәсе генә. Гадәттә, нәтиҗәгә каршы көрәш сирәк очракта уңышка ирештерә. Без, татар телен аякка бастыру өчен, аның һәлакәт хәленә җитүенең сәбәпләрен ачыкларга, шулардан котылдыру юлында эшләргә тиешбез.

Татарларга, аларның диннәренә, гореф-гадәтләренә каршы пропаганда Сергий Радонежский нотыкларыннан башлана. Бүгенге русофилларның аллалары саналган Изге Сергий үзенең ялкынлы талантын рус князьләрен берләштерүгә генә түгел, «басурманнар»ны кырып, юк итүгә дә юнәлткән. Казан татарларына каршы махсус коткы Иван Пересветов әсәрләрендә шулкадәр кискенләнгән ки, ул хәтта болай дип яза: «Андагы җәннәтнеке шикелле җирләр, татарлар үзләре безгә дус булган очракта да, басып алынырга тиеш». Иван Пересветов язмаларында кешелек дөньясының иң әшәке дошманы итеп татар күрсәтелә. Аның токымы, теле, гореф-гадәтләре юкка чыгарылырга, бетерелергә тиеш, янәсе. Бу документның төп максаты шул.

Казан каласы 1552 елның 2 октябрендә басып алына. Башкалабызның урамнарында кан елга булып ага. Бу вәхшәтне онытырга хакыбыз юк безнең. Иван Грозный вандалларының иң беренче эше шуннан гыйбарәт: татарларның байлыкларын талау белән бергә, ничә гасырлар тупланып килгән елъязмаларны, архивларны яндыру коточкыч вәхшилек белән башкарыла. Казан ханлыгындагы 483 мәчет белән 483 мәдрәсә көлгә әйләндерелә. Татар аристократиясенең күбесе Иван Грозный ягына күчә, татар теленең зур бер өлешенең юкка чыгуын аңлатып тору кирәк түгелдер дип уйлыйм. Йөз егерме биш елга сузылган азатлык көрәшендә татар халкының өчтән бер өлеше үтерелә, калганнары төрле якка тарала. Бу хәл, билгеле, туган телгә тәэсир итми калмый. Бөек рус тарихчысы Михаил Георгиевич Худяковның фәнни эшләре белән таныш кеше белә: Иван Грозный Казанны алырга юнәлгән чакта татарлар һәм руслар сан ягыннан тигез була. Ул чорда, билгеле, халык санын язу булмаган. Тарихчыларның кайберләре бу ике халыкның саны ун миллион чамасы булган дип бара, икенчеләре алты миллион белән чикләнә. Эш анда түгел. Бүгенге көндә без һаман шул чама исәпләнәбез. Казан ханлыгын җимерүче халыкның саны исә бүгенге көндә йөз кырык миллионга җитеп килә. Территория өчен башланган көрәш тел өлкәсенә дә күчми калмый. Шуларның кайсы җиңеп чыгарга тиеш?

Берничә гасырга сузылган чукындыру процессы да, татарларның җырларен килмешәк алпавытларга, патша куштаннарына кисеп биреп, халыкны туган җиреннән куу да теленең үсүенә, ныгуына ярдәм итми, билгеле. Тик хәттә шушындый чаралар да татар телен җиңә алмый. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Дин яши. Дин халыкны эчтән, рухи яктан, шәхеснең әхлагы, җаны аша берләштерә, шул диндәге башка халыкларга тоташтыра. Кыскасы, унтугызынчы гасырның азагында, егерменче гасырның башында җанланып киткән татар Ренессансына тикле гореф-гадәтләрне, халык иҗатын, телне, милли горурлык хисен дин саклап торган. Сүз уңаенда әйтеп китик: бездә халык иҗатының гаҗәп бай бер тармагы — дин каналы аша сулыш алып, татар халкының рухи дөньясына туктаусыз тәэсир итеп торган мөнәҗәтләр бөтенләй өйрәнелмәгән әле.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, туктаусыз кысылган, мәйданы һаман тарая килгән татар теленә Яңару чорында әзме-күпме үсү мөмкинлеге туа. 1905 ел революциясеннән соң газета-журналларның ишәеп китүе, Кол Гали, Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый шикелле шәхесләрнең иҗатларына игътибар уяну, Шиһабетдин Мәрҗани кебек гигантлар калдырган хезмәтләрне аңлау һәм пропагандалый башлау дәрәҗәсенә күтәрелү бу чорның чын-чынлап татар дөньясында Ренессанс чоры барлыкка килүен күрсәтә. Әгәр егерменче гасыр башында җанланган хәрәкәт өзлексез дәвам итсә, татар теле, тулысынча үзенең уналтынчы гасырга кадәрге хәленә кайта алмаса да, яшәвен, үсешен дәвам итәр иде әле. Утызынчы елларда кузгалган Сталин ерткычлыклары Иван Грозныйның канлы кулы эшли алмаган афәтләрне китерде.

Шиһабетдин Мәрҗани, Тукай һәм Риза Фәхретдинев чорларында татар теле бик зур уңышлыкларга ирешә, шуңа карамастан безнең туган телебез байлык һәм диапазон киңлеге ягыннан барыбер XVI гасырдагы дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Мәрҗани чоры теленең фикер йөртү, мәгърифәт тармагын үстерсә, Тукай һәм Дәрдмәнд чоры әдәби телне баета. Дипломатия, чит илләр белән элемтә тоту юкка чыгарылган. Дәүләт, идарә итү теле — руслар кулында. Телнең армия, сугыш гыйлемендә кулланыла торган тармагы да — аларда. Хәтта фән, сәнгать, культура өлкәсендә кулланыла торган лексикага да, татар телен үткәрмәс өчен, киртәлекләр куелган. Ярый әле ул чорда дин исән булган. Туган телебез дин өлкәсеннән философик терминнарны, логика алымнарын, абстракт фикер йөртү механизмнарын туктаусыз үзләштереп торган.

Сталинның беренче һөҗүме юкка гына Солтангалиевкә каршы юнәлтелмәгән. Революция чорында да, егерменче елларда да ислам динен тотучы милләтләр һәм, гомуман Шәрыкта яшәүче халыкларның алдынгы сафларында татарлар бара. Урта Азиядәге революцияне оештыруда татарларның өлешен күптән өйрәнергә вакыт. Үзәктәге Милләтләр халык комиссариатында, Мөселман комитетында, Мәскәүдәге милли матбугатта дисеңме, кая гына карама — татар зыялылары. ЦИК татар телендә газета чыгара. «Исәбәт» авторы, указын югалткан мулла Чыгтай, Идел буе, Урта Азия, Себер һәм Кавказга тарала торган «Фән һәм дин» журналын бастыра. Донбасста, Каспий диңгезе буенда, Себердә, Урта Азиядә татарларның культура учаклары оеша.

Солтангалиевне эзәрлекләү, асылда, татарларны, аларның милли тойгыларын, горурлыкларын эзәрлекләү иде. Һәм бу хәрәкәт, беренче чиратта, талантларны юкка чыгаруга юнәлтелгән. Төрмәгә эләккән, атып үтерелгән язучыларны, артистларны, сәнгать һәм культура әһелләрен генә алып карагыз. Һәр талант иясе тапталган, сытылган, тар-мар ителгән. Шушы процесс, күпмедер йомшартылып, торгынлык чоры аша безнең көнгә кадәр килеп җитте. Халыкны юкка чыгаруның иң уңышлы тактикасы — аның талантларын кырып ташлау. Тоталитар диктаторның, административ-бюрократ түрәнең иң куркыныч дошманы — талант. Талант бит ул иман сизгерлеге һәм вөҗдан егәрлеге. Культ һәм торгынлык чорында моны аңлап эш иткәннәр.

Татар телен юкка чыгару өчен ташланган бомбаларның иң көчлесе, минемчә, Кырым татарларына, Ватан сугышында каһарманнарча көрәшкән, тулы бер халыкка сатлык җан мөһере сугып, аларны туган туфракларыннан сөрү. Мин — ул трагедиянең шаһиты.

Курку һәр очракта телгә зыян китерә. Курыкканнан соң адәм баласы тотлыгып сөйләшә башлый. Кайвакыт көчле тетрәнү кешене мәңге тотлыгып сөйләшү зәгыйфьлегенә дучар итә. Кырым татарларын туган туфракларыннан куғандагы бер хәлгә тукталасы килә.

Геноцид белән җитәкчелек итүче Богдан Кобулов 1944 елның 19 июлендә Л. П. Берияга рапорт бирә: «Кырым татарлардан азат». Берия шул ук рапортны Сталинга җиткерә. Шушы операцияне уңышлы үткәргәннәре өчен меңләгән кешегә орден өләшәләр. «Җиңү» бәйрәменә багышланган банкет барганда Кобуловка әйтәләр: «Арабат атавындагы татар

авылларын чистартырга оныткамбыз». Сивашны диңгездән каплап торган Арабат атавында балыкчылар һәм тоз чыгаручылар яшәгән булган. Ирләр, билгеле, фронтта кан коя. Күбесе — хатын-кыз, бала-чага, картлар.

Кобулов боера: «Ике сәгатьтән Арабатта бер татар заты да калмаска тиеш. Бер генә татар заты исән калса да, башыгыз белән җавап бирәчәксез». Берия фашистына ике сәгатьтә йөз километрга диярлек сузылган утраудан татарларны җыеп өлгереп булмавын аңлаталар һәм Сталинның ялчысы Арабатны чистартырга бер тәүлек вакыт бирә.

Геническ портыннан бер иске баржаны буксирга тагып алып чыгалар. Утраудагы татарларны җыеп шул баржага төяиләр. Баржаны Азов диңгезенең тирән җиренә илтеп, кингстонын (корабльнең су асты өлешендәге уем капкачы) ачалар, кеше белән тулы трюмны чөйләп биклиләр. Баржа безнең кан кардәшләребезне су астына алып китә. Буксирга төялгән җан кыючылар, автомат тотып, баржа баткан җирне берничә сәгать саклап торалар. Тарих бит бу. Шул ук — безнең канга баткан, тапталган, сытылган тарих.

Аларны геноцидка дучар иткәннән соң, казан татарларының күпчелеге: «Кырым татарлары — бөтенләй башка халык, безнең алар белән бернинди кан кардәшлегебез, уртаклыгыбыз юк»,— дип, маңгайларын җиргә орып, туганлыктан ваз кичәргә тотындылар. Кабахәтлек, сатлык җанлык, җаһиллек иде бу. Соң бит безнең арада Иван Грозный чорыннан ук туктаусыз эшкә ашырылып килгән колониаль сәясәтнең, халыкларны бүлгәләп, кисәкләп юкка чыгару тактикасын аңлаучылар булмый калмагандыр? Эш менә нәрсәдә: шул ук канлы Иван чорыннан көндәлек тормышта кулланылып килгән бер феномен, кырым татарларын сөргәннән соң, тагын да көчәебрәк китте. Колониаль шартларда төп түреләр җирле халыкның милләтен сатарга әзер торган вәкилләрен идарәгә утыртып, аларга мул, рәхәт яшәү шартлары булдыра башлады. Әкренләп, культура, мәгърифәт, фән өлкәләренә дә шундыйрак кешеләр килә торды. Шул рәвешле халык мәнфәгатен сату, милләткә хыянәт итү отышлы бер бизнеска әйләнеп китә. Тора-бара бу эшнең әхлакый шапшаклыгы, кабахәтлеге дә күзгә бәрелми, гадәти бер җайланыш булып тоела. Безне кырым татарларыннан читләштереп, аларга таш аттыру гадәте дә шушындый кешеләр аша таралды.

Татарлар — тырыш һәм эшчән халык. Алар ышанычлы. Юкка гына рус патшаларын саклаучы гвардия татарлардан оештырылмаган бит. Башкалада метро казый башлагач, бу авыр һәм җаваплы эшкә дә күбрәк татарларны сайлап алалар. Метрополитен төзүчеләрнең беренче газеталары татар телендә чыга. Безнең халыкның тырышлыгы, аның гасырларга сузылган изелүдән, кимсетелүдән котылырга тырышуы бер зыян да эшләп ташлый. Милләтчелеккә каршы көрәш башлангач, рәсми эш теле итеп рус теле таныла. Җитәкчелеккә күтәрелү һәм җәмгыятьтәге абруйлырак урынга элагү өчен рус телен үзләштерү зарури шартка әйләнә.

Минем халкымда «укып кеше булу» өмете канга баткан иң каһәрле елларда да сүнмичә саклана алган. Рус телен без, халкыбызны белемгә, культурага ирештергән тел, дип игълан иттек. Яңарту чорының күзаллавына, яңача фикер йөртүгә ирешкәч, аңладык: «белем» дип аталган нәрсә сталинизм тәгълиматының бер инструкциясе, «культура» дип аталганы тоталитар ритуалларның бер шаблоны гына икән. Бүгенге көндә безгә ул «белем» һәм «культура» трафаретларыннан ашыгыч рәвештә котылырга кирәк.

Татарларда элек-электән һәм бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң Европа, Шәрык илләренең уку йортларында белем алу табигый хәл санала иде. Диктатураның ата-баба гадәтләрен юкка чыгаруы безнең өчен коточкыч югалту булды.

Безнең гаиләдә белем һәм дин, белемле кеше һәм иманлы кеше синоним санала иде. Изелүдән, фәкыйрьлектән, гасырлар буе халкымның җелеген суырган кытлыктан котылу һәр татар гаиләсенең якты өмете иде. Әле дә хәтеремдә, утызынчы елларда безнең Исергәптә җәйге кичләрдә капка төбенә чыгып «ләчтит» саталар. Әйе, диләр аксакаллар, хәзер инде татарча белән ындыр артыннан ары китеп булмый. Урысча үрәнергә кирәк... Татарча белемнең ничә классы русча белемнең ничә классына тиң икәнлеге турында бәхәс башлана. Татарчаның ун классы русчаның җиде классы чамасы инде ул, диган карарга киләләр. Чөнки тормыш тәҗрибәсе нәкъ шуны күрсәтә. Әлләни сәләте булмаган, тырышлыгы да ташка үлчим Габделгани малае, русча шома сукалавы аркасында, район башкарма комитетыннан өлкә күләмендәге эшкә күтәрелгән. Ә мескен Хәйрулланың Әбугалисинага тиң газиз улы, русча белмәгәнгә күрә, һаман баткак буразнада сабан

артыннан сөйрәлеп йөри. Чоры нинди иде бит аның! Рус галиме Отто Юльевич Шмидт Котыпны җиңгән, Чкалов, Төньяк полюс аша очып, АКШка барып җиткән. Папанин, Ширшов, Кренкель, Федоров — барысы да русча белем алган кешеләр, бозга утырып, Котып диңгезен аркылыга-буйга кичеп чыкканнар. Татарча белем алган сөлек кебек безнең балалар, борыннарыннан кан киткәнче тырышсалар да, клуб мөдире постыннан уздыра алмый. Әтиләр, бу чарасызлыкка аптырап, газиз балаларын рус мәктәбенә илтә башлады. Бөтенләй башка телдә укып «кеше булган», дөнья күләмендә данлыклы вулконолог Һарун Таҗиев, галим, әдип-фантаст Айзек Әҗимов, дөнья балеты сәнгатен яңа баскычка күтәргән Ковент-Гарден король балетының балетмейстеры Рудольф Нуриевлар турында татар халкы әле шушы көнгә кадәр хәбәрдар түгел диярлек.

Татар теленең тамырына тагын бер кат балта чабуга Татарстанда нефть чыгара башлау сәбәп булды. Бу чорга кадәр татар теленә җитәкчеләр генә төкерә иде әле. Бригадирлыкка ирешүчеләр русча сүгенә башлый, председательлеккә ирешкәннәр яртылаш русча сөйләшә, район комитетына кадәр күтәрелгән татарлар инде татар телендә сөйләшүне оят саный башлый иде. Шушы агымга нефть чыгаручылар кушылды. Чөнки бу эшне бары тик русча сөйләшеп эшләгәндә генә башкарып була иде. Барлык инструкцияләр, кулланмалар,терминнар русча язылган. КамАЗ, Түбән Кама химия комбинаты шулай ук татар телен корытуга байтак өлеш кертте. Идел һәм Чулман елгаларына салынган гидроэлектростанцияләр безнең ата-бабаларыбызның сөякләрен генә түгел, аларның кабер ташларын, җир астында яткан археологик, топонимик хәзинәләрне дә суга тончыктырдылар. Кайбер язучыларыбыз шушы төзелешләргә багышланган сандык зурлыгы романнарында варварлыкка мәдхия җырлады.

Мин үзем — Баулы тирәсендә нефть чыгара башлагач туган хәлләрнең шаһиты. Нефтьчеләр килгәнче, безнең Исергәп инешенә коя торган Шәмәй елгасында «патша балыгы» керкә яши иде. Безнең инешкә, Ык елгасына бер тапкыр җәтмә белән кереп чыксаң, гаиләңә бер тәүлек буе ашарлык балык тота идең. Авыл тирәсендә суер, ас, сусар, ятчә шикелле җәнлекләрнең исәбе-хисабы юк иде әле ул чакта. Урманнарда җиләк-җимеш үсә, берничә гектарга җәелгән чиялекләр, карлыган һәм балан, шомырт һәм бөрлегән куаклары каплаган әрәмәлекләр. Бәлки, дала белән урман зонасы арасында булганлыктандыр, мондагы табигать чиктән тыш нәзберек икән.

Баулы районы җиреннән нефть тапкач, монда үзгә халык җыела башлады. «Янгын» исемле повестенда андыйларны Валентин Распутин «архаровлар» дип атый. Чыннан да, аларның кайбере Африкага барып, сафари ясап йөрүчеләрне хәтерләтә иде. Бер җирдә дә тамыр җибәрмичә, пәри үләне шикелле, акча җиле кайсы якка иссә, шунда тәгәри торган бәндәләр иде алар. Табигатьне дә Аллаһы тәгалә, әйтерсең, бары тик аларның күңелләрен ачу өчен генә яраткан. Безнең җиргә урнашу белән алар балыкка, ауга, табигать кочагында ял итәргә йөри башлады. Балыкны динамит белән шартлатып кына тоталар. Елгадан балыкны җыеп кына өлгер. Ауга, «бобик»ка утырып, караңгыда чыгалар. Машинаның утын яндыралар, ялан бетереп куян куалар, тәгәрмәч белән таптаталар. Кырыгынчы елларның азагында иде булса кирәк, шулай, «ду» китереп яланнарда җәнлек куып йөргәндә безнең Исергәп авылының Газнан абзый кызы Фәүзияне атып, канга батырып киттеләр. Газнан абзый гаиләсе Таллык дигән җирдә хутор рәвешендә салынган йортта яши иде. Кызы Фәүзия икенче сменада укый. Мәктәптән кайтып килгән баланы, җәнлеккә санап, атканнар да, абайлагач, кар өстендә канга батып яткан килеш, калдырып качканнар.

Нефть манараларын сөйрәгәндә тапталган болыннар, киселгән урманнар һәм нефтькә буялган куаклыкларның күбесе, терелә алмыйча, һәлак булды. Соңгы кайтуымда мәктәп балаларыннан сорыйм. Аларның күбесе кеш, суар, суер, ятчә шикелле җәнлекләрнең нәрсә икәнлеген бөтенләй белми. Андый исемнәр телебездән төшеп калып югалган. Ногыт чикләвегенең нәрсә икәнлеген дә белүче юк. Кытлык елларда халкымны яман авырулардан коткарып калган какы, юа, җенлекәй кебек шифалы үләннәрне танучы да шактый аз. Әгәр экологик катастрофа шушы темп белән барса, безнең оныкларыбыз кибеттә сатыла торган бәрхет аюдан башка җәнлекләрне белми башлаячаклар. Тел белән табигать, зират ягына таба, янәшә атлап баралар.

Баулыдагы 41 урамның нибары алтысына гына татар исеме кушканнар, калганнарында — бу җиргә килеп урнашкан халыкның исеме. Авыл исемнәре югалып бара. Авылны колхоз исеме белән атау гадәткә кереп киткән. Хәтта тулы район исеме юкка чыгуын да очратырга була. Мәскәү шифаханәсендә ятучы бер татар малае үзенең туган ягын миңа: «Дрожжаной»,— дип аңлата...

Саян-Шушенск ГЭСын төзегәннән соң безнең ерак төрки бабаларыбызның ташка язган истәлекләре, орхон-енисей руник язмалары юкка чыкты. Уссури үзәнлекләреннән алып Кара диңгез, Днепр елгасына кадәр җир өстен каплаган курганнарга күмелгән кан кардәшләребез сөннәр, бәҗәнәкләр, кыпчаклар калдырган мирасларны хәзер шәм яндырып эзләсәң дә табарлык түгел. Шунлыктан, революциягә кадәр татарлар шыр надан булган, аларны социалистик революция генә укырга-язарга өйрәтте, дип, курыкмыйча әйтергә була.

Безнең туган телебезне юкка чыгаруда нинди көчләр роль уйнавын да күрсәтү кирәк кебек. Минемчә, менә болар:

— Мөстәкыйльлекне югалткандагы катаклизмнар, җимергеч борылышлар;

— Ялган, ясалма, кара тарих;

— Сталинның милли сәясәте аркасында өченче сортлы милләткә әйләнеп, милли хокукны югалту;

— Туган җиребезгә туктаусыз куып, китерелеп торган миграция ялары һәм, шуңа параллель төстә, төп халыкны читкә җибәрү хәрәкәте;

— Табигатьне һәм телне катастрофага җиткергән экология кризисы;

— Идарә эшенә туган теленә дошман кешеләрне сайлап утыртуларның яман нәтиҗәсен дә онытырга ярамый. Бу процесс 1938 елны Сталин һәм Молотов имзасы белән Советлар Союзында яшәүчеләргә рус теле мәҗбүри, диган карар чыкканнан соң башланды. Ул карар үзгәртелмәгән, яши, «эшен» дәвам итә;

— Татар теле өчен кара кайгылы, канлы еллар — Сталин диктатурасы еллары. Ул чорда «милләтче» яисә «халык дошманы» исемен алу өчен туган телгә тугрылык та җитә иде. Татарларның бик күпләре туган телдән ваз кичеп, русча сөйләшеп яшәүне исән калу юлы итеп сайладылар;

— Әдәбият мәсьәләсе. Сталин чорында безнең әдәбият культка хезмәт итте, торгынлык елларында — җитәкчеләр мафиясенә. Кызганычка каршы, минемчә, әдәбиятыбыз халыкка хакыйкатьне җиткерә алмады. Халык — әдәбияттан, бер уңайдан, әдәбиятның нигезе булган телдән дә бизде.

Туган телне үтерүдә катнашкан көчләрнең бер өлешен генә искә алып уздым мин. Андый көчләр безнең тормыш-көнкүрешне төрле яктан чорнап алган. Ә без әлегә, телне тергезү өчен, ике генә чараны көн тәртибенә куя алдык: бакчаларда балаларга үз телебездә тәрбия бирү һәм татар мәктәпләрен торгызуны. Йөз төрле чир белән хасталанып яткан кешене терелтү өчен аның бары тик бер генә авыруын дәвалау җитәме? Туган телебезне коткару өчен комплекслы чаралар күрергә кирәк! Тиз вакыт эчендә объектив тарихны язып халыкка җиткерү зарур. Культ һәм торгынлык чорында репрессиягә эләгеп һәлак булган язучыларның, галимнәрнең мирасларын өйрәнергә дә вакыт җитте. Бу эшне озакка сузмаска иде! М. Г. Худяковның китапларын рус телендә һәм татарчага тәрҗемә итеп күп тираж белән халыкка тарату турында әйтеп тә торасы юк. Белмим, ни сәбәптер, безнең нәшриятта Лев Николаевич Гумилев әсәрләре дә күренми әле. Бәлки безгә, тарихи кыйммәткә ия әсәрләргә юл һәм кәгазь бирү өчен, үз әсәрләребездәге «су»ны кысып, тыгызрак язарга кирәктер?

Шиһабетдин Мәрҗани, Һади Атласи һәм Михаил Худяков язган тарихны халык белми. Татар тарихын, халык фаҗигасен аңлату хәзер дә кичермәслек дәрәҗәдә сүлпән бара. Без әле һаман, авызыбызны ачып, югарыдан боерык көтеп утырабыз. Тарихыбызны пычрату процессы исә дәвам итә. Шул процессның меңнән, йөз меңнән бер мисалы:

«...Татары хватают всех подряд, без разбора, они режут каждого, кто защищает себя. Выводят скот, жгут дома, тащат добро. Люди не успели опомниться, как — связанные и полуголые,— они уже гонимы навстречу рабству.

Выгоняют их прочь из Руси — быстро, безжалостно. Татары спешат на просторы родных степей, прочь из мрачных лесов Московии. А в степи дают отдых коням, начинают делить добычу. И тут же сквернят на глазах мужей и детей, свершают обряд обрезания над мальчиками, рвут из рук в руки девочек, которых можно продать для гаремов, *вспарывают на глазах у всех — животы ясырей и, вывалив теплые кишки в тазы, татары ковыряются пальцами в парных внутренностях, чтобы по изгибам кишок людских предугадать свою дикую татарскую судьбу...*»

Юк, Иван Грозный чорында язылмаган бу юллар. Хәбәрдарлык һәм хакыйкать эзләү чорында, халыклар дуслыгы өчен көрәш, шәфкатьлелек эзләү чорында, бүгенге көндә

иң популяр, лауреат язучы Валентин Пикульның канлы кулы белән язылган. (В. Пикуль. Избранные произведения. 1988 год. Том 2. Летопись вторая. Стр. 132.) Китап 250 000 данә таралган. Моңа кадәр бу язма миллион тираж белән басылып чыккан иде инде һәм 1989 елны, Мәскәүдә уздырылган китап ярминкәсендә макталып, чит илләргә дә сатылды.

Виктор Астафьев грузиннар турында, алар — сәүдәгәр халык, дип әйткән өчен генә дә, Грузия язучылары съездны бердәм ташлап чыгып киткәннәр иде. Безнең татар язучылары арасында җиде миллионлы халкыбыз йөзенә кан катнаш пычрак ыргыткан кешегә каршы сүз әйтүче булдымы? Юк, булмады һәм булмаячак. Бармы ул безнең татарда пәйгамбәрлек вазифасын өстенә алган әдипләр? Бу сорауга укучы җавап бирергә тиеш.

Мин түземсезлек белән Татарстан Верховный Советының дәүләт теле турындагы карарын көтәм. Туган республикамда бер генә телме, әллә ике тел дәүләт теле статусын алырмы икән? Әгәр дәүләт статусын ике тел алса, татар теленең аякка басуына өмет баглау буш иллюзия генә булып калачак. Идарә итәргә тигез хокуклы ике түрәне утырттык, ди. Шуларның берсе таза, көчле, икенчесе бик нык авыру. Шушы очракта җитәкчелек эшендә аларның өлешләре тигез була аламы? Мин озак еллар АКШтагы «ак» халык белән негрлар арасындагы мөнәсәбәтне күзәтеп йөрдем. Илленче елларда «ак» халыкны «кара»лардан аерып карау илдә чиктән тыш кискен, хәтта куркыныч хәлләр тудырган иде. Соңгы вакытта бу турыда сүз кузгалмый. Нью-Йоркның һәм башка зур шәһәрләрнең мэры итеп негрларны сайлый башладылар. Негрлардан министрлар, генераллар, зур ранглы культура җитәкчеләре, сәнгать һәм әдәбият әһелләре күтәрелеп чыкты.

Алтмышынчы еллар башында АКШта бер даһи закон кабул ителде: дәүләт эшенә бәйле тармакка ике бертигез сыйфатлы шәхес табылса, беренче чиратта, негрны яисә башка бер азчылык милләт вәкилен сайлап алырга! Университетларга һәм колледжларга кергәндә абитуриентларны да нәкъ шушы принцип нигезендә үткәрәләр. Гаҗәп акыллы, Америка өчен искиткеч отышлы закон булып чыкты бу. АКШка негрлар иленә әйләнү куркынычы янамый, шушы закон аркасында, илдәге милләтләр арасындагы дошманлык юкка чыкты. Бездә дә шушы алымны куллана алырлармы икән?

Без шушы көнгә кадәр милләт турында, бигрәк тә үзебез, татарлар, турында эндәшмәүне алга сөрдек, чөнки милли мәсьәләне кузгатучының язмышы фаҗига белән тәмамлана иде. Язучылар арасында да бу темага кагылган кешеләр яшьләр арасында гына очрый диярлек. Әле узган айны гына Туфан Миңнуллин Мәскәү радиосыннан чыгыш ясады. Милләтләргә карата гаделлеккә өндәүче акыллы чыгыш иде бу. Шулай да депутатыбыз, чыгышын тәмамлаганда, шаблонга әйләнгән өндәмәне кычкырмыйча булдыра алмады: «Руслар белән мәңге дуслык!»

Дөрес, әлеге өндәмә бүгенге көндә дә бәясен югалтмаган, ләкин мин, дуслык ике яктан да дәлилләнсен һәм ныгытылсын өчен, руслар тарафыннан да: «Татарлар белән дуслык мәңге яшәсен!» дигән өндәмә ишетергә телим. Кырык алты ел рус арасында яшәп, минем бу сүзне бер генә тапкыр да ишеткәнем булмады.

Бу дуслык турында уйлаганда без тарихны онытып торырга тырышабыз. Изге хискә кан шәүләсе, Казан каласының урамнарында аунап яткан мәетләрнең шәүләсе төшмәсен! Тагын бер шарт: йөз кырык миллион белән җиде миллион арасындагы мөнәсәбәтне күз алдына китереп карагыз әле. Шул йөз миллион ярым рус кешесенең һәммәсе дуслык серләрен дөрес аңласын өчен, безгә бик нык тырышырга кирәк бит. Уйлап карасаң, ул яктан күрсәтелгән дуслык хисе кайнаррак булырга тиеш иде, чынбарлыкта исә, ни сәбәптер, без моны сизмибез.

Кырык алты ел рус арасында яшәп мин руслардан татар булганлыгым өчен кимсетү һәм читкә этүне тоймадым. Чыннан да, руслар — киң күңелле, ярдәмчел һәм интернациональ табигатьле халык. Шул ук вакытта шовинистлык һәм русофиллык мәсьләсе бүгенге чынбарлыкта бөтенләй юк дисәк, ялганчы булыр идек.

Хезмәт коллективы шартларында шовинистлык та, милли эгоизм да барлыкка килә алмый. Әгәр син алган вазифаңны гадел башкарасың, хезмәттәшләреңә тугрылык һәм ихласлык белән карыйсың икән, синең нинди милләт вәкиле булуыңа беркем дә әһәмият биреп тормый. Табигый интернациональлыкны күрсәтергә теләгәндә журналистлар мисалга хезмәт коллективын күрсәтәләр. Чын-чыннан зыялы шәхесләр арасында да милли киеренкелек юк. Туган җирләреннән куылган милләтләрне язучы Анатолий Приставкин, академик Сахаров һәм шагыйрь Евгений Евтушенко яклап чыкты. Татар интеллигентлары арасында, Рөстәм Кутуйны искә алмаганда, бу мәсьәләне күтәрергә батырлыгы җиткән язучыны хәтерләмим мин.

Милли киеренкелек тудыручы сыйфатлар бюрократлар арасында барлыкка килә, шулардан тарала. Бюрократларның аппаратта гына түгеллеген аңлатасы юктыр дип уйлыйм. Андый кешеләр интеллигенция катламында да җитәрлек. Бюрократ ул, бер карасаң, интернационалист, ләкин аның интернационалистлыгы милләтләр арасындагы интернациональлыкка бер тамчы да охшамаган. Алар, төрле милләт бюрократлары, үз интернационаллыкларын ясаганнар. Бюрократлар кодексы адәм баласын, аның сәләтен, хисләрен, язмышын һәм башка сыйфатларын анкетадагы сүзләргә алыштыра да абстракт бер фикциягә әйләндерә. Безнең замандагы татар бюрократы, өстәл артына килеп утыру белән, руска әйләнә. Үземне татар итеп белгертсәм, руслар урынымнан куып чыгарыр, дип курка ул һәм властька тугрылыклы булуын үз милләтенә карата эшләгән әшәкелекләре аша исбатларга тотына.

Бюрократлыкның иң каты, иң аяусыз бер төре белән очрашу гомер онытылмаслык булып бәгыремә сеңеп калган.

Кара диңгез пароходчылыгында эшләгәндә, 1961 елны миңа Феодосиядән квартира бирделәр. Кулыма ике бүлмәле квартираның ордерын тотып, прописка артыннан йөри башладым. Паспорт өстәле, милиция идарәсе, шәһәр башкарма комитеты, партиянең шәһәр комитеты, Симферопольдәге өлкә башкарма комитеты, ниһаять, иң югары нокта — партиянең өлкә комитеты. Егерме сигез көн буена, иртәдән кичкә чаклы, шул оешмаларның ишек төбен таптап, барысында да булып чыктым да... больницага кереп яттым. Шул бюрократларның берсе генә дә, сине, анкетаңда «татар» сүзе торганга, пропискага алмыйбыз, дип әйтмәде. Шулкадәр ягымлы, елмаеп кына сөйләшәләр һәм, футбол тубын тибеп җибәргән шикелле, икенче бюрократка озаталар. Ә үзем — ул чакта диңгезчеләргә интернациональ тәрбия бирүче, политработник. Чит илләрдә йөргәндә илебездәге интернациональ дуслык, азчылык милләтләрнең совет чорында шундый зур уңышлыкларга ирешүләре, культура ялаулары, совет илендә кешенең кадере биниһая зур булуы турында лекцияләр сөйләп йөрим...

Туган республикама соңгы кайтуымда партия работниклары арасында милли мәсьәләне аңлаучы кадрлар барлыкка килүен күреп куандым. Баулының райком секретарьлары шундый матур итеп татарча сөйләшә башлаганнар. Культ һәм торгынлык еллары калдырган сәбәпсез курку тиз генә бетмәс бетүен. Ул бар әле, сизелә, комачаулый. Чаллыда, Түбән Камада шәһәр башкарма комитетының культура бүлегендә, партиянең шәһәр комитетындагы идеология эшендә милли мәсьәләнең җитдилеген аңларлык, югарырак утыручылар аяк чалмаган очракта, катлаулы мәсьәләләрне хәл итәрлек кадрлар барлыкка килгән. Соңгы вакытта партиягә каршы күсәк күтәрү модага кереп китте. Тупаслык, сукырлык күсәге менә шушы вөҗданлы яңа кадрларга тия күрмәсен иде. Без, язучылар, аларга ярдәм итәргә тиешбез.

Республикада бүгенге көндә катастрофа хәлендә торган тел мәсьәләсен һәм барлык милли проблемаларны һәр очракта руслар белән бергә хәл итәргә туры киләчәк. Патша заманы, культ төрмәсе, торгынлыкның тынчу атмосферасы безне яман бер гадәткә өйрәткән: милли мәсьәлә каршыбызга килеп басу белән без йә йодрык йомарлап кычкыра башлыйбыз, яисә тынычрак якка китеп посабыз. Бүгенге көндә бу гадәтләрнең икесе дә куркыныч, икесе дә җиңелүгә дучар булачак. Милли горурлыкны, тапталган абруйны кире кайтару — гаҗәеп авыр, катлаулы эш. Бу эшкә керешер алдыннан без акыл, түземлек, чама, фидакярлек белән коралланырга тиешбез. Каршылыклар очраганда (алар һәр адымда очрый һәм очраячак), кире борылмыйча, әдәп саклап, акыл һәм түземлек белән, аңлашу, аңлату, халыкка мөраҗәгать итү юлы белән эш итәргә тиешбез. Эш авыр. Безгә бердәмлек кирәк. Бүгенге көндә иң кирәк нәрсә — бердәмлек.

Балтыйк буендагы республикаларны алыйк. Милли мәсьәләне иң уңышлы чишкән халыклар хәзергә шулар. Аларда экстремистлык юк. Алар европача культуралы. Литвалылар, латышлар, эстоннар максатларына ирешүгә инанганнар. Инану аларга көч бирә, аларны берләштерә. Без дә ышанырга тиеш. Безнең максатның тормышка ашуы беркемгә дә, бер генә башка милләткә дә зыян китерми. Киресенчә, без милли мәсьәләләрне уңай хәл итсәк, регионыбызда тынычлык һәм дуслык тагын да көчәячәк. Шартлар бер — яңару, хәбәрдарлык, яңача фикер йөртү. Бәхетле, яңача чорда яшибез.

*Баулы — Түбән Кама — Мәскәү.*

*Ноябрь, 1989 ел.*

## Диас Вәлиев

# ЫШАНЫЧЫҢ ӘГӘР КАКШАСА...

Көннәрдән бер көнне өемә ирле-хатынлы Сергеевлар килеп керде. Башларына бәла төшкән икән, уллары Вадим Сергеев алты елга төрмәгә ябылган.

— Радиодан, телевизордан сөйләгән сүзләрегезне тыңлап-тыңлап тордык та, киңәшеп карарга булдык,— ди әни кеше.— Башка ышанычыбыз калмады. Улыбыз бер дә юкка интегә бит, бөтенләй гаепсезгә...

Ата белән ана гына түгел, Вадимның элекке классташлары да, адвокаты да, аның һичнинди гаебе булмавын раслап, төрле оешмаларга мөрәҗәгать итеп караганнар. Файдасы тимәгән. Боздай салкын сүзләр язылган кыска җаваплар өеме генә хасил булган.

Эшнең башы 1984 елның 26 маена барып тоташа. Ул көнне «йөгәнсез» малайлар төркеме Казанның Тирән күле ягында бер кыз баланы мәсхәрәлиләр. Бу чакта Вадим Сергеев, үзе әйтүенчә, өендә була. Хәер, Вадим әнисенең туганы А. Ефимова һәм Ефимова күршесендәге тугыз яшьлек Л. Дубровина да шуны дәлилли. Аларның раславынча, Ефимова белән Дубровина 26 май көнне бергә циркка баралар. Цирктан чыккач, сәгать өчтә, Сергеевларга шалтыраталар. Трубканы Вадим ала. Алар сөйләшәләр. Әмма тикшерүче, Ефимованың туганлык мөнәсәбәтен сылтау итеп, эш барышында бу дәлилгә илтифат итми.

Шулай да Вадим бу вакыйгага ничек эләккән соң? Болай була. 31 майда Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре Киров районы бүлекчәсе хезмәткәрләре шул ук Тирән күл тирәсендә бер төркем малайларны кулга ала. Алар уенча, төркемдә 26 май көнне эшләнгән җинаятькә катнашучылар да булырга тиеш, янәсе. Вадим шунда эләгә. Ул бу якка пионерлар лагерена вожатыйлыкка эшкә урнашырга теләп килгән икән. Кесәсендә — паспорт. Өенә кайтырга автобус көтеп тора. Нәкъ шул чакта аны, су кереп чыккан егерме бишләп башка малай белән бергә, милиция урап ала.

Дүрт тәүлек Киров районы бүлегендә тоткынлыкта ята Вадим. Кат-кат сорау алалар. Шул арада Сергеевлар өендә тентү ясыйлар, бер ни дә табылмый, әлбәттә. Әле өйдәгеләр ни булганын, Вадимның нәрсәдә гаепләнгәнен дә белмиләр. «Күзгә-күз» очраштырганда, мәсхәрәләнгән Г. С. Вадимны танымый. Шуннан соң тикшерүче А. Макаров егетне өенә кайтарып җибәрә. Паспорт исә милициядә кала. Вадим аны-моны сорап тормый, автобус тукталышындагы ыгы-зыгы вакытында югалтканмын, дип кенә уйлый.

Әмма аның паспорты, өч ай узгач, 29 августта Казан шәһәренең Эчке эшләр идарәсе тикшерүчесе В. Попов кулында кабат күренә. Яңадан сораулар башлана. Вадимны кулга алалар. һәм бу юлы инде мәсхәрәләнгән кыз да, җинаятьне нәкъ менә шушы яшүсмер эшләде, дип белдерә. Леонов, Балякин фамилияле, Вадимга бөтенләй таныш булмаган малайлар да җинаять кылынган урында Сергеевны очратулары турында әйткәннәр. Вадим, әлбәттә, бу гаепләрнең барысыннан да баш тарта. Әлеге җинаять эшләнгән көнне өйдә утыруын, туганы һәм Дубровина белән телефоннан сөйләшүен тәкърарлый. Файдасы тими. Хәтта аның сүзләрен расларлык яки юкка чыгарырлык тикшерү эксперименты да ясап тормыйлар.

17 декабрьдә Киров районы халык суды халык судьясы Н. Золотов, халык утырышчылары Сәйфетдинова һәм Алексеев составында, прокурор И. Риянов катнашында, җинаятьче төркемгә хөкем карары чыгара. Вадим Сергеевны көчле режимдагы колониягә алты елга ябарга хөкем итәләр. Шулай да утырыш барышында башка сыймаслык әллә нинди хәлләр туа. «Мине Вадим харап итте»,— дигән Г. С. бу юлы Сергеев хакында берни дә әйтә алмавын хәбәр итә, үзенең буталуын белдерә. Леонов та беренче сорау алулар вакытындагы күрсәтүләреннән чигенә, җинаять урынында В. Сергеевны күрү-күрмәвен раслый алмавын әйтә, ялгышканлыгын таный.

Бу бик мөһим үзгәрешләр приговорга да теркәлгән. Димәк, Вадимны җинаятьтә гаепләрлек иң төп дәлилләр юкка чыккан. Белякин фамилияле шаһиттан исә судта берни дә сорамыйлар. Леоновның судтагы чыгышыннан тикшерүче В. Попов эшчәнлегендәге бер сәер алым ачыклана: әлеге шаһитларның белдерүе Вадимның паспортындагы фотосурәткә генә нигезләнгән икән. Тикшерүче, ул чакта җинаятьченең аерым билгеләре турында әйтүне таләп иткәч, Леонов:

— Таза, юан,— дип саный башлаган. Шуннан соң В. Попов аңа Вадим паспортындагы фотоны күрсәтә:

— Шушындыймы? Шулмы? — янәсе. Леонов ризалашуын белдерә.

Г. С.ның беренче дәлилләвендә дә сорау алуның шушындый ук ялгыш юлдан киткән булуы ихтимал. Суд барышында исә Г. С. үзенең беренче белдерүеннән кискен рәвештә баш тарта, В. Сергеевны С. Шепелев белән бутаганлыгын судья Н. Золотовка язып та бирә. Бу ике шаһитның да судтагы сөйләгәннәре «чынбарлыкка охшамаган» дип табыла, Г. С.ның гаризасы кабул ителми.

Әлеге вакыйга белән таныша башлагач, чәчләр үрә тора. Бүген Сергеев, иртәгә башка берәү шундый ук хәлгә дучар булырга мөмкин иң. Уйламаган-нитмәгәндә сине коточкыч җинаятьтә гаепләүләре ихтимал: поповлары, тикшереп, юк гөнаһыңны бар итәр, золотовлары хөкемен чыгарыр. Ярый әле гамәлдә эш алар белән генә чикләнми, кассацион шикаять язып, югарырак дәрәҗәдәге гаделлек сакчыларына мөрәҗәгать итү тәртибе бар дөньяда.

Вадим Сергеев хәле дә 1985 елның 13 мартында ТАССР Верховный судында кабаттан карала. Суд рәисе — В. Кучин, членнар — Г. Мәхмүтова, Л. Романов, прокурор — Г. Дрямин, адвокат — В. Кузовков. Монда, халык судьясы Н. Золотов игътибарга да алмаган мөһим документ, рәнҗетелгән Г. С.ның гаризасы калкып чыга: «...мин ялгыш күрсәткәнмен. Мине җәберләүче — Сергеев түгел, Шепелев». Адвокат В. Кузовков та җитди рәвештә кисәтә: «...тазалык, юанлык кебек кешенең аерым сыйфатларына таянып кына соңгы нәтиҗә ясау дәреслеккә китерми. Шул ук Г. С.ның әйтүенә караганда, җинаятьченең кайбер сыйфатлары, әйтик, «сирәк, эре тешле», «янга тырпайган колаклы» булуы Сергеевка бөтенләй туры килми.

Хәйран калырлык! Кинофильмнар караганда, без милициядә әллә нинди криминалистик техника чаралары кулланыла, дип утырабыз. Тормышта исә, төрмәгә ябып кую өчен, гәүдәнең җинаятьче кыяфәтенә охшашлыгы да җитә икән ләбаса!!! Югары квалификацияле тикшерүче В. Попов, гәүдәсе охшаш булгач, теш, колак кебек органнарга игътибар да итеп тормаган. Игътибар ителмәгән серле яклар шактый күп бу эштә. Шаһитларның төрле вакытта төрлечә сөйләүләренең сәбәбе белән дә кызыксынмыйлар. «Дөреслеккә охшамаган»,— дип кенә нәтиҗә ясала. Бу очракта, ягъни шаһитларның ни өчен төрлечә сөйләүләре ачыкланмаган чакта, тикшерү тулы түгел, берьяклы саналырга тиеш. Гаганов, Карасев, Колоколов кебек башка шаһитларның сүзләре дә каршылыклы. Әмма адвокатның бу мәсьәләне күтәреп чыгуы судны һич кызыксындырмый. Ефимова белән Дубравина әйткән сүзләргә колак та салмыйлар. Ефимованы исә: «Ялган шаһитлык өчен җаваплылыкка тартылачаксыз!»— дип кисәтергә онытмыйлар, билгеле. Миңа калса, бу хәлне тагын да төпченебрәк тикшерергә иде! Вадим, бәлки, тагын берәр кешегә шалтыраткандыр? Бәлки, күршеләре аның өйдәлеген белгәннәрдер? Музыка-фәлән ишетелгәндер? Юк, берәү дә болар белән кызыксынмый. Хәтта Дубравина белән Ефимованың әйткәннәрен кире кагучы дәлилләрне дә эзләп азапланмыйлар. Җитди кисәтү һавада эленеп кала. Әлеге җинаятьне үз күзләре белән күргән һәм гаепле саналган Йосыпов, Хафизов, Головачев, Мингалиев та, Кочуев, Әбделхәлимов, Тимершәехов, Кәримов кебек шаһитлар да җинаять кылынган урында Сергеевны күрмәүләрен әйтәләр. Шуңа Леоновның судта сөйләгәннәрен дә өстәсәң, Вадимның эше тәмам җиңеләя, дип уйлыйсың. Әмма — ни гаҗәп! — ТАССР Верховный суды 1985 елның 13 мартында уздырылган утырышында элекке приговорны үз көчендә калдыра. Әле алай гынамы? Ул документта менә мондый юллар да бар: «...суд коллегиясе хөкемне законлы, нигезле дип таба һәм үзгәрешсез калдыра. Сергеев В. А.ның гаебе, үзенең танымавын санамаганда, нигездә һәм башлыча раслана. Моны мәсхәрәләнгән Г. С. сүзләре, шаһитлар Белянкин, Тимершәехов, Кәримов, Әбделхәлимов чыгышлары раслый...» Менә сиңа мә!

Сергеев гаебен танымый, Г. С. та, югарыда телгә алынган яшүсмерләр дә үз сүзләрендә Вадим Сергеевка каршы берни әйтмиләр, киресенчә, җинаять кылынган урында ул юк иде, дип торалар, әмма республика Верховный суды коллегиясенең билгеләмәсендә акка кара белән: «...г а е п  р а с л а н а», дип язып куелган. Һәм шул приговор белән үк икенче хата ясалган; телгә алынган Шепелев бөтенләй читтә кала!

Бу кәгазьләр белән танышкач, мине, барыннан да бигрәк, җәмгыятебез өчен гарьләнү хисе биләп алды. Әлеге очеркны язу теләгем дә, Вадим Сергеев турында борчылудан гына түгел, хокукларыбызны сакларга алынган органнарның хаталарын ачарга тырышудан туды бугай.

Инде алга таба барыйк: Вадимның эше ничегрәк дәвам итте соң? Егетнең әти-аниләре дә, адвокат та ТАССР Верховный судыннан соң да тынычлана алмадылар. Шулкадәр чуалчык, кеше ышанмаслык хөкем җанны ничек тынычландырсын инде? Аларга мин дә кушылдым. Шикаятьләр яздык.. Аларны тикшерү кемгә тапшырылды дип уйлыйсыз? Казанның Киров районы эчке эшләр бүлегенә! Янәсе, үзең башлагансың, үзең үк очлап та бир инде, иптәш! Кызык бит, ифрат кызык! Бу юлы инде С. Шепелевның кылганнарын тикшерә башлыйлар. Эш белән милициянең Киров район бүлегендәге тикшерүчеләр А. Гыйниятуллин, Х. Гыйльметдинов, аннары прокуратура тикшерүчесе В. Антонов шөгыльләнә.

Тагын бер хәйран калырлык деталь: А. Гыйниятуллин сорау алганда, Г. С., үзенең әллә ничә тапкыр кабатлаган сүзеннән баш тартып, яңача сөйли башлый: «...җинаять урынында Шепелев та, Сергеев та бар иде»,— дип белдерә. ТАССР Прокуратурасына тапшырылган магнитлы тасмада Г. С.ның сүзләре ап-ачык яңгырый: «...мин анда Сергеевны күрмәдем, мин Шепелевны күрдем»,— ди ул.

— Яңа сорау алу вакытында ник башкача сөйлисең? — дигәч, ул:

— Сергеев файдасына әйткәнне аларның (тикшерүчеләрнең) ишетәселәре дә килми,— дип җавап кайтара.— Аны барыбер акламаячаклар. Суд үзен-үзе гаепләп утырмас бит инде?!

Вадимның әти-аниләре кискен каршылык күрсәткәч, Гыйниятуллинны тикшерү эшеннән читләштерделәр. Яңа тикшерүче Х. Гыйльметдиновны исә, төрмәдә утыручы Сергеевка караганда, әле һаман ирektә йөрүче Шепелев мәсьәләсе ныграк кызыксындыра иде. Шепелевны бит беренче тапкыр нәкъ менә Гыйльметдинов кулга алган икән. Шепелев исә ул арада армия хезмәтенә үк китеп барган. Егетне тиз генә аннан чакыртып кайтаралар. Әмма эш башка тикшерүчегә — В. Антоновка тапшырыла. Анысы да, Сергеев язмышы турында уйлаудан бигрәк, Шепелев белән күбрәк кызыксына.

Яшь юристларның хәлен аңларга була: Сергеев эшен тикшергәндә хата киткән икән, шуны ачыклыйсың икән, димәк, арадан берәү, ялгыш җибәргәнлеге өчен, җәза алырга тиеш. Йә шелтә белдерерләр, йә хөкемгә үк тартырлар, «мондый эшкә яраксыз» дип табулары да бик мөмкин. Инде икенең берсен сайларга кирәк: үзең белән рәттән эшләп йөргән иптәшеңне утка салыргамы, әллә инде төрмәдә утыручы билгесез бер яшүсмернең язмышын пакьларгамы? «Ул бит инде ике елын утырган, дүрт елын ничек тә тутырып бетерер...»— дип, тынычланырга да мөмкин. Әмма болай фикер йөртү гадел хөкемнең төп кагыйдәсенә хилафлык китерә: «...һәр җинаятьче җәзасын алган кебек үк, гаепсез бер генә шәхес тә... рәнҗетелмәскә тиеш!»

Әлеге тикшерүләр нәтиҗәсендә исә Шепелевның гаебе тулысынча раслана. Ул беренче сорауда ук бөтен гаепне үз өстенә ала һәм алты елга иреגеннән мәхрүм ителә. Өстәп тә әйтергә була: Шепелев җинаятьчеләр арасында һичнинди Сергеевның да күренмәгәнлеген әйтә. Вадим файдасына тагын да саллырак дәлил өстәлә. Тик, кызганычка каршы, бу дәлилләр инде берәүне дә кызыксындырмый. Шушы коточкыч ваемсызлык аркасында, бер җинаять өчен, ике егет җәза ала. Сөлек кебек ике егет төрмәдә гомер кичерә!

...Язу өстәлемдә — хатлар, шикаятьләр, гаризалар һәм шулар уңаеннан алынган боздай салкын, кырыс җаваплар өеме. Вадим язмышын бернигә санамаган чиновниклар, сөйләшенеп куйгандай һәммәсе дә бер төслерәк җавап җибәрә: барысы да Г. С.ның беренче сүзен, Попов, Гыйниятуллин кебек ялгыш юлдан киткән тикшерүчеләрнең эш нәтиҗәсен, Леонов кебек сәер шартларда Сергеевны гаепләгән шаһитларның аерым җөмләләрен төп дәлил итеп китерә.

Гайсин, Мәүләвиев, Гагаров кебек, беренче мәртәбә ялган күрсәтмә биргән шаһитлар, өч айдан соң, Сергеевның язмышы белән яман «шаярулары» аңлап, РСФСР Прокуратурасына аклану сорап шикаять язалар, Мәскәүгә баралар, башкаладагы бер газета редакциясенә дә мөрәҗәгать итәләр. Файдасы гына тими, тими файдасы! Аларга да алда телгә алынган рәвешле коры җавап килеп төшә.

Юриспруденциядәге бюрократлыктан да хәтәррәк нәрсә юктыр, мөгаен. Сергеев эшенең башында ук коточкыч гаделсезлекләр кылына: Вадимны, гаебе расланмаган килеш, дүрт көн буе ябып тоту, өйләрендә тентү оештыру, егетнең паспортын яшереп калу һәм аңардан астыртын файдалану, ниһаять, Шепелев үз гаебен таныганнан соң да, Сергеевның эшенә кабат мөрәҗәгать итәргә теләмәү... Җитмәсә, бу юристлар үз-үзләренә, чыгарган нәтиҗәләренә, шулкадәр нык ышанганнар ки, мин вакыт-вакыт шикләнә башлыйдем: бәлки, ялгышамдыр? Бәлки Вадим Сергеев, чыннан да... Мин — юрист түгел, геолог

һәм язучы мин. Белеп, аңлап җиткермимме соң әллә? Әмма шикләнүләремне ныгытырлык бер генә дәлил дә юк. Монда бит теләсә кемгә аңлаешлы хакыйкать күзгә ташлана — ведомствочылыкның корычтай кабыкка төрелгән эгоизмы бу, бер ведомство эчендә тәмам чиләнеп беткән башбаштаклык.

1987 елда мин «Казан утлары» журналында отставкадагы милиция подполковнигы Наил Абзаловның щелоковчылыкка каршы ничек көрәшүе турында язып чыккан идем. Ул очерк «Смена» журналында да басылды. Язмада Эчке эшләр министрлыгы системасында законнан тайпылулар, бу адымның нинди аяныч хәлләргә китереп чыгаруы тасвирланган иде. Көрәш бик кискен бара. Абзалов тәмам чиргә сабыша, инвалид булып кала. Әмма аны җиңә алмыйлар. Ышанып әйтергә мөмкин: бүген законга таянып яшәү кирәклеге ачыктан-ачык таләп ителә башлаган икән һәм бу өлкәдә инде беренче адымнар да ясалган икән, монда Абзалов көрәшенең дә өлеше бар.

Мин Сергеев эше турында да Наил ага белән киңәшергә булдым. Кулымдагы язуларны аңа тапшырдым. Берничә көннән соң яңадан очраштык. Ул:

— Сергеевның гаепле булуы бик шикле,— диде.— Судка кадәр алып барылган тикшерү нәтиҗәләре көчсез. Аларга таянып кына эшне судка тапшырырга да мөмкин түгел... Сергеевны Г. С.ка ике тапкыр күрсәтү — үзе үк закон нормасын бозу. Прокурор бу ялгышны тоярга тиеш иде!..

Ул халык судының да, ТАССР һәм РСФСР Верховный судларының да күзгә бәрелеп торган хаталарын санап чыкты һәм:

— СССР Верховный суды коллегиясенә шикаять язарга кирәк! — диде.

Мин бу эш белән ник болай мавыгып киттем соң диярсез. Аңлатам. Чөнки монда Вадим язмышы гына хәл ителми бит. Юристлар җибәргән бер төгәлсезлек әллә нинди башка хаталар тудыра. Сергеев белән бергә үк, мәсәлән, Игорь Йосыпов та биш елга иреге͏ннән мәхрүм ителә. Ул Г. С.ны мәсхәрәләүче бер төркемдә тотылган. Гаепләме ул, мин инде ышанмыйм. Анысы — бер хәл. Шул ук төркемдә булган биш малай әле дә иректә йөриләр бит. Берәүне «утыртып куйгач», безнең җан тынычлыгын саклаучылар үзләре дә тынычланып калганнар: Сергеев белән Йосыпов «утырамы?», «утыра!». Димәк, бөтенләй үк кул кушырып утырмыйбыз...

Юк, монда бер Вадим Сергеев язмышы гына хәл ителми. Мондый хаксызлык аркасында безнең теләсә кайсыбыз, Сергеев кебек, өендә торган көенчә дә әллә нинди баш җитмәслек җинаятьләрдә «гаепләнә» ала лабаса! Әгәр без дөреслекне вакытында ачыклый бармасак, һәр гаделсезлеккә каршы көрәшмәсәк — тормышыбыз мәңге яхшырмаячак, өйләребезгә рәхәт тынычлык иңмәячәк, кеше үз гомеренә үзен хуҗа итеп тоя алмаячак.

Сүз дә юк, хокук саклау органнары илдә зур эш алып бара. Авыр, кара, пычрак эшләрнең астын-өскә китерәләр алар, гаделлек эзлиләр. Рәхмәт аларга! Шул ук вакытта без аларның закон бозуга юл куйю очракларына да күз йомып калмаска тиешбез.

Сергеев башына төшкән бәла аерым шәхесләргә генә кагылмый. Мондый хаталар җәмгыятьнең нигезен какшата, кешеләрнең илгә ышанычын бетерә, әллә нинди яман хәлләр тудыра. Вадимны яклау юлларын эзләнә киткәч, мин дә хокук яклау органнарына йөрүнең мәгънәсезлеген аңладым. Егеткә ярдәм итүнең бердәнбер юлы калды: хәбәрдарлык. һәм мин «Смена» журналына «Ни өчен?» исемле мәкалә яздым. Шул басылып чыккач, инде ике ел да сигез ай төрмәдә интеккән Вадимны азат иттеләр. Эшендә профессиональ хата җибәргән А. Макаров, В. Попов кебекләр нинди җаза да алдылар.

Миңа исә яңа фаҗигаләр теркәлгән дистәләрчә хатлар агыла башлады. Ниләр генә юк ул хатларда?! Менә кеше үтерүдә гаепләнеп ун елга «утыртылган» Николай Серегин язмышы. Кызганыч ки, мин аңа, бик теләсәм дә, һичничек ярдәм итә алмадым. Николайны әнисе Валентина Михайловна коткарды. РСФСР Прокуратурасы законсыз приговорны кире какканда, Николайның җиде ел гомере төрмәдә узган иде инде. Менә сиңа —«ялгышлык»!

Хатлар, телефонограммалар, ерак-ерак шәһәрләрдән өемә шалтыратулар... һәммәсендә кеше язмышы, гарипләндерелгән тормыш, ышанычын җуйган җаннарның әрнүе.

Ленинградтан Л. Тасуева яза: җитәкчесен тәнкыйть иткән өчен кафедра мөдире вазифасыннан азат ителгән, эш эзли. Новокузнецкида физкультура укытучысы И. Скачков зарлана, Херсоннан милиция майоры А. Козинец үзенең четерекле хәлдә калуын хәбәр итә. Өч елдан бирле җәфалана икән инде.

Бәлагә кем генә тарымый бу дөньяда?

«1983 елның 10 сентябрендә төнге унберенче яртыда Булаевск район эчке эшләр бүлегенең (Төньяк Казахстан өлкәсе) «УАЗ» машинасы «Урал» мотоциклын бәреп уза. Авария булган җиргә, «Жигули»га утырып, бүлек начальнигы майор Б. килә. Аның янында Булаевскидагы мәктәп укытучысы М. Ручкина да утырган. Болар «УАЗ»ны тиз генә читкә илтеп, яшереп куялар. Майор авария булган урында кала. Мин нәкъ шул вакытта «ЗИЛ» машинасында кырга ашыга идем. (Комбайн суктырган ашлыкны амбарга ташыйм). Кинәт каршыда көчле фаралар кабынды, күзгә берни күренмәс булды, машинам авария булган җирдән 10-15 метр ераклыкта аунап ятучы мотоцикл өстенә барып менде. Шуны гына көткәндәй, минем күзне чагылдырган «Жигули» әллә кая китеп югалды. Мин, милиция килгәнен көтеп, мотоцикл янында калдым. Тирә-ягымны күзәтәм. Юл читендә ике мәет ята икән. Урталарында бер малай да бар, ул әле исән кебек, хырылдаган тавыш бирә. Аны узып баручы бер машинага салып җибәрдем.

Милиция хезмәткәрләре мине КПЗга (камера предварительного заключения) ябып куйдылар. 3 ай утырдым. Җинаять эше «әмәлләделәр», унбиш ел бирделәр. Бераздан теге укытучы «эш»кә ачыклык керткән. 1984 елның февралендә ул минем хатын янына килгән: «Башкача булдыра алмыйм, дөресен сөйлим,— дигән.— Баланың ачырганалып кычкырганы колак төбендә яңгырый. Йокым качты. Синең Валераң гаепсез. Әйдә райкомга! Сөйләп бирәм».

Баксаң, мин больницага озатасы 5 яшьлек бала баштарак ип-исән булган икән. Ул өзгәләнеп: «Әни! Әни!» — дип кычкырган да кычкырган. Майор Б. һич кирәге булмаган бу шаһитне юк итәргә хәл кылган. Башына сугып «тынычландырган». Шуны күреп торган Ручкинаны райкомда, «телен озайтып» йөргәне өчен, тиләләр йортына ябып куялар. Озак үтми, майор Б. атылып үлә. 13 мартта психбольницадан чыгарылган Ручкина да, поезд астында калып, һәлак була...» В. Мамонтов, Күкчәтаудан җибәргән бу хатына кушып, шикаять-гаризаларына алган 38 (!) җавапны да салган. Утыз сигезнең ник берсе генә кеше хәлен аңларга тырышып язылса иде! Юк, барысы да — коп-коры, сап-салкын, ышандырмый торган сүзләр тезмәсе.

Миңа килгән хатларның һәммәсендә — гаепсезгә ифрат каты җәза алган кешеләр зары. Казан егете Герман Стороженко тугыз елга хөкем ителгән. РСФСР Верховный суды ике елны киметкән. Әмма тирәннәнрәк танышсаң, бу эшнең дә өстән-өстән генә тикшерелүен сизәсең... Монда да «ялгыш» җибәрелгән булуы бик ихтимал, дигән нәтиҗәгә килеп төртеләсең. Кемнәрдер сугышкан. Сугыш чыккан җирдә туры килгән кешеләрнең барын да кулга алганнар: тикшерербез, гаебегез булмаса, кайтарып җибәрербез, дигәннәр. Стороженкога әнә төрмәдә утырырга туры килә. Кем белә, бәлки, гаепледер, бәлки түгелдер дә. Үзе ул гаебен танымый, мин дә шикләнәм. Өч мәртәбә матбугат аша юристларга мөрәҗәгать иттем — файдасыз.

Аптырагач, «Социалистическая индустрия» газетасының Казандагы үз хәбәрчесе У. Богдалов белән Стороженко янына, колония начальнигына киттек. Мәшһүр Плэтэн төрмәсенең начальнигы полковник П. Тарасов кабинетында Герман Стороженко белән сөйләшәбез. Егет кара-соры төстәге ямьсез киемгә төренгән. Чәчен кырганнар.

— Сәламәтлегең ничек? — дибез.

— Санчастька йөрим, алар: «Ярый»,— ди.

— Үзеңә ничек тоела соң?

— Әйбәт түгел шул.

— Кыйныйлармы әллә?

— Буладыр инде. Белмим. Аңым югала минем, берни белмим...

— Син монда күптәнме?

— Дүрт ел да җиде ай, тагын ике ел ярым кала...

Германны алып киттеләр. Мин кабинет хуҗасыннан:

— Петр Тимофеевич, сезнең уегызча, тикшерүчеләр һәм суд хатасы аркасында, ялгыш утыручылар юкмы икән монда? — дип сорыйм.

— Без монда суд карарын яңадан тикшереп утырмыйбыз. Үз күзәтүләремә таянып әйтсәм, болай: төрмәдәгеләрнең күбесе үзен гаепле саный. Шулай да арада үзен һичнинди җинаять эшләмәгән дип исәпләүчеләр дә бар. Алары күп түгел, нибары биш процентлап булыр...

Иңрәп киттем. «Биш процентлап»! Әйтик, төрмәдә ике меңләп мәхбүс булса, йөздән артык кеше нахакка иза чигә, дигән сүз бит бу! Бу эшкә ник алынганлыгыма үкенә башладым. Үзгәртеп корулар заманында саф әдәби әсәрләр язу гына мине канәгатьләндерер

житкерми, шунлыктан тормыш хәлләре, кичекмәстән чишәргә кирәкле четерекле мәсьәләләргә кереп баткан идем. Ай-һай! Мин генә ерып чыгарлык түгел икән! Булмый. Җаным өзгәләнә, әмма гаделсезлекләрне фаш итәрлек мөмкинлекләр таба алмыйм. Хәтта бу хакта язмаска дип үз-үземә тәүбә дә иттем инде.

Әмма әүвәл язган мәкаләләрем буенча хатлар һаман килә тора. Красноярскиның Октябрь поселогыннан Сергей Ниретин яза: «Алтай краеның Б. Исток районы милициясенең начальник урынбасары белән конфликтка кергән идем. Озак та үтмәде, мине машина кууда гаепләп, җинаять эше ачты. Шул дөрес буламы инде? Кулындагы властеннан файдаланып, үз сүзен сүз итәр өчен генә, минем биш ел гомеремне сызып ташлау — бигрәк зур гаделсезлек бит!» Молдавиядә Александр Дурканны алты елга хөкем иткәннәр. «Шаһитларның сүзенә һичнинди игътибар булмады. Хәтта мин әйткәннәрне дә үзгәртеп язганнар, судка ышанмыйм, гаебем юк»,— дип хәбәр салган.

«Милиция бүлегендә мине кысрык бөо урынга тыктылар да бик каты кыйнадылар. Таяк белән. Үзем дә белмәгән ниндидер җинаять теркәлгән кәгазьгә кул куярга мәҗбүр булдым». Моңысын Ставрополь краеннан Евгений Байков язган. «Сигез ел буе язам. Шикаятьләремне шулкадәр игътибарсыз укуларына гаҗәпләргә калам — дип зарлана Пермь өлкәсеннән Виктор Ханин.— Ант итеп әйтәмен, бер гаебем дә юк минем!» Тернополь гражданкасы Людмила 22 яшьлек улы Леонид Каргалицкийның һичнинди гаепсезгә инде ике ел төрмәдә утыруын хәбәр итә. Шикаятьләремне укып караучы да таба алмыйм, ди.

Юк, никадәр генә тырышсам да, бик кыскартылган килеш тә, кулымдагы хатларның барын да күрсәтеп бетерә алмыйм. Бөтенләй игътибарсыз калдыруны да күңелем күтәрми. Шунлыктан мин журнал аша юристларга мөрәҗәгать итәм. Түбәндәге кешеләрнең җинаятькә катнашу-катнашмауларын кабат ихлас кайгыртучанлык белән тикшерүгә ничек ирешергә? Миңа хат салучылардан — сигез елга ирегеннән мәхрүм ителгән М. Демидов (Тула өлкәсе), С. Шинелько (4 ел, Тирасполь), В. Попов (Җамбул), Гогян (Грузия), П. Новиков (10 ар ел, Краснодар крае) һ. б.лар өметләнеп көтәләр бит. Гостелерадио комитетының Мордовиядәге элекке дикторы Г. Биушкин, хәзер Днепропетровск өлкәсендә тоткынлыкта ятучы Н. Богомолов, Коми АССРда мәхбүслектә интегүче А. Клинцов та хөкем карарларының яңадан тикшерелүен тели.

Әлбәттә, эшләренең кабат тикшерүен таләп итүче һәр кеше бөтенләй гаепсездер, дип өзеп әйтеп булмый. Алар үзләре дә сүзгә генә ышануны таләп итмиләр ләбаса. Тикшерүдәге үзләрен ышандырмаган якларны телгә алалар, шуны төпченергә кирәклеген аңлаталар. Бездәге бюрократизм исә шул дәрәҗәдә ныгып җиткән ки, адәм балаларының гади сүзе генә аны һичничек какшата алмый. Бу җәһәттән тагын бер хатка тукталмый кала алмыйм. Аны Могилев өлкәсеннән Татьяна һәм Евгений Пузыревскийлар язган: «...Биш бала үстердек без. 1986 елның 12 ноябрендә 1968 елда туган төпчегебез Володя Армиягә китте. Декабрь башларында хәбәр алдык. Үзбәкстанның Термез шәһәренә урнашканнар икән. Без, аны Әфганстанга җибәрерләр инде, дип көтә башладык. Володя 5-23 декабрьләрдә, үпкәсе ялкынсынып, госпитальдә яткан икән. Ә 23 ендә, частена кайткач, хәрби формасының югалуы беленә. Яңасын бирәләр. Ул шунда ук яңа киемне үзенә җайлаштырырга тотына. Сержант шулай куша, чөнки 24 декабрьдә полигонда атышлар билгеләнгән икән.

Полигонга китәр алдыннан Володяга бернәрсә дә өйрәтелми, аның мондый атышларда беренче катнашуы була. Шунлыктан аның атуы да шома гына бармый. Полигоннан кайтканда исә төне буе керфек какмаган Володя, машина арҗасена менеп утыргач, йокымсырый. Автоматның прикладына арҗа төбенә терәлгән, ә көпшәсе — күкрәгенә. Машина сикертеп куя. һәм шулчак улыбызның автоматы атып җибәрә. Хәле киткән, күп каны аккан, җилкәсе, үпкәсе яраланган Володяны кабат санчастька салалар. 28 декабрьдә реанимациядә ятучы егет янына замполит килә һәм... солдат антына имза куйдыра. Улыбыз бу хәлнең мәкерле тозак икәнен соңыннан гына аңлый: частьта һичнинди шаккаткыч тәртипсезлек юк, әлеге шартлау исә егетнең үз-үзенә кул салуы итеп билгеләнергә тиеш.

48 тәүлек дәваланганнан соң Володяны кулга алалар, хәрби трибунал егетне дүрт елга ирегеннән мәхрүм итә. Шул булдымы дөреслек? Без Совет армиясенә таза, нык, саф күңелле улыбызны озаттык. Берничә ай эчендә аңардан җинаятьче, инвалид ясадылар. Аның яралары әле дә сызлый, сулыш алуы да авыр...»

Хатларда җәмгыятебезнең төрле яклары ачыла. Күпме вакыйгалар, ничәмә-ничә төрле фаҗигалар, чарасызлыктан интегүчеләрнең аһ-зарлары... Әле күптән түгел генә яңача иттереп сайланган депутатларыбыз тормышыбыздагы шундый хәлләргә дә игътибар итсеннәр, кешеләребезнең хокукын сакларга алынсыннар иде! СССР Верховный Советын-

дагы депутатларны гына әйтүем түгел. Алар бездә бик күп бит: авылда да, районда да, шәһәр Советларында да. Сайлау вакытында гына фотосурәтләре күзгә чалынып китә дә әллә кая юкка чыгалар. Хәтта исем-фамилияләре дә онытылып бетә. Мин бу мәсьәләгә тиктомалдан гына кагылмыйм. Киевта яшәүче укучым В. Монлаков болай хәбәр итә: «...Җирле Советларда колонияләрне күзәтү комиссиясе бар,— ди ул.— Закон аларга прокурорныкына тиң хокуклар бирә. Алар теләсә кайчан колониягә барып керә, шикаятьләр, гаризалар кабул итә ала. Төрмәдә утыручыларның эшен тикшерергә дә мөмкин аларга. Хезмәт итү тәртипләрен дә тикшерергә ярый. Чынлыкта исә комиссия членнары бу эш белән бөтенләй шөгыльләнми. Мәхбүсләр белән елга бер мәртәбә очрашып алалар да ике тиенгә кирәкмәгән отчет тутырып бирәләр. Шунлыктан милициядән, прокуратурадан, башкарма комитетлардан һәм үз депутатларыннан тәмам гайрәте чиккән, ышанычын җуйган адәм балалары газета-журнал редакцияләренә, язучыларга ялвара башлыйлар. Тик, кызганычка каршы, журналистларның мөмкинлекләре теге оешма кешеләренекенә караганда күпкә чикләнгән. Аларның һичнинди тикшерү аппараты да, криминалист техникасы да, сиреналы машинасы да — берсе дә юк, кулларында — кәгазь белән каләм».

Хатларның кайберләрендә җитди фикерләр, тәкъдимнәр дә бар. «Ни өчен без җинаятьчеләрне төрмәләргә дыңгычлап тутырабыз? Әллә, анда адәм баласы әйбәтләнә, дисезме? Киресенчә»,— дип язган берсе. Свердловскидан хәбәр салучы А. Новиков хәтта санап та күрсәткән: «Хәзер безнең илдә алты миллион чамасы тоткын бар. Анда утырып чыкканнар өч-дүрт тапкыр артыграк. Кыскасы, халыкның ун процентлабы «төрмә исен иснәгән». Мин боларны харап ителгән язмышлы корбаннар, дип атар идем. Кайбер мәгълүматларга караганда, Бөек Ватан сугышында егерме миллион кеше һәлак булган диелә. Төрмәләрдә аннан да күбрәге интегә. Минемчә, халкыбызның язмышын уңай якка хәл итәргә тырышканда, тормышыбызны матурайту, мул итү юнәлешендә уйлаганда, мәсьәләнең бу ягына да игътибар бирелергә тиеш».

Өстәлемдә хәл ителмәгән сиксән өч хат ята. Аларның кыяре минем кулдан килми торган ярдәмне көтә. Беләм: барысы да саф күңелле үк түгелдер. Кайчак бит җилләнеп тотынасың; тик, кызганычка каршы, син яклап йөргән кешенең гөнаһысы ачыла да куя. Йөздән берен аклый алсаң, бик хуш. Йөздән бере... Шул берәүне коткару өемә тагын йөзләрчә хат килүгә сәбәп була. Димәк, төрмәдәге кешеләргә сыңар-сыңар яхшылык эшләү белән генә җәмгыятьне сафландыру, хаталардан арыну һич мөмкин түгел. Тормышыбыз, гомумән, инсафлыкка мохтаҗ, шәфкатькә, миһербанлылыкка. Бу өлкәдә безнең барыбызга да кулдан килгән кадәр тырышырга кирәк.

«Комсомольская правда» газетасында бер мәкаләм басылып чыккач, миңа Шахтерск шәһәрендә яшәүче Катя Ещенкодан хат килде. Бик шатландырды мине ул хат. Кызчык, җирдәге барлык кешеләргә мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Мин башкача дәшми кала алмавымны аңладым. Мин шәфкатьле, ихлас күңелле, ярдәмчел барлык кешеләрне Вадим Сергеев кебек урынсызга рәнҗетелгән җаннарга ярдәм итәргә чакырам. Кешеләр, әйдәгез гаделлек өчен көрәшик! Әйдәгез, гаепсезләрне коткаруны үтенеп, имзалар җыйыйк! Заманында Леонард Пелтиерны яклауга күтәрелгән идек бит. Тавышларыбызны СССР Верховный Судына юрештерик! Гаепсезләр кичекмәстән азат ителсен, әниләре күз яшьләрен сөртсеннәр! Без — миллионнар бит. Кемнәрдер бөһтан яладан интегә. Аларга бары без генә ярдәм итә алабыз. Һәр язмышны җентекләп тикшергәндә тиешле оешма вәкилләре шиккә төшсен: «Бәлки, чыннан да, хата миндәдер?»— дип икеләнеп калсын һәм эшкә тотынсын...»

Мине канатландырып җибәргән тагын бер хат бар. Анысын Түбән Кама колониясендәге отряд начальнигы Ю. Кощеев язган. «Казанның Идел буе район халык суды тарафыннан 12 елга иреgennән мәхрүм ителгән Сафин, 10 елга утыртылган һәм төрмәдә вафат булган Әхмәтов, 11 елга ябылган Әхмәдиев үзләрен һәрвакыт гаепсезгә санадылар. Аларның гаепсезлеген хатыннары да раслый. Суд кына бу сүзләрне игътибарга алмый. Аларны гаепләү өчен нибары бер шаһит җиткән. Башка дәлилләр юк. Мин бу өлкәдә 12 ел эшлим инде, тәҗрибә җитәрлек, Шамил Әхмәдиев белән еш кына әңгәмә корып утырам. Минемчә, аның, чыннан да, гаебе юк. Аны да, башкаларны да кабат тикшереп карау урынлы булыр иде. Тик хәтта СССР Генераль прокурорына язылган 12 шикаять тә коры җаваптан башка нәтиҗә бирмәде. Уйлыйк әле: гаепсездән гаеплеләргә ничек ярдәм итеп була?..»

Башкаларга караганда сирәгрәк килсәләр дә, мондый хатлар аерым игътибарга лаек. Болары — инде уяна башлаган шәфкатебезнең беренче бөреләре...

**Альта Мәхмүтова,**
тарих фәннәре кандидаты

# ӘЙДӘ ХАЛЫККА ХЕЗМӘТКӘ!

Гасыр башындагы иҗтимагый активлык дулкыны өскә күтәргән исемнәр арасында беренче хатын-кыз татар укытучыларыннан һәм публицистларыннан берсе булган Фатыйма-Фәридә исеме дә бар.

Фатыйма-Фәридә бик кыска гомерле (1889—1914), ул 25 яшендә туберкулездан үлгән. Әмма шул арада да ул яшен ташы кебек балкып калырга өлгергән. Татар хатын-кызларын мәгърифәтле, иреклe итү, җәмгыять тормышына тарту. Аның көрәш максаты — шул.

Фатыйма-Фәридәнең дөньяга карашы гомумроссия чынбарлыгы тәэсирендә формалашкан. Фатыйма-Фәридә очрашкан социаль изүнең иң беренче формасы — хатын-кызларның хокуксыз хәле. Ислам динен тоткан башка халыклардагы кебек үк татар хатын-кызының хәле бигрәк аяныч була. Чагыштырмача иркен шартларда үскән булса да, Фатыйма-Фәридә ирексезлек тезгенен һәрдаим тоеп яши. Атасы, Чистайның мал-мөлкәтле сәүдәгәре Мортаза Ваһапов, бердәнбер кызын укытырга тели, әмма татар кызларына рәтле белем бирердәй татар мәктәбен каян табасың?! Кызны рус гимназиясенә бирү шәригатькә сыя торган эш түгел. Кыз бер ел Казанда Маһруй Барудиянең җәдит мәктәбендә сабак ала, ләкин уку нәтиҗәләре ата-ананы канәгать калдырмый.

Мортаза Ваһапов Чистай дамелласы Ибраһим Камаловның сеңелләрен өендә укытуын ишетә һәм кызын да шулар белән бергә укытырга сөйләшеп кайта. Шулай итеп җиде яшьлек Фатыйма, апалы-сеңелле Камаловалар белән бергә европача белемле укытучыда укый башлый. Ибраһим Камалов, ул заманның алдынгы карашлы интеллигентларыча фикерләп, кызларга дөньяви фәннәр — география, арифметика, тарих, биология, татар, гарәп, фарсы, төрек теле һәм әдәбиятын укыта. 1903 елның язында И. Камалов рус теле укытучысы да китертә. Әмма Фатыйма-Фәридә рус теле дәресләренә аз гына йөреп кала, атасы рөхсәт итми башлый.

Ибраһим Камалов кызларда мөстәкыйль фикернең күнекмәләрен дә тәрбияли. Фатыйма-Фәридә үзлегеннән дә бик күп укый, дус кызлары ярдәме белән рус телен дә өйрәнә. 1903—1905 елларда аның төрки-татар, гарәп, рус китапларына шактый бай шәхси китапханәсе туплана. Китаплары Казаннан, Истанбулдан кайтартыла, әтисе дә барган җирләреннән җыя торган була.

Җан-фәрман тырышып, белемен киңәйтергә омтылган саен Фатыйма-Фәридә татар кызларының хокукы, аларны белемле итү турында тирәнрәк уйлана. Тора-бара бу аның төп максатына, тормышы мәгънәсенә әверелә. Тиздән ул дус кызларына дәресләр бирә башлый. Җиткән кыз яшенә кергәч Фатыйма-Фәридә үзенең төп эше итеп татар кызларын укытуны саный һәм, кайда барса, шунда кызлар мәктәпләре ачарга омтыла. Мәсәлән, 1907 елда аның тырышлыгы белән Самара губернасының Бөгелмә өязе Кәрәкәшле авылында мәктәп ачыла. Әтиләре белән ул шунда күчеп килгән була. Беренче көнне сабакка 5-6 гына кыз килә, аның каравы ел ахырына аларның саны 50-70 кә җитә.

Бай сәүдәгәрнең бердәнбер кызы мөгаллимәнең аз-маз килеренә һич тә кызыкмагандыр. Ул мөмкин кадәр күбрәк кызларны белемле итәргә, томаналыктан коткарырга, үзенең хокуксыз хәлен аңлау дәрәҗәсенә җиткерергә теләгән.

Мәктәптә көнгә 7-8 сәгать сабак бирганнең соңында Фатыйма-Фәридә Кәрәкәшле

хатыннары янына кич утырырга да йөргән. Аларга китаплар укыган, киңәшләр биргән. Шул ел дәвамында күрше авылларның берничә абыстаен да яңа ысул белән хәреф танырга өйрәткән. Үзенең берничә сәләтле шәкертен Иж-Бубый мәдрәсәсенә мөгаллимәлеккә укырга китәргә күндергән. Шул чагында ук инде аңарда чын мәгърифәтче сыйфаты ачык сизелә. Аны халык язмышы борчый һәм ул, булдыра алганча, аны агартырга омтыла. Кәрәкәшледән татар газета-журналларына Фатыйма-Фәридәнең беренче мәкаләләре китә башлый.

1908 елда ул кияүгә чыга һәм ире белән Томскига китә. Анда ул татар кызлары өчен мәктәптә укыта, үзе исә рус телен өйрәнүен дәвам итә. Әмма кызларның дини ата-аналары мәктәптәге яңалыкларны, укытуның яңа ысулларын ошатмыйлар. Фатыйма-Фәридә, аңа-моңа игътибар итми, тота да учительлеккә имтихан тапшыра һәм татар кызлары өчен үз мәктәбен ачуга рөхсәт алуга ирешә. Бу мәктәп Томскидагы рәсми рөхсәт ителгән, өстәвенә, шәһәр бюджетыннан бераз матди ярдәм дә алып торучы беренче татар мәктәбе булган.

Фатыйма-Фәридә җирле интеллигенция белән нык аралаша. Шәһәрдәге барлык гыйльми һәм шәфкать җәмгыятьләренең члены була. Урта һәм югары белемле рус хатын-кызлары белән ул да барлык кичәләргә, лекцияләргә һәм гыйльми мәҗлесләргә йөри. Анда карала торган мәсьәләләргә карата үзенең үткен фикерләрен әйтергә дә тартынмый.

1912 елның февралендә аның ире Мөхәммәтвагыйз Нәүрузов «Сибирия» дигән татарча газета чыгара башлый. Шул көннән Фатыйма-Фәридә үзен газета эшенә багышлый. Ул һәр санда «Хатыннар дөньясы» дигән рубрика алып бара. Баштарак мәкаләләрнең бердәнбер авторы үзе була. Әмма тиздән аның язганнары киң җәмәгатьчелекне уятып җибәрә, илнең төрле тарафларыннан газетага хәбәрләр ява башлый. Күрәсең, бик тиз арада Фатыйма-Фәридә газетаның рухи җитәкчесенә әверелә. Газетаның дөнья күргән 145 санының 123 е редактор вазифаларын башкаручы Фатыйма-Фәридә имзасы белән чыккан.

«Сибирия»нең хатын-кыз мәсьәләләре белән кызыксынуы «Хатыннар дөньясы» дигән рубрикага гына бәйләнмәгән, әлбәттә. Бу проблема — Фатыйма-Фәридәнең авырткан җире.

Татар хатын-кызларын агарту өчен көрәш — Фатыйма-Фәридә өчен, милләт үсешен тышаулап торучы көчләргә каршы көрәш ул. Фатыйма-Фәридә, сыйныфларга аермастан, татар хатын-кызларының барысының да тулы хокуклы булуы турында сүз алып бара.

Журналист «Сибирия» битләрендә татар хатын-кызларының хәленә кагылышлы байтак мәсьәләләрне күтәрә, мөгаллимәләрнең авыр материаль хәле, хокуксызлыгы турында яза, аларны әзерләү өчен махсус уку йортлары ачарга өнди.

Фатыйма-Фәридә татарларда кызларны укытуның торышы кызганыч хәлдә икәнлеген күрсәтү өчен теләсә нинди мөмкинлекне файдаланып калырга омтыла. Мәсәлән, ул Киев университетында ике хатын-кызга профессор урыны бирелү турында хәбәр яза, ахырда өстәп куя: «Бездә башлангыч мәктәпләр өчен мөгаллимәләр юк. Безнең кебек үк кызлар башка җирдә профессорлык урынын дәгъвалый. Аерма бик аз!»

Беренче рус революциясеннән соң мәгърифәтчелеккә аяк баскан татар кызы өчен милли йомыклыктан чыгарга омтылу хас. Ул рус культурасына милләтнең үсеш юнәлеше итеп тә, белемен тирәнәйтү чарасы итеп тә карый.

«Бүген татар милләте белем сарайлары салып куя алмый икән, без булмастайны көтеп ятмыйк. Без кызларыбызны рус мәктәпләрендә укытырга тиешбез»,— дип яза ул.

Фатыйма-Фәридә татар кызларын тормышка әзерләү, аларга төрле һөнәрләр өйрәтү мәсьәләләрен дә күтәрә. «Без кызларыбызны мөстәкыйль тормышка әзерләмибез. Һөнәрсез, белемсез татар кызы, авыр материаль шартларга тарыдымы, идән юып, кер юып тамак туйдырырга мәҗбүр. Һөнәрсез хатынга ир күзенә карап яшәргә генә кала»,— дип яза ул.

Гаиләдә һәм җәмгыятьтә татар хатыннарының хәлен тәгәл беләсе килеп, ул «Сибирия»дә анкета бастырып тарата. Редакциягә бик күп җаваплар алына. Чөнки бу чорда татарларда хатын-кыз мәсьәләсе тәмам кискенләшкән була. «Хатыннар дөньясы» дигән рубрика Себер һәм Идел буе татарлары арасында бик нык популярлаша. Рубрика белән бергә журналистка Фатыйма-Фәридә исеме дә киң тарала. Бу уңыш мәгърифәтчене татар телендә махсус журнал чыгара башларга вакыт дигән фикергә китерә. Газета аша ул Россия мөселманнарына мөрәҗәгать итә. Фатыйма-Фәридә журнал чыгаруны үз кулына

алырга ниятли: журналның программасын әзерли, журнал нәширлек итүгә рөхсәт сорап үтенеч яза, әмма эш җәелдереп җибәрергә инде өлгерми. Көчтән килмәс эш аның сәламәтлеген какшата. Газета редакторы вазифаларын асылда үзе башкарып, почта, банк, типография эшләрен дә үзе үти, хәбәрчеләр белән хат алыша. Шул вакытта мәктәптә дәресләр бирүен дәвам итә, күп төрле җәмгыятьләр эшендә дә катнаша. Белемен күтәрергә дә вакыт таба: өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшырырга әзерләнә, югары белем алырга хыяллана. Кыскасы, таза-сау ир-ат чыдамаслык шушы эшләрнең барысын хаста хатын-кыз берүзе башкара.

1913 ел аның өчен гаять авыр ел: ул материаль кыенлыкларга килеп терәлә һәм, ел ярым чыкканнан соң, «Сибирия» ябыла; бер яшьлек улы үлә; иреннән күңеле сүрелә... Болар һәммәсе туберкулез авыруын көчәйтеп җибәрә һәм шул елның көзендә каты авыру хәлендә Фатыйма-Фәридә Кәрәкәшлегә, атасы йортына кайта. Ире, Уфага күчеп китеп, анда «Тормыш» дигән газета чыгара башлый.

Фатыйма-Фәридә каты авырудан арына алмый һәм 1914 елның 16 февралендә Кәрәкәшле авылында вафат була. Аны күмгәндә тирә-күрше авыллардан мең ярымлап кеше катнаша. Мәктәпләрдә дәресләр туктатыла. Нотыклар сөйләнә. Кәрәкәшле һәм Әпсәләм авылларында аның истәлегенә кызлар мәктәбе салырга карар кылына.

Фатыйма-Фәриданең үлеме — татарлар өчен зур югалту, чөнки ул бөтен көчен, тырышлыгын кавемдәшләрен азат итүгә багышлаган аз санлы гыйлем хатын-кызларның берсе була. Ул заманның татар дөньясы аның үлемен әнә шулай кабул итә. Бу хакта Россиянең төрле почмакларыннан «Тормыш» газетасына яуган кайгылы телеграммалар сөйли. Газета баштарак «Сибирия»нең бөтен традицияләрен саклый, дәвам итә: «Сибирия»нең байтак хезмәткәре дә ияреп килә, шуңа күрәдер инде кайгы уртаклашкан телеграммалар «Тормыш»ка җибәрелә. Телеграммалар Мәскәүдән, Казаннан, Петербургтан, Томскидан, Оренбургтан, Минусинскидан... бик күп, бик күп шәһәрләрдән килә.

Барлык татар газета-журналлары некрологлар баса. Берсендә М. Гафури болай дип яза: «Фатыйма-Фәридә ханымның вафатына бар күңелемнән хәсрәтләнәм. Ул Россия мөселман хатын-кызлары арасында иң якты йолдыз иде». Некролог хәтта В. И. Ленин «иң киң таралган газета» дип санаган «Русское слово» газетасында да чыга.

Фатыйма-Фәридә эшчәнлегенең кайсы гына ягын алмыйк, анда без хатын-кызлар бәхете өчен ялкынлы көрәшче сыйфатлары күрәбез.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## Мансур Вәлиев

# МӘХӘББӘТ ЯШӘРГӘ ТИЕШ!

Милләтебез хәлләре...

Илдә революция бара.

Әйе-әйе, чып-чын революция бара!

Безнең өчен 1905 елда ук башланып киткән революция ул... Һәм без тагын шунысын да яхшы хәтерлибез: озак еллар буена дәвам иткән Сталин террорыннан соң, илленче елларның уртасы җиткәндә, Н. С. Хрущевның шәхси каһарманлыгы аркасында яңадан да бер мәртәбә җанланып алган иде ул...

Менә хәзер, инде бу юлы, ул канатларын киң җәйде. Тормышыбызның бик күп тармакларына үтеп керде.

Без, татарлар, революцияләрнең һәммәсенә актив рәвештә катнашып килдек. Чөнки бик күп нәрсәдән мәхрүм идек. Безнең яулап аласы хокукларыбыз күп иде!

Бу революциядән дә күпне көтәбез без. Бик күпне! Чөнки Сталин кыяфәтендә ил башына менеп утырган явызлык безнең милләтне — татарны — бөтенләй дә бетерергә теләде. Татар өчен, Иван Грозныйдан кала, икенче палач булды ул.

Брежнев исеме аша идарә иткән явызлык исә безнең халыкны бүтәнрәк юл — тыныч агрессия юлы белән юк итәргә керешә. Ул ассимиляция процессын, илдәге төрле милләтләрне бергә кушу, бутау процессын бик тә ашыктырды. Аеруча Татарстанда кызулатылды бу хәрәкәт. Әнә шул максат белән безнең республикада бихисап зур предприятиеләр салынды. Алар күп итеп, берсе өстенә икенчесе салынды! Эшләү өчен исә илнең төрле почмакларыннан үзенә урын таба алмый йөргән тамырсыз адәмнәр ташкыны агылды.

Нәтиҗәдә, республикада яшәүчеләр арасында татарлар биләгән өлеш тагын да кечерәйде. Бу — аерым игътибарга лаеклы бик тә зур нәрсә. Бу — татарларга милләт буларак үсә алу өчен гарантия бик нык кимү дигән сүз. Милләтнең яшәү ышанычы азаю дигән сүз!

Шушы зур куркынычны әле күпләр аңлап бетермиләр. Аңлап бетермәгәч, тиешле игътибарны да бирмиләр. Әнә шул сәбәпле, фикер ачыграк күз алдына килсен өчен, бер чагыштыру китереп үтик.

Мисал өчен бер гаиләне алыйк. Аның үз өе яисә фатиры була. Шул өйдә яисә фатирда әлеге гаилә матур гына гомер кичерә, үз өендә үзенчә яшәп, әйбәт кенә көн күрә. Сөенә-сөенә бала-чагалар үстерә. «Минем ныклы киләчәгем бар»,— дип уйлау аңа шатлык бирә, тагын да матуррак яшәү өчен көч һәм дәрт тудыра. Мондый кеше инде җирдә очраклы зат булып яшәми. Аның гомере мәгънәле була, ямьле була. Ул — мәңгелеккә баручы нәселнең бер бөҗрасы шикеллерәк.

Инде хәзер күз алдына китерик: шул фатирга, болар өстенә тагын бер гаилә, бөтенләй чит гаилә килеп керде, ди. Алар белән бергә даими рәвештә яши башлады, ди... Һәркем алдан ук белеп тора: мондый очракта инде тормышның бөтенләй рәте китә. Яшәү — яшәү булмый, балаларга үзенчә тәрбия бирү турында инде әйткән дә юк!

Соңгы елларда кайбер кешеләр тарафыннан алга сөрелә торган «уртак өй» дигән сүз — әнә шундый ситуация бит инде ул! Бер үк өйдә әллә ничә гаиләне бергә яшәтергә маташу...

Балтик буе республикалары, Молдавия һәм башка халыклар менә ни өчен борчыла башлады хәзер. Кешелек табигатенә каршы эш эшләнгәнгә күрә, бик дөрес борчылалар алар.

Аннан соң, әйдәгез әле, җитди кешеләр булып уйлап карыйк. Милләтнең Җир йөзендә **бер** ышанычлы урыны булырга тиешме, юкмы?! Милләт үзе теләгәнчә һәм иркенләп, кысылмыйча, башкалар белән бәхәсләшмичә-тарткалашмыйча, үз көенә генә яши алырдай андый **бер** урын — Ватан булырга тиеш. Бу бит инде бер дә бәхәсле фикер түгел кебек. Ә без соңгы елларда тырыша-тырыша шуның киресен расламакчы булабыз. Ягъни, бер өйдә ике яки берничә гаилә яшәргә тиеш дип расламакчы булабыз. Шулай итеп, объектив чынбарлыкның объектив таләпләренә каршы барабыз. Ләкин вакыт агышы безне тора-бара барыбер киресенә ышандырыр: без бу мәсьәләдә дә үзебезнең ялгышыбызны аңларбыз — һәр халыкның, һәр милләтнең үзбаш булып, бәйсез рәвештә яшәвенә юл куймыйча булдыра алмабыз!

— Әйе, безнең бу революциягә өметләребез зурдан.

Ләкин шунысы бар: өметләнеп кенә ятсак, безнең милләтнең хәле тамчы да үзгәрмәячәк. Хәтта әле алай гына да түгел: көтеп яту безне агым буйлап кире якка таба алып китәчәк. Үткән еллар кочагына таба!

Димәк, хәзер безнең — нәкъ көрәш вакытыбыз! Җиң сызганып эшләр вакытыбыз һәм милләт өчен куанычлы олы-олы яңалыкларны яулап алу вакытыбыз!

Моңа кадәрге революцияләрнең, көрәшләрнең иң алгы сафында барган татар шигърияте өчен бүген — көрәшнең бигрәк тә зурысы, мөһиме, әһәмиятлесе! Шуңа күрә, без биредә шигъриятнең хәзерге хәлен кыскача гына тикшерергә алынгач та — иң башта аның, шигъриятнең, көрәшче сыйфатын барлау сорала кебек.

Чыннан да, бу революциянең — Яңарыш революциясенең көрәшчесе буларак татар шигърияте ничек яши? Анда бүгенге зур көрәшнең ялкыны дөрлиме? Бүгенге шигърияттә көрәшче йөрәге тибәме?

Юк, әдәбиятның һәм, аерым алганда, шигъриятнең эстетик ягы өчен җан атучылар биредә борчылмасыннар. Без вульгар социологизм сызган юлдан китеп, әсәрләрнең бары тик идея ягын гына күздән кичерергә теләмибез. Без биредә, эстетик якны да күздән ычкындырмастан, шигырьдә бүгенге зур көрәш ялкыны ни дәрәҗәдә чагылуын күзәтеп чыгарга гына телибез. Хәер, «көрәш ялкыны» дигән сүз бер үк вакытта эчтәлек мөһимлеген дә, хис кайнарлыгын да, димәк, әсәрнең укучыга тәэсир көчен дә — һәммәсен дә берләштерә түгелме соң?!

## Шигъриятебез хәлләре...

Газета-журналларыбызның соңгы саннарына күз салыйк.

Сөбханалла, әле тәмам канәгать кылырдай ук булмаса да, әдәби матбугатыбызның киңәя төшүе сизелә. «Идел» журналыбыз яңа революция җимеше булып туды. Ә хәзер ул үзе, басылып чыккан беренче саннары белән үк, үзендәге әсәрләрнең эчтәлеге белән үк, Яңарыш революциясен көчәйтергә булыша. «Идел»дә революцион аһәң шактый көчле. Моңа карата без, картларча әйтсәк, «Бәрәкалла!» — дияргә тиешбез.

Шулай ук «Социалистик Татарстан»ыбызның да соңгы елларда халык, милләт җанына якынаюы нык сизелә. Мәкаләләрдә һәм шигъри әсәрләрдә бигрәк тә күренә. Ә «Әллүки» кушымтасы исә тәмам халык күңеленә сары май булып ятты! Язучылар инде аны хәзер булачак әдәби газетаның бик әйбәт үрнәге итеп күрәләр.

Шулай да, «Татарстан яшьләре» бүгенгәчә татарча басмалардан иң демократик юнәлештәгесе булып кала бирә. Гәрчә «Идел» бу яктан аның үкчәсенә басып килсә дә, әлегә беренчелек барыбер яшьләр газетасында торып кала. Чөнки ул төрле катлам укучыларының мәнфәгатьләрен киңрәк чагылдыра. Хис, йөрәк аша тәэсир итүче язмаларга күп урын бүлеп тә газета дөрес эшли. Чөнки безнең халкыбыз, нигездә барыбер көнчыгыш милләте. Ул дөньяны, чынбарлыкны күбрәк йөрәк һәм хис аркылы кабул итеп яши. Икенче яктан, бүгенге укучыларның иң зур катламы — хатын-кызлар. Ә алар, белгәнегезчә, бик тә үзенчәлекле психологиягә ия. Минемчә, матбага әһелләре укучылар катламын тулырак иңләү өчен тырышканда боларны истә тотарга тиешле.

Шулай итеп, газета һәм журналларыбызның яңа саннары, дидек...

Аларда бүген дәвам итүче революция аһәңе, чыннан да, шактый гына сизелә икән бит. Әйдәгез, мисалларга мөрәҗәгать итик.

*Беткән Хәтер, онытылган Тарих!*
*Тәрәзәсез-нисез туң йортта*
*Шат, бәхетле булып яшәү җиңел,*
*Әверелсәң гамьсез маңкортка.*

*Минме синең улың, мокыт кавем?*
*Кем син? Кайда? Кемгә хезмәтең?*

*Үзеңә тиң дөрес тарихыңны*
*Кайсы гасырлардан эзләттең?*

Бу тавышны, бу шигъри аһәңне таныйсызмы?

Татар халкының яшь буыны исеменнән әлеге ялкынлы сүзләрне шагыйрь Ркаил Зәйдуллин әйтә. Кискен итеп, бәгырьләргә үтәрлек итеп әйтә! Һәм без, үзебезне татар диеп йөрүчеләр, намуслы яшь буынның югарыдагыча чагылган кискенлегенә лаек. Безнең моңа кадәр дәвам итеп килүче битарафлыгыбызга — яшьлек исеменнән. Намус исеменнән бары тик әнә шундый җавап кына була ала!

Ркаилнең «Идел»дә басылган (2 сан, 1989 ел) «Күңелемдә яшьни яшеннәр» циклында көчле шигырьләр, ялкынлы әсәрләр тагын да бар. Торгынлык чорын кыш белән чагыштырып язылган шигырьдә, мәсәлән, мондый юллар бар:

*Яз килгәндә бераз җанда*
*Уяныр китә өмет.*
*Тирәкләрдәге бөреләр*
*Күккә үрелгән кебек,*
*Нурга төрелгән кебек.*

Бу һәм башка шигырьләрнең тирән мәгънәле эчтәлеге белән танышуны укучының үзенә калдырып, биредә үзебезнең бер зур куанычыбызны гына әйтеп узасы килә. Шагыйрь зур Шигърият юлына килеп чыккан. Иң авыр, иң олы каршылыклар тупланган юлга аяк баскан. Талант һәм каһарманлык иң күп сорала торган юл ул... Бу гасырның башында Тукайлар атлаган юл! Гасырның ахырында, инде гасыр тәмамланып килгән чагында, Тукайча әнә шундый кыю аһәңле яшьләрнең ул юлны дәвам итүе — татар укучысына гына түгел, ә тулаем татар милләтенә дә бик зур куаныч!

*Йөрәгендә моның, җелегендә*
*Ашкын атлар, алар тик тормас.*
*Баш бирәчәк түгел,— диде хуҗа,—*
*Бер ычкынса, бүтән тоттырмас.*

«Ашкын ат» дип исемләнгән бу шигырьнең авторы — сезгә бик таныш булган талантлы шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин. «Казан утлары» 1989 елгы 7 санында аның тугыз шигырен урнаштырган. Кыска гына итеп әйткәндә, К. Сибгатуллинның бу бәйләмендә заман рухы көчле, аның бөтен иҗатына хас булганча, халыкчанлык көчле. Чор күренешләре шигырьләр аша тирән фәлсәфи мәгънә ала. Анда «Яңадан сайлау» сыман көн кадагына сугучы әсәрләр дә бар, «Бурыч» шикелле мәңгелек темага багышланганнары да очрый.

*«Бурычлы мин», диләр гомер буе,*
*«зур бурычлы мин», дип яшиләр...*
*Бурычларын түләр вакыт җиткәч*
*бурычлылар бер сүз дәшмиләр.*

Ә өченче бер шигырендә К. Сибгатуллин бүгенге кайгылы-гарасатлы чор кешеләренең күңел төпкелләренә үк үтәрдәй сүзләр әйтә:

*Мәрхәмәтең, изгелегең кала*
*җанда балкыш булып.*
*Җирдә кылган бөек эшең кала*
*күктә алкыш булып.*

. . . . . . . . . . . .

*Кешеләрнең хыянәте кала*
*синдә нәфрәт булып.*
*Якыннарның бәхетсезлекләре*
*кала хәсрәт булып.*

Әйе, шагыйрь безнең тел очында торганны яза. Чыннан да, дөньяда нинди генә үзгәрешләр булса да, кешеләрнең кылган гамәлен билгеләү өчен һәрчак әнә шул ике сүз кирәк булачак. «Изгелек» һәм «әшәкелек» дигән сүзләр. Кешеләрнең язмыш сукмаклары гел Изгелек дигән тау белән Әшәкелек дигән упкын арасыннан бара!

Кадыйр Сибгатуллинның яңа бәйләме шагыйрь иҗатында икенче сулыш ачылу турында сөйли. Шул ук вакытта бу — Яңарыш чорының шифалы җилләре җимеше дә.

Шул ук «Казан утлары» журналының узган елгы 8 санында басылган шигырьләрендә Лена Шакирҗанова үзенең илһам юлына тугры калып, күңеленең яңа серләрен ача. Бередә: туры сүз, намус, ил кайгысын уйлау һәм әлбәттә — сөю! «Сөю» диган һәйкәлгә эпиграф итеп язардай ялкынлы сүзләр:

*Көлдән гөлләр яралт,*
*кабат ярат,*
*сүнеп калма йөрәксезлектән!..*

Шагыйрәнең «Социалистик Татарстан» битләрендә дә кыю, революцион фикерле әсәрләре еш басыла тора. Иң мөһиме, ул халык йөрәгендәгене, безнең йөрәк түрендәгеләрне төп-төгәл итеп, бик тә тәэсирле итеп әйтеп бирә. «Туган телгә», «Кәгазь кадере»— әнә шундыйлардан.

*Халкым теле — хак телем син,*
*йөрәк телем.*
*Киләчәгем өчен мәңге*
*кирәк телем!!*

Тагын бер шагыйрь турында әйтми китү мөмкин түгел. «Социалистик Татарстан» безнең зур шагыйребез Мөдәррис Әгъләмовның «Исәннәр турында балладалар» циклын баса башлады. Миңа ул балладаларның әле дөньяга чыкмаганнарын да укырга туры килде. Алар — чын мәгънәсендә көрәшче токымыннан яралган балладалар. Революцион рухлы, кайнар хисле әсәрләр алар!

Газета-журналларыбызда соңгы вакытта басылган андый шигырьләрнең бередә барысын да китерә калсак — шактый мәйдан кирәк булыр иде. Әйбәт шигырь язып матбугатта бастырган, ләкин бары тик урын җитмәү аркасында гына исеме бу мәкаләдә телгә алынмый калган бүтән шагыйрьләр миңа үпкәләмәс дип ышанам. Соңгы елларда безнең поэзия, чыннан да, шактый җанланды, кайнарланды, активлашты. Югарыда без моның кайбер мисалларын күреп үттек. Алар күп.

Бусы шулай. Шигърият, һичшиксез, активлашты. Ләкин, мин шул фикер белән бергә, тагын шунысын да әйтми китү ярамый. Бездә кайчак поэзияне бөтенләй тәнкыйтьтән өстен итеп куярга теләү очрый. Бигрәк тә журналда «Заман һәм шигырь» диган дискуссия булып, аның барышында бүгенге кайсыбер шагыйрьләр колагына шактый усал сүзләр әйтелгәннән соң, шуңа җавап рәвешендәрәк калкып чыкты сыман әлеге тенденция.

Ләкин кистереп әйтергә кирәк: җанлану һәм активлык сизелүгә карамастан, әле безнең поэзияне бөтенләй кимчелексез дип булмый. Ә аз гына элегрәк, торгынлык елларында һәм аның ахыргы чорында, безнең шигърияттә борчылырдай хәлләр тагын да күбрәк иде! Шуңа күрә теге яки бу кеше сүз алып, шигъриятебезнең аерым кимчелекләрен күрсәтә икән, аның бу адымын «тулаем поэзиягә кизәнү» дип аңлатырга ашыкмасак иде. Кимчелекне күрсәтү — шигърият үсеше өчен кирәк! Әлбәттә, бередә уңай якларга да басым ясап барылырга тиеш.

Яшь шагыйрьләрбез иҗаты турында сүз кузгалгач, бередә тагын шунысын да әйтеп китү сорала. Алда билгеләп үткәнебезчә, тулаем алганда бик тә кызыклы булып чыга башлаган «Идел» журналының кайбер әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә яшь шагыйрьләр иҗатын бер дә кимчелексез итеп күрсәтергә тырышу тенденциясе сизелә. Беренче санда урнаштырылган Ф. Зөлкарнәев мәкаләсе һәм дүртенче сандагы Ә. Рәшитов язмасы әнә шундыйрак тәэсир калдыра. Әлбәттә, яшь шагыйрьләрне мактау — җиңел эш. Авторлар алдында да яхшы буласың, укучыларда «әйбәт кеше» диган тәэсир дә калдырырга мөмкин... Ләкин әдәби тәнкыйтьнең бурычы — яхшы якны да, җитешсез якны да гадел рәвештә әйтү. Һәр икесен дә билгеләү! «Казан утлары»ның 1985 елгы 1 һәм 1989 елгы 6 саннарында басылган мәкаләләрдә яшь шагыйрьләр иҗатының уңышлы һәм җитешмәгән яклары хакында сүз бара. Һәр ике як бергә карала ул мәкаләләрдә. Ф. Зөлкарнәев белән Ә. Рәшитов исә бу яшь шагыйрьләрнең әлеге мәкаләләрдә әйтелгән йомшак якларын юк итеп күрсәтергә тырышалар. Фактта аларны гел мактауны гына таләп итәләр. Болай эшләү — дөрес түгел. Чын әдәбияттан читкә алып китә торган мондый юл белән килешеп булмый. Без иҗатчыларыбызның уңышлы һәм уңышсыз якларын үз вакытында әйтә барырга тиешбез! Җитәр, торгынлык чорында инде бик күп макташтык. Тик эшебез генә алга бармады. Яшь шагыйрьләрнең үзләре өчен дә, гел мактауга караганда, ике якны да билгеләп бару, һичшиксез, файдалырак. Алар үзләре дә моны яхшы аңларга тиешләр.

Бүген — реаль тормышны, аның каршылыкларын һәм кимчелекләрен чын хәлендә әйтү һәм язу мөмкин булган дәвердә, үткән чордан ияреп килүче мондый сабаклардан без гыйбрәт алырга тиешбез.

Әйе, авырткан-сызлаган җирләребез турында ачыктан-ачык сөйләшер көннәр килде. Әдәби иҗат мәйданына аяк баскан җегетләргә халыкның олы мәсьәләләрен күтәреп чыгу көне килде. Тагын бер мәртәбә булса да янә кабатлыйк: Тукай кебек кыю рәвештә күтәрер вакытлар җитте! Яшәүнең олы дәреслеген генә төп хакыйкать дип саный торган, бары тик шуңа гына табына торган көннәр бу!

Иҗаттагы егетләрнең чыннан да җегетлеге сынала торган чак бу!

Ә соң кызларыбыз? Алар соң ни дип җырлый бүген?

## Урман җыры

*езнең бәхет — шаулы урман иде...*

Алсу Гайфуллина.

Яшь шагыйрә Алсу Гайфуллинаның узган ел басылып чыккан беренче китабына исем бик тә дөрес куелган — «Урман җыры». Бу исемдә халык һәм җәмгыять бәхетенең бердәнбер ныклы җирлеген, бердәнбер дөрес нигезен әйтеп бирү дә бар... Бу исемдә табигатьнең шигърият өчен бигрәк тә төп таяныч икәнлеген раслау да бар. Шул ук вакытта шигъриятнең үзен серле урман белән чагыштыру, аларның икесен тәңгәлләштерү дә күңелгә хуш килә. Чыннан да, ихлас шигърият ул урман җыры сыман була. Бүгенге тормыш һәм табигать шавы шагыйрьләр йөрәгендә әнә шундый калын урман аһәңнәре сыман тирән серләр иштетереп шаулый. Җырлый!

*Их, минә икәү булсамы*
*Бу тормыш дигәннәре!*
*Берсендә утыртыр идем*
*Агачлар,—*
*Имәннәрне!*
*Икенчесендә аларга*
*Сөялеп торыр идем.*
*Шул имәннәр арасында*
*Уйланып йөрер идем...*

Ишеттегезме, күрдегезме — беренче юлда ук нинди үзенчәлекле һәм табигый тавыш! Нәкъ менә Алсуның үзенеке булган шигъри аһәң, интонация!

Биредә эш шигырьнең тышкы рәвешендә, формасында гына түгел. Эш шигырь эчендә яши торган үзенчәлекле йөрәктә, натурада, шәхестә! Беренче юллардан ук игътибарны җәлеп итәрдәй әлеге үзенчәлек — әнә шул йөрәкнең ихлас авазы. Бу — яшьлек авазы! Ләкин анда якындагы балачактан килгән самими беркатлылык та чагыла: «Их, минә...» дип башлау — шуның ачык билгесе. «Бу тормыш дигәннәре» — монысы инде акыл ала, ачы сабаклар җыя башлаган, уйлана башлаган кеше сүзләренә күбрәк тартым... Ә инде «агачлар — имәннәрне!» диюдә без кыю, тәвәккәл фикер һәм карар тавышын ишетәбез.

Шигырьдә әнә шундый хәрәкәтчәнлек, активлык көчле. Динамизм көчле. Нәтиҗәдә, әсәрнең тәэсир көче зур.

Әле мисал итеп китерелгән шигырьдә чагылган сыйфат: йөрәкнең бик тә кайнарлыгы, ярсу хисләр, кичерешләр муллыгы, тормыш һәм яшәү күренешләренең әнә шундый кайнар халәттә «эретелеп» бирелүе — Алсуның бик күп шигырьләренә хас. Бөтен шигъриятe өчен хас.

Китапның исеме дә «Урман җыры» дип куелгач, шагыйрә үзе дә урман кызы булгач (Алсу һөнәрен дә табигатькә бәйле рәвештә сайлаган, ул университетның география факультетында укый), китаптагы шигырьләрнең дә күпчелеге, табигый ки, урманга багышланган.

Табигать күренешләре әнә шулай бик тә актив монда. Аларны беркайчан да кешедән аерым күрмисең. Алар шагыйрәнең үз йөрәге төсле леперdәп торалар... Кеше йөрәге белән табигать күренеше бергә тоташып ук китә! Бу ялгануның, бу берлекнең иң ачык мисалы түбәндәге шигырьдер, мөгаен:

*Заманында мин урманны*
*Тузгыган яшел чәченә*
*Ромашкалар кадап куйган,*
*Минем белән һәрвакыт дус*
*Бер кызга тиңли идем.*

Кешеләр һәм тормыш күренешләре хакында язганда да Алсу иң кайнар, иң киеренке ситуацияләрне табарга тырыша. Яшәүнең иң калку чагылышларын эзли, шуларны күзли.

Ә шулай да «Урман җыры»ның иң сокландыргыч һәм иң моңлы өлеше — сөю турында, мәхәббәт турында. Шагыйрәнең андый шигырьләрен мисал өчен китергәндә һич тә тукталып булмый, шуңа күрә берсен тулы килеш укыйк:

*Мин ефәк ак күлмәк киярмен,*
*Чәчемне сибәрмен җилкәмә,*
*Йөгереп каршыңа чыгармын*
*Иртәгә,*
*иртәгә,*
*иртәгә.*
*Яныңда очынып йөрермен,*
*Уралып гаҗәеп челтәргә.*
*«Йа аллам, купсенмә»,— диярсең*
*Иртәгә,*
*иртәгә,*
*иртәгә.*
*Ә бүген, соңгы кат талпынып,*
*Мин кайтам үземнең үткәнгә.*
*Тотып ал син мине, җибәрмә,*
*Яныңнан йөгереп үткәндә.*

Күрдегез: монда «сөю» дигән сүз дә юк. Әмма анда сөйгән йөрәкнең шулкадәр дә балкыган, нурланган халәте бар! Яшьлекнең чын яме, тәме, ләззәте анда. Ашкыну һәм уенчаклык анда. Шигырь үзен укучы кеше йөрәгенә әнә шуларның — яшьлеккә бәйле хисләрнең — барысын да берьюлы бүләк итә! Синеке итә. Менә чын поэзиянең көче кайда!

Әйе, Алсуның беренче китабы кайнар хисләргә бик тә бай. Ул үз укучысын яшь йөрәк кичерә торган дулкынланулар, бәргәләнүләр белән еш очраштыра. «Диңгез булса — шундый булсын, Җанын бәрсен ярларына!» Бу сүзләр аның шигырьләрендә яши торган лирик геройның асыл сыйфатын гәүдәләндерәләр. Китап мәхәббәт лирикасының иң тирән топкелләрендә йөздерә.

*Кочак-кочак*
*мин ягармын учак,*
*Газабымны яндырырга теләп.*
*Тагын-тагын*
*җылысында аның*
*Сине көтеп әрнеп куяр йөрәк.*

Әйе, безнең алда — сәләтле шагыйрә. Чын шагыйрә. Яшәү дигән күренешнең бик күп драма һәм трагедияләренә сизгер шагыйрә. Әле алдагы иҗаты белән тагын да күбрәк яңа, гүзәл җырлар бүләк итәчәк шагыйрә.

Кайчагында яшь шагыйрьгә, тормыш турында тулаем карап уйлануга күчкән чакларда, вакыт-вакыт шигъри энҗеләргә барып җитмичә дә кала. Андый әсәрләрдә барыбызга да билгеле булган таныш сүзләр тезелеп китә, ә хис кузгалмый. Алсуның иң әйбәт шигырьләрендә була торган кайнар кичереш андый әсәрләрдә күренми. Китапны ачып җибәргән берничә тезмә әнә шундый тәэсир калдыра. Болар инде яшь шагыйрәнең яшүсмер чак мавыгуларыдыр, мөгаен. Аларга шулай дип карарга кирәктер. Балки, аларны китапның иң беренче рәтенә чыгарып куймау дөресрәк булыр иде...

Элекке еллар, торгынлык чоры булса, Алсуның бу китабындагы байтак кына шигырьләрне кайберәүләр «альбом шигырьләре» дип кенә җибәрер иде. Ләкин без хәзер андый шигырьләргә дә бераз бүтәнчәрәк карарга тиештер.

«Елак шигырьләр» дип тамга сугылган әсәрләр матбугаттан кире борылганда, гадәттә, автордан зур социаль-фәлсәфи мәгънәле әсәрләр таләп ителде. Ләкин үз йөрәге белән әле ул дәрәҗәгә күтәрелеп җитмәгән яшьлек андый әсәрләрне каян алсын соң?! Менә шуннан китте инде ихласлыктан баш тарту, елак йөрәк шигырьләреннән баш тарту хисабына бик тә акыллы, бик тирән фикерле әсәрләр язарга омтылыш. Алар күбрәк очракта акыл белән, баш вату юлы белән иҗат ителделәр...

Нәтиҗәдә, күпләр шигърияте байтак кына дәрәҗәдә үзенең чын юлыннан, асыл сукмагыннан читләште. Салкынлык ягына таба авышты. Поэзиябезнең укучы каршында абруе да кимеде... Әйе, абруй төшүгә бер яктан буш, көпшәк тезмәләр булышса, икенче яктан салкын, хиссез юллар нык ярдәм итте.

Хәзер — яшәвебезнең үзәгенә кешелек сыйфатлары куела башлаган чорда — безгә ихласлык кадерен белер чак җитте. Чөнки ул — кешенең кешелеген билгеләүче иң асыл сыйфатлардан берсе, иң мөһиме. Алсуның бу китабындагы үтә ихлас шигырьләр дә, кайчак бер кеше язмышын гына күздә тоткан сыман булып тоелган әсәрләр дә, бүген «альбом шигырьләре» дип түгел, ә яшь йөрәкнең садә хисләре дип кабул ителергә тиеш. Салкын акыл белән генә яшәүче, йөрәкләре инде картаеп килүче кайберәүләр андый саф хисләрнең кадерен дә, бәһасен дә онытмаска тиешләр! Поэзия өчен, ә бигрәк тә татар поэзиясе өчен, робот акыл уйлап чыгарган авыр метафораларга караганда, тере хис күпкә кадерлерәк, кыйммәтрәк. Чөнки аның җаны бар! Ә җаны бар нәрсә — ул үсә ала! Ул киләчәктә зур була ала!

Әйе, бу бит әле беренче китап. Без хәзер беренче китапларны алай еш күрмибез. Җиде миллионлы татар халкы өчен бердәнбер булган китап нәшрияты елга 3-4 тән артык чыгармый беренче китапларны. Шулай булгач, бу очрак инде татар укучысы өчен икеләтә бәйрәм төсен алырга тиеш. Бердән, яңа авторның тәүге китабы, шигырь сөючеләргә тәүге бүләге. Ә икенчедән — анда һәркемнең йөрәген кузгатырдай ялкынлы әсәрләр тупланган. Үз кулына алып укыган кеше ул шигырьләрне язган авторга, һичшиксез, рәхмәт сүзен әйтәчәк!

## Язгы ярсу

Фирая Зыятдинова исеме безнең халкыбызга барыннан да бигрәк җыр аша таныш. Композитор Луиза Батыркаеваның Фирая сүзләренә язган «Мин сине шундый сагындым...» җыры замананың катлаулы чынбарлыгында гомер итүче бөтен гашыйк йөрәкләрнең дә эчке халәтен әйтеп бирә төсле. Сөйгән кешеңне үтә нык сагыну да, ялгыз йөрәкнең үз тиңен көткән чагындагы төрле-төрле шик-шөбһәләре дә, куркү-борчулары да — һәммәсе, һәммәсе гаять тә нечкә итеп, бик тә нәфис моңга төреп әйтелә анда! Аннан соң ул җырның сүзләре белән көе бик тә тәңгәл килгән, алар бер-берсенә шулкадәр дә ятышып тора! Инде мәшһүр җырчыбыз Айдар Фәйзрахмановның ягымлы, йөрәккә ятышлы лирик аһәңендә дә яңгырагач — «Мин сине шундый сагындым...» камиллекнең иң-иң югары дәрәҗәсенә менеп җитә төсле. Тыңлаучының күңел дөньясын тоташы белән, бер генә тыныч почмак та калдырмыйча, тулысынча айкап чыга ул җыр, ул моң!

Ә китапларына килсәк, шагыйрә үзенең «Матур буласым килә» дип исемләнгән китабын 1986 елда чыгарган иде. Ул китап кибетләреннән тиз югалды.

1988 елда шагыйрәнең икенче китабы да басылып чыкты. Аның исеме «Язгы ярсу». Фирая Зыятдинованың бу китабы тәнкыйтьче Фәиз Зөлкарнәев редакциясендә чыккан. Шигырьләрнең урнаштырылуында бу бик тә сизелә. Китапның беренче битен ачуга ук укучы күңеле моң һәм кичерешләр дәрьясына килеп эләгә, хиснең кайнар ялкыннары белән очраша. Тәүге шигырьнең исеме үк «Җыр ул — минем җаным...» дип билгеләнгән.

*Элек-электән үк*
*Халык белеп әйткән:*
*«Тән ярасы нәрсә?!*
*Җан ярасы хәтәр!»*
*Күбәләктәй җанны*
*Тәннән өстен куйган.*
*Кайчак кеше җаны*
*Тик бер җырга сыйган.*

Моң һәм хис дөньясы булган шигъриятне Ф. Зыятдинова әнә шулай яза. Бу мохитне гаять тирәннән, эчкәредән тою аның шигъриятендә ачык сизелә.

Бүгенге замандаш йөрәген яулау өчен ни кирәк?

Шигырь язган кешенең үз күңеленең хискә, моңга бик тә бай булуы кирәк. Беренче карашка үтә гади сыман тоелган әлеге таләпне кайчакларда санга сукмау да сизелә. Янәсе, аны кем белмәгән инде! Аны кем аңламый инде! Ләкин үз күңелендә моң дигән изге халәтне гомерендә бер мәртәбә татып карамаган ничәмә-ничә кешенең шигырь язып, шагыйрь булып йөрүен беләбез бит! Шуңа күрә шигъриятнең бу нигез таләбе безнеке сыман чуалчык заманда һич тә игътибардан читтә калырга тиеш түгел!

Моңга, хискә ия шагыйрьнең исә үз иҗатында тулысынча ачыла алуы кирәк. Үз күңеленнән ташыган кичереш ташкынына тулысынча иярә алуы кирәк. Шулай булса — инде аңа без дә ияреп китәчәкбез, битараф калмаячакбыз.

Ф. Зыятдинованың ихласлыгы, эчкерсезлеге укучыны үзенә тиз ияртә.

*Болын буйлап бер кыз кила*
*Унсигезда ул. Кола...*
*Мин дә елмаймакчы булам.*
*Никтер елыйсы кила.*

. . . . . . . . . . . .

Моңга булган зур тугрылык шагыйрә йөрәген менә нинди кыюлыкка да алып бара! Әлеге батырлыкның ни бәһа торганын укучы, әлбәттә, бик яхшы аңлап тора.

Бу китапта без инде сөю хисенең бүтән төрләрәген күрәбез. Ул хис инде тормышның, көнкүрешнең бихисап ваклыклары белән бәйләнгән, шуларга ялганган. Ярсу тай кулга ияләндерелгән шикелле, яшьлекнең ярсу хисләре дә «тормыш» дигән авыр да, мәгънәле дә арбага җигелгән. Ул хәзер, югарыга ашкынудан бигрәк, әлеге арбаны алга таба тартырга тиеш. Яшәү кануны шулай таләп итә... Татар хатын-кызлары гомер-гомергә изге итеп үтәгән авыр вазифа бу. Милләт өчен, халык өчен кадерле олы хезмәт, гаять кадерле эш ул. Әнә шул процесста тагын — үзәк өзгеч шигырь юллары пәйда була:

*Үтә гомер, сизелми дә*
*Сизелми дә үтә көннәр...*
*Гел көрәш тә, гел бәрелеш —*
*Ничек түзә нәфис гөлләр?!*

Замананың әлеге нәфис гөлләре янәшәсендә барган байтак кына көрәшләр күренә бу китапта. Шагыйрә йөрәге — аларның урта бер җирендә. Үзенә бик күп төрле вазифалар алган бүгенге хатын-кыз йөрәге ул. Шул ук вакытта без аның нәкъ менә татар хатыны икәнен дә белеп, күреп торабыз. Милли сыйфатлар шигърият аша шактый ачык гәүдәләнә. Мисал өчен, бер шигырендә Фирая: «И көйдерә рәхимсез ут,— Көйдерә йөрәк турын... Ничек итеп ялгыйм икән Өзелгән кояш нурын?!»— дип бик тә гаҗиз хәлдә калса, бүтән бер шигырендә инде ул болай дип белдерә:

*Нәрсә кирәк ул болытка,*
*Нәрсә калган күгемдә!*
*Таратыйм әле мин аны*
*Яшен булып телим дә!*

Бу тәвәккәллектә дөнья каршысында югалып калырга яратмаган үзебезнең татар хатын-кызлары холкы ярылып ята. Әйе, бирелә бик күбесе милли чынбарлыктан алынган: хатын-кызга игътибарлы һәм җылы караш җитмәү дә, шул сәбәпле гөлләрнең җылыга тилмерү күренешләре дә, баштан ашкан мәшәкать арасына йөрәк хәлләре килеп катнашу да, дөнья агышының бер мәлгә эздән чыккандай булып алуы да, оялчан холык-фигыль дә... һәм янә йөрәкнең үзен сиздерә башлавы, күкрәк эчендәге читлектә сулык-сулык килүе...

Китапны укып чыккач та шуны әйтергә була: шагыйрә йөрәге көнкүреш гадәтилегенә баш бирмәс өчен, үзенең ихласлыгын, кайнарлыгын, эчкерсез-садәлеген саклап калу өчен көрәшә.

Әмма тормыш ваклыкларына һәм, алардан да куркынычрагы, еллар агышына каршы торуы кыен. Вакыт-вакыт чын шигырь үк булып җитмәгән кайбер тезмәләрнең китапка үтеп керүен дә, бер яктан, әнә шуның белән аңлатырга буладыр... Турыдан-туры үгет-нәсихәт сүзләре дә тешкә тигәләп уза...

Ф. Зыятдинова иҗат дөньясының серләрен, иҗат газапларының чын бәһасен бик яхшы белә. Бу хакта ул шактый гына шигырьләр дә яза. Тик шагыйрәнең яңа китабы уңае белән язылган бу күзәтүебезне «Шагыйрь» дигән әсәр юллары белән тәмамлыйсы килә:

*Аллага табынган кебек,*
*Кояшка табына ул.*
*Балакай гына очкыннан*
*Ут булып кабына ул.*

## Хәтер тәрәзәләре...

Шигырь сөючеләргә моңа кадәр дә үзенең күп кенә китапларын бүләк иткән шагыйрә Клара Булатова узган елда (1989) әнә шулай дип исемләнгән яңа китабын чыгар-

ды. Хәтер тәрәзәләре... Әйе, ике сүз дә бик саллы. Ә алардан хасил ителгән яңа сүз, яңа төшенчә исә тагын да саллырак, тагын да мәгънәлерәк. Ул — хәтер тәрәзәләре аша яшәеш күренешләренә күз салырга, кадерле уйлануларын безнең белән уртаклашырга ниятли.

Әйдәгез, без дә шагыйрәнең хәтер тәрәзәләренә багыйк. Укучының сизгер күңел күзе ниләр күрә ала соң анда?

Бик тә шигъри тасвирланган һәм тәэсирләндерерлек килеп чыккан вакыйгалар, күренешләр шактый гына очрый бу китапта. Ләкин шулай да шагыйрә туган якка, җанга якын урыннарга багышланган әсәрләрен укучыга иң башта тәкъдим итә. Аларга китабының иң беренче битләрен багышлый. Кайбер авторларның җыентыкларын укый башлагач, андый әсәрләрнең гадәт буенча гына иң алга чыгарып куелуын сизәсең. Андый әсәрләр, гадәттә, темасы өчен генә алгы планга чыгарылалар. Шундый хәйлә, алым безнең редакторлар тарафыннан да шактый яклау таба. Ләкин кызганыч, байтак очракларда ул әсәрләрне үтеп чыгуы, үтеп китүе кыен була. Алар күп чагында ниндидер бер мәҗбүрият кушуы буенча гына язылганлыкларын сиздереп торалар...

Ә биредә, Клара Булатованың яңа китабында, алар — иң изге, иң кадерле сүзләр сыман кабул ителә. Шагыйрәнең туган җиренә, туган халкына карата үз йөрәгендә олы мәхәббәт хисе йөртүен бик дәлилле раслыйлар.

*Энҗе сипкән, чык төшкән,*
*Дога иңгән һәр төштән*
*Чишмә типкән җирем син;*
*Кер чайкаган инештән*
*Челтер-челтер көмештәй*
*Көйләр откан җирем син.*

Шушы берничә генә юлда укучы үз туган җиренә олы мәхәббәт уятучы, аны сөю тәрбияләүче нинди нечкә агым белән очраша! Игътибар итегез әле: иң беренче итеп «энҗе сипкән, чык төшкән» сүзләре кулланыла. Бу бик матур чагыштыру туган якның иртәнге гүзәл бер манзарасы гына түгел бит! Биредә әнә шул «энҗе» дигән сүз аша туган якның кадере дә, кеше өчен үтә мөһимлеге дә сеңдерелә... Ә инде икенче юлдагы «дога иңгән» тәкъбиренең нинди җитди сүз булуы барыбызга да мәгълүм. Без инде аның күңелләрне буйсындыручан көчен беләбез. Биредә шагыйрә әлеге тәкъбирне кулланып бик тә ота. Чөнки ул сүзләр, ул тәкъбирләр — безнең тормышның аерылгысыз өлеше. Ата-бабаларыбыз һәм бүгенгебезнең рухи тамыры ул.

Кыскасы, нибары бер строфада туган якның җанга якын, кадерле чынлыгы ачыла. Шигырь укучыны үзенең туган авылына алып кайта. Аны үз авылының яшел чирәмендә ялан тәпи килеш китереп бастыра. Туган җир җылысын, дымын тойдыра. Әнә шулай итеп сиңа сихәт, ныклык иңдерә. Бу әхлакый һәм рухи ныклык кына түгел, ә чын мәгънәсендәге, туп-туры мәгънәсендәге физик ныклык та! Хәзерге медицина җирдә ялан тәпи йөрүнең кеше өчен бик кирәк булуын инде, ниһаять, аңлый башлады. Моны без дә истә тотарга тиеш!

Әйе, шагыйрәнең шигъри осталыгы күз алдында. Аның шигырь юллары төзек, йөгерек. Алар бик җитез, хәрәкәтчән. Ә бу сыйфат исә укучы күңелен җәлеп итүдә мөһим роль уйный. Чөнки рухи активлык дигән сүз бу! Ә андый активлык, көчле хәрәкәт күңелне җәлеп итә, битараф калдырмый?

Әле алай гына да түгел. Гүяки К. Булатова үз укучыларының каршыларына килеп баскан да, ягымлы тавышы белән шигырьләрен укый, күңелләргә сала.

*Ярый әле җырым тына белми!*
*Калган булса әгәр тукталып,*
*Минем җирне ничек сөюемне*
*Кайдан белер иде бу халык?*

Әнә шундый табигый, иркен агыш. Ике якын кеше үзара сөйләшеп утырган төсле гади генә сүзләр... Ләкин, шигырьнең үзенә тарта торган, җанга үтеп керә торган бер көе, бер моңы бар. Музыка коралларының алиһәсе булган скрипка моңы кебек нәфис аһәңе бар аның. Шул аһәң гади генә тоелган сүзләр тезмәсен шигърият дәрәҗәсенә күтәрә. Гади генә тоелган юллардан безнең күңелләргә шигъри тәэсир агыла.

*Юк, мин китмим әле, монда калам*
*Аерылып киткән кошлардан;*
*Җанга кирәк назны, җырны, язны*
*Монда табуыма ышанам.*

Беренче юлларда, инде шактый кабатланган кошлар образы алынуы бераз ошамаса да, өченче юлда шагыйрә безнең игътибарны тартырлык тәэсирле, яңача яңгырый торган сүзләр таба. Шул ук вакытта туган якка бәйле рәвештә лирик геройның үз җаны, үз күңеле дә ачылып китә. Без аның эчке халәтен тоеп алабыз.

Туган ягыбызга, Татарстанга мәхәббәт тәрбияләү чарасы буларак мондый шигырьләр хәзер, билгеле, бик зур роль уйнарга тиешләр. Китапта андый әсәрләр, уңышлы шигырьләр күп. Яшь буын күңеленә шифалы яңгыр булып яусын иде алар. Бүтән мәктәпләрдәге, бүтән урыннардагы тәрбиячеләр, укытучылар актив файдалансын иде андый шигырьләрне!

Туган җирдә яшәүче замандашларыбыз күңелен тирәннән ачучы, психологик яктан нечкә иҗат ителгән шигырьләр дә күп бу китапта. Кышның соңгы көннәрендә шагыйрә күңеленә менә нинди уйлар килә:

*Алданма, кар, гомерең аз*
*Безнең яшьлек шикелле...*
. . . . . . . . . . . . .

*Күбәләк кар, уйнаклап кал*
*Соңгы тапкыр очынып.*

Шагыйрәнең җанын ачучы әсәрләр күп бирелә. Менә тагын бер өзек.

*Гәүдә дә калынаядыр,*
*Йөреш тә салмаклана.*
*Үзгәрәм.*
*Бары йөрәгем*
*Тынгысыз килеш кала.*
*Ул һаман үлчәү сакламый,*
*Карамый уңга, сулга,*
*Ялгыша, яна, алдана*
*Һәм... хаклы булып чыга.*

Бу инде бер К. Булатованың гына түгел, бу инде бик күпләрнең рухи портреты дияргә була. Шигырьдә тасвирланган андый җаннар бүгенге таш-тимер дөньясындагы бер яшел бакча кебек алар! Алар дөньяны чын кешелек матурлыгы белән бизәп, сулышны иркенәйтеп торалар. Мондый чын яшәү мисалы янында исәп-хисапка корылган мескенлекләр түбән кала. Табигый яшәү гүзәллегеннән туган камиллек белән бер генә карьераның да, дан һәм дәрәҗә артыннан кууның да ярыша алмавын шигърият һәрчак раслап килде. К. Булатова шигыре шуның тагын бер мисалы. Ләкин бүген безнең поэзиядә бу юнәлештә көчне күп мәртәбә арттырырга кирәк. Чөнки хәзер таш-тимер ташкыны тормышка гына түгел, ә поэзиянең үзенә дә үтеп керә башлады! Ә бу кеше өчен генә түгел, поэзиянең — бөек Гармониянең — үзе өчен дә һәлакәт дигән сүз!

Туган җиргә, кешеләргә мәхәббәт хисе әлеге китапта хатын-кыз мәхәббәте биеклегенә күтәрелеп тагын да тәэсирлерәк булып яңгырый башлый. Әнә шул мәхәббәт хисе бүгенге кешенең кешелеген ныгытуда, аны үстерүдә булыша. Андагы хис дөньясын баета, зурайта, тирәнәйтә. Менә бер үрнәк:

*Үзеңне күрепләр күзем туймый*
*Янымда син барда җырым тынмый,*
*Син юкта сагыштан җаным тынмый,*
*Синеңчә, бу ни соң, сөю булмый?*

Укучы шундук сизгәндер: бу юлларда без югарыда карап үткән ике шагыйрәнең берсенекенә дә охшамаган мәхәббәт. Бу инде — сабыр, тыйнак, ләкин тирән эчке көчкә, күңел тартылуына нигезләнгән мәхәббәт. Шигырьнең язылу рәвеше дә борынгы шагыйрьләребезнең үлемсез әсәрләрен хәтерләтә. Ерак тарихыбыздан ук килә торган йөрәк моңының иплә-салмак, тирән агышы да бар анда. Дастаннар рухы чагылып китә сыман кыска гына күләмле менә шушы бер мәхәббәт шигырендә!

Күпчелек укучылар инде беләдер: шагыйрә К. Булатова озак еллар буена Әлмәт шәһәрендә укытучы булып эшли. Шуңа күрә мәктәп темасы аның яңа китабында зур гына урын били. Ләкин бу — иҗат өчен азык бирүче гади бер эш кенә түгел. Мәктәп — яшь буынның киләчәк язмышын хәл итү урыны, яшь буын өчен көрәш мәйданы. Моны аңлау бүген бигрәк тә мөһим. Ул көрәштә укытучы — төп фигура, үтә җаваплы вазыйфа башкаручы. Аның яшь кешегә карата сизгер, игътибарлы, нечкә күңелле булуы ае-

руча зарур, аеруча мөһим. Ә инде мәктәптә шагыйрә эшләү — балалар өчен бик тә зур бәхет!

Яшь буынны югалтмау бүген татар халкы өчен бигрәк тә кирәк. Без хәзер буыннарны ялгый алырга тиешбез. Шунсыз халык гомерен озайту мөмкин түгел. Шагыйрә Клара Булатова ничә еллар инде менә шул изге вазыйфаны фидакарьләрчә башкарып килә. Бу эш — үзе зур батырлык түгелмени?! Их, бүтән шагыйрә һәм шагыйрьләребез дә кушылсыннар иде бүген яшь буынны яклау, саклау көрәшенә! Аларның үзләре өчен үк күпме файда булыр иде. Күп әсәрләренә тормыш һәм яшәү чынлыгы кушылыр иде! Конкрет мәгънә артыр иде. Чынлыктан килеп кергән кайнар-кайнар проблемалар булыр иде әсәрләрдә. Шул юл белән алар бүгенге татар халкының реаль хәленә якынрак килерләр иде!

*Апа, хәтерлисез микән*
*Безгә килгән көннәрне?*
*Шул чактан нурга төрдегез*
*Сез безнең күңелләрне.*

Безнең бүтән иҗатчыларыбыз да үзләренә әнә шундый сүзләр ишетә алу хыялыннан ваз кичмәсеннәр иде. Заманның бик реаль көрәшеннән күпләр читтә йөргән чагында (күп чагында иҗатлары да кызганыч чорга кереп баруга карамастан!) шагыйрә К. Булатова үрнәге якты мисал булып балкый!

## Соңгы сүз

Әйе, көрәш һәм мәхәббәт — поэзиянең ике канаты. Алар шагыйрь йөрәгендә дә, укучы күңелендә дә кайнар хис, тирән кичереш булып яшиләр. Бары тик шулай гына!

Бүгенге шигъриятнең татар халкы, татар милләте белән бәйләнеше дә әнә шундый кайнар хисләр аша ныгытылганда гына нык һәм ышанычлы була ала. Ә хәзерге чынбарлыкта, алдарак күреп узганыбызча, кайнар кичерешләр тудырырдай күренешләр күп. Бик тә күп!

Димәк, шагыйрьләребезнең дә, шагыйрәләребезнең дә көрәш һәм мәхәббәт җыры тагын да көчәячәк диган сүз!

Халкыбызга, милләтебезгә булган олы мәхәббәт тойгысы да бүген әнә шундый кайнар хисләр ташкыны булып яшәсен иде.

Флера Рәмиева

# ШАГЫЙРЬ БЕЛӘН ЯНӘШӘ

*Шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең кызы булам мин. Укучылар инде беләләр: безнең әтиебез 1926 елда вафат булды. Ул вакытта әле миңа сигез генә яшь иде. Шуңа күрә үземнең сабый хәтереннән әллә ни зур истәлек таба алмыйм. Бары тик әтиемнең безгә, балаларга карата бик тә шәфкатьле булуын, нинди генә шаянлык кылсак та безне беркайчан да бәрелеп орышмавын гына хәтерлим... Тагын әтиебезнең авырып ятканы истә... Ләкин, аның каравы, әниемнең сөйләгәннәре бик тә хәтердә. Ул безгә әтиебез турында бик күп, бик еш сөйли иде. Биредә, менә хәзер, журнал укучыларына тәкъдим ителә торган хатирә дә шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең хатыны, ә минем әнием Бану Рәмиева авызыннан бәян ителә. Мин бары тик ул истәлекләрне язып баручы һәм редакциягә юллаучы гына.*

*Шагыйрьнең кызы Флера Рәмиева-Ясемчик.*

## Шагыйрьнең хатыны сөйли:

1912 елның көзе иде. Мин, шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең булачак тормыш иптәше Бану, Уфада кызлар гимназиясендә укый идем. Әлеге гимназияне ярлы мөселманнарга ярдәм итү буенча хатын-кызлар җәмгыяте тотты. Шул ук җәмгыять гимназиядә әдәби-музыкаль кичәләр дә үткәрә иде. Сәгыйть Рәмиев шигырьләре белән дә мин әнә шул кичәләр аркасында таныштым. Дөресрәге, кичәгә бергә йөрүче иптәш кызларымның өстәлендә күрдем мин беренче мәртәбә Сәгыйть Рәмиев китабын. Ул китапта миңа таныш шигырьләр күп иде. Арадан берсе — «Уку» дигәне — бигрәк тә якын иде. Чөнки без ул шигырьне мәдрәсәдә укыганда имтиханнар алдыннан һәм бәйрәм көннәрендә көйләп җырлый да торган идек. Ә соңрак ул җыр губернатор тарафыннан тыелды.

1913 елны Уфа гимназиясенең алтынчы классын тәмамлагач, авыл мәктәпләренең берсенә укытырга китәргә тиеш идем. Ләкин шул чорда Әстерхандагы мөселман мәктәпләре өчен мөгаллимәләр җыялар икән. Әстерханнан Уфага моның өчен махсус кеше килгән. Әнә шул кеше минем укытучыларымны очраткан ди, болар бергәләп мине үгетләргә тотындылар. Ахыр чиктә, тәки күндерделәр. Август ахырында без инде юлга чыктык.

Уфадан Самарага кадәр поезд белән бардык, аннан соң пароходка күчеп утырдык. Юл, билгеле, ерак иде. Ләкин миңа, әле үзенең унҗидесен генә тутырган һәм яшәгән шәһәреннән моңа кадәр беркая да чыкмаган кешегә, ул бик кызык та иде.

Әстерхан шәһәренә без бик яхшы кәеф белән килеп төштек. Күңелле, омтылыш-дәрт ташып тора. Тизрәк балалар укытырга тотынасыбыз килә. Иптәш кызым Шәмсенур белән мине бер вак сәүдәгәр йортына фатирга урнаштырдылар.

Килеп төшүебезнең икенче көнендә үк үзебезне эшкә чакырган җәмгыятькә барырга дип җыена башладык. Шунысы бик хәтердә: урамга чыгар алдыннан мин, гадәтемчә, башыма бернәрсә дә кимәгән идем, бу хуҗабикә апабызга бер дә ошамады. «Безнең шәһәрдә хатын-кызлар гына түгел, хәтта ирләр дә яланбаш йөрми»,— дип, ул миңа үзенең ефәк шәлен бирде. Аннары шунысын да өстәп куйды: «Әгәр дә сез урыс хатыннары сыман яланбаш йөрсәгез, мәктәбегезгә бер генә мөселман хатыны да үзенең кызын бирмәс».

Җәмгыять идарәсендә безне олы гына яшьтәге, күзлекле бер абзый каршылады. Хәл-әхвәл сорашкан чагында без аңа Әстерханда алган беренче тәэсирләребезне әйттек. Монда бәләкәй кызлар да чапан бөркәнеп йөриләр икән, дидек. Безнең Уфада бөтенләй бүтәнчә, дидек.

— Һич тә борчылмагыз, кызлар,— диде әлеге абзый.— Биредә сез ялгыз булмассыз. Монда алдынгы карашлы кешеләр, зыялылар шактый күп. Артистлардан

Сөннә ханым белән Зәйни Солтанов бар, укытучылар да шактый. «Идел» газетасында эшләүче шагыйрь Сәгыйть әфәнде Рәмиев бар... Алар барысы да хатын-кызларны әлеге чапан астыннан азатлыкка, кояш нурына чыгару өчен көрәшеп, тырышып йөриләр. Сез дә алар белән бергә булырсыз дип уйлыйм. Минә тиздән әдәби-музыкаль кичәнең репетициясен башлыйбыз, шунда безнең зыялыларның барысы белән дә танышырсыз.

Икенче көнне безне Абруй һәм Сөннә ханымнар белән таныштырдылар. Сәгыйть Рәмиев белән очрашуыбыз да әлеге әдәби кичәгә кадәр үк булды.

Иң элек безнең Әстерханга килүебез хакында «Идел» газетасында хәбәр итүләрен әйтеп узарга кирәк. Озак та үтми, шәһәргә килгән яңа укытучылар белән шәһәр зыялыларының очрашуын да оештырдылар. Безне шуңа чакырдылар. Ул кичәгә бару теләге, әлбәттә, көчле иде. Ләкин, шул ук вакытта, күңелдә курку сыман бер хис тә бар шикелле. Шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең дә булачагын белү бигрәк тә әллә нишләтә. Шуңа күрә мин ул очрашуга бармаска ниятләдем.

Ә Абруй ханым исә, әлеге шик-шөбһәләремне белү белән, мине шундук тынычландырырга кереште. Танылган шагыйрь булса да, Сәгыйть әфәнде болай кешелек ягыннан бик гади, тиз аралашучан, яшь җилкенчәк белән төрле культура чараларында да бик теләп катнаша,ди. Еш кына хатын-кыз рольләрен дә башкара икән... Бүгенге очрашуга «берничә минутка гына» килеп китәсе икән...

Очрашу кичәсенә без беренчеләрдән килдек дияргә була. Укытучы Мортаза Гыйлманов белән Абруй ханым бик шатланып каршы алдылар. Бераздан рус теле укытучысы Мария Ивановна да килде. Ә аннан соң утыз яшьләр чамасындагы, уртачадан калкурак буйлы, кара костюмлы берәү күренде. Үзе чибәр генә: зур кара күзләр, туры борын, матур гына иреннәр һәм маңгайга ук төшеп тора торган дулкын-дулкын кара озын чәч... Шул арада Мортаза абый безне аның белән таныштыра да башлады: «Сәгыйть әфәнде, таныш булыгыз, безгә Уфадан килгән яшь мөгаллимәләр менә шушылар була инде — урыс теле укытучысы Бану туташ Әюпова һәм татар теле укытучысы Шәмсенур туташ Хәсәнова».

Әлбәттә, «Сәгыйть» исеме чыгу белән мин үзебезнең алда шагыйрь Сәгыйть Рәмиев басып торганлыгын аңлап алдым. Беренче кыенсынуны җиңә-җиңә, кул бирешеп күрештек. Сәгыйть ике кулын да биреп күреште, «Бик шат, бик шат,— диде ул,— безгә милләтне үстерү өчен яшь көчләр, бигрәк тә хатын-кызлар бик кирәк!» Шуннан соң безнең арада бүтән сүз булмады кебек, алар Мария Ивановна белән сөйләшә-сөйләшә бездән ераклаштылар. Озакламый бүтән кунаклар да килде.

Уфада мин күргән кичәләрдән аермалы буларак, бу — җәмәгать хәлләре турында сөйләшүгә корылган мәҗлес иде. Башта безне Сәгыйть әфәнде укыту-мәгърифәтчелек юлына аяк басуыбыз белән котлады. Балаларга белем бирүдә генә түгел, шәһәрнең иҗтимагый-мәдәни тормышында башкарылачак эшләребездә дә уңыш лар теләде. Безнең халык патша изүе аркасында шактый артта калган, шуңа күрә барыбызга да үзебезне үзебез аямыйча, тырышырга кирәк, диде.

Ул матур итеп сөйли белә иде, аны игътибар һәм хөрмәт белән тыңладылар. Башкаларның чыгышында да халыкны агарту мәдәни яктан тәрбияләү кирәклеге басым ясап әйтелде. Шулай ук Г. Тукай, С. Рәмиев һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләрен уку булды. Абруй ханым Г. Тукай сүзләренә язылган «Сөялгәнсең чатта бага нага» җырын бик тәэсирле итеп башкарды. Ә Шәмсенур белән мин С. Рәмиев сүзләренә «Уку»ны җырлап бирдек. Аны бик ошаттылар, мәктәптә укучыларга һәм аларның ата-аналары җыйналгач та җырлап күрсәтергә киңәш иттеләр. Соңрак халык җырларын җырладык. Алда торган әдәби-музыкаль кичә хакында фикер алыштык. Бары тик таң алдыннан гына таралыштык. Соңрак үзенең истәлекләрендә Сәгыйть тә бу кичә турында бик җылы итеп язып калдырды.

Беренче күрүдә үк мин Сәгыйтьне ошатып калдым. Аның гадилеге һәм бер үк вакытта кешегә карата игътибарлы булуы күңелне яулый иде. Сөйләшкәндә «җаным», «акыллым» дигәннәрен инде әйтсәм дә юк. Ул минем белән дә шулай сөйләште. Баштарак мин андый рәвештә сүз алып барудан бераз кыенсынсам да, тора-бара, аның нияте изгелектә икәнлекне күреп һәм ихласлыгын тоеп, ияләштем. Без, әлбәттә, минем алда торган зур эшләр турында күбрәк сөйләштек. Ул миндәге куркуны юкка чыгарырга тырыша, «Без күбәү бит, ярдәм итәрбез»,— дия иде.

Билгеләнгән көнне исә мин репетициягә бара алмадым. Шулай берничә көн үткәч, Сөннә ханым миңа мондый хәбәр әйтә: «Сәгыйть әфәнде безне спектакльдә катнашырга өндәмәкче була. Шуның өчен бүген кич безнең янга киләчәк, өйдә булырга кирәк».

Сәгыйть әфәнде килде. Ләкин Шәмсенур да, мин дә үзебездә сәхнә сәләте сизми идек. Шул сәбәпле, хорда гына җырларга килештек. Әле, аның өстәвенә, миңа кичәнең программасын сату эше дә тапшырылды.

Кичә ноябрь башына билгеләнгән иде. Аның алдагы көнне без Сәгыйть белән извозчик яллап кибетләргә киттек. Чәчәкләр, тасмалар һәм башка кирәк-ярак алдык... Ә инде кичә көнне Сәгыйть мине театрга барырга чакырды. Арцыбашев дигән язучының «Көнчелек» дигән спектакле иде. Ул мине өйгә кереп алды. Ул кичәбез бик матур үтте. Һәм гомергә истәлекле дә булып калды — чөнки Сәгыйть нәкъ әнә шул көнне миңа үзенең мәхәббәтен белдерде һәм тәкъдим ясады. Аның тәкъдиме минем өчен бик тә көтелмәгән хәл иде. Ул мине шактый куркытты да. Шуңа күрә ул чагында аңа болайрак дип җавап бирдем. «Мин бит әле бик яшь. Әле эшлисем, гаиләмә булышасым бар, энеләр-сеңелләремне дә укытасым бар. Мин бит бай гаиләдән түгел. Җитмәсә әле әтием дә үлде, балалар әни белән үги әти карамагында».

Мондый җавап Сәгыйтькә ошады булса кирәк. Ә миңа ул болайрак диде: «Мин бер бай кызын яраткан идем дә, әмма безнең дуслык ныгып китә алмады. Икебезнең ике баскычта булу комачаулады... Гади кешеләр күбрәк ошый миңа. Дусларымның да күбесе гадиләрдән...»

Берничә көннән «Идел» газетасында шагыйрь Сәгыйть Рәмиевнең мөгаллимә Бану Әюповага өйләнәчәге турында, туйның 1913 елның 5 декабренә билгеләнүе хакында хәбәр басылып чыкты.

Безнең туйны үткәрешүдә бөтен Әстерхан зыялылары катнашты диярлек. Ә туйга кадәр үк безнең өчен бер әйбәт кенә фатир да табып куйдылар. Ул өч бүлмәле һәм кухнялы иде. Шулай ук өй кирәк-яраклары һәм байтак кына савыт-саба да бирделәр.

Туйның беренче өлешенә, нигездә, өлкәнрәк кешеләр килде. Ә икенче өлешен, бик күп зыялылар һәм яшьләр катнашында, алдынгы карашлы вак сәүдәгәр Дашкин йортында уздырдык. Халык, чыннан да, бик күп иде. Илнең төрле якларыннан килгән котлау телеграммалары да бихисап санда укылды. Татарның ил буйлап таралган газета редакцияләре барысы да диярлек котлаган иде безне.

Шулай итеп, уртак тормышыбыз башланып китте. Без бик тә бәхетле идек. Сәгыйть «Идел» редакциясендә эшләвен дәвам иттерә, ә мин мәктәптә укытам. Әкренләп өй эшләренә дә күнегә башладым. Сәгыйть миңа бик тә булышты. Эшеннән иртәрәк кайткан чакларда ашарга үзе дә пешереп куя, миңа карата һәрвакыт ягымлы, игътибарлы. Кичләрен исә мин дәрескә әзерләнәм, Сәгыйть газетага мәкалә яза яки берәр әйбер редакцияли. Ә кайбер көннәрне безгә кунаклар килә. Кунак дигәнебез артист Зәйни Солтанов, укытучылар Әбүбәкер Мәзини һәм эшче Даут Мөхәмәдов була иде. Шулай ук азәрбайҗан врачы һәм язучысы Нариман Нариманов та Сәгыйть белән дус иде, аңа үзенең китапларын язып бүләк итә иде.

Ләкин безнең бу бәхетле тормышыбыз озак дәвам итә алмады. 1914 елның март башында Сәгыйть көннәрдән бер көнне өйгә бик тә борчылып кайтты. Сәбәбе — «Идел»нең яңа санын конфискацияләгәннәр икән. Инде өйгә дә тентү килүен көтәкөтә, без Сәгыйтьнең кульязмаларын, хатларын һәм китапларын күздән кичерә башладык. Тентү килмәде, ләкин, аның каравы, берничә көннән соң «Идел» газетасының ябылуы турында хәбәр булды. Ә аның редакторы Гомәров әфәндегә бер тәүлек эчендә Әстерханнан чыгып китәргә кушылган икән.

Безнең алга да «Инде нишләргә?» дигән сорау килеп басты. Күренеп торган ике юл бар иде. Питерда чыга торган «Ил» газетасына барырга мөмкин. Яки инде Уфадагы татар журналларының берәрсенә йөз тотарга... Бераз киңәшкәннән соң, Уфага дип карар кылдык. Әлбәттә, башта Сәгыйть үзе генә барырга, эшкә урнашырга тиеш иде.

Аерылышу авыр булды. Без бит әле яңа гына өйләнешкән кешеләр. Дуслар, билгеле, безне тынычландырырга тырыштылар. Үз иреге белән ташлап китми бит, аңларга тырыш, диделәр. Шулай итеп, мин җәйге каникулга кадәр Әстерхан шәһәрендә торып калдым.

Сәгыйть Уфага күчеп киткәч, бергә-бергә җиңелрәк булыр дип, мин иптәш кызым Шәмсенур фатирына күчендем. Аерылышу сагышын исә Сәгыйтьнең җылы хатларын укып һәм эш-мәшәкать белән басарга тырыштым. Авыр чакларда Сәгыйтьнең якын дуслары да бик ярдәм итте.

Көтә торгач, җәйге ял вакыты да килеп җитте. Уфага чыгып киттем. Сәгыйть мине Самарага килеп каршы алды. Пароходта кайтканда үзенең Уфадагы яңа танышлары Мәҗит Гафури һәм аның гаиләсе турында, Галимҗан Ибраһимов турында сөйләде. Шулай ук шагыйрь Шәехзадә Бабич, «Тормыш» газетасы редакторы Закир Кадыйров һәм башкаларны телгә алды.

Башта минем әнидә, район җирендә яшәдек. Ә бер-ике айдан Агыйделгә ерак түгел урыннан икенче фатир табып, шунда күчендек.

Безнең Уфага кайтуыбызга күп тә үтмәде, сугыш чыкты. Беренче империалистик сугыш. Кешеләрне сугышка ала башладылар. Сәгыйтьне күп тапкырлар ча-

кырып йөртсәләр дә, ахырдан калдырдылар. Ул Уфадагы авыл хуҗалыгы журналында русчадан татарчага тәрҗемәче булып эшләвен дәвам итте. Бу журнал айга дүрт мәртәбә чыга иде. Өстәвенә әле тагын Сәгыйть башка техник эшләрне дә башкара. Шуңа күрә мәшәкате бик күп, эше муеннан була. Айга 100 таңкә хезмәт хакы ала. Көздән башлап, мин дә хатын-кызлар мәктәбендә русча укыта башладым. Миңа да 25 таңкә түлиләр. Кыскасы, материаль яктан начар яшәми идек.

Сәгыйть Уфадагы әдәби-музыкаль кичәләрдә бик актив катнашты. Үзенең шигырь һәм хикәяләрен еш укыды. Халык аның укуын бик тә ярата иде. Күп чагында сәхнәгә тагын-тагын чакырып чыгаралар иде.

Әдәби түгәрәк эшендә дә Сәгыйть якыннан катнашты. Бу түгәрәк Солтан Габәши өендә җыйнала иде. Соңрак мәшһүр композитор булып киткән Габәши шагыйрь сүзләренә «Сызла, күңелем» дигән җыр да язды.

Безнең өйгә дә кунаклар еш килә иде. Сәгыйть аларга һәрчак шат булды. Кайчакларда без җыйнаулашып кино, театрларга барабыз. Тәнәфес вакытларында Сәгыйть барыбызны да буфетка алып керә, рәхәтләнеп сыйлый, кунак итә.

Ул чагында зыялылар арасында өй мәҗлесләре үткәрү гадәте бар иде. Шуңа күрә Мәҗит Гафури һәм Галимҗан Ибраһимов гаиләләре белән якыннан дус булып, үзара йөрешеп яшәдек. Ул очрашу вакытларында әдәби әсәрләр уку белән генә чикләнелми. Төрле темаларга бәхәсләр дә килеп чыга, уеннар, диспутлар, аттракционнар да уздырыла. Кайчакларда Сәгыйть хатын-кыз арасында гына кала да, иптәшләрем миңа төрттерәләр: «Син моңа ничек түзәсең?» — диләр. Аларга җавап итеп болай дим: «Мин аңа ышанам, шуңа күрә борчылмыйм».

1915 елның язы җитте. Безнең гаиләбез ишәер вакыт якынлашты. Бала туганчы ук, аңа кирәкле бөтен нәрсәне Сәгыйть үзе алып кайтты. Март аенда улыбыз тугач, Сәгыйть аңа «Рафаэль исемен бирик»,— диде. Бөек итальян рәссамы хөрмәтенә. Ләкин исем сайлавы җиңел булса да, аны законлаштыруы шактый авырдан узды. Эш Уфа мулласы Абызгильдинның мондый ят исемне кушарга теләмәвендә иде. Исем кушарга дип килгән бүтән дини әһелләр дә ризалашырга теләмәделәр. Әле ярый ул чагында Уфага Питер мулласы Муса Бигиев килгән иде. Балага исемне ул кушты. Шуннан соң бу исем татар халкында байтак кына таралды. Сәгыйтьнең улыбыз Рафаэльгә багышланган шигырьләре дә байтак язылды.

1917 елда Февраль революциясе булды. Ләкин безнең гаиләгә бу вакыйга уңаеннан бер күңелсезлек тә килеп керде. Көннәрдән бер көнне Сәгыйть өйгә гаять үзгәреп кайтып керде. «Ни булды?» — дип сорагач, ул эшне башыннан ахырына кадәр сөйләп бирде. Кайбер нәрсә минем дә исемә төште.

1915 елның ахыры яки 1916 елның башы идеме икән, бер көнне безнең фатирга повестка китерделәр — полициягә чакыру кәгазе. Ул анда барып кайтты. Ә өйгә кайткач шуларны сөйләде. Полициядә аннан: «Мөселманнар арасында панисламизм хәрәкәте бармы?» — дип сораганнар. Сәгыйть: «Андый хәрәкәт юк»,— дип язган иде. Мин ул язуны күрдем. Шуннан соң Сәгыйть киңәшү өчен «Тормыш» редакторы Закир Кадыйров янына китте. Теге кәгазьне полициягә илткәнме-юкмы, аңысы исемдә калмаган. Ул чагында әлеге нәрсә шуның белән онытылган иде. Тик илдә Февраль революциясе булганнан соң Уфа жандармериясенең архивы тикшерелә һәм шул вакытта Сәгыйтьнең исеме килеп чыга. «Бернинди дә мәгълүмат бирмәде»,— дигән язу белән янәшә була аның исеме. Сәгыйть һәм аның дуслары моны гаять авыр кичерделәр. Җитмәсә әле — мәхшәр чоры булу сәбәпле ныклап аңлатып торырга, тикшерергә дә вакыт юк иде...

Октябрь революциясеннән соң Сәгыйть «Спартак» романын тәрҗемә итү эшенә кереште. Ә 1917 елның декабрендә Уфада җыйналган милләт мәҗлесендә әлеге жандармерия исемлеге яңадан куеп тикшерелә һәм Сәгыйть гаепсез дип табыла. Бу хәбәргә Сәгыйть сабый балалар сыман шатланды! Милли мәҗлеснең әлеге карары «Тормыш» газетасының 1918 елгы 17—18 январь санында басылып та чыкты. Шул уңайдан шагыйрь Сәйфи Кудаш безнең Сәгыйтькә багышлап «Сайра» дигән шигырь дә язды.

Сәгыйтькә эшкә урнашырга кирәк иде. Дуслары аңа Мәскәүгә барып, анда чыга торган «Сүз» редакциясенә эшкә керергә киңәш бирделәр. 1918 елның февраль тирәләрендә Сәгыйть Мәскәүгә чыгып китте. Ә мин, улым Рафаэль һәм ике кызым белән, Уфада торып калдым. Май аенда ул безне алырга дип кайтты. Бергә булу шатлыгыннан бераз кунак та булыйк, ял итик, дип Чебенле авылына кымыз эчәргә барган идек, ул арада тагын дөнья болганып китте. Барыбыз бергә Уфада торып калдык. Сәгыйть бер ширкәткә тәрҗемәче булып урнашты.

Әйтергә кирәк, Уфада бу чорда власть бик тиз алмашынып торды. Сәгыйть, нигездә, тәрҗемә эше белән мәшгуль булды. Ә сугыш хәрәкәтләре узып, дөнья бераз тынычлангач, Сәгыйтьнең карт әтисенең хәлен белергә кайттык. Аңа инде 82 яшь иде.

Авылда без ике айга якын тордык. Сәгыйтьнең әтисен җирләдек. Инде Уфага әйләнеп кайтырга кирәк иде. Ләкин бөтен төбәкләрдә сугышлар бара, ничек юлга чыгасың?! Без вакытлыча Әбләздә торып калдык. Ә көннәрдән бер көнне, якын тирәдәге авыллар тупланып җыелыш үткәрделәр дә, Сәгыйтьне ревком секретаре итеп сайлап куйдылар. Ревком күрше Агапово поселогында урнашкан иде. Безгә шунда күчәргә туры килде. Мин анда балалар укыттым. Ә Сәгыйть ревкомда көн-төн эшли иде. Халык аңа ышана, аны хөрмәт итә иде.

Ә тагын берничә айдан Сәгыйтьне Магниткага халык мәгарифе бүлеге мөдире итеп күчерделәр. Шул чорда ул РКП(б)га да керде. Сәгыйтьне ак банда һәм дезертирлар белән көрәшүче отрядка да тарттылар. Бәрелешләрдән кайткач, ул сугышның шактый каты булганын, куплэрнең үлүен һәм каты яралануын сөйли иде. Ә Сәгыйть бу отрядта тәрҗемәче вазыйфасын башкарган һәм кулга төшүчеләрне совет властен кабул итәргә үгетләгән.

1920 елның язында Югары Урал шәһәрендә партия конференциясе булды. Анда Сәгыйтьне милләтләр эше буенча өяз бүлеге мөдире итеп сайладылар. Шулай итеп, безгә тагын Югары Урал шәһәренә күчәргә туры килде. Танышларыбыз, дусларыбыз безне бик җылы озаттылар, юлга он һәм тагын байтак кына ашамлык бирделәр. Ә бу безгә юлда да бик ярады, яңа шәһәргә килеп төшкәч тә авыр хәлдән коткарды. Чөнки базарларда азык искиткеч кыйммәт, безнең әле хезмәт хакы да юк иде. Дуслар биреп җибәргән азык-төлек гаиләбезнең алты кешесен тукландырып торды. Бу вакытта инде безнең дүртенче балабыз да туган иде. Бераздан махсус паек бирә башладылар тагын. Хәлебез әзрәк җиңеләеп китте.

Шул ук елның җәй ахырларында Сәгыйтьне тагын яңа эшкә — Чиләбе губернасының милләтләр эше буенча бүлек мөдире итеп күчерделәр. Без тагын Чиләбегә күчендек. Миңа исә ятим балалар йорты оештыру эше йөкләнде. Моның өчен ике катлы зур гына өй табып, аның аскы катын эш бүлмәләре иттек, безнең гаиләгә яшәү өчен фатир ясадык, ә өскә балаларны урнаштырдык. Бик тә авыр чор иде бу. Бөтен җирдә ачлык, тиф һәм башка куркыныч авырулар таралган. Чиләбегә төрле яктан җыелган балаларның да күбесе диярлек — авыру. Врачлар җитми. Ач балаларны ничек ашата башларга икәнен белмичә, баштарак уңышсызлыкка да очрадык. Ач кешене кинәт кенә туйганчы ашатырга ярамавын беренче көннәрдә белми идек әле. Шуңа күрә үлүчеләр дә булды. Ләкин бераздан барысына да өйрәндек, үлүчеләр саны нык кимеде. Ул вакытта Чиләбедә ятим балалар йорты дистәдән артык оешты. Ә безнеке мөселман балалары өчен иде. Тора-бара безнең балалар йорты алдынгылар рәтендә йөри башлады. Монда Сәгыйтьнең дә өлеше зур иде, әлбә тә. Чөнки ул шәһәрнең бөтен зыялыларын диярлек шушы эшкә тартты. Алар өчен күп санлы кичәләр, башка төрле күңелле чаралар оештырды.

Ул чор тормышыбыздан бер күңелсез вакыйга да истә калган. 1922 елның язлары иде бугай. Сәгыйть эшли башлаганчы бу урынны биләгән И. Юманкулов дигән кеше бер партия җыелышында Сәгыйтькә каршы сүз кузгаткан. 1916 елгы патша жандармериясендәге исемлеккә бәйле тарихны искә төшергән. Җыелышта төрле фикерләр булган, ләкин Сәгыйтьне ул эштән азат итеп, аның урынына әлеге Юманкулов дигән кешене куйдылар. Ә Сәгыйть бүлектә инспектор булып калды.

Бу күңелсезлек артыннан, үч иткәндәй, өебезгә тагын да зуррак кайгы килеп җитте. Куркыныч авыру бик тиз арада ике улыбызны да алып китте. Олы улыбызга 7, ә кечесенә нибары 2 яшь ярым гына иде әле...

Болар барысы да, билгеле, Сәгыйтьнең сәламәтлегенә бик нык тәэсир итте. Ул авырый башлады. Ләкин баштагы мәлне һич кенә дә эшеннән аерылырга теләмәде. Бик кыен булса да, эшкә йөрде.

1922 елның җәендә миңа балаларны Новосибирск һәм Красноярск шәһәрләренә илтүче санитар поездында уполномоченный булып барырга тәкъдим иттеләр. Ә без, мондый мөмкинлек күренеп торганда, бөтен гаиләбез белән барырга булдык. Сәгыйтьне дә тәрбияче итеп штатка керттек һәм юлга кузгалдык. Балаларның беренче төркемен Ачинск шәһәрендә калдырдык. Калганнары белән Красноярскига киттек, ә анда барып җиткәч, балаларны Минусинск дигән бер бәләкәй генә шәһәргә илтәсе калды. Бу шәһәргә бары тик су юлы белән генә барып була иде. Ә шәһәрнең үзенә барып җиткәч, ул урын Сәгыйтькә бик ошады. Хәтта ул В. И. Ленин сөргендә булган бу якны өйрәнү өчен озаккарак калырга да теләгән иде. Кире үзебезгә кайтырга Сәгыйтьне көч-хәл белән генә күндердек.

Уфада безне әйбәт каршыладылар. Сәгыйть җир эшләре буенча Башкортстан халык комиссариатына тәрҗемәче булып эшкә урнашты. Фатир да бирделәр. Тик Сәгыйтьнең эш урыны кышын ягылмый торган салкын бинада иде. Киеме дә юка: көзге пальто һәм ботинка. Шуңа күрә ул еш авырый башлады. 1923 елның язында бөтенләй урынга ук ятты. Врачлар, үпкә туберкулезы, диделәр... Җәй җиткәч кымыз

белән дәваланып карады, аннан шактый рәтләнеп кайтты. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша башлады. Ул башкорт ягын өйрәнү буенча оешкан фәнни җәмгыять әгъзаларының берсе булды, мәгариф эшләре буенча академик үзәктә эшләде, өлкәннәргә һәм балаларга башкорт телен укытты. Латин шрифты нигезендә татар-башкорт әлифбасын төзеп бетерде. Бу эшне ул революциягә кадәр үк башлаган иде инде.

1923 елда, «Интернационал» текстын иң яхшы тәрҗемә итү буенча конкурс ачылгач, Сәгыйть анда катнашты һәм җиңүче булды. Шул ук елны Сәгыйть «Спартак» романын тәрҗемә кылу эшен дә тәмамлады. Кулъязманы Мәскәүдә татарча китаплар бастыручы нәшриятта эшләүче Шамат Шәрәфетдинов дигән танышына җибәрде. Бер еллап вакыт үтте һәм берчакны ни күрик: «Спартак» басылып та чыккан, тик аның тәрҗемәчесе — Зәки Шәрәфетдинов дигән кеше! Теге танышыбызның туганы! Мондый хәлгә Сәгыйть нишләргә дә белмәде, бик тә борчылды. Әле җитмәсә ул елларда: «С. Рәмиевнең иҗат ялкыны бетте»,— дигән сүзләр дә куертыла башлаган иде. Шуларның барысына да җавап итеп, Сәгыйть 1923 елның 11 январенда «Башкортстан» газетасында «Үзем һәм сүзем» дигән шигырен бастырды. Ләкин эш моның белән генә дә бетмәде. Сәгыйтьнең бу шигыренә каршы Г. Касимов мәкаләсе чыкты. Ул мәкалә Сәгыйть шигыренең мәгънәсен бүтәнчәрәк аңлаткан иде. Сәгыйть шулай ук моның белән килешергә теләмәде. Тагын газетага мәкалә язды. Ләкин анысын басмадылар. Бераздан бу бәхәс килешү белән тәмамланды кебек...

Әйе, ул елларда Сәгыйть күп яза алмады. Аның эш белән бик мәшгуль булуы, авыруы, зур гаилә алып баруы — болар берсе дә иҗат өчен уңай тәэсир итмәде. 1923 елда безнең бит әле тагын бер улыбыз — Рәми туды. Аңа да күп игътибар кирәк иде. Ләкин Сәгыйтьнең һаман күңеле күтәренке, кәефе яхшы иде. Шул елларда ул яңа поэма язарга керешә. Аның кереш өлешен һәм беренче бүлеген язып та өлгерде. Тик алар миндә калмады, комиссия тарафыннан алынды.

Сәгыйть шахмат уйнарга бит тә ярата иде. Хәтта 1923 елда үзенә кышкы пәлтә алырга барган җирдән дә ул фил сөягеннән ясалган кыйммәтле шахмат күтәреп кайтты. Әнә шул шахматта уйнарга аның дуслары килә иде. Бер кичне алар Галим Айдаров белән кич буе шахмат уйнадылар. Мин алар уйнап бетергәнне көтеп тормыйча, йокларга яттым. Ә иртән Сәгыйть аякларының бик нык авыртуыннан зарланды. Врач чакырдык. Ул: «Аяк буынында ревматизм»,— диде. Сәгыйть бер атна чамасы өйдә ятты. Аннары аны больницага салдык. Иске Уфадагы ул шифаханәгә дуслары да еш килеп йөрде. Хәле дә рәтләнә башлаган иде. Ләкин көтмәгәндә, һич уйламаганда...

1926 елның 14 марты — якшәмбе көн иде. Бу көнне Сәгыйть янына аның дуслары Мәҗит Гафури, Касим Гыйрфанов, Газим Касимов, Имай Насыйров, Хәбир Габдрәшитов һәм башкалар килеп, аңа сөенечле хәбәр җиткерәләр. Латинчыларның Бакуда булган киңәшмәсе Сәгыйть тарафыннан төзелгән проектны хуплаган, ул тулысы белән диярлек нигез итеп алынган. Сәгыйть моңа бик сөенгән, киңәшмә турында тагын да күбрәк мәгълүмат алып килүләрен үтенгән. Шул ук көнне балалар белән мин дә аның янында булдым. Аның кәефе бик әйбәт иде. «Минем янга иртәгә килеп йөрмәссез инде»,— диде ул... 17 мартта, иртәнге сәгать 10 да минем эшкә Сәгыйтьнең вафатын әйтеп шалтыраттылар.

Уфадагы мөселман зиратындагы Сәгыйтьнең кабер ташына аның үзе тарафыннан иҗат ителгән мондый юллар язып куелган:

*Булмас артык, олуг бер'эш*
*Илгә хезмәт итүдән...*

## Әмирхан Еники

# САРЬЯН



Шушы җыйнак, матур исем белән ул әдәбиятка керде. Үзенә килешеп торган шушы исеме белән ул безнең хәтерләрдә дә саклана. Тик ул исемен фамилия итеп, фамилиясен исем иткән иде: Хәсән Сарьян... Туган елы 1930, үлүе 1978 елның сентябрендә. Бары 48 ел гына ул дөньяда яшәп калды.

Җитмеш сигезенче елның көзендә мин Ялтадагы иҗат йортында идем. Минем китәр вакыт җиткәндә генә Казаннан мәрхүм Галимҗан Латыйп килде һәм иң беренче хәбәр итеп, ул миңа Сарьянның кинәт үлеп китүен әйтте. Бу шул хәтле көтелмәгән, акылга сыймас бер мәгънәсез хәбәр булды ки, гүя башка төшкән кирпеч шикелле, ул мине тәмам һушсыз итә язды. Кайчан, ничек, нидән? Галимҗанның сөйләвенә караганда, Сарьян кичтән үз бүлмәсендә ятып йоклаган, ә иртән янына керсәләр, йөз түбән капланган, тавышы-тыны юк, селкетсәләр дә уянмаган... Үлгән кеше!.. Хода вәндә, шулай ансат кына да үлеп була микәнни?!.. Ул бит, Сарьянны әйтәм, типсә тимер өзәрлек көчле, нык, таза ир иде. Бары 48 яшендә!

Үз гомеремдә миңа күп кешеләрнең дөньядан китүләрен күрергә туры килде, арада бик үкенечлеләре дә булды, әмма ки Сарьян үлеме шикелле хәйран иткән үкенечлесе минем өчен, юк, булмады. Һәм бик озак мин бу югалту белән һич кенә дә килешә алмыйча, дөресен генә әйткәндә, көтелмәгән сәер үлемнең чын сәбәбен дә аңламыйча шактый аптырап йөрдем...

...Еллар узды... Сарьянның вафатына да инде ун елдан артты. Дөнья мәшәкатьләренә күмелеп яшәсәк тә, мәрхүм вакыт-вакыт искә төшә иде, уйландыра иде, юксындыра иде, әмма тора-бара — сәер бер хәл! — аның вакытсыз үлеме мине инде гаҗәпләндерми дә башлады. Киресенчә, кыска гомер аның туган чагында ук тәкъдиренә язылган булса кирәк дигән уй ничектер үзеннән-үзе күңелгә кереп урнашты. Чынлап та, тәкъдир дигән нәрсәгә ышану бар. «Күтәрелми күңелләрем, кыскадыр гомерләрем» диелә бит халык җырында да. Хәер, бу очракта эш ышану яки ышанмауда түгел. Хикмәт шунда ки, мин Сарьянны үлгәннән соң гүя ныграк аңлый башладым. Гүя аның тумыштан ук билгеләнгән язмышы миңа тирәнрәк ачылгандай булды. Ә язмыш дигәнең, яшерен кодрәткә ия бер көч шикелле, кеше белән сиздермичә генә идарә итә диләр. Шулайрак аңларга өйрәнгәнбез без аны... Менә мин дә шуны истә тотып, тере Сарьянны еш кына күз алдыма китерәм һәм аның шул чактагы рухи халәтен аңларга тырышам. Әйтергә кирәк, миңа Сарьян мәрхүм белән күп аралашырга туры килде. Шуңа күрә, һич икеләнмичә әйтә алам: талантлы, дәртле, энергияле, кулыннан һәр төрле эш килүенә карамастан, Сарьянның җаны бервакытта да тыныч була алмады, ниндидер бер канәгатьсезлек — әллә үзеннән, әллә тормыштан — аның бәгырен гел кимерде дә торды. Хәтта яшьлеге, тазалыгы китергән, мәхәббәттә яки эшендә уңышлар кичергән шат, ваемсыз чакларында да ул әлеге каядыр тирәндә яткан канәгатьсезлек тойгысыннан котыла алмады. Аның бу хәлен, үзе телдән әйтеп бетермәсә дә, мин ничектер сизмичә калмый идем. Бигрәк тә моңаеп җырлаган чакларында аңарда, җан тынычсызлыгы өстенә, тагын ниндидер яшерен хәсрәтле сагышы да бар кебек тоела иде. Ә ул, мәрхүм, озын көйләрне үзенчә бер тою белән, тавышын да артык көчәйтмичә, бик үтемле итеп җырлый торган иде... Менә шуларның барысын да искә төшергәч, аның кыска гомерле булуы баштан ук тәкъдиренә язылмады микән дигән уй ирексездән күңелгә килә дә инде. Чөнки тирән торгынлыкка төшкән кешеләрнең озак яши алмаулары тормышта булгалый торган хәл. Моны инкарь итүе читен.

Әмма ләкин торгынлыкның бик җитди сәбәпләре булырга тиештер бит инде. Мәсәлән, Сарьяндагы җан тынычсызлыгы һәм канәгатьсезлек кайдан ул, нәрсә аркасында, ничек туган?.. Дөресен генә әйткәндә бит, тынычсызлык белән канәгатьсезлек безнең күбебездә бар иде, чөнки без кичергән заманның ялганнарын, кимчелек һәм гаделсезлекләрен күзе ачык кешегә күрмичә тору мөмкин түгел иде. Тик менә

күрә торып та шулар белән килешә алмау, борчылу, ризасызлык белдерү кадәресе бер түгел — бусы инде төрле кешедә төрлечә.

Билгеле ки, Сарьянның да бөтен тормышы һәм рухи халәте нәкъ шул без күреп уздырган ясалма-ялган заман белән турыдан-туры бәйләнгән иде. Һәм икеләнмичә әйтәсем килә, аның күңел сизгерлеге һәм эчтән уйланулары күпләрнекеннән тирәнрәк тә, газаплырак та булып чыкты. Бер караганда бу гаҗәбрәк тә тоелырга мөмкин, чөнки Сарьянның тормыш юлы артык авыр сынаулар аша узмаган да шикелле. Дөрес, аның бала чагы фаҗигале утызынчы елларга туры килә (бу елларның кайберләре якыннарына да кагылган бугай — сүзләреннән шулаерак хәтеремдә калган), ә үсмер чагында инде аңа рәхимсез сугыш елларының бөтен коточкыч авырлыгын татырга туры килә. Сугыштан соң да әле ул, нужа тырнагыннан тиз генә ычкына алмыйча, авылдан-авылга сукыр музыкантларны җитәкләп, тамак хакына концертлар куеп йөрергә мәҗбүр була. (Кызганычка каршы, үзеннән-үзе кәгазьгә төшүне сорап торган аның шушы бик гыйбрәтле материалы, минем кат-кат әйтүемә карамастан, ни сәбәптер язылмыйча, әрәм булып калды.)

...Әнә шундый шатлыгы аз, михнәте күп ач-ялангач еллар аша уза Сарьянның һәм аныңише авыл малайларының нәкъ җитлегер, ныгыр чаклары. Бу еллар аша узган Сарьян буыны бик тирән җан ярасы алып кала, минемчә... Ахыр чиктә нәкъ шул еллар күпләрнең тормышка мөнәсәбәтен һәм яшәү кагыйдәләрен билгеләде дә булса кирәк... Монда икесенең берсе: яки һичнигә карамастан беткәнче заманга яраклашу; яки кешелегеңне саклап, намусың кушканча яшәргә тырышып карау...

Һәм Сарьян да шуның беренчесен сайларга тиеш кебек иде. Чөнки нужа мәктәбен узганнан соң, ниһаять, аңа да киң юллар ачыла. Башта Бөре педагогия мәктәбен, аннары Уфа педагогия институтын тәмамлый. Уфа аңа якын, туган җиренең баш каласы... Ул шунда төпләнә, өйләнә, хезмәт юлын башлый — редакцияләрдә эшли, башкорт университетында лекцияләр укый... Шулай әйбәт башлана, әйбәт бара, инде хәзер аңа үргә табан кыю, туры атларга гына кирәк. Моның өчен акылы да, сәләте дә, тырышлыгы да җитәрлек. Ихтимал, ерак китә дә алган булыр иде ул...

Әмма, туры гына барасы урында, Сарьян тота да кинәт кискен борылыш ясый: ул, Уфаны ташлап, Казанга күчеп килә. Башта (1960 елда) ялгызы гына, ә күпмедер вакыттан соң гаиләсен дә китерә... Нинди сәбәпләр аркасында соң, күпләр өчен көтелмәгән мондый кискен борылыш?..

Мәрхүм Казанга килү белән мине эзләп тапкан иде. Беренче очрашудан диярлек, без уртак тел таптык һәм ничектер җиңел генә якынаеп та киттек. Күп сөйләшүләрдән чыгып, мин аның Казанга килүен беренче нәүбәттә болай аңлатыр идем: ул — язучы, ул язарга тиеш, әмма аның татар телендә язасы килә, иллә мәгәр Уфа шартларында татарча китап бастыру мөмкин түгел. Казанда гына мөмкин... Кыскасы, ана сөте белән кергән туган теле аны Казанга тартып китерә. Бу бик табигый хәл, минемчә: Башкортстан туфрагында туып та, татар әдәбиятына хезмәт итәргә теләп, үз халкының мәдәни үзәгенә килүчеләр аз булдымыни безнең дәвердә?! Бу уңай белән Дәрдемәнд сүзләрен искә төшерү дә урынлы булыр кебек:

*Ни газизрәк — бу Ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкаддәс кан белән*
*Ул изге сөткә ни җитәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!*

Әйе, бу сүзләрдә тирән мәгънә ята: ватан китсә дә «изге сөт» кала. Аерым кешеләр язмышында гына түгел, бөтен бер халыклар язмышында да без моны ачык күрдек.

Тик шулай да, Сарьян мәсьәләсенә килгәндә, уйландыра торган бер момент бар. Иң элек әле Башкортстан белән Татарстан арасында ватан булу ягыннан әллә ни зур аерма да юк. Мәсәлән, мин үзем ул аерманы сизмим диярлек — берсендә туганмын, икенчесендә яшим — һәр икесе дә минем өчен бик кадерле. Билгеле, Сарьян өчен дә ул шулай булырга тиеш иде. Шул ук вакытта башкорт теле дә аңа бер дә ят түгел. Ул инде Уфада башкортча яза да һәм басыла да. Шуңа күрә Казанга китүенең сәбәбен бары тел мәсьәләсенә генә кайтарып калдыру дөрес булыр микән?.. Бүтән тирәнрәк сәбәп тә юк микән?..

Безнең бу хакта да сөйләшүебез күп булды. Чыгышы, милләте белән кем ул?.. Сарьян үзе, бабасыннан ишеткән сүзләрне исенә төшереп, болаерак аңлаткан иде: без җир биләүче буларак башкорт, мәгәр милләтебез белән татар!.. Һәм бабасының шул сүзләренә ул, мәрхүм, бик нык ышана иде.

Үзеннән-үзе сорау туарга мөмкин: башкорт булып саналгач, телен дә белгәч, аңа Уфадан китүнең нигә кирәге булды икән? Алдагы язмышы өчен китми калу, бәлки, отышлырак та булган булыр иде... Күреп тора бит, күпме татар дуслар иҗади язмышларын башкорт әдәбияты белән бәйләделәр — кайсы шагыйрь, кайсы әдип — башкортка әйләнеп, яки әйләнмичә генә. Ә аңа әйләнеп торуның кирәге дә юк, күкрәк киереп чын башкорт булып йөрер иде. Бөтен хокуклардан файдаланып, ихтимал, тыныч-рәхәт кенә яшәр дә иде. Башкортлык аның табигатенә күпмедер дәрәҗәдә хас та иде — мин моны бик ышанып әйтә алам.

Иллә мәгәр Сарьян кайсы әдәбиятны сайлау мәсьәләсен андый фани дөнья исәпләреннән өстен торып, вөҗданы кушканча хәл итәргә тырышкан. Ләкин бу тел сайлау белән генә түгел, үзеңне кайсы милләт кешесе итеп тану белән дә бәйләнгән булырга тиеш иде. (Һич тә җиңел булмагандыр бу аның өчен!) Татар белән башкорт икесе ике халык, әмма күп заманнардан бирле бер үк җирләрдә яши-яши алар үзара якынаеп, аралашып киткән халык... Анда татарлашкан (тел җәһәтеннән) башкортлар бар; башкортлашкан яки башкорт булып саналган татарлар бар. Әмма үзенең йөзен, телен, тарихи бөтенлеген саклаган саф башкорт белән саф татар ике халыкның да күпчелеген тәшкил итә. Инде менә шушы бер-берсенә бик якын тугандаш халыкның үзара мөнәсәбәтләре ничек булырга тиеш иде? Бу бик нечкә, бик четерекле мәсьәлә. Чөнки сан ягыннан да, милләт булып формалашу җәһәтеннән дә аерма шактый зур. Хәлбуки, республика исемен йөрткән башкорт халкының аң-белемен, мәдәниятен үстерүне, бигрәк тә кадрларын җитештерүне тизләтергә кирәк. Бу законлы таләп. Ләкин ничек итеп? Республика җитәкчеләре моның ансат юлын табалар — ягъни, татар халкының рухи ихтыяҗларын, культура таләпләрен чикләү, кысу исәбенә «башкортны үстерергә» керешәләр. Баштарак бу тенденция үзен артык сиздерми кебек, ләкин инде ул елдан-ел отыры көчәя бара. Моның нинди ямьсез нәтиҗәләргә китереп чыгаруын әйтеп тору кирәк тә түгелдер, бик мәгълүм алар, әмма бер нәрсәне шулай да әйтмичә булмый: бер халыкны чикләү, кысу хисабына икенче халыкны үстерергә, көчәйтергә тырышу бу бездә күптән яшәп килгән командалык итү системасының бик зарарлы бер күренеше... Зарарлы, чөнки ул дуслыкны да какшата, гаделсезлек тә тудыра, һәр төрле гаепләүләргә, дөреслекне бозуларга да юл ача. Һәм моның мисаллары да соңгы вакытта, кызганычка каршы, бик күбәеп китте.

Сарьян менә шуларны күрә, күрү генә түгел, үз җилкәсендә татый башлый. Билгеле инде, аның хөр табигате моның белән гаделсезлек белән килешә алмый. Ул үзен ике халыкның баласы дип санаса да, алар арасында ясалма рәвештә тудырылган ялган хәлдән чыгу юлын эзләргә мәҗбүр була. Казанга күчеп китүен тизләткән төп сәбәпләрнең икенчесе, минемчә, әнә шунда иде.

Әйтергә кирәк, Казан Сарьянны кочагын җәеп каршы алмады. Бездә дә шул ук система бит — әдәбиятың, мәдәниятең барысы да аның кулында. Дөрес, бездә татар-башкорт проблемасы юк, аның каравы, кешегә шикләнеп, ышанмыйча карау бар. Сарьянга карата да башта шундыерак караш сизелде: ник килгән, нәрсә мәҗбүр иткән, «тегендә» нәрсә эшләгән?.. Билгеле, Сарьян мондый карашны, телдән әйтелмәсә дә, тоймыйча калмады. Нилэр кичергәнен эченә йотты, кире чигенү мөмкин түгел иде, ни күрсә дә аңа шушы каты туфракта калырга һәм тамырланырга кирәк иде.

Үнсигез ел яшәп калды ул бу туфракта. Зур өметләр баглап килгән хыялларына ирешә алдымы соң ул? Мин моны өзеп әйтмәс идем. Мәгәр бер хакыйкатьне өзеп әйтергә була: Казан Сарьянны ниһаять таныды, белде аның нинди талантка ия икәнен... Тик, кызганыч, шактый соңлап. Ничектер шулай килеп чыкты ки, Сарьян башта үзен җитди тел белгече, аннары гына чын художник — әдип итеп танытты. Уфадан килеп, ул безне туган телебезнең нечкәлекләрен аңларга, сүзләрне белеп, дөрес кулланырга өйрәтә башлады. Газеталарыбызның, радио тапшыруларының шактый чүпләнгән, бозылган, агачланган телен анализлап язган мәкалә һәм чыгышлары бик вакытлы да, бик кирәкле дә бер эш булып чыкты. Әнә шулай тел бабында авторитет казанып, ул ахырда Татарстан радиосының «Тел күрке сүз» дигән даими тапшыруларын алып бара башлады. Телебезнең сафлыгын, байлыгын саклауда күрсәткән аның бу тырышлыгын без, әлбәттә, онытмаска тиешбез.

Мәгәр, әйткәнемчә, Сарьянның әдәби иҗаты болай тиз генә җәелеп, үсеп китә алмады. Сәбәпләрен белү җиңел түгел, иҗат итү бик нечкә, бик катлаулы эш. Һәрбер язучыда ул гаять үзенчәлекле... Шулай да башта язганымны кабатлап әйтәсем килә: Сарьян мәрхүм гомеренең ахырына кадәр җанын гел борчып торган нидер эчке бер канәгатьсезлектән котыла алмады. Ул үзе бу хакта күп сөйләшергә яратмый иде, әмма канәгатьсезлекнең тирән яткан бер сәбәбе, һичшиксез, әдәби иҗаты белән бәйләнгән иде — мин моны бик ышанып әйтә алам. Ул бит иҗат мәсьәлә-

сендә гаять таләпчән иде — үзенә дә һәм башкаларга карата да... Инде үзенә килгәндә, мин аның кебек бүтән рәхимсез таләпчәнне белмим диярлек. Яза торган әсәрен һәр җәһәттән камил итү өчен ул күпме көч түкми, күпме газапланмый, әмма никадәр генә тырышмасын, газапланмасын, тулы камиллеккә ирешү юк, мөмкин дә түгел, бу — күптән билгеле хакыйкать. Шуңа күрә һәр язучы, хәтта иң таләпчәне дә, ирешелгән кадәресе белән килешергә мәҗбүр. Ә Сарьянда килешү юк, сизелми — гүя эшеннән канәгатьсезлек аны гел кимерә дә тора. Хәер, чын язучы өчен бу табигый хәл. Ләкин Сарьяндагы канәгатьсезлекне бары иҗат газапларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Тагын бер искә төшерик: мәрхүмнең Казандагы гомере тулысынча торгынлык заманына туры килде. Тыштан бу шактый тыныч-имин вакыт иде, ә чынлыкта исә мактану, шапырыну, тормышны буяп күрсәтү, чын хәлне халыктан яшерү, башлыча табигатьне талап яшәү чорына әйләнгән иде. Данисем һәм байлык артыннан куу бик көчәйде бу чорда... Һәм моңа ирешүчеләр дә булды, тик моның өчен тизрәк килешеп, тизрәк яраклаша белү генә кирәк иде.

Хакимлек итүче чор идеологиясенә буйсынган безнең әдәбият та башлыча әнә шул ялган-ясалма таләпләргә көйләнгән иде. Әмма ләкин чын хәлне күрә белгән, уйлый белгән, үзенең иҗатында тормышны ничек тә дөрес чагылдырырга омтылган язучылар да бар иде. Боларның күбесе алтмышынчы елларның кыска гына «җылыту» вакытында әдәбиятка килгән яшьләр иде — һәм Сарьян да нәкъ шулар җөмләсеннән. Чын талант, хис кешесе, сәнгатьне тирән аңлаучы, әсәр язуның да бөтен нечкәлекләрен белә, әмма үз иптәшләреннән характеры белән нык аерыла иде ул. Нәкъ менә язу эшендә башкалардагы активлык җитми иде аңарга. Ул күп уйлана, тик нигәдер аз эшли... Көнелендә йөрткән темалары да күп (материалга бай иде ул), язасы килүе дә көчле, тик үзен утырып язарга гүя мәҗбүр генә итә алмый. Әйе, иҗат аның өчен үтә җитди эш, бөтен җанын, кодрәтен салырга тиеш ул аңа. Моның өчен язучыда таланттан башка, Чехов әйткән әчке хөрлек хисе дә булырга тиеш. Ә ул юк, яки бик зәгыйфь, нәкъ үзең теләгәнчә генә язып булмый, ирексездән өстеңдә торган ниндидер ят көчләргә буйсынырга кирәк. Бу инде Сарьян табигатенә сыя торган нәрсә түгел, яраклашып, үзен көчли-көчли язуны ул булдыра алмый... Аз язуын, авыр язуын, башкача ничек аңлатырга? Күрәсең, «теләк» белән «таләп» каршылыгын ул аеруча тирән кичерә торган булган...

Әмма, шуңа да карамастан, иҗат процессы аның эчендә өзлексез дәвам иткән. Ул яза, ул язачак! Торгынлык кичергән, утыра алмаган чагында да ул туачак әсәре турында уйланудан бер генә минутта да туктап тормаган. Һәм әсәр, ниһаять, туган!

Шуны да әйтергә кирәк, мәрхүмнең янә бер бик әйбәт һөнәре бар иде. Атасыннан калган һөнәр — «Әткәм һөнәре» дип китап та язган иде... Бик шәп балта остасы иде ул. Бөтен кирәкле кораллары да бар иде. (Атасыннан калган пыяла кискеч алмазны чиста чүпрәккә төреп кенә йөртә иде.) Гадәттә бик теләп тотына иде ул бу балта эшенә. Онытылып, ләззәтләнеп эшли торган иде. Эшләп бетергәч, ясап куйган әйберенә сокланып, еш кына: «Менә, сылап куйган кебек булды!» — дип әйтә торган иде... Мәгәр бу һөнәрен ул кәсепкә әйләндермәде. Кәефе килсә эшләде, килмәсә — юк.

...Аның мавыгып китеп, балта эшенә күп вакыт сарыф итүе бер яктан иҗатына зарар да итәдер кебек иде... Ә бәлки, киресенчә, файда да иткәндер. Җаны тынычланып, үзенең көченә ышанычы артып, язарга утырган чакларында аңа һәр төрле шик-шөбһәләрне селтәп ташлатырлык чын илһам да китергәндер. Гомеренең ахырына таба язган ике үлемсез әсәре — «Бер ананың биш улы» белән «Җәза» повестьларына карап әйтәм мин моны... Тормышның чын йөзен бизәмичә һәм кешеләрнең катлаулы язмышын шомартмыйча кыю сурәтләгән, мәгәр хиссияткә бирелмичә, тыелыбрак тыгыз язылган, шуңадыр ахры, беркадәр Хемингуэйны да хәтерләткән бу әсәрләре Сарьянның нинди зур талантка ия булуын ачык күрсәтте. Әйе, бу җитди, таләпчән әдиптән күпне көтәргә була иде әле. Әмма ни кызганыч, бик вакытсыз өзелде аның ачылып кына килгән иҗаты. Үз үлеме белән дөньядан китсә дә, ни сәбәптер ул миңа авыр, каршылыклы заманның бер корбаны булып тоелган иде. (Тукташ үлгәннән соң да күңелдә шундый тойгы калган иде.) Сарьян мәрхүмнең озак онытылмавы, һаман уйландыруы, ихтимал, шуңардан килә дә торгандыр... Вакытсыз киткәннәр алдында без һәрвакытта бурычлы!

**Китап күзәтү**

# СИСКӘНДЕРӘ ТОРГАН ШИГЫРЬЛӘР

Шагыйрь Рафикъ Юнысның яңа шигырьләр җыентыгын беренче мәртәбә кулына алган укучы аннан нечкә лирика, мөлаем образлар, купшы детальләр эзләп ялгыша. Китапның исеме («Учтагы песнәк») укучы күңелен шунда ук лирик аһәңгә көйли көйләвен... ...Ләкин Р. Юныс иҗаты үзенең беренче шигырьләреннән үк укучыны сискәндереп җибәрә.

*Танымыйсың әллә мине?*
*Белмисеңме кемлегем?*
*Мин — үзәге шушы җирнең,*
*Мин — дөньяның кендеге.*
*Начар үзәк — килә һәрчак*
*Читтә торып каласым.*
*Начар кендек — төшеп кала*
*Язды тормыш арбасы!*

Укучы уйга кала. Ничек инде ул? Лирик герой һәрвакыт уңай, бөек идеаллар белән ашкынып яшәүче чын гражданин булырга тиеш лабаса! Шулай күнеккәнбез. Шулай күнектергәннәр. Ә монда... нинди дер «начар үзәк», төшеп кала язган тормыш арбасы хакында сүз бара. Алай гына да түгел икән әле:

*Оныттырдылар —*
*Хак хуҗа*
*Без икәнне оныттык.*
*Кемгәдер алтын-көмештән*
*Кыйммәт безнең мокытлык!..*

Укучы исә, үз халәтенә җавап эзли-эзли, башка шигырьләргә күз сала. Менә «Үткәргеч» шигыре:

*Ага вакыт. Мин карышмыйм.*
*Үткәргеч мин — үткәрәм.*
*Мәшәкатьме — салкын гына*
*Башкаларга этәрәм...*

Яисә инде менә «Минем вөҗдан шундый» әсәреннән юллар:

*Минем вөҗдан әдәп белә:*
*Уятмый ул мине төнлә,*
*Көндез керә шакып кына...*

. . . . . . . . . . .

*Һәр кушканга күнеп торган*
*Бухгалтер кук минем вөҗдан...*

«Күнеккәнбез» шигырендә дә шул аһәң дәвам итә:

*Бер гамь дә юк! Уңайсызрак*
*Фидакарьләр каршында тик.*
*Юанабыз аларның да*
*Сугарлар бер башына, дип...*

---

Рафикъ Юныс. Учтагы песнәк. Татарстан китап нәшрияты. — Казан, 1989.

Баштарак укучы өчен сәеррәк тоелган иҗат манерасы, шикле, бәхәсле лирик герое, астыртын көлү, төрттерү, ишарәләре белән китап безне үзенә бөтенләй яулап ала. Ләкин гаҗәпсенсә, укучы тагын бер ялгышыр. Чөнки шигъриятнең Р. Юныс тәкъдим иткән юлы безгә бик тә таныш бит. Чынлыкта Тукай, Бабичларның пародик поэзия традицияләрен дәвам итә шагыйрь. Инде онытыла язган иҗат алымнарын, образларны бүгенге көн материалы белән яңарта, үстерә. Читләтеп әйтү, ироник көлү, ишарәләү, үз кимчелек һәм гөнаһларын лирик геройларның үзләреннән әйттерү — болар вакытында сатирик поэзиянең иң отышлы алымнарыннан берсе иде ләбаса.

Р. Юныcның пародик лирикасы, әлбәттә, юктан бар булмаган. Мондый шигърият, гадәттә, җәмгыять үсешенең иң мөһим, кискен борылыш моментларында активлаша. Р. Юныс та бүгенге чорыбызны бөтен катлаулыгында тоя һәм аны пародик-лирик герой образы аша кыю ачып бирергә омтыла.

Укучыны дистә еллар буе, совет әдәбиятының төп герое — уңай герой гына булырга тиеш, дип ышандырып килделәр. Р. Юныс лирик героен нинди кысаларга кертергә соң? Бирелә Г. Ибраһимовның бер сүзе искә төшә. Ул, Ш. Бабичның «Газазил» поэмасындагы уңай герой хакында сүз чыккач, аны «көлү» дип билгеләгән иде.

Р. Юныс та үз шигъриятe белән кеше күңелендә ысланып яткан хисләрне кузгатмакчы, укучыны тирән уйларга этәрмәкче була. Ул куркаклыктан, мокытлыктан, ялган активлыктан көлә. Шагыйрьнең лирик герое, беренче карашка, коеп куйган тискәре герой да түгел. Ул бары тик торгынлык чорының типик герое, тирә-юнебездәге меңәрләгән, миллионлаган кешеләрнең берсе.

Шуны да искәртергә кирәк: Р. Юныcның герое, җыентыкны уку барышында даими үсә, үзгәрә. Ул үз эченә генә бикләнеп, үз күңел ваклыкларында гына чокчынмый, хәтта үз кимчелекләрен, үз хаталарын тану дәрәҗәсенә дә менеп җитә.

*Партиягә алдык — ришвәтчене,*
*Белгән килеш, мин кул күтәрдем.*
*Дошманны мин, димәк, күрә торып,*
*Чик сызыгы аша үткәрдем...*

Әмма, төп иҗат алымы буларак, һәр әсәрдә диярлек, шул ук ирония, шул ук ишарә, көлү дәвам итә.

*Ай, бетмәгән әле дары,*
*Битарафлык базында.*
*Дошман тыныч йоклый ала*
*Дөньяда без барында.*

Шул ук ироник ясcылыкта язылган, әмма инде политик мотивлар белән өртелгән бер төркем әсәрләрендә шагыйрь әле халыклар язмышы мәсьәләсен («Һәйкәл», «Китсеннәр», «Кулымда әрем исе»,) әле авыл борчуларын («И авыл», «И ана»,) әле яшь буын яшүсмерләр проблемасын («Урам сугышы каһарманнары», «Мескеннәр», «Сәяркә») әле табигатьне саклау мәсьәләсен («Тәртипкә саласы бар» һ. б.) күтәреп чыга.

Р. Юныс яңа җыентыгына исемне «Учтагы песнәк» исемле поэмасыннан алып куйган. Димәк, бу әсәрдә әйтелгән фикерләр — җыентыкның да үзәк, төп фикере. Шуңа күрә дә укучы поэманы икеләтә, өчләтә игътибар белән укый. Ләкин автор бу әсәрен җыентыкның башына да, ахырына да куймаган. Әйе, бу аңлашыла да. Чөнки укучыны поэмага әзерләргә кирәк. «Дөнья кәтәбез», «Көньяк, диңгез яры», «Сагынам», «Балыкчы бәете», чынлап та, укучыны шушы поэмага алып киләләр, аны аңлау өчен ачкыч хезмәтен үтиләр.

Әйтергә кирәк: бу лирик фәлсәфи поэма табигатьне саклау хакында гына түгел. Замандашының асылына төшенергә, аның уй-ниятен, омтылышларын барларга һәм битарафлыгын, куркаклыгын, ерткычлыгын рас итәргә алына автор. Төрлечә сынап, сындырып яисә сыйпап карый. Табигать аша, табигатьнең җанлы күзәнәкләре аша сыный шагыйрь. Һәм һәрчак үзенең иҗат манерасына тугры кала.

Кыскасы, бик авыр һәм җаваплы миссия башкара шагыйрь. Лирика белән көлүне бергә кушып, Тукайлардан килүче шигъри традицияне яңарта. Икеләнми әйтергә мөмкин: Бу яктан Р. Юныс бүгенге татар поэзиясендә үзенчәлекле оригиналь шагыйрь буларак билгеләнергә хаклы.

**Галимҗан ГЫЙЛМАНОВ.**

*Татар халкы:*
*төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә*

**Дамир Исхаков,**
тарих фәннәре кандидаты

# НОКРАТ ТАТАРЛАРЫ

Нократ татарлары — Казан татарларының этнографик бер төркеме. Вятка — Нократның сулъяк кушылдыгы Чепца елгасы буенда яшәүче бу татарлар төркемчәлек исеме итеп үзләренең тарихи үзәге булган Нократ (Карино) авылы атамасын алганнар. Бу авыл 1542 елгы чыганакларда Вятка җирендәге шәһәрләр белән бергә искә алына. Чыннан да, авыл янында әле хәзер дә элек ныгытмалары булган шәһәрчек эзләре бар. Тарихчы галимнәр Р. Н. Степанов, М. Г. Госманов фикере буенча, урта гасырларда Нократ аерым князьлек үзәге булган. Нократ татарлары бүгенге административ бүленеш буенча Киров өлкәсенә (Слободск р-ны) һәм Удмурт АССРга (Юкамен, Балезин һәм Глазов районнары) карыйлар. Революциягә кадәр бу төбәк Вятка губернасының Слободск һәм Глазов өлкәләренә кергән. Нократ татарлары күп санлы түгел: 1920 елларда алар 15 мең кеше чамасы исәпләнгән (барлыгы 40 тан артык авыл). Ләкин шуны да истән чыгармаска кирәк: нократ татарлары актив миграцион процессларга катнашканнар. Мәсәлән, Алабуга ягы татарларының шактый өлеше — нократ татарларыннан, бер өлеше Башкортстан АССРга да күчкән, Казан артына да килеп чыккан.

Нократ татарларының бабалары беренче тапкыр рус елъязмаларында 1489 елны «арча князьләре» исеме астында телгә алына. Шул елны Мәскәүнең бөек князе Иван III Вятка җирен яулап ала һәм бу төбәкнең «олы кешеләрен» әсир итә. Алар арасында «ар князьләре» дә була (кайбер елъязмаларда алар «татар князьләре» дип тә атала). Иван III бу князьләрне үзенә хезмәткә ала һәм үз җирләренә кайтарып җибәрә. 1489 елдан башлап «Нократ иле» Мәскәү дәүләтенә буйсына, ә «ар князьләре» йомышлы татарларга әйләнә. XVI гасырдан сакланган грамоталар Чепца буендагы Нократ (Карино) шәһәрчегендә яшәгән «ар князьләре»нең һәм аларга бәйле булган «кара халык»ның тормышын шактый кызыклы итеп ачып бирә. Мәсәлән, 1521 елгы грамотадан бер өзек китерик: «...мин, бөек князь Василий Иванович, Дәүләтьяр исемле татарга — Мөхәммәт Казый улына, аның балаларына Вяткадагы Каринoның яртысын — ар татарларын һәм вотякларны бирдем... Дәүләтьяр һәм аның балалары бу ар татарларын һәм вотякларны карый һәм аларны судка тарта ала...» Иң кызыгы шул: XVI гасырдан калган грамоталарда князьләргә буйсынган халык төрлечә атала — «ар татарлары», «беләк», «карин аренналары», «ар чувашлары», «вотяклар». Ләкин XVII гасырдан башлап алар барысы да бер исем белән — «бесермен» (татарча — бочорман) дип йөртелә башлый. Әйтергә кирәк, нократ татарлары составындагы үзгә бер төркем буларак, бочорманнар XX гасыр башына кадәр аерылып торганнар. Кайбер авылларда әле хәзер дә татарлар кемнең бочорман токымыннан булганын хәтерлиләр. Шулай ук, тарихи чыганаклар һәм халыктан җыйнаган мәгълүматлар күрсәтүе буенча, нократ татарлары составына (бочорманнар аша) удмуртлар да кереп киткән. Ләкин удмуртлар («ар» токымнары) бочорманнар белән XVII гасырның икенче яртысында гына кушылганнар. Авылларда кемнең «ар» токымыннан икәнлеген хәзер дә яхшы беләләр. Ә инде «чиста бочорманнар» үз бабаларын да бочорман булган дип саныйлар.

Нократ татарларының шактый өлеше элеккеге «ар» князьләреннән чык-

кан. Билгеле, аларның күпчелеге XIX йөздә инде гади крестьян булган, ләкин бабаларының морзалар булганлыгын онытмаганнар. Күп төрле тарихи чыганаклар, шәҗәрәләр әнә шул турыда сөйли. Безнең фикер буенча, «ар князьләре» аерым югары катлау тәшкил иткән социаль төркем генә түгел, ә аерым этник тамыры булган төркем дә. Ягъни, бу төркем нократ татарларының бочорманнардан аерылып торган аерым бер компоненты. Аның шулай икәнлеген күп санлы шәҗәрәләр дә раслый. Бу шәҗәрәләрне башта Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинев, соңрак М. Госманов һәм М. Әхмәтҗанов өйрәнә. Безнең кулда да нократ татарларының XVIII гасырда һәм соңрак төзелгән шактый шәҗәрәләре бар. Төрле вариант шәҗәрәләрдә «ар князьләре»нең токым башы итеп Кара бәк күрсәтелә. Шул шәҗәрәнең бер кызыклы вариантына тукталыйк. (Китерелгән өзек М. Әхмәтҗанов хезмәтеннән алынды.)

## Кара бәк шәҗәрәсе

*«Ул — олуг Сократ хәким нәселе. Әүвәл Сократ хәким, Искәндәр шаһ берлә Мәңү суы эстәгәндә берлә, имеш. Олуг бабаның Гиффәт солтан, аның улы Габделгазиз солтан, аның углы Әлвар солтан, аның углы Бирде солтан, аның углы Габделрахман солтан, аның углы Баҗтан солтан Рум вилайәтендән килүб Иайукка Сакмар тамагында күп рузгар (тормыш) иткәннәр. Баҗтан солтанның углы Балым бәк, аның углы Калдар бәк, аның углы Күкчә тархан, икенчесе Ханбар бәкдер, Ак Идел буенда рузгар иткәннәр. Ханбар бәкнең өч углы бар иде: Нар бәк, Ишем солтан, Кара бәк. Килеп Өчпүләдә йорт иткәннәр. Ул Кара бәк агаларына үнчесе тартып кәтүб (ягъни, башкалыгы чыгып) Калталы Иванга[1] — карт Иванга, сар Иван Вачилийга килүб, баш салуб... падишаһымыз... йарлукаган Нукрат Йирин биргән. Ул Нократта һич мөселман йук ирмеш иде. Ул йирнең исеме — шәрифе Нократ улсун дәйү ат биргәннәр... биклек үтенеп йарлыкаш бабамыз Кара бәкне... йарлыкаб Чүлчә дигән су буен башында тамагына тигрү ары вә урысы берлән, татары вә чирмеше берлән крәстийәнгә биргән... Ул йарлыкаб тиргән йарлыкашны бабамыз Бичура биккә тигрү (тикле) вә ашаганнар...»*

Тарихчы М. Госманов китерелгән шәҗәрәнең кайбер өлешләре (Сократ, Александр Македонский белән бәйләнгән урыннарны) урта гасыр татар язма чыганакларыннан алынганлыгын күрсәткән иде инде. Шулай ук Кара би нәселенең берничә буыны Җаек, Сакмар, Агыйдел буйларында яшәвен ул аларның Алтын Урда тарихы белән бәйләнгәнлеге аша аңлата. Бу фикер белән килешеп, аңа кайбер өстәмәләр кертүне кирәк саныйбыз. Беренче чиратта Кара бинең яшәү вакытын билгеләп карыйк. Шәҗәрә буенча Кара бинең нәселе түбәндәгечә бара: Кара би — улы Гали би — соңгысының улы — Әльсуфи һәм аның улы Сәйтәк. Сәйтәк 1495 елны туган (аның кабер ташы сакланган). Димәк, Кара би XIV йөзнең ахыры — XV йөзнең башында яшәгән булып чыга. Шәҗәрәнең борынгырак өлеше турында М. Әхмәтҗанов түбәндәгечә фикер йөртә: шәҗәрәдәге Баҗтан (Бачман) солтан — тарихта монголларга каршы Түбән Идел буенда көрәш алып барган каһарман шәхес Бачман солтан. Шулай да, искәртеп үтик: Кара бидән солтанга кадәр буыннар саны аз. Моның сәбәбе: бәлки, кайбер исемнәрнең төшеп калуында яисә бер-берсенә кушылып буталуда. Шәҗәрәдә бутау бераз сизелә, аны М. Әхмәтҗанов та күрсәтеп үтә. Бачман солтанга бәйле исемнәрнең кайберләре тарихи чыганакларда да чагылыш тапкан. Мәсәлән, Калдар би «Дәфтәр-и Чыңгыз намә»дә искә алына. Аннан соң шундый сорау да куярга була: Балым би белән Балымер шәһәрчегенең легендар хөкемдары Балын хуҗа бер үк кеше түгел микән? Кыпчакларның күчеш юнәлешләре бу фикергә каршы килми. Мәсәлән, Җаек-Сакмар буйларына кыпчаклар монгол яуларыннан соң, XIII гасыр урталарында гына күчәләр, ә инде XIII-XIV йөзләрдә кыпчаклар Татарстанның хәзерге көньяк-көнчыгыш районнарына һәм Агыйдел бассейнына да үтеп керәләр. Шул фикерне куәтләп әйтеп үтәсе килә: шәҗәрәдәге Ханбар бәк уллары яшәгән Өчпулә авылы хәзергә Башкортстан АССРның Дүртөйле районындагы Агыйделгә бик якын утырган Өчбулә авылына туры

[1] Калталы Иван — Мәскәү князе Иван Калита.

килә булса кирәк. Шунысы кызык, бу җирләрдән әллә ни ерак булмаган Кама елгасының Сарапул тирәсендәге бер кушылдыгы Камбарка (Ханбар бәк исеменнән русча ясаган атама) дип атала. Бу фактларны очраклы дип булмый шикелле.

Кара бинең көнчыгыш Кама буена, аннан соң Казан һәм Вятка җиренә килеп чыгуы кайчан һәм ни сәбәпле булган соң? Бу сорауларга бүгенге көндә әле тулы җавап биреп булмый, ләкин бу уңайдан кайбер фикерләр белән уртаклашу кирәк дип саныйм. Әйтик, 1445 елны Казанда хөкемдар булып утырган Гали би мәшһүр Кара бинең улы түгел микән? Ш. Мәрҗани бу турыда болай дип яза: «Болгар һәм Казан җимерелгәннән соң, Галибәк дигән кеше Казанга килеп кереп хөкүмәт төзи башлаган була. Олуг Мөхәммәт хан килгәч, ханга буйсына. Хан шунда бер кальга бина кылып, аны ныгыткannан соң, Галибәкне шунда хөкемдар итеп калдыра. Үзе Нижнийга китә. Олуг Мөхәммәт ханнан соң, аның углы Мәхмүд хан Казанга кермәкче була. Гали бәк каршылык күрсәткәч, Мәхмүд хан шәһәрне сугышып алып, үзе Казанда торып калган булса кирәк». Ш. Мәрҗани икенче версияне дә китерә: «Олуг Мөхәммәд хан Сарай шәһәреннән куылып чыгарылганнан соң, Казанга килмәстән, Нижнийда һәм Курмышта торып калган, имеш. 1445 елда углы Мәхмүд хан, Курмыштан килеп сугышып һәм Галибәкне үтереп, Казанны алган. Үзе Казанда торып калып, Казан ханлыгына нигез салынган». Ш. Мәрҗани тагын бер искәрмә ясый: «Олуг Мөхәммәд Василий II не әсир итеп Курмышка килгәч (1445 ел, 25 август), «Галибәк исемле кешенең Казан шәһәрен яулап алу хәбәре килә». Бу мәгълүматларга өстәп шуны да әйтеп үтик: кайбер документларга караганда, Кара би нәселе Арча шәһәренә хуҗа булган, ә Арча даруга, ягъни өлкә үзәге булып саналган. Ә ул төбәктә удмуртлар (арлар) да яшәгән. Шуннан «ар князьләре» атамасы килеп чыкса кирәк. Кара би нәселе Казан ханлыгында булган дүрт төп феодаль «клан»ның (аргын, барын, ширин һәм кыпчак) соңгысын тәшкил иткән булса кирәк. Ә инде Чепца елгасы буена бу нәсел вәкилләре, безнең фикер буенча, XV йөзнең икенче яртысында гына килеп утыралар. Бәлки ул күчеп утыру Ибраһим ханның Вяткага 1468 елны килүе белән бәйледер. Билгеле булганча, 1468 елны «Казанлылар... зур көч белән Вяткага килделәр һәм вятчаннар, аларга каршы тора алмыйча, Ибраһим ханга бирелделәр». Бу фикер,, әлбәттә, киләчәктә тарихи чыганаклар нигезендә тагын да җентекләбрәк тикшерүне сорый.

Ничек кенә булмасын, XIV йөз ахыры — XV йөз башында булачак Казан ханлыгының үзәк төбәкләренә Агыйдел ягыннан төрки кабиләләр үтеп керүнең сәбәпләре әлегә ачык түгел. Ләкин шунысы кызык: Кара би яшәгән урыннар соңыннан Казан «даругасын», ягъни өлкәсен тәшкил итә. 1469 елгы рус елъязмаларындагы мәгълүматларга караганда, ул төбәк аерым бер район — рус чыганакларында «Беловолжская земля» булып йөргән һәм анда башкортлар яшәмәгән, чөнки алар елъязмада аерып бирелгәннәр. Ниһаять, әле XVI йөзнең беренче яртысында да бу төбәктә Казан князьләре утырганлыгы билгеле.

XX гасыр башына караган саннар буенча, нократ татарларының өчтән берен элек бочорман саналган төркем тәшкил иткән. Әгәр дә катнаш гаиләләрдә туып үскән кешеләрне дә исәпкә алсак, бочорман компонентының нократ татарлары формалашуда тоткан урыны тагын да зуррак икәнен күрербез.

Бочорманнарның этник нигезләре турында гипотезалар шактый. Ләкин аларны болгарлар белән бәйләү дөреслеккә иң якын килүче караш булса кирәк. Чыннан да, Нократ авылында сөйләнгән риваятьләргә караганда, анда яшәүчеләрнең бабалары Болгардан чыкканнар. Киров өлкәсе, Малмыж районында язып алынган риваятьләрдә шушы фикер телгә алына. Тел белгече Т. И. Тепляшина фикере буенча, бочорманнар калдырган топонимнар белән Казан артындагы топонимнар арасында зур охшашлык бар. Шул ук вакытта Г. Ф. Саттаров та Казан артында болгар топонимнарының күп булуларын исбат итә. Тагын бер кызыклы фактка тукталып үтик. Билгеле булганча, XVI — XVII гасырларда кайбер документларда бочорманнарны «чуаш» (чуваш, ар чувашы) дип атыйлар. Шундый ук хәл Казан арты өчен дә хас — анда да «ясаклы чувашлар» яисә «ар чувашлары» документларда күпләп теркәлгән. Беренчедән, документлар Казан артыннан Чепца буена шушы «ясаклы чуашлар» күчеп килүне исбат итә. Аларны 1489 ел-

дан соң Мәскәү дәүләтенә буйсынган «ар князьләре» чакырып китерә. Шуңа күрә, XVI гасырда Нократ халкының «кара» өлешен икегә бүлеп йөрткәннәр: «иске Карино чувашлары» һәм «Казан җире чувашлары». Шушы исем астында йөрүчеләр төрки телдә сөйләшкәннәр. Һәм ислам динен тоткан нар. Икенчедән, күп санлы документлар нигезендә «Ясаклы чуашларның» чын чуваш түгеллеге, ә болгарларга барып тоташучы халык икәнлеге ачыкланды. Кайбер галимнәрнең фикере буенча, «бочорман» сүзе «мөселман» сүзеннән үзгәртеп ясалган. Рус елъязмаларында ул сүз «бесерман» яисә «бесермен» рәвешендә язылган. XIV-XV йөзләрдә Урта Иделдә, элекке Болгар дәүләте яшәгән төбәктә рус елъязмалары халыкның бер өлешен гел «бесермен» дип атыйлар. Академик М. Н. Тихомиров фикере буенча, рус елъязмалары шушы исем белән «кама болгарларын» атап йөрткәннәр. Димәк, Нократ тирәсендә яшәгән төркемнең «бесермян» (бочорман) дип аталуы очраклы хәл түгел. Бочорманнар телен өйрәнгән Т. И. Тепляшинаның ясаган нәтиҗәсе дә шул турыда сөйли. Аның фикере буенча, бочорманнар теле болгар теленә барып тоташа. Ләкин удмурт теле дә аңа зур йогынты ясаган. Әйтеп үткәнебезчә, бочорманнарның бер өлеше удмурт булган, соңыннан алар төрки бочорманнар тарафыннан йотылганнар. Шуның өстенә, 1740 елларда бочорманнарның яртысы чукындырыла, ә бу аларның удмуртлар белән якынаюына китерә.

Болгарлар Чепца буена кайчан үтеп кергәннәр соң? Бер фактка игътибар итик: чепца төбәгендәге Гурья-кала авылы янында 1323 елгы болгар кабер ташы табылган. Шулай итеп, XIV гасырда бу җирдә болгарлар яшәгән, бу турыда кайбер археологик табылдыклар да сөйли. Ләкин бу фактны турыдан-туры бочорманнар белән бәйләп булмый. Мәсьәлә шунда ки, XVI гасыр ахырларына тикле Нократ князьләре һәм бочорманнарның бабалары Нократ (Карино) тирәсендә яшәгәннәр, ә Гурья-кала тирәсенә XVII йөздә генә күчкәннәр. Тагын шуны да онытмыйк: Кара би шәҗәрәсендә күрсәтелгәнчә, Кара би нәселе килгәнче Чепца буенда мөселманнар яшәмәгән. Шушы фактлардан чыгып карагандa, бочорманнарның Нократка күчүләре «ар князьләре» белән бер үк вакытта булган дип уйларга мөмкин. Бочорманнар Казан артының төньяк төбәкләреннән күчкәннәр, ахрысы, чөнки этнограф Р. Г. Мөхәммәдова язмалары буенча, Киров өлкәсе, Малмыж районындагы Иске Бурец (удмурт авылы) һәм Дубровка (рус авылы) авыллары арасында «Болгар» дип аталган бер урын һәм мөселман зираты бар. Элек шул җиргә Нократтан татарлар килеп «бабалар хөрмәтенә» дога укый торган булганнар.

Шулай итеп, нократ татарларының формалашуы төп ике этник тамырга барып тоташа.

XVIII йөз документлары татар морзалары токымыннан чыгучылар белән бочорманнар арасында кыз бирү, кыз алуның шактый таралганлыгын күрсәтә. Ләкин бу әле берьяклы күренеш булган. Мәсәлән, 1839 елда Нократта булган бер автор түбәндәгечә яза: «Татарлар бочорманнарны үзләреннән түбән саныйлар... алардан кияүгә кыз алалар, ә үз кызларын бирмиләр». Чынлап та, патриархаль тормыш шартларында, ике якның да төркемчелек үзаңы шактый нык булган чорда, «кара халык» булган бочорманнарга татарлар ягыннан кыз бирмәү аңлашыла: кыз бирсәң аннан туган балалар социаль хәле түбәнрәк булган төркемгә күчә булып чыга. Ләкин XVIII йөздә үк инде бочорманнарның бер өлешенең социаль хәле үзгәрә: алар, татарлар төсле үк, йомышлылар катлавына керә башлыйлар. Шуңа күрә дә мөселман динен тоткан бочорманнар белән татарлар арасында якынаю барган. Бу процессның нәтиҗәләре XVIII йөздә үк күренә башлый. Әйтик: мөселман динендәге бочорманнар кайбер документларда «татар» дип языла башлый. XX гасыр башында исә күп бочорманнарның хатыннары татардан чыккан була.

Чукындырылган бочорманнар башкачарак үсеш юлына баса. Алар акрынлап удмуртлар белән якыная башлый һәм XX йөз башына удмурт телендә сөйләшүче, ләкин әле үзләрен һаман да аерым этник төркем дип санаучы берләшмә тәшкил итәләр. Хәзерге вакытта алар паспортка удмурт дип языла, ләкин үзаңнарын саклыйлар. Телләре дә чиста удмурт теле түгел. Бу төркемнең саны 1926 елда 9,2 мең кеше була.

Бочорманнарның мөселман һәм чукындырылганнары арасында якынлык XIX йөздә әле бик нык сизелгән. Мәсәлән, 1846 елны Вятка губернасында язылган бер документта болай дип әйтелгән: «Кайбер татарлар белән бергә яшәүче бочорманнар хәзер татарча сөйләшә, башкалары удмуртлар арасында яшәп, удмурт телен кулайрак күрәләр... Әмма тормыш-көнкүреш

ягыннан алар удмуртларга караганда татарларга күбрәк охшаган». Шул ук елларда христиан рухание Сатрапинский түбәндәгене күрсәтә: «Бочорманнардан чукындырылганнары «яңа христианлаштырылганнар» дип йөртелә, ә аларның якын туганнары, чукындырылмаганнар татар дип языла... үзләре исә үз-үзләрен бочорман дип атый». Инде XIX йөз ахырында-XX йөз башында татар телендә сөйләшүче бочорманнарның (кайбер очракта алар ике телдә — татар һәм удмурт телендә сөйләшкәннәр) күпчелеге үзен татар дип саный башлый. Шунысы кызыклы, бүгенге көндә бочорманнан татар булып киткән төркем вәкилләре үзләренең бочорман бабалары турында бер нәрсә дә белмиләр, янсә бабалары татар булган, ләкин аларны билгесез сәбәп аркасында бочорман дип йөрткәннәр, дип уйлыйлар. Слободск районында, ягъни татар князьләре күбрәк булган төбәктә шактый үзенчәлекле культура формалашкан. Мәсәлән, анда туй йолалары шактый үзенчәлекле, ә сабан туе электән булмаган. Удмуртия ягында исә — анда бочорманнар күбрәк була, туй йолаларының бүтән варианты яшәгән, сабан туе традицион бәйрәм итеlгән (туй йолалары бу төбәктә казан татарларыныкына һәм Сергач мишәрләренекенә тартым).

Шулай итеп, нократ татарлары казан татарларының этнографик төркеме буларак, кыпчак һәм болгар компонентлары нигезендә һәм шулай ук удмуртларның берникадәр тәэсире нәтиҗәсендә формалаша.

---

*Котлыйбыз!*

## Мәхмүт Газизовка 50 яшь



Шагыйрь Мәхмүт Минәхмәт улы Газизов 1940 елның 8 февралендә Татарстанның Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Туктар Урдалысы авылында туган. Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлагач, Казанга килеп, педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. 1963-1969 елларда туган районында — мәктәпләрдә укытучы, укыту бүлеге мөдире, директор булып эшли. 1970 елдан бирле — Чаллыда. Анда ул — тулай торакта тәрбияче, төзелештә геодезист, мастер, тимерчелек заводында эшче, газеталарда очерк-репортажлар белән катнашучы журналист...

«Миләш сиртмә» исемле беренче китабы 1969 елда дөнья күрә. Аннары балалар өчен «Бер, ике, өч» исемле шигырьләр җыентыгы (1972), КамАЗ темасын яктырткан «Тәгәри китте йомгагым» (1976), «Майдан» (1990) исемле китаплары дөнья күрде. Аерым шигырьләре «Новый мир» һәм «Волга» журналларында, коллектив җыентыкларда рус телендә дә басылды.

Мәхмүт Газизов — 1978 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы.

*Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлыйлар, сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телиләр.*

# ҖИДЕНЧЕ ДӘРЕС

Узган дәресләрдә без телебезнең грамматик үзенчәлекләре турында сүз башлаган идек, шуны дәвам итик. Татар телендә фигыль-хәбәрләр (сказуемое) генә түгел, ә һәртөрле башка сүзләр белән белдерелгән хәбәрләр дә, гадәттә, ахырдан килә.

Мәсәлән:

| | | |
|---|---|---|
| Миндә б а р курчак | түгел, | Миндә курчак б а р. |
| Миндә к ү п уенчыклар | түгел, | Миндә уенчыклар к ү п. |
| Я х ш ы м ы китап? | түгел, | Китап я х ш ы м ы? |

Балалар еш кына килеш кушымчаларын куллануда да хата җибәрәләр:

| | Дөресе: |
|---|---|
| Мин укыйм к и т а п н ы. | Мин к и т а п укыйм. |
| Миңа к у р ч а к н ы сатып ал. | Миңа к у р ч а к сатып ал. |

Татар телендә эшнең объектын баш килеш белән дә (китап, курчак ал), төшем килеше белән дә (китапны, курчакны ал) белдереп була. Кушымчасыз булганда, билгесез предмет турында сүз бара, ә төшем килеше (винительный падеж) кушымчасы белән килгәндә, ниндидер билгеле предмет турында сүз бара:

| | |
|---|---|
| Миңа к у р ч а к алып кайт. | Принеси мне к у к л у. |
| Миңа к у р ч а к н ы алып бир. | Передай мне ту к у к л у. |
| Миңа к ү л м ә к тек. | Сшей мне п л а т ь е. |
| Миңа к ү л м ә к н е тек. | Сшей мне то п л а т ь е. |

Телдә билгеле һәм билгесез әйберләрне аерып карау бик әһәмиятле күренеш. Күп кенә телләрдә ул махсус тел чаралары — билгелелек һәм билгесезлек артикльләре белән белдерелә.

А в а з л а р н ы ң д ө р е с ә й т е л е ш е. Татар телендә ш ә һ ә р, һ ә й к ә л, һ ә р ч а к, һ ә м, һ ә р б е р кебек сүзләрдә, З ө һ р ә, З ә һ и н ә, М а һ и р ә, Ф ә һ и м ә кебек кеше исемнәрендә кулланыла торган **һ** авазы үзенчәлекле аваз. Ул ясалышы белән рус һәм татар телләрендәге **х** авазына беркадәр ошый, шуңа күрә аларны еш кына бутап әйтәләр. Ә бу сөйләмне бик ямьсезли. **һ** авазы **х** авазы белән чагыштырганда тирәндәрәк, йоткылыкта ясала, ул йоткылык тартыгы.

һ а в а з ы н д ө р е с ә й т е г е з:
Безнең шәһәрдә һәйкәлләр күп.

Бик тырыш кыз Зөһрә
Һәммә эшкә өлгерә:
Әнисенә булыша,
Чынаяклар юыша.

Су сибә гөлләренә
Түкмичә күлмәгенә.
Себереп ала идәнне,
Көтми эшлә дигәнне.

Р. ХӘБИБУЛЛИНА

Бүгенге дәрес савыт-сабалар һәм аш-су атамалары турында. Сүзләр: т ә л и н к ә, ч ы н а я к, к а ш ы к, ч ә н е ч к е, п ы ч а к, а ш, п ә р ә м ә ч, а к м а й, ш и к ә р, с ө т, ч ә й һ. б.

Кызым (улым), әйдә бергәләп өстәл хәзерлибез. Башта син карап тор, сүзләрне отып ал: бу зур тәлинкә — аш тәлинкәсе, бу кечкенә тә-

линкә — өлеш тәлинкәсе. Бу чынаяк, бу кашык, бу чәнечке һ. б. (Сүзләр берничә тапкыр кабатлана. Әйдә өстәлнең бу ягын бергә тезәбез: бу зур тәлинкә..., бу өлеш тәлинкәсе һ. б. (Бала сүзләрне кабатлап бара.)

— Без нәрсә пешердек?
— Без аш пешердек.
— Тагын нәрсә пешердек?
— Пәрәмәч пешердек, чәй кайнаттык.

Шигырьне укыгыз:

Әни пәрәмәч пешерә
Вак итеп, тәмле итеп.
Без табында, чәй эчәбез
Бергәләп, ямьле итеп.

Мин дә булыштым әнигә
Пәрәмәчләр ясарга.
Үзең эшләгәч тәмле ул,
Кирәк эшләп ашарга.

ӘЗЬӘР ГАБИДИ

Өстәлне җыештыру: бала савытларын өстәлдән алып, исемнәрен әйтеп бирә: бу чынаяк, бу кашык, бу чәнечке һ. б.

Ашамлык кибетендә уены. Әни кеше — сатучы, киштәдә ашамлыкларны белдергән тартмалар.

— Син нәрсә аласың?
— Миңа сөт белән чәй бирегез.
— Конфет бармы? Мин конфет алам.
— Кибеттә тагын нәрсәләр бар?
— Ак май, шикәр, тоз, сыр һ. б.

Шигырьләрне ятлагыз:

— Минем апа Хәтирә
Ашханәдә аш бирә.
Ашны пешерә үзе,
Һәрвакыт ачык йөзе:
— Рәхим итегез! — ди ул,
— Туеп китегез! — ди ул.
— Ә менә минем апа

Конфет, прәннек сата.
Ул эшләгән кибеттә
Бар ак күмәч тә, сөт тә.
Әйбер ала күп кеше —
Олысы һәм кечесе.
Һәммәсе мактап китә.
Апамны хөрмәт итә.

МӨХӘММӘТ САДРИ

Хикәяне укыгыз, эчтәлеген бергәләп сөйләгез.

## КАБАРТМА

Бабай да, әби дә, әни дә, шулай ук кечкенә Әнисә дә — барысы да өстәл янында утыралар иде.

Өстәлдә зур җиз самавыр дөбердәп кайнап тора. Барысының да чынаяклары төрле-төрле. Әбинеке — зәңгәр, әнинеке җиләк бизәкле, Әнисәнеке әтәч сурәтле.

Бабайның чынаягы юк, ул чәйне стаканнан эчә.

Әби мичтән бер таба кайнар бәрәңге чыгарды. Кызарып пешкән түгәрәк бәрәңгеләр өстендә эре тоз бөртекләре ялтырый. Ә Әнисәнең тәлинкәсенә әби кызарып пешкән арыш кабартмасы салды. Әнисә шатланды.

— Әй, бабай, синең кабартмаң юк, ә минем бар! — дип кычкырды ул.

— Исең киткән икән! Кабартма! — дип җавап бирде бабай.— Аның каравы, мин зәңгәр кошчык күреп утырам, ә син күрмисең.

— Кайда, кайда зәңгәр кошчык?

Әнисә тәрәзәдән үрелеп карады.

Бер каенга күз төшерде, икенчесенә күз салды. Юкәгә дә карап бакты.

— Кая соң ул кошчык?

Бабай өстәл янынннан торды да, өйалды баскычына чыгып китте. Ә аннан кергәч, зәңгәр кошчыкны тагын күрдем, диде.

— Син картлачны тыңлама,— ди әби.— Ул юри шулай әйтә.

— Менә бит син нинди бабай! — ди Әнисә үпкәләп.— Һаман алдашасың.

Ул үз урынына утырып, кабартмасын алмакчы булган иде, караса, кабартма юк.

Әнисә бар кешегә дә берәм-берәм карап чыкты. Кабартманы кем алган?

Әнисе көлә, тик кабартма аңарда түгел. Әбидә дә кабартма юк. Ә бабай шаккаткан була:

— Нәрсә? Кабартма югалганмыни? И! Мин аны әле генә ишегалдында күрдем, шул түгел иде микән?

— Ничек инде ул алай, ишегалдында?

— Менә шулай. Мин өйгә кереп киләм, ә кабартма миңа каршы очрады. Мин аңа: син кая барасың? — дим, ә ул: мин кояшка кызынырга чыгам,— ди. Бар әле, карап кер, баскыч төбендә юкмы икән.

Әнисә баскыч төбенә йөгереп чыкты, ни күрсен,— чыннан да аның кабартмасы анда кояшта кызынып ята!

Әнисә сөенде, кабартманы алды да, кире йөгереп керде.

ЛЮБОВЬ ВОРОНКОВА буенча.

## МАРТТА

«Кар, кар! — дип кычкыра карга
Күп яттың, кар, кит, җитәр»,— ди.
Бабай әйтә:
— Бу дөрес,— ди,—
Карга килгәч, кар китәр,— ди.

ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ.

## 8 нче МАРТ — ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕ

Без әниләрне ничек котлыйбыз?

Кадерле әнием (әбием, дәү әнием, апам һ. б.) мин сине 8-Март, әниләр бәйрәме белән котлыйм!

Шигырьне укыгыз, ятлагыз.

## ДӘҮ ӘНИЕМ

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел ул,
Ул минем дәү әнием.

Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп,
Чисталыкка өйрәнәм
Мин дә аңардан күреп.

Күзлексез күрмәсә дә,
Таяксыз йөрмәсә дә,
Җитмеш яше тулса да,
Бик картайган булса да.

Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

ЭМИНӘ БИКЧӘНТӘЕВА.

Фәһимә ХИСАМОВА, филология фәннәре кандидаты.
Рәшидә БОРЬАНОВА, методист.

*Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре*

# ЗӨҺРӘ ЙОЛДЫЗ

**РИВАЯТЬ**

Заманында Зөһрә исемле бик матур, бик акыллы, бик эшчән кыз булган. Аның булдыклылыгына, уңганлылыгына, һәр эшне белүенә, кешеләргә карата игелекле булуына бөтен тирә-як исләре китеп сөйли икән. Ләкин ул үзенең матурлыгы, уңганлыгы белән бер дә эреләнмәгән. Аның бик усал үги анасы булып, ул Зөһрәдән бик көнләшеп, һәрвакыт юк сәбәпләр белән аны тирги, ачулана, кыен эшләр куша икән. Иртәдән алып кичкә кадәр эшләгән Зөһрә. Юри, кешеләрнең җылан, ерткыч күп дип сөйли торган куркыныч урманнарга Зөһрәне коры утыннар җыярга җибәрә икән үги анасы. Зөһрә бер дә карышмый, үзенә кушылган эшләрне эшли, аңар һични булмый икән. Ничаклы ачуланса да, ничаклы эшләтсә дә, Зөһрә үги анасына бер дә усаллык кылмый икән. Күңеле һәрвакыт изгелектә генә булган. Кулыннан килгән эшләрне көн димәгән, төн димәгән эшләгән, ничек тә үги анасын ризалатырга тырышкан. Зөһрәнең шундый сабырлыгы, шундый түземлеге үги ананы бигрәк тә ачуландырган.

Шулай бер көнне, иртәдән кичкә кадәр эшләп бик арып кайткач, Зөһрәне үги анасы төпсез савытка су ташырга кушкан, үзе бик ачуланып: — Әгәр дә таң атканчы тутырмасаң йортыма аяк басачак булма, кыйнап үтерермен, — дигән.

Зөһрә бер сүз әйтмичә көянтәсе белән чиләкләрен күтәреп суга киткән. Көн буе эшләүдән куллары талган, аяклары йөрүдән көчкә-көчкә генә атлыйлар, җилкәләре буш чиләкләр күтәргәнгә дә сызлана икән. Бик матур айлы кич булган. Ай күктән көмеш нурларын җиргә коя, бөтен җир йөзе иркәләнеп тын гына ята икән.

Яр буенда Зөһрә, бер аккан суга, бер күктәге айга, бер тирә-ягына карап, тирән уйга чумган. Туган әнисенең ягымлы сүзләре, җылы куены исенә төшкән. Шунда үзенең бәхетсезлеген уйлап, кайнар яшьләре бит буеннан җиргә тәгәрәгәннәр. Ул ялгыз үксеп-үксеп җылаган да, «уф»... дип сулап, чиләкләре белән су алган. Сулы авыр чиләкләр аның җилкәләрен тагын да авыррак басалар икән. Ул тагын айга караган. Ай һаман нурланып йөзә икән. Үзенең бәхетсезлегенә кызның җаны әрнегән, ләкин бәхетсезлеге өчен берәүне дә гаепләмәгән. Күңелендә үги анасына бер усал уе юк, тик аңар миһербанлык кына тели икән. Шунда бер йолдыз атылып, дөнья тагын да нурланыбрак киткәндәй булган. Зөһрәнең күңеленә дә әллә нишләп җиңел була башлаган. Күңеле һәрвакыт яхшылыкта булганга Зөһрәне бер якты йолдыз һәрвакыт күзәтеп торган икән, менә шул җиргә атылып аны нурларына чолгап күтәрә башлаган. Зөһрә үзе дә кайдадыр күтәрелгәнен сизгән, чиләкләре җиңеләйгәндәй булган. Аның йөрәгендәге авыр төен беткән, күңеленә бик йомшак, бик җиңел, бик рәхәт булган. Шунда озын керфекле күзләрен ачып җибәрсә, үзен ай уртасында күргән.

Сез әгәр дә айга игътибар белән күзләрегезне текәп карасагыз, ай уртасында көянтәсенә чиләкләрен аскан Зөһрә кызның басып торганын әле дә күрерсез. Ә ай янында ялтырап яна торган йолдыз булыр, бусы инде Зөһрәне күккә күтәргән йолдыз. Аны Зөһрә йолдызы дип йөриләр.

## زهره یولدز

زماندا زهره ایسملی بیك ماتور، بیك آقللی، بیك أشچه‌ن قز بولغان. آنڭ بولدقلیلیغینا، اوكغانلیغینا، هر أشنی بلووینه، کشیلرگه قاراتا ایگیلكلی بولوویننا بتون تیره یاق ایسله‌ری کیتوپ سویلی ایکه‌ن. لکن اول اوزینڭ ماتورلغی، اوكغانلغی بله‌ن بر ده أریله نمه‌گه‌ن. آنڭ بیك اوسال اوگی آناسی بولوپ. اول زهره‌دن بیك کونله‌شپ هر وقت یوق سبپلر بله‌ن آنی تیرگی، آچولانا، قیین أشله‌ر قوشا ایکه‌ن. ایرته‌دن آلوپ کیچکه قدر أشله‌گن زهره. یوری، کشیلرنڭ یلان، یرتقچ کوپ دیپ سویلی تورغان قورقنچ اورمانتارغا زهره‌نی قوری اوتینتار جیارغا جیبه‌ره ایکه‌ن اوگی آناسی. زهره بر ده قارشمی، اوزینه قوشلغان أشله‌رنی أشلی، آگار هیچ نی بولمی ایکه‌ن. نی چاقلی آچولانسا دا، نی چاقلی أشله‌تسه ده، زهره اوگی آناسینا بر ده اوساللق قیلمی ایکه‌ن. کوڭلی هر وقت ایزگیلیکته گنه بولغان. قولیتتان کیلگه‌ن أشله‌رنی کون دیمه‌گن، تون دیمه‌گن أشله‌گه‌ن، نیچك ته اوگی آناسن ریزالاترغا ترشقان. زهره‌نڭ شوندی سابرلغی، شوندی توزملگی اوگی آنانی بیگره‌ك ته آچولاندرغان.

شولای بر کوننی، ایرته‌دن کیچکه قدر أشله‌پ بیك

آروپ قايتقاچ، زهره نى اوگى آناسى توپسز ساويتقا سو تاشرغا قوشقان. اوزى بيك آچولانوپ:

— اگرده تاڭ آتقانچى توترماساڭ يورتيما آياق باساچاق بولما، قيناپ اوترورمن، — ديگه ن.

زهره بر سوز ده ئه يتميچه كويه نته سى بله ن چيله كله رين كوته روپ سوغا كيتكه ن. كون بويى أشله ودن قوللارى تالغان، آياقلارى يورودن كوچكه - كوچكه گنه آتليلار، جيلكه لرى بوش چيله كلر كوته رگنگه ده سزلانا ايكه ن. بيك ماتور آيلى كيچ بولغان. آى كوكته ن كموش نو- رلارين جيرگه قويا، بتون جير يوزى ايركه له نپ تن غنا ياتا ايكه ن.

يار بويندا زهره، بر آققان سوغا، بر كوكته گى آيغا بر تيره - ياغينا قاراپ، تيره ن اويغا چومغان. توغان ئه ني- سينڭ ياغملى سوزلرى، جلى قوينى ايسينه توشكه ن. شوندا اوزينڭ بختسزلگين اويلاپ. قاينار يه شله رى بيت بويننان جيرگه ته كه ره گننه ر. اول يالغز اوكسوپ - اوكسوپ يلاغان دا. «اوف»... ديپ سولاپ، چيله كلرى بله ن سو آلغان. سولى آور چيله كلر آنڭ جيلكه لرين تا- غن دا آورراق باسالر ايكه ن. اول تاغن آيغا قاراغان. آى همان نورلانپ يوزه ايكه ن. اوزينڭ بختسزلگينه قز- نڭ جانى ئه رنيگه ن، لكن بختسزلگى اوچون بركمنى ده

عیبله‌مه‌گن. کوگلنده اوگی آناسینا بر اوسال اوی یوق،
تیك آگار مهربانلق قنا تلی ایکه‌ن. شوندا بر یولدز
آتلوپ، دنیا تاغن دا نورلانبراق کیتکه‌نده‌ی بولغان.
زهره‌نك کوکلینه ده ئه‌لله نیشله‌پ جیکل بولا باشلا-
غان. کوکلی هروقت یاحشیلقتا بولغانغا زهره‌نی بر
یاقتی یولدز هروقت کوزه‌تپ تورغان ایکه‌ن. منه شول
جیرگه آتلوپ آنی نورلارینا چولغاپ کوته‌ره باشلاغان.
زهره اوزی ده قایدادر کوته‌رلگه‌نن سیزگه‌ن، چیله-
کله‌ری جیکله‌یگنده‌ی بولغان. آنك یوره‌گنده‌گی آور
تویون بتکه‌ن. کوکلینه بیك یومشاق، بیك جیکل، بیك
راحت بولغان. شوندا اوزون کرفکلی کوزلرین آچوپ
جیبه‌رسه اوزین آی اورتاسندا کورگه‌ن.

سز اگر ده تولغان آیغا اعتبار بله‌ن کوزلریگزنی
تکه‌پ قاراساغز. آی اورتاسندا کویه‌نته‌سینه چیله‌ کله-
رین آسقان زهره قزنك باسوپ تورغانن ئه‌لی ده
کوروسز. ئه آی یانندا یالتراپ یانا تورغان یولدز
بولر، بوسی ایندی زهره‌نی کوککه کوته‌رگن یولدز.
آنی زهره یولدزی دیپ یوریله‌ر

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. — Казан, 1987, 233-234 бб.

*Текстны журнал өчен Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

Әхәт Сафиуллин

# НЮАНС

Шиһап Мөбәрәкеч, әйдүк, әйдүк! — дип елмайды идарә башлыгы ишектән керүчегә.— Безнең якларга нинди җилләр ташлады?

— Бер йомыш төште әле менә, Камил Әсхәтович,— диде тегесе, күрешеп.— Тукта, мәйтәм, шефлар ярдәм итми калмас...

— Кулдан килгән хәтлесен ярдәм итәрбез, әлбәттә.

— Әй-й...— кунак кулын селтәп куйды.— Теплица ясап маташа идек тә, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, базада металл беткән икән, каһәр суккыры! Кулыбызда акча була торып, тимер өрлек эзләп йөреш.

— Күпме кирәк соң? — дип сорады кабинет хуҗасы.

— Тонна ярым чамасы юнәтеп булса, эш пеште дигән сүз инде, Камил Әсхәтович. Бер башлагач, бетереп куясы иде.

Идарә башлыгы утырган урыныннан кузгалып куйды:

— Күп тә түгел икән үзе...

— Юк инде! — Шиһап Мөбәрәкович, кесәсеннән тешсез тарагын чыгарып, иясен ташлап китәргә оялган алты бөртек чәчен сыпыргалап алды.— Күп булса, өч йөз илле сумлык нәрсәдер.

— Анысы шула-а-й,— кабинет хуҗасы бармакларын өстәлдә уйнатып алды.— Тик эш аның бәясендә түгел, катлаулырак...

— Нәрсә, юкмы әллә? — дип куркынып сорады кунак кеше.

— Бар барын... Тик читкә материал җибәрү ка-а-атгый тыела шул. Менә хикмәт нәрсәдә, хөрмәтле Шиһап Мөбәрәкеч...

— Сез безнең шефлар ич! Кем нәрсә әйтсен?!

— Ә анда, өстә белсәләр? — идарә башлыгы, йөзенә җитдилек бөркәп чыгарып, түшәмгә төртеп күрсәтте.— Муенны борачаклар. Авыр йомыш белән килгән син бу юлы... Син миннән идәнгә җәя торган плита сорасаң икән. Унбер меңлек ята. Ревизия ясаган саен шуны чәйнилар.

— Нишлим мин аның белән? — диде кунак.— Миңа өрлек кирәк, тимер өрлек! Я, әйт, бирәсеңме, юкмы? Әллә шефлык итә торган колхозыгызга биргән өч йөз сумлык әйбер өчен асып куярлар дип куркасыңмы?

— Болай гына биреп булмый. Уйларга кирәк,— дип, муенын кашып алды идарә башлыгы.— Болай эшләсәк кенә инде...— Ул кунакның йөзенә төбәлеп, бер мәлгә тынып калды.

— Ничек итеп? — дип, түземсезлек белән кабатлады тегесе.

— Әйтик, әлеге дә баягы тонна ярым өрлекне сезнең колхоз парнигына безнең оешма монтажлап куйган ди...

— Куегыз соң, Камил Әсхәтович, куегыз! Рәхмәт әйтербез,— диде кунак һәм, урыныннан ук сикереп торып, аның кулын кысарга кереште.

— Син мине аңлап җиткермәдәң, Шиһап Мөбәрәкеч... Аны сез үзегез куясыз. Ә безгә... Эшләгән өчен акча түләрсез. Ул чагында без аны шул нигездә гамәлдән чыгара алабыз. Менә шундый эшләр...— диде идарә башлыгы.— Һәр нәрсәнең үз җае бар бит...

— Кирәк икән, килештек,— диде колхоз вәкиле.— Ат бәясе түгелдер...

— Ләкин монда әле тагын кечкенә генә бер нюанс бар шул...

— Анысы нәрсә тагын? — дип куркып сорады Шиһап Мөбәрәкович.

— Эш шунда ки, бу нәрсә дөреслеккә туры килергә тиеш. Үзең беләсең, заманы шул: алны-артны карап эш итәргә кирәк. Тикшерә-нитә калсалар,

бар да тәртиптә булырга тиеш,— кабинет хуҗасы җиңелчә генә көлеп куйды.— Хәзер, үзең беләсең...

— Моның өчен ни кирәк соң?

— Димәк, өрлекне парник түбәсенә куйдык ди. Ә парник түбәсе нәрсәгә таянып торырга тиеш?

— Аның стеналары әзер инде,— диде Шиһап Мөбәрәкович.— Түбәсе менә шул стенада тора инде аның...

— Менә шулай шул: стена-да то-ра,— дип җәһәт кенә эләктереп алды Камил Әсхәтович.— Димәк, бу инде нәрсә дигән сүз?

— Ә нәрсә? — дип сорады колхоз вәкиле һәм урындыгын алгарак күчерә төште.

— Димәк,— диде идарә башлыгы,— үтәлгән эшкә стена салуны да кертергә кирәк булып чыга. Логика шулай куша, Шиһап Мөбәрәкеч, ло-ги-ка! Хәзер аңлашылдымы инде?

— Ә стена фундаментта тора...— дип куйды кунак, үз-үзе белән сөйләшкәндәй.— Ә фундамент — җирдә...

— Дөрес! Бик дөрес! Менә ичмаса баш! — дип күтәреп алды Камил Әсхәтович.— Дөрес, Шиһап Мөбәрәкеч, исәп-хисапка фундамент салу белән җир эшләрен дә кертмичә булмас. Алайса, килештек?

— Өрлек бик кирәк бит,— диде вәкил.— Күпмегә тартыр соң бу нәрсәләр?

— Миллионер колхоз юк-бар чыгым белән генә чутлашып тормас инде. Шефыгыз булганга күрә генә бирәбез. Башка берәү булса, сөйләшеп тә тормас идек... Мин монда хисаплап карадым, бу эш сигез мең дә ике йөз чамасы тарта.

Кунак, корт чаккандай, утырган урыныннан сикереп торды.

— Сигез мең дә ике йөз?! — дип ыңгырашты ул, урынына авып.— Өч йөз сум урынына сигез мең дә ике йөз?!

— Син нигә шул хәтле гаҗәпкә калдың әле, Шиһап Мөбәрәкеч? — дип сорады кабинет хуҗасы, аңа стакан белән су биреп.— Юк-барга исең китмәсен, саулыгыңны сакла!.. Әгәр кирәк түгел икән, үзеңә карыйсың... Ирексезләмим бит...

— Мин риза, риза! — дип кычкырды Шиһап Мөбәрәкович, исенә килеп.— Пичәтем дә үзем белән... Әйт, әзерләсеннәр кирәкле документларны. Хәзер үк кул куям!

Бераздан, үтәлгән эшләр күләмен күрсәтеп, документ төзелде, имзалар салынды.

— Башка берәү булса...— диде Камил Әсхәтович, колхоз вәкилен ишек төбенә кадәр озата чыгып.— Үзең беләсең, Шиһап Мөбәрәкеч, безнең эштә менә шундый кечкенә-кечкенә генә кайбер нюанслар бар инде ул... Кирәк нәрсәләрегез булса, килегез, кил! Ярдәм итәрбез. Ни әйтсәң дә, без сезнең шефлар ич!

Бераздан алар, үзара җылы гына саубуллашып, бер-берсеннән канәгать булып аерылыштылар. Юкка гына да булмаган икән: төзелеш идарәсе начальнигын — колхозга парник төзеп биргәне, ә колхоз председателен төзү оешмасы белән уртак тел табып эшли белгәне өчен әле күп мәртәбәләр мактап-мактап сөйләделәр.

Тик нигәдер Шиһап Мөбәрәкович идарә ишеген бүтән ачып кермәде... Аның кермәвенең бер нюансы бар иде...

## КИНОЧЫЛАР СЪЕЗДЫ

Узган елның 13 декабрендә Казанда Татарстан Кинематографистлар союзының чираттан тыш съезды булды. Аны иҗат союзы идарәсенең беренче секретаре Х. Ф. Фәхретдинов ачты.

Съездда ТАССР Кинематографистлар союзының яңа уставы проекты, шулай ук СССР Кинематографистлар союзының ноябрь пленумы материаллары тикшерелде.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының идеология бүлеге мөдире Р. М. Харисов һәм СССР Кинематографистлар союзы идарәсе секретаре К. Л. Лаврентьев катнашты.

## «МИН ДӘ БЕР КИЧӘ»

Идел буе һәм Урал ягы автономияле республикаларының Казанда ачылган региональ Композиторлар йорты «Мин дә бер кичә» исеме астында иҗади очрашулар үткәрә башлады. 26 декабрьдә Җыр сәнгатенә багышланган беренче кичәдә композиторлар, шагыйрьләр, башкаручылар катнашты. Уртак проблемалар турында фикер алышу җыр тыңлау белән аралаштырылды.

«Мин дә бер кичә»нең беренчесен ТАССР Язучылар союзы каршында эшләүче поэзия секциясе җитәкчесе шагыйрь Зиннур Мансуров алып барды.

## ТАТАРЧА ЯҢА ГАЗЕТАЛАР

Зур йөк автомобильләре җитештерүче Ленин орденлы Кама производство берләшмәсендә эшләүче милләттәшләребез яңа елда зур бүләк алдылар. Берләшмәнең парткомы, профкомы, ВЛКСМ комитеты һәм администрациясе татар телендә «Нур» исемле газета чыгара башлады.

Газетаның Яңа елга багышланган саны бизәлеп, төсле итеп, ике санны берләштереп чыгарылган. Анда Чаллы әдипләре һәм танылган журналистлар төрледән-төрле язмалар белән чыгыш ясыйлар. Тагын шунысы игътибарга лаек: газета компьютерда әзерләнгән.

Редакция хезмәткәрләре үз укучыларына байтак кына шатлыклы мизгелләр бүләк иткән. Әхлак темасына язылган мәкаләләр, «Кети-кети» чәйханәсендәге көлкеле сөйләшүләр, табигать күренешләрен тасвирлаучы «Фасыл» сәхифәсе яратып укыла, уйландыра, күңелдә яхшы тәэсир клдыра.

Газетаның редакторы — Н. Таҗиев.

1990 нчы ел Киров өлкәсендә яшәүче татарлар өчен истәлекле вакыйга белән хәтергә кереп калачак. Бирегә КПСС өлкә комитеты һәм өлкә Советы башкарма комитеты органы — «Дуслык» газетасы чыга башлады. Ул Татарстанның Балтач, Кукмара һәм Мари АССРның татарлар яши торган Мари-Төрек районы белән чиктәш булган Малмыж шәһәрендә басыла. Газета әлегә Киров өлкәсенең Вятские Поляны, Көлмез һәм Малмыж районнарында яшәүче татар укучылары мәнфәгатен истә тотып чыгарыла. Якын киләчәктә, өлкә газетасы буларак, ул башка районнарга да таратылачак.

Газетаның редакторы — Ш. Бухаров.

Яңа елда Ульяновск шәһәрендә һәм өлкәсендә яшәүче милләттәшләребез тормышында зур вакыйга булды: Ульяновскида «Өмет» дип аталган яңа газета чыга башлады.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң Сембер (Ульяновск) шәһәрендә «Таң» исемле газета чыккан. Аның кайчан туктап калуы билгеле түгел. Ләкин иң әһәмиятлесе шул: башка исем белән булса да, ул яңадан ачылды, ул яши башлады.

Шунысы игътибарга лаек: «Өмет» КПССның Ульяновск өлкә комитеты, халык депутатларының өлкә Советы һәм «Туган тел» җәмгыяте органы булып чыга. Димәк, әлеге статус аңа өлкә күләмендә эш йөртергә, проблемаларны тирәнрәк өйрәнергә зур мөмкинлекләр бирәчәк.

Газета үз алдына туган телебезне пропагандалау, балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү, халкыбызның милли культурасын, тарихын, гореф-гадәтләрен киң яктырту, өйрәнү һәм тергезү кебек әһәмиятле бурычларны куя. Әлеге максатларда газета битләрендә балалар өчен мавыктыргыч әсәрләр тәкъдим ителәчәк, аңлатмалы сүзлек алып барылачак, милләттәшләребезнең тормыш-көнкүрешен, милләтара мөнәсәбәтләрне чагылдырган язмалар биреләчәк.

Газетаның редакторы — К. Сафиуллин.

Чиләбе шәһәрендә һәм өлкәсендә 200 меңнән артык татар яши. Бирегә Муса Җәлил исемендәге әдәби берләшмә күптәннән эшләп килә. Аның әгъзалары Казан һәм Уфа шәһәрләрендә үзләренең китапларын бастырып чыгардылар. ЧТЗ производство берләшмәсе культура сараенда эшләп килүче татар драма театры халык театры исемен яулады. «Таң нурлары» һәм «Айгөл» ансамбльләре, Магнитогорск, Златоуст, Миәс шәһәрләрендәге үзешчән сәнгать түгәрәкләре дә халыкта зур ихтирам казанды. Милли культура үзәге теләген истә тотып, институтларда, педагогия училищеларында татар һәм башкорт теле укытучылары әзерләү группалары ачылды. Өлкә мәктәпләрендә ана телен өйрәналәр.

Быелның 1 январенда милләттәшләребез «Челябинский рабочий» газетасының махсус чыгарылышы — татар телендәге «Дуслык» дигән яңа газетаның беренче санын кулга алдылар. «Дуслык» аена бер тапкыр чыгарылачак һәм «Союзпечать» киоскалары, җәмәгать оешмалары аша таратылачак.

Газетаның редакторы — Ш. Айбулатов.

## КАЗАННЫ ТЫҢЛЫЙСЫҢ КИЛСӘ...

Хәзер Пермь, Свердловск, Төмән өлкәләре татарларына, Казан һәм Татарстан яңалыклары белән танышасылары килсә, радиоалгычларны 41. 75 метрлы дулкынга күчерү җитә.

Моның өчен өлкәнең көньяк районнарында яшәүче татарлар һәм башкортлар Пермь элемтәчеләренә бурычлы. Чөнки алар көче белән радиоүзәкнең бер антеннасы Казан тапшыруларына кабул итү өчен көйләнде.

## КОМИТЕТ СОСТАВЫНДА

СССР Министрлар Советы СССР Министрлар Советы каршындагы әдәбият, сәнгать һәм архитектура өлкәсендә Ленин һәм Дәүләт премияләре комитетының составын раслады.

Комитетның матур әдәбият секциясе составында безнең республикадан драматург, СССР халык депутаты, СССР Верховный Советының Милләтләр Советы члены Туфан Миңнуллин да бар.

## РӘССАМНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Узган елның 28 октябрендә Мәскәүдә, Фәнни атеизм үзәк йортында, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам-монументалист А. Х. Мусаловның иҗат кичәсе булды. Аны «Туган тел» культура-агарту татар җәмгыяте һәм «Гуманист» культура-агарту үзәге оештырган иде.

Атеизм йорты залына Мәскәү татар интеллигенциясенең күренекле вәкилләре, сәнгать сөючеләр, рәссамның дуслары җыелды. Алар арасында СССР халык депутаты Т. Миңнуллин, кардиологлар ассоциациясе президенты Р. Әмиров, генерал-лейтенант Р. Вәлиев, рәссам А. Китаев, сәнгать белгечләре В. Трофимов, Г. Блинов, «Туган тел» җәмгыяте советы члены М. Миначев һәм башкалар бар иде. Кичәне аны оештыручыларның берсе А. Бәйрәмов ачты.

Вестибюльдә А. Мусалов картиналарыннан күргәзмә оештырылган иде.

## АЛМА-АТАДА ӘДӘБИ КИЧӘ

Казахстан башкаласының М. Әүэзов музей-йортында җомга көннәрендә казакъ әдәбияты һәм сәнгате халык университеты эшләп килә. Күптән түгел шундый сабакларның берсе татар әдәбиятына, аның казакъ мәдәнияте белән бәйләнешләренә багышланды.

Әдәби кичә филология фәннәре кандидаты, татар әдәбиятын өйрәнүче казакъ галиме, танылган шагыйрь Бөркет Исхаков чыгышы белән башланды. Аннары сүзне казакъ язучылары, татар шигърияген татар теленә тәрҗемә итүче Хәмзә Абдуллин, Есәт Әукәбаевлар дәвам итте. Кичәдә Алма-Атада яшәүче татар язучысы, казакъ телен дә яхшы белүче, татар һәм казакъ әдәбиятларын русчага тәрҗемә итүче Әсгать Хәмидуллин да катнашты. Ул тыңлаучыларны Татарстанның бүгенге культура казанышлары белән таныштырды.

Кичә татар җыр-биюләре белән тәмамланды. Алма-Атада яшәүче милләттәшләребез бу мәҗлесне оештыручыларга, бигрәк тә татар әдәбиятын зурлап чыгыш ясаучы казакъ язучыларына чын күңелдән рәхмәт белдерделәр.

## ТАШКЕНТТА ОЧРАШУЛАР

Шиһап Мәрҗани исемендәге мәдәни җәмгыять юнәлтүе буенча язучы Тәүфикъ Әйди былтыр декабрь аенда Ташкент шәһәренә барды. Халыклар дуслыгы музеенда, Трактор заводында, 153 нче мәктәптә Татар культурасы үзәген оештыручылар, туган әдәбиятыбызны сөючеләр белән очрашты. Республикабызның рухи тормышы, милли матбугатыбыз үсеше хакында башлангыч эңгәмәгә әдип Мәгъсүм Насыйбуллин, «Азат хатын» журналы редакциясе хезмәткәре Әлфия Сәгъдиева һәм Ташкентта яшәүче шагыйребез Әдхәт Синугыл да кушылды. Музейдагы очрашу Үзбәкстан телевидениесе тарафыннан язып алынды һәм «Әхбарәт» программасында күрсәтелде.

Үзбәкстанда хәзер татар теле һәм әдәбияты дәресләре 35 мәктәптә укытыла, 153 нче мәктәптә бу дәресләргә 200 укучы йөри. Алар кунакларны татарча шигырь сөйләп, җыр җырлап каршы алдылар һәм озатып калдылар.

## КАРДӘШЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК

«Җидегән чишмә»гә чит республикалардан һәм өлкәләрдән культура һәм сәнгать эшлеклеләрен чакыру күптән инде традициягә әверелде.

Бу юлы Башкортстанның күренекле татар шагыйре, публицист Айдар Хәлим һәм популяр җырчы, виртуоз тальянчы Фән Вәлиәхмәтов «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсенең кадерле кунаклары булдылар. Тамашачылар соравы буенча «Җидегән чишмә» беренче тапкыр ике көн барды. Шуңа да карамастан, ике көнне дә зал тулы иде. Ә 24 декабрьдә шундый ук кичә Чаллы шәһәрендәге иң зур концерт залларының берсендә булды.

Айдар Хәлимне Түбән Камада моңарчы да яхшы беләләр иде. Чөнки ул — яшь шәһәр төзелә башлаганда монда төзүче булып эшләүчеләрнең берсе. Фән Вәлиәхмәтовның көчле, моңлы тавышы, тальян гармунда искиткеч оста уйнавы тыңлаучылар күңеленә бик тә хуш килде.

Кичәләрне Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре Рахмай Хисмәтуллин алып барды.

## БАТУЛЛАНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

29 январьда Казанның Актерлар йортында язучы Батулланың иҗат кичәсе булып узды. Кичәдә язучының торгынлык елла-

рында дөнья күрәлми калган әсәрләре яңгырады. Тамашачы белән турыдан-туры әңгәмә алып бару, дистәләрчә актуаль сорауларга җавап бирү һәм уен-көлкеле сәхифәләр бу кичәне онытылмаслык итте. Кичәдә халкыбызның танылган сәнгать осталары да катнашты.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Фәнни һәм педагогик эшчәнлектәге хезмәтләре өчен тарих фәннәре докторы, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты профессоры, кафедра мөдире Нәфыйков Рафикъ Измайловичка, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 15 декабрь Указы белән, «РСФСРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт культура институтының оркестр дирижерлыгы кафедрасы доценты Хәсби Вәлиевич Фазлуллинга, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 27 декабрь Указы белән; «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Минзәлә татар драма театры артисткасы Мөслимә Гарифуллинага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1989 ел, 25 декабрь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры артистларыннан балет солисты Ринат Габдрахмановка, балет солисткасы Луиза Мөхәммәтгалиевага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1990 ел, 9 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт консерваториясенең махсус фортепиано кафедрасы доценты вазифаларын башкаручы Әлфия Вафовна Бурнашевага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1990 ел, 9 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры артисты Мөнир Якуповка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1990 ел, 9 январь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

---

## *Безнең календарь*

Аңа февральдә 50 яшь тулган булыр иде...

Шагыйрь Тәүфикъ Камалиев (Тәүфикъ Салих улы Камалетдинов) 1940 елның 3 февралендә Татарстанның Буа районы Ташкичү авылында туа. Алтынчы классқа кадәр ул туган авылы һәм Апас районының Кызыл Тау мәктәпләрендә укый, ә җиденче классны Казанда тәмамлый. Аннары икееллык техник училищеда слесарьлык һөнәренә өйрәнеп, 1958 — 1961 елларда Казанның Горбунов исемендәге заводында слесарь-җыючы булып эшли, кичке мәктәп тәмамлый. 1961 — 1966 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны тәмамлагач, Татарстан телевидениесендә өлкән редактор, күп тиражлы газета редакторы һәм «Ялкын» журналы, «Социалистик Татарстан» газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1966 елда КПСС сафларына керә. 1980 елның 13 февралендә кинәттән вафат булды.

Шигърияткә Т. Камалиев алтмышынчы елларда килә: туган як, эшчеләр һәм студентлар тормышына багышланган беренче шигырьләре көндәлек матбугатта басыла; 1967 елда аның «Ромашкалар эзлим» исемле беренче китабы дөнья күрде. Аннары «Сабыр канатлары сынмый» (1969), «Адымнар» (күмәк җыентык, 1969), «Сезгә генә сөйлим» (1970), «Хәләл көчем белән» (1972), «Яшьлеккә кайту» (1987) һәм «Ак өметләр» (1986) исемле китаплары басылып чыкты. Аларда да без шагыйрьнең авыл, гади кешеләр, завод тормышы темасына тугры калуын күрәбез.

Тәүфикъ Камалиев 1971 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

# КАРА ПУЛАТ

Бу серле һәм мәһабәт бина Шәһре Болгарда гына түгел, ә бәлки илебездә урта гасырлардан калган иң күренекле тарихи-архитектура ядкарьләреннән санала. Археологларның тикшеренүләренә караганда, бу кызыклы бина XIV гасыр урталарында төзелгән. Хәзерге вакытта без инде борынгы зур корылма комплексының бер өлешен генә тамаша кыла алабыз. Болгар монументаль архитектурасының гүзәл үрнәк хисаплanучы әлеге бинаны заманында янкормалар әйләндереп алган. Пулатның икенче катында гөмбәзле залы һәм аның тирәсендә бүлмәләр тезелеп киткән. Икенче катның дүрт ягында берәр ишек уелган, ике тәрәзә булган.

Төзелеше ягыннан Кара пулат шул дәверләрдә салынган Урта Азия корылмаларына охшаш. Әйтик, Бакудагы «Диванханә» Кара пулатның әлгәреге хәленә аеруча якын булган корылмалардан санала.

Кара пулатның нинди бина булганлыгы, нинди максатларга хезмәт итүе турында төрле фикерләр яшәп килде. Берәүләр анда мәчет булган дисә, икенчеләр бу бина мәдрәсә яисә төрбә (мавзолей) вазифасын башкарган дип раслады. Хәзерге вакытта белгечләрнең күпчелеге биредә хөкем сарае булган дигән фикерне алга сөрә.

Шигъри күңелле халкыбыз, Шәһре Болгардагы башка бинала кебек үк, Кара пулатны да легенда-риваятьләрдән мәхрүм итмәгән Буыннан буынга, телдән-телгә сөйләнеп, алар безнең көннәргә дә килеп җиткән. Әйтик, ни өчен бинаның исеме «Кара пулат», бу исем каян килеп чыккан? Риваятькә мөрәҗәгать итик: дәһшәтле хөкемдар Аксак Тимер Шәһре Болгарны яулап ала, халыкның олысы-кечесе кылычтан үтә. Болгар ханы Габдулла гаиләсе белән әлеге бинага кереп бикләнә. Канэчкеч илбасарлар бинаны бүрәнәләр белән әйләндереп алып ут төртәләр. Хан гаиләсе һәлак була.Шулвакыт мәйданга җыелган халык бина түбәсенә менеп баскан ханның зирәк һәм искиткеч гүзәл төпчек кызын күрә. Аксак Тимер кызны үзенә хатынлыкка алырга теләвен белдерә. Ләкин горур кыз бу тәкъдимне кире кага. Әмма кыз, дошманнарга әсир төшкән абыйларын күргәч, аларны коткару өчен Аксак Тимергә ризалык бирә. Утны сүндерәләр, кыз куйган шарт буенча ике абыйсына да яхшы аргамак бирәләр. Атка атланган абыйлары күздән югалгач, батыр кыз янып беткән бүрәнәләр өстенә сикерә. Ә исән калган хан уллары Казан суы буена килеп яңа шәһәргә — Казан каласына нигез салалар. Бинаның каралыгы риваятьләрдә әнә шулай аңлатыла. Әмма бинаның Кара пулатка әверелү сәбәбе — башкада. XVIII гасырда рус монахлары, бу бинаны үз хаҗәтләренә җайлаштырып, Казан, Тәтеш һәм Спасск базарларында сату өчен балык, дуңгыз ите ише нәрсәләр ыслаганнар. Андый эшләрдән соң бина кара сөремгә батмыйча калмаган, әлбәттә.

Халкымның йөрәк түрендәге иң якты уй-хыяллары белән үрелгән Кара пулат кара сөремле елларны кичсә дә, гасырларга сузылган азатлык өчен тиңдәшсез көрәш сәхифәләренең тапсыз бер ядкаре булып тарихка кереп калган.

Җәүдәт **МИҢНУЛЛИН.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле татар әдибе, РСФСРның М. Горький һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Аяз Гыйләҗев.

Юрий **ФИЛИМОНОВ** фотолары.

# *Китаплар дөньясында*

Татарстан китап нәшрияты былтыр түбәндәге китапларны басып чыгарды:

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). 416 бит, рәсемнәр белән. Тиражы 50000. Бәясе 1 с. 60 т.

XIX йөзнең мәшһүр татар галиме, тарихчы, философ һәм мәгърифәтче Ш. Мәрҗанинең (1818 — 1889) бу хезмәте беренче мәртәбә ике томлык рәвешендә 1885 — 1900 елларда басылып чыга. Әсәр халкыбызның борынгы заманнардан алып XIX йөзнең икенче яртысына кадәр булган тормышын, мәдәният һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнү өчен бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмаган кыйммәтле чыганак булып тора. Галим турында күренекле язучыбыз Фатих Әмирхан: «Мәрҗани моннан йөз ел әүвәл туган, милли мәгыйшәт җирлегенең бер дә әзерләнмәгән дәверендә дөньяга килгән... Гыйлем вә хакыйкатьне эзләргә булган бу дәрте белән, булдыклылыгы, бу эшчәнлеге белән ул әгәр җитмеш биш ел соңрак туган булса иде, аның исеме Европа фән академияләре әгъзалары эчендә мөхтәрәм бер урын биләп торыр иде», — дигән.

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИН. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәтләр. 336 бит, портрет белән. Тиражы 10000. 1 с. 20 т.

Бу китапка авторның нигездә егерменче елларда гарәп хәрефе белән басылып чыккан хезмәтләре кертелгән. Алар татар халкының килеп чыгышы һәм гомуми тарихы, сыйныфлар һәм сыйнфый көрәш, иҗтимагый фикер үсеше, тарихи әдәбиятны өйрәнү мәсьәләләрен яктырталар. Газиз Гобәйдуллин (1887 — 1938) — сәүдәгәр улы, мәдрәсә һәм классик рус гимназиясен, революциягә кадәр үк Казан университетын тәмамлаган, төрек, гарәп, фарсы, немец, француз, латин, инглиз телләрен өйрәнгән, әдәбият тарихы һәм төрки халыкларның үткәне хакында 120 ләп фәнни хезмәт язган киң колачлы галим, тарих буенча татарның беренче профессоры (1927), язучы, җәмәгать эшлеклесе, Г. Тукай, Ф. Әмирханнарның дусты була. Бу китап сталинчылыкның кара сәясәте корбаны Г. Гобәйдуллинның башка тарихи хезмәтләре белән танышуга ныклы этәргеч бирә ала.

АБРАР КАРИМУЛЛИН. Татары: этнос и этноним (Татарлар: исеме һәм җисеме). Икенче басмасы. Рус телендә. 128 бит. Тиражы 50000. Б. 50 т.

Филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Әбрар Каримуллин нигездә китап белгече. Әмма китапта табигатьнең һәм кеше эшчәнлегенең бөтен өлкәләре чагылганлыктан, китапчы галимгә дә бик күп нәрсә белән танышырга туры килә. Шунлыктан Ә. Кәримуллинның татар матбугаты сәхифәләрен, борынгы Шумер халкы һәм Америка индеецлары телен, байтак күренекле шәхесләрне өйрәнүенә берәү дә гаҗәпләнми.

Галим, үз халкының тугрылыклы улы буларак, татар тарихын тикшерүгә дә даими игътибар биреп килә. «Татарлар: исеме һәм җисеме» китабы аның күпьеллык эзләнүләре нәтиҗәсе. Бу хезмәтендә ул: «Татар» исеме кайдан килеп чыккан? Борынгы бабаларыбызның теле, мәдәнияте нинди булган? Тарих китаплары халкыбыз үткәнен дөрес яктыртамы?» — диган кебек сорауларга җавап бирергә тырышкан. Бу хезмәт шушы өлкәдә мәгълүмәты әз киң катлау укучыларына атап нәшер ителгән.

ИСТОРИЯ КАЗАНИ (Казан тарихы). Беренче китап. 328 бит. Б. 1 с. 20 т.

БЕЗНЕҢ ЗООПАРК. Буяу өчен альбом. Шигырьләре авторы Эльмира Шәрифуллина һәм Марк Зарецкий. 32 бит. Б. 10 т.

НАДЕЖДА БОГДАНОВА, ГАЛИНА ОСИПОВА. Яшелчәләр тиз өлгерә. Яшелчә үстерергә өйрәтә торган китап. 126 бит, рәсемнәр белән. Б. 55 т.

ЛЮДМИЛА ВАСИЛЬЕВА-ГАНГУС. Әдәплелек әлифбасы. Балалар өчен рәсемле китап. 110 бит. Б. 65 т.

ВЕНЕРА ВАЛЕЕВА. Предчувствие (Алдан сизенү). Шигырьләр, тәрҗемәләр. Рус телендә. 64 бит. Б. 25 т.

ГАЛИМЗЯН ГИЛЬМАНОВ. Татарская баллада (Татар балладасы). Тикшеренү. Рус телендә. 192 бит. Б. 35 т.

ҖӘМИЛ ГЫЙЛЬМАНОВ. Без сугышта юлбарыстан көчлебез. Татарстанның Бөек Ватан сугышында катнашуы хакында очерк. 280 бит. Б. 80 т.

ЛЯБИБЯ ИХСАНОВА. На душе не спокойно (Күңел тыныч түгел). Повестьлар. Рус телендә. 200 бит. Б. 60 т.

СВЕТЛАНА ЛЕЖНЕВА. Кызым, сиңа әйтәм... Кызларның сәламәтлеген ныгытуда спорт, көнкүреш, ял. 126 бит. Б. 45 т.

ЛЕВ МУХИН. Планеталар һәм тереклек. Фәнни-популяр басма. 176 бит. Б. 40 т.

КОНСТАНТИН ПЛАТОНОВ. Кызыклы психология. 230 бит. Б. 65 т.

МИТРОФАН СТУДЕНИКИН. Балалар сәламәтлеге турында. 216 бит. Б. 50 т.

ТОРАК ТУРЫНДА ЗАКОННАР. 135 бит. Б. 15 т.

ТУГАН ЯГЫМ, ТАТАРСТАН. Фотоальбом. 158 бит. Б. 5 с. 50 т.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адреслар: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга-почтой». 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1, отдел «Книга-почтой».

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ